I. МИЛЛИ МӘГАРИФ ҺӘМ ПЕДАГОГИКА

1.1. Хәзерге дәрес

(Хәзерге дәрес. “Совет мәктәбе”, № 1, 27 бит, 1987)

1) Дәреснең максаты, эчтәлеге һәм структурасы

Мәктәп реформасының Төп юнәлешләрендә дәрескә, аны оештыру һәм үткәрүгә яңа таләпләр куела. Дәрес — мәктәптә, профтехучилищеда һәм техникумда укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Бу хакта күп сөйләргә һәм язарга була. Ул я «актив», я сүлпән, күңелсез, нәтиҗәсез булырга мөмкин. Берничә ел инде «Учительская газета» битләрендә дә дәресне активлаштыру ысуллары турында сөйләшү дәвам итә. Бер төркем эксперименатор педагоглар, бергә җыелып, дәресне активлаштыру, аның нәтиҗәлелеген күтәрү буенча үз фикерләре белән уртаклаштылар («Учительская газета», №125, 1986 ел), «Советская педагогика» журналы битләрендә дә «Дәрес бүген һәм иртәгә» дигән темага галимнәр дискуссиясе булды (№№ 2—12, 1986). Шаталов, Ильин шикелле алдынгы укытучылар да дәреснең яңа вариантларын эзлиләр. Кыскасы, дәрес игътибар үзәгендә тора, аны камилләштерү буенча эзләнүләр көчәйгәннән-көчәя.

Безнеңчә, бу эзләнүләр вакытында инде элек тупланган бай хәзинәне онытып җибәреп, һәрчак эшне нульдән башларга ярамый. Татарстан укытучыларының, Липецк, Ростов өлкәләре мәктәпләренең кыйммәтле тәҗрибәсе фәнни хезмәтләрдә гомумиләштерелгән иде. Хәзер фән-техника революциясе казанышлары, мәктәп реформасы шартларында шул тәҗрибәне тагын да үстерү, талантлы практик укытучылар тәҗрибәсе үрнәгендә, галимнәрнең дәресне камилләштерү турындагы

хезмәтләрендә чагылыш тапкан яңалыкларны укыту процессында файдалану, аларны практикага кертү таләп ителә.

Дәрес заманчалаша бара: аны оештыруның яңа алымнары табылды, күптөрле техник чаралар файдаланыла, телевизион дәресләр үткәрелә, дәрестә микрокалькуляторлар, электроник-хисаплау машиналары кулланыла башлады. Ләкин дәреснең төп параметрлары, аның (пространство) урыны һәм вакыты ягыннан булган күрсәткечләре, йөз ел элек нинди булган булса, шул көенчә калды.

Хәзерге дәрес нинди соң ул? Аның үзгәрешендә нинди тенденцияләр сизелә? һ.б. шундый күп кенә сораулар галимнәрне һәм укытучыларны яңадан-яңа эзләнүләргә этәрә.

Без дәресне белем бирү, укучыларның акыл сәләтен үстерү һәм тәрбияләү бурычларын күмәк һәм индивидуаль рәвештә хәл итү өчен укыту-тәрбия процессының вакыт белән чикләнгән бер этабында укытучылар һәм укучыларның максатка юнәлешле үзара тәэссирен (эшчәнлеген һәм аралашуын) оештыруның күп вариантлы формасы итеп саныйбыз.

*Мәгълүм ки, кешенең теләсә нинди эшчәнлеге максат куюдан башлана һәм шул максатка «иярә».** Дәреснең төп максатлары нидән гыйбарәт соң? Беркадәр элегрәк педагоглар дидактик максатлар куялар, дидактик максат дигәннән алар өйрәнелә торган материалны укучыларның үзләштерүен күздә тоталар иде. Укытучының һәм укучыларның эшчәнлеге дә әнә шуннан чыгып оештырылды. Әмма мәсьәләгә болай килү материалны үзләштерү барышында укучыларның акыл сәләтен үстерүне һәм аларга тәрбия бирүне гарантияләми иде.

Дәрес максатының эчтәлеге һәм структурасы нинди булырга тиеш? Ул өч өлештән тора: белем бирү, укучыларның акыл сәләтен үстерү һәм аларны тәрбияләүне күздә тотып планлаштырырга тиеш. Димәк,

дәреснең максаты педагогик процессның һәр ягын искә алып билгеләнә: а) фәнни һәм техник белемнәр системасын; теоретик һәм практик эш осталыгын (күнекмәләрен) формалаштыру; б) укучыларда танып белү мөстәкыйльлеге тәрбияләү, аларның диалектик фикерләү һәм ижади сәләтләрен үстерү; в) укучыларда дөньяга фәнни караш, тормышта үзенең урынын таба белү һәм актив тормыш позициясе тәрбияләү.

Традицион дәрестән аермалы буларак, хәзерге дәреснең төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Беренче чиратта, ул — балаларның акыл сәләтен үстерә. Моның өчен укучыларның фикерләвен, белем алуга һәм хезмәткә теләк-омтылышын (мотивациясен) үстерү, дөрес мөнәсәбәтләр тәрбияләү буенча максатчан эш алып барыла. Әлбәттә, зиһенгә алу, дикъкать, күзәтүчәнлек, күпне белергә омтылыш, мавыгучанлык, хәтер, күзаллау, яхшы сөйли белү, физик хәрәкәтләрне үстерү кебек, элеккеге традицион дәресләргә куела торган максатлар да игътибардан читтә калмый.

Мәктәп реформасының Төп юнәлешләрендә укытуны профессиональ дәрәҗәдә җитештерүчән хезмәт белән бәйләп бару бурычы куелды. Шуңа күрә хәзерге дәрес ике төр белемнең үзара бәйләнешен искә алып оештырылырга, укучыларның җитештерүчән хезмәте, аларга белем һәм тәрбия бирүнең класстан тыш формалары белән бәйләнгән булырга тиеш.

Хәзерге дәреснең традицион дәрестән җитди аермасы шунда: дәреснең **типлары** һәм төрләре, аның **структурасы,** аңа әзерләнү кагыйдәләре, дәресне оештыру һәм анализлау методикасы (болар һәммәсе дә укытучы һәм укучыларның үзара эшчәнлегенең нинди булуына йогынты ясый), укыту методлары һәм чараларын сайлау һәм куллану — барысы да яңа эчтәлек белән баеды.

Фәнни әдәбияттә дәреснең типологиясе турында төрле карашлар бар, мәсәлән, 4 тән алып 18 гә кадәр дәрес тибы күрсәтелә, әмма

бердәм төгәл классификация юк иде. Дәресләрне типларга бүлүдә галимнәр укыту **методларын**, укучыларның уку эшчәнлеген оештыру **ысулларын**, дәрес **эчтәлеген**, дидактик **максатларны,** укыту процессы **этапларын** нигез итеп алдылар. Кереш дәресләр, төшенчәләр белән беренчел таныштыру, күнекмәләрне ныгыту буенча эшләү, кабатлау һәм гомумиләштерү, катнаш (комбинированный) дәресләр һ.б. шундый типлар, укытуның тулы бербөтен системасының аерым компонентлары арасындагы табигый бәйләнешләрне өзеп, дәресне оештыруга комплексны якын килүне тәэмин итмәде. Катнаш дәрес тибы билгеле бер дәрәҗәдә бу кимчелектән котылырга ярдәм итте, ләкин ул бертөрле типта булды, шуңа күрә шаблон структуралы иде.

Хәзер галимнәр дәресләрне типларга аларның оештыру максатына карап бүләләр. Мәсәлән: яңа материалны өйрәнү; белемнәрне, осталык һәм күнекмәләрне камилләштерү һ.б. Ә **типларны** төрләргә бүлгәндә укыту методларын гамәлгә ашыру формаларын (әңгәмә дәресе һ.б.) искә алып эш итәләр.

Мәсьәләгә әнә шулай якын килгәндә, дәресләрнең түбәндәге типларын аерып күрсәтергә мөмкин: **яңа материалны өйрәнү дәресе** (лекция дәрес, әңгәмә дәресе, кино дәресе, компьютер кулланып үткәрелә торган дәрес һ.б. төрләр**); белемнәрне, осталык һәм күнекмәләрне камилләштерү дәресе** (мөстәкыйль эшләр дәресе, лаборатор һәм практик эшләр дәресе, семинар дәрес һ.б. төрләр); **белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру дәресе** (әңгәмә дәресе, семинар дәрес һ.б. төрләр); **катнаш**[1] **дәрес** (барлык

[1] «Катнаш дәрес дигәндә дүрт дидиактик бурыч — укучыларның белемен тикшерү, яңа материалны аңлату,үзләштергәнне ныгыту һәм өйгә эш бирүне аңлыйлар. Без «катнаш» дәресне бераз башкачарак күз алдына китерәбез, аерым алганда, ул — барлык тип дәресләрнең функциясен үти торган «синтетик» дәрес (яңа материалны өйрәнү, белемнәрне, осталык һәм күнекмәләрне камилләштерү, гомумиләштерү һәм системалаштыру, контроль) булып тора.

төр дәресләр); **контроль дәрес** (контроль эшләрнең, белем тикшерүнең, зачетлар, үзара контроль, үзконтроль һ.б. барлык төрләре). Югарыда санап узылган барлык типтагы бер үк дәресне ике фән (мәсәлән, физика һәм математика укытучысы бергә үткәрсә, **«аралаш» дәрес** («совмешенный» урок) дибез һәм аны аерым тип итеп карарга мөмкин).

Дәресләрнең бу типлары һәм төрләре проблемалылык принцибы нигезендә **проблемалы** һәм **проблемасыз** дәресләргә бүленәләр. Алар занятиеләрне оештыру максаты белән генә түгел, дәреснең структурасы, укыту методлары һәм алымнары белән аерылып торалар. Мәсәлән, 1 типтагы проблемасыз дәрес — укучыларның белемнәрен телдән тикшерү (опрос), ә проблемалы дәрес, проблемалы ситуация барлыкка китереп, фронталь мөстәкыйль эштән һ.б. башлана. Дәреснең дидактик бурычларын үзара эчке бәйләнеш нигезендә бергә кушу — эшне оештыру системасы буларак, проблемалы дәреснең үзенчәлекле ягын тәшкил итә. Дәреснең югарыда санап үтелгән типлары матбугатта шактый киң яктыртылды. (Карагыз: М.И.Махмутов Современный урок. 2 басма. М., 1985; Мәктәптә проблемалы укуны оештыру. Казан. 1980; Ю.Б.Зотов. Организация современного урока. М., 1984 һ.б.).

Дәреснең структурасы (ягъни «скелеты») бик әһәмиятле булганлыктан, аның төп компонентларының үсешенә тукталып узыйк. Башта терминның мәгънәсенә ачыклык кертик. Теләсә нинди дәрес билгеле бер өлешләрдән тора. Дәреснең башы, уртасы һәм ахыры — аның өлешләре. Вакыт күрсәткече буларак, бу өлешләрне дәреснең **этаплары** дип атыйлар. Этаплар, үз чиратында тагын да ваграк өлешләрдән тора; аларның эчтәлеге укытучы һәм укучыларның **эш-хәрәкәтеннән** чыгып билгеләнә. Болар исә дәреснең элементларын тәшкил итә, шул элементлар җыелмасын без дәреснең **компонентлары** дип йөртәбез. Вакыт ягыннан караганда,

дәреснең этаплары һәм элементлары еш кына бергә туры киләләр. Дәреснең барлык өлешләре һәм элементларының бәйләнеше аның **структурасын** тәшкил итә.

Дәрес өлешләренең, аның элементларының нинди эзлеклелектә булуы, роле, урыны, күләме һ.б. ничек булуы белем алу һәм укытуның закончалыкларын дөрес исәпкә алуга, укыту процессының логикасына бәйле.

Дәреснең төрле өлешләре һәм элементлары төрлечә чиратлашкан, төрле чагыштырмада булырга, укучыларда белем һәм күнекмәләр формалаштыруда төрле нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Шуңа күрә дәресне оештыру һәм үткәрүнең үз кагыйдәләре, үз теориясе бар. «Дәреснең структурасы» бу теориядә иң әһәмиятле төшенчәләрнең берсе булып санала.

Укучыларның акыл сәләтен үстерә, укыту процессы логикасын төгәл чагыштыра торган һәм шул ук вакытта укытучыга ижади методик мөмкинлекләр бирә торган дәрес структурасының закончалыклары нәрсәдән гыйбарәт соң?

Алдан әйтеп үтелгәнчә, традицион катнаш дәреснең структурасы дүрт элементтан (укучыларның белемен тикшерү, аңлату, ныгыту, өйгә эш бирү) тора һәм аның үз кимчелекләре бар.

Проблемалы дәресләрнең ничек үткәрелүенә анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, андый дәресләр белемнәрне тикшерүдән түгел, ә еш кына мөстәкыйль эш (яисә уку фильмын карау, яки текстны, биремне анализлау, яки типик мәсьәләләрне чишү) белән башлана. Яңа материалны укытучы үзе аңлатмый, ул танып-белү мәсьәләсе яки лаборатор-практик эш рәвешендә тәкъдим ителә, яңа төшенчәләрне укучылар күмәк рәвештә бергәләп үзләштерәләр, үзләре, проблеманы хәл итеп, билгеле бер нәтиҗәгә киләләр. Аннары шул үзләштерелгән белемнәрне практикада куллану буенча мөстәкыйль эш оештырыла (мәсәлән, күнегүләр эшләтелә,

мәсьәләләр чишелә һ.б.). Яңа материал ныклы үзләштерелсә, укытучы өйгә эш бирмәскә дә мөмкин.

Элекке дәрес белән чагыштырып карасаң, каршылыклы күренеш барлыкка килә: дәрес үзе бар, аның структур элементлары исә юк! Болардан чыгып, белемнәрне тикшерү (опрос), яңа материалны аңлату, үзләштергәннәрне ныгыту, өйгә эш бирү — болар һәммәсе дә традицион дәрес элементлары гына икән, алар хәзерге, яңача оештырыла торган дәреснең даими элементары булып тормый, дигән нәтиҗә ясарга ярамый.

Дөрес, ул элементларның кайберсе укытуда максатка ирешүне генә ачыкларга, укучыларның өйгә эшне ничек үтәүләрен белергә генә ярдәм итә. Мәгълүм ки, яңа материалны аңлатырга, ул белемнәрнең ничек үзләштерелүен тикшерергә кирәк. Күренгәнчә, биредә укучының танып-белү эшчәнлеген оештыру максатлары күләгәдә кала, алар булырга тиеш дип кенә уйланыла. Шуңа күрә традицион дәрес структурасы укучының танып-белү эшчәнлеген активлаштыруга шартлар тудырмый.

Укытуда проблемалылык принцибы («Вопросы психологии» журналының 1984 елгы 5 нче саныннан безнең мәкаләне карагыз) системалы рәвештә укучыларның мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеген оештыруны күздә тота. Бу исә укучыларның яңа материал белән элек үзләштергәннәр арасындагы бәйләнешне ачык күрүен таләп итә. Кыскасы, аларга **терәк** белемнәр кирәк.

Димәк, дәресне яңача оештыру укучыларның яңа материал, яңа тема белән турыдан-туры бәйләнешле элек үзләштерелгән белемнәрен һәм танып-белү күнекмәләрен башта активлаштыруны, ягъни искә төшерүне таләп итә. Шуңа күрә дә дәреснең беренче этабын яңача үзгәртеп кору ихтыяҗы килеп туды. Хәзер бу этап, элеккечә, «өйгә эшне тикшерү», традицион дәрес башы гына була алмый.

Терәк белемнәрне һәм танып-белү күнекмәләрен «актуальләштерү» (яңарту) әнә шул функцияне үтәргә мөмкин. Актуальләштерү — укытуда **дәвамчанлык** принцибын тормышка ашыру белән бергә, белемнәрне истә калдыру, аңлы рәвештә үзләштерү өчен дә объектив шарт булып тора. Проблемалылык дәрәҗәсе һәм укучыларның танып-белү активлыгы никадәр югарырак булса, укытуда дәвамчанлык һәм аңлылык принциплары да шулкадәр нәтиҗәлерәк тормышка ашырыла.

Дәреснең икенче этабы — яңа төшенчәләрне һәм эш-гамәлне үтәү ысуллары (күнекмәләр) формалаштыру (барлыкка китерү). Ул — белемнәрне актуальләштерү этабында элек үзләштергәннәрне искә төшерүдән, аларны системага салудан һәм үзара эчке бәйләнеш урнаштырудан башлана. Хикмәт белемнәрнең генә түгел, эш-гамәлне үтәү ысулларының (способы действия) да хәтердә яңартылуында. Укучының акыл сәләте ул үзе танып-белү эшчәнлеге белән шөгыльләнгәндә генә үсә, шуңа күрә аны эш ысулларына өйрәтү — дәрес структурасында мөһим һәм яңа моментларның берсе ул. Дәреснең бу этабында яңа материал проблемалы ситуацияләр барлыкка китереп яки гади генә сөйләп аңлатырга, яки тулысынча яисә өлешчә мөстәкыйль эш рәвешендә оештырылырга мөмкин.

Мәгълүм ки, укучылар үзләштерелгән белемнәрне гамәлгә куя (практикада куллана) белергә тиеш. Шуңа күрә дәреснең өченче этабы өйрәнелгәннәрне гамәлгә куюга, практикада кулланыга багышлана, таныш ситуациядә — тиешле мәсьәләләр чишү, үрнәк буенча текстны анализлау һ.б. шундый эшләр башкарыла; таныш булмаган ситуацияләрдә исә проблемалылыгы төрле дәрәҗәдәге танып-белү мәсьәләләре чишелә. (Яңа төшенчәләр һәм белемнәрнең ничек үзләштерелүен, укучыларның аларны практикада ничек

куллануын исәпкә алып, өйгә эш бирелә.) «Белемнәрне куллану» укыту теориясен практика белән бәйләү принцибын таләп итә.

Шул рәвешчә үзенчәлекле бер триада барлыкка килә: белемнәрне **актуальләштерү; яңа белемнәр** формалаштыру; үзләштергәннәрне практикада **куллану.** Нәрсә үзгәрә соң? Дәрес өлешләренә бирелгән билгеләмәләрнең асылы да, максатчан установка да (психологик установка да шуңа керә) үзгәрә. Актуальләштерү вакытында укучыларның белемен тикшерү төп бурыч булып тормый (дөрес, ул да игътибардан читтә калмый), яңа белемнәр формалаштырганда иң мөһиме укытучының аңлатуы гына түгел, бәлки эзләнү эшчәнлеге нәтиҗәсендә укучының яңа белемне үзе мөстәкыйль үзләштерүендә дә. Бу өч өлешнең (структура компонентларының) логик бәйләнеше һәм диалектик бердәмлеге дәрестә укыту процессын оештыруның бер закончалыгы булып әверелә. Дәреснең әнә шундый өч компонентлы дидактик структурасы үзгәрешсез характерда була. Ләкин һәр компонентны укытучы үзе белгәненчә мөстәкыйль төзи.

Дәреснең өч компонентлы структурасы традицион дәреснекеннән шактый катлаулы. Бу аңлашыла да: хәзерге дәрестә, катнаш дәресләрдәгегә караганда, катлаулырак мәсьәләләр чишелә.

Хәзерге дәреснең эчтәлеге һәм структурасына туры китереп, методларга да яңачарак якын килергә кирәк. Методларны без ике подсистемадан: бинар (иш, куш) методлардан, ягъни эш алымнарын сайлап алу һәм куллану кагыйдәләреннән, шулай ук укучылар һәм укытучының конкрет эш алымнары һәм ысулларыннан тора торган белем һәм эш-гамәлләр системасы итеп карыйбыз. Уку-укыту процессында белем һәм эш-гамәлләрнең органик рәвештә бергә үрелеп баруының бердәмлеге әнә шунда чагыла. Методка карата әнә шулай якын килү яңача педагогик фикерләүне, укыту процессын яңача оештыруны таләп итә. Бу исә укыту-тәрбия эшен мәктәп реформасы таләпләре яктылыгында оештырырга ярдәм итә.

Дәреснең нәтиҗәлелеге нәрсәгә бәйле? Дәрескә әзерләнү һәм аны планлаштыру, беренче чиратта, методик яктан дөрес булырга тиеш. Дәрескә әзерләнү, аңа максат кую, материалның эчтәлеген анализлау һәм структурасын билгеләү, укыту методларын һәм чараларын сайлау, дәреснең планын төзү кебек эшләрдән тора.

Биредә дәреснең максатын билгеләү аеруча зур әһәмияткә ия. Хәзерге дәрес, укучыларга билгеле бер фәнни һәм техник белемнәр бирү белән бергә, аларның акыл сәләтен, интеллектуаль һәм эмоциональ активлыгын үстерергә, аларда дөньяга фәнни караш формалаштырырга, укучы шәхесен тәрбияләргә, кыскасы, тәрбияви дә булырга тиеш. Болар һәммәсе дә дәрес планында чагылыш таба. Шуңа күрә дәреснең гомуми (дидактик) максатын өч өлешкә бүлеп: белем бирү (укучының белемен өстәмә рәвештә тагын нинди төшенчәләр һәм күнекмәләр белән баету); акыл сәләтен үстерү (укучыларның тагын нинди логик операцияләр — мәсәлән, чагыштыра, гомумиләштерә белү — һәм эш алымнары үзләштерелергә тиешлеге) һәм тәрбия (нинди шәхси сыйфатлар формалаштыру) максатларын күрсәтеп планлаштыру отышлы.

Дәрескә әзерләнгәндә укытучы, башлыча, укыту материалының эчтәлеге белән эш итә. Гамәлдәге укыту теориясе һәм практикасы, кагыйдә буларак, киләсе дәрестә өйрәнеләчәк материалның күләмен һәм катлаулылыгын билгеләү белән генә чикләнә иде, соңгы елларда исә материалны төп һәм ярдәмче өлешләргә бүләргә, предметара бәйләнеш тә урнаштырырга кирәклеге һ.б. тәкъдим ителә башлады. Әмма материалның эчтәлеге укыту закончалыклары белән бәйләп каралмый, бу исә укучыларның мөстәкыйль, нәтиҗәле танып-белү эшчәнлеген активлаштыруга һәм аның белән идарә итүгә тиешле мөмкинлек бирми иде.

Шундый проблемалы сорау килеп туды: дәреснең өч төрле максатын искә алып, укыту материалы структурасы белән

укучыларның танып-белү эшчәнлеге (һәм уку методлары) структурасы арасында нинди бәйләнеш бар? Укыту материалына дифференциаль психологик-педагогик анализ нәтиҗәсендә бу сорауга җавап табылды. Ул анализ түбәндәгеләрдән гыйбарәт: төшенчәләрне анализлау (төп төшенчәләрне, аларның катлаулылыкта һәм аңлаешлык дәрәҗәсен, терәк төшенчәләр белән бәйләнешен, аларның политехник һәм профессиональ юнәлешен көчәйтү ысулларын билгеләү һ.б.), логик анализ (төшенчәләрнең эзлеклелеген, үзара каршы килү-килмәвен һ.б. билгеләү), психологик анализ (яңа белемнәрне үзләштерүне аңлы һәм эмоциональ итү шартларын, проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү ысулларын һ.б. ачыклау), материалның эчтәлегенә дидактик анализ ясау (дидактик бурычларны дөрес кую, материалның күләмен һәм мөстәкыйль эш төрләрен аныклау һ.б.) һәм аның тәрбияви әһәмиятен анализлау.

Белемнәрнең комплексы булуына (системность), үз чиратында, укыту материалын логик яктан дөрес аңлату белән бергә, укытуда дәвамчанлылык принцибын тормышка ашыру да ярдәм итә. Биредә һәр дәрестә, перспективада да предметара бәйләнеш урнаштыру бик мөһим бурыч булып тора. (Карагыз: И.Д. Зверев, В.Н. Максимова. Межпредметные связи в современной школе. М., 1981.) Ул бәйләнешләр, актуальләштерү этабыннан башланып, дәрес ахырына кадәр «үтәли» дәвам иттерелергә, төрле фәннәр буенча дәресләр системасында да кызыл җеп булып сузылырга тиеш. Алар политехнизм, профориентация, дәвамчанлык һ.б. шундый принципларны гамәлгә ашыруда җитди роль уйный.

Укытуның сыйфаты, әлбәттә, төрле методлардан оста файдалануга, аларны урынлы-урынсыз түгел, ә кирәкле методны тиешле урында куллана белүгә бәйле. Укыту методлары бер-берсеннән аерылалар: аларның кайберләре (мәсәлән, эвристик яки проблемалы эзләнүле

методлар) укучыларның акыл эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итә, башкалары материалны яки күнегүләрне яттан өйрәнүне сорый һәм, нигездә, хәтерне һәм күнекмәләрне үстерә (репродуктив, искә төшерү, эш башкаруны таләп итә торган методлар). Методларның бу ике төркеме дә әһәмиятле, аларны дөрес чиратлаштыра, рациональ куллана белергә генә кирәк.

Дәрескә әзерләнгәндә үк укыту методларын дөрес сайлау, аларның үзара чагыштырмасын, ничек чиратлашуын билгеләү зур әһәмияткә ия. Элегрәк укыту методларын укытучы үзенең педагогик алдан күрүчәнлеге, интуициясе нигезендә генә сайлый, шуңа күрә алар кайчакта максатка ярашлы булып бетми иде. Моннан шундый проблемалы сорау туа: укытуда методлар һәм ысуллар сайлауга комплексны якын килүне тәэмин итә торган психологик-педагогик закончалыклар (бәйлелекләр) нидән гыйбарәт соң?

Галимнәр укыту методларын объектив дөрес сайлауның дүрт төрле төп факторын күрсәтәләр: яңа материалның эчтәлеге; укытылу — өйрәтелү, ягъни тәгълим дәрәҗәсе, укытучының методик осталыгы. Шушы бәйләнеш һәм шартлар комплексына анализ ясау укыту методларын дөрес сайлауның фәнни нигезен тәшкил итә. Практик эш алымнарын сайлау да методка бәйле. Эштә теге яки мондый методларның, алымнар һәм ысулларның булуы яки булмавы да укыту методларын дөрес сайлауның фәнни нигезе булып тора. Практик эш алымнарын сайлау да методка бәйле. Эштә теге яки мондый методларның, алымнар һәм ысулларның булуы һәм булмавы укыту процессының характеры турында сөйли. Әгәр дәрестә тикшеренү характерындагы эвристик методлар кулланылмаса, укучыларның иҗат сәләтләрен үстерү турында сүз алып барып булмый. Биредә укучылар репродуктив эшчәнлек белән шөгыльләнәләр. Тәрбия методлары (инандыру, мактау, ярыш

оештыру, җәза бирү һ.б.) белән бәйләнеш урнаштырылмаса, дәреснең тәрбияви функциясе дә тулысынча үтәлми.

Дидактикада дәрес планнары төзү буенча бай тәҗрибә тупланган. Әмма аларның күп кенә вариантларында дәрес этапларының һәм аның дидактик структурасы компонентларының үзара бәйләнеше, дәрес максатлары һәм укыту методларының закончалыклары һ.б. шундый мәсьәләләр искә алынмый диярлек.

Безнеңчә, хәзерге дәрес планы өч компонентлы система нигезендә төзелергә тиеш. Анда өч максат: (белем бирү, акыл сәләтен үстерү һәм тәрбия максаты), **методлар** (гомуми һәм бинар), **мәгълүмат** (информация) **чыганаклары, мөстәкыйль эш һәм предметара бәйләнеш типлары, техник чаралар күрсәтелә. Дәрес планы укытуның бинар** (куш) **булуын** (ягъни укытучы һәм укучының һәркайсының нәрсәләр эшләвен күрсәтеп) искә алып **төзелә**. План график-схема төсендә, ягъни схематик рәвештә дә булырга мөмкин. Планны төзү барышында укытучы аның конкрет методикасын билгели, шулай итеп, дәреснең һәр этабында укыту һәм укуның үзара логик бәйләнешен, йогынтысын һәм ысуллары эзлеклелеген ачыклый. Дәрес планын киң, хәтта конспект рәвешендә төзергә дә була.

Хәзер укытучылар материалны проблемалы планда сөйләп аңлатырга өйрәнделәр инде. Димәк, күп кенә педагоглар укучыларны проблеманы хәл итә белергә дә өйрәтә алалар. Ләкин укучыларның теоретик белемнәр белән кызыксынуын ничек үстерергә соң? Белемнәрне һәрьяклап, комплекслы үзләштерүенә ничек ирешергә? Дәреснең нәтиҗәлелеген ничек күтәрергә? Бу мәсьәләләрне уңышлы хәл итү һәм тормышка ашыру өчен, укыту-тәрбия эшенең сыйфатын күтәрү буенча яңадан-яңа эзләнүләр алып бару таләп ителә.

Дәреснең аерым этапларында укытуның төрле принципларын гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләр дә төрлечә. Мәсәлән, беренче этапта, ягъни белем һәм күнекмәләрне актуальләштергәндә, проблемалылык, дәвамчанлык, белем бирү, акыл сәләтен үстерү һәм тәрбиянең бердәмлеге, предметара бәйләнеш принциплары шактый ансат тормышка ашырыла. Өченче этапта, ягъни белемнәрне практикада кулланганда, политехник укыту, профессиональ ориентация бирү принципларыннан чыгып эш итү ансатрак. Дәреснең икенче этабы нигездә үзгәрешсез була, яңа теоретик материалны укучылар сайлаган профессия белән бәйләп өйрәтү кыенрак. Бу, мәсәлән, физиканы өйрәнү логикасын теләсә нинди уку йортларында шул көенчә сакларга мөмкинлек бирә. Дәреснең беренче һәм өченче этапларында үзләштерелә торган материалның эчтәлеге исә күләм һәм сыйфат ягыннан шактый үзгәрергә мөмкин.

Хәзерге дәреснең нәтиҗәлелеге күп кенә факторларга бәйле. Әйткәнебезчә, фәнни-педагогик әдәбиятта ул хакта шактый язылды инде. Күптән түгел бер төркем новатор укытучылар — дәрескә яңалык кертүчеләр — бу хакта «Учительская газета»да да язып чыктылар (№ 125, 1986 ел). Шулай да, безнеңчә, барыннан да бигрәк укытучыларның игътибарын үзләрендә яңа күнекмәләр булдыру кирәклегенә юнәлтәсе килә. Ул күнекмәләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— дәреснең өч максатын да дөрес куя белү;

— укучыларны белем ала, укый белергә өйрәтү, ягъни аларны уку (үз эшен планлаштыру, конспект төзү, тыңлау, мәсьәлә чишү планын әзерләү һ.б.ш.) һәм танып-белү (анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү ясау, дәлилләү һ.б.ш.) күнекмәләренә өйрәтү;

— уку материалын программалаштыру, укыту алгоритмыннан файдалану, проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү, укучыларны проблемалы сораулар куярга һәм мәсьәләләр төзергә, үз фикерен

дәлилли һәм башкаларның ялгыш фикерен кире кагарга белергә һәм башка шундый күнекмәләргә өйрәтү;

— предметара һәм циклара бәйләнешләр урнаштыру, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү;

— дәрестә телевидение тапшыруларыннан файдалану;

— дәрестә магнитофон язмалары һәм грампластинкалар, сәнгать чаралары куллану;

— укыту методларын тәрбия методлары белән бергә кушу, укучыларны үзконтрольгә (уку процессында һәм үз-үзен тотуда) өйрәтү;

— дәресне укучы шәхесен социаль тәрбияләү факторлары (мәсьәләләрне бергәләп чишүдә, коллектив җитештерүчән хезмәттә, җәмәгать тормышында һ.б. шундый эшләрдә катнаштыру) белән баету; укучыларда әдәп-әхлак, бурычлылык һәм җаваплылык хисе тәрбияләү;

— мәктәп балаларында профессия белән кызыксыну, тырышып уку һәм хезмәттә катнашу мотивлары (ихтыяҗ, теләк, кызыксыну) тәрбияләү;

— дәрестә контрпропаганда материалларыннан файдалану һ.б.

Дәрестә укучылар белән мөнәсәбәткә кергәч, укытучының эчке, рухи дөньясы, акыл һәм хисләре, белем байлыгы, тормыштагы мөнәсәбәтләре нинди булуы ачык чагыла. Тәҗрибәле педагог укучыларның рухи дөньясын һәм ихтыяҗларын, хәтерен һәм фикерләвен үстерүне, аларда югары гражданлык сыйфатлары тәрбияләүне игътибар үзәгендә тора. Әлбәттә, болар һәммәсе дә зур профессиональ осталык аркылы гына килә. Педагогиканың хикмәте шунда — ул фән генә түгел, хәтта сәнгать тә ул.

Дәрес барышында алдан планлаштырылмаган «кырык төрле ситуация» туарга мөмкин. Ләкин аларның берсе дә укытучы өчен һич тә көтелмәгән хәл булырга тиеш түгел, бу аның балаларның

психологиясен белүен, профессиналь осталыгын күрсәтә. Педагогик алдан күрүчәнлеккә ия булган укытучы «көтелмәгән хәлләрне» башта ук сизеп-белеп тора, бу исә, укыту-тәрбия процессына тиешенчә җитәкчелек итүдә, укучыларга нык тәрбияви йогынты ясауда зур әһәмияткә ия.

2) Дәресне оештыру һәм үткәрү

(Хәзерге дәрес. «Совет мәктәбе», № 2, (26 бб), 1987)

Мәгълүм ки, дәрескә өч җәһәттән: укыту процессын оештыру **формасы** («дәрескә таләпләр», аны «классификацияләү», «структурасын билгеләү» һ.б. шундый төшенчәләр ярдәмендә); укыту процессын оештыру методикасы (яңа материалны өйрәнү, белем һәм күнекмәләр үзләштерү, дәрестә индивидуаль якын килү, күрсәтмәлелек куллану, ягъни укыту методларын һәм алымнарын куллану һ.б.) итеп һәм, ниһаять, форма белән методларның **бергә үрелеп барылуы** дип карарга мөмкин. Башта без дәреснең беренче җәһәтенә күбрәк тукталган идек, чөнки дәрес теориясенең төп төшенчәләрен (типология, структура һ.б.ш.) аңлатуга яңача якын килүнең асылын ныграк яктыртырга кирәк иде. Шулай да, дәреснең төп өлешләренең (компонентларының) эчтәлеген яңача аңлатуның әһәмиятен күрсәтү өчен, хәзер аның методикасының төп моментларына тукталып узыйк. Әлбәттә, укытуның барлык методлары һәм ысуллары да бер дәрестә кулланыла алмый, алар бер-берсенә тоташып барган дәресләр системасында файдаланыла.

Гадәттә, дәреснең башы, барышы һәм азагы турында сөйлиләр. Бу өч өлешнең тоташ барышы — процесс ул. Димәк, бу — дәреснең билгеле бер этапларының, структурасы компонентларының чикләрендә төрле-төрле методлар куллану дигән сүз. Укыту процессы хосусый методикаларда шактый тулы яктыртылса да,

башта — укыту процессын оештыру ысулларына, ә аннары дәреснең төрле этапларында аларның ничек кулланылуына тукталырга булдык.

Укыту процессында укытучы төп өч гомуми функцияне (вазифаны) үти: укучыларга яңа текстны бәян итә, яңа материалны үзләштерү буенча аларның мөстәкыйль эшен оештыра, уку процессына контроль ясый, ягъни шул процесс белән идарә итә.

Яңа материалны бәян итү ике төрле дәрәҗәдә: хәбәр итү (информацион) һәм проблемалы бәян итү рәвешендә булырга мөмкин. Беренчесендә укытучы практикада киң таралган «монологик» (ягъни үзе генә сөйли) укыту методын куллана (ул сөйли, аңлата, укучылар тыңлыйлар, күзәтәләр, ятлыйлар). Проблемалы бәян итү укытуның катлаулырак төре булып тора; ул укытуның өч гомуми методы ярдәмендә тормышка ашырыла:

а) «күрсәтмәле» метод кулланганда укытучы фән тарихында барлыкка килгән фәнни проблемаларны һәм галимнәрнең аларны чишү ысулларын (сөйләп) күрсәтә, яки шул фәнни һәм практик проблемаларны (өйрәнелә торган материал нигезендә) ул үзе әйтә (тәкъбир итә) һәм төрлечә фараз итеп һәм аларны исбатлый-исбатлый, тәкъбир ителгән проблемаларны чишү ысулларын аңлата; укучылар игътибар белән тыңлыйлар (проблемалы ситуация акыл читенлеге буларак «эчке диалогны» активлаштыра), аларның тема белән кызыксынуы көчәя, укучылар материалны тиешенчә эмоциональ фонда үзләштерәләр;

б) «диалогик» метод яңа материалны хәбәр итү рәвешендәге әңгәмә ярдәмендә бәян итүдән гыйбарәт; укытучы проблемалы сораулар куя, аларга үзе җавап бирә, бу вакытта укучылар да укытучы куйган проблеманы чишү юлларын эзлиләр һәм үзләре дә сорау-җавап бирәләр;

в) «эвристик» метод та диалог кебек, ләкин ул эвристик әңгәмәнең проблемалы мәсьәләләр (бурычлар) куелу белән бергә кушылуыннан, үрелеп баруыннан гыйбарәт: яңа материалның бер өлешен укытучы танып-белү бурычлары һәм мәсьәләләре рәвешендә тәкъдим итә, икенче өлешне укучылар, проблемалы сораулар һәм мәсьәләләрне чишә-чишә, үзләре мөстәкыйль рәвештә үзләштерәләр. Монологик методтан эвристик методларга күчә барган саен укытуның проблемалылык һәм укучының танып-белү мөстәкыйльлеге дәрәҗәсе арта төшә. Бу күп кенә факторларга, әмма нигездә, укыту методларын[2] **сайлап** алуга йогынты ясый торган факторларга бәйле.

Яңа материалны бәян итүнең әлеге төрләрен кулланганда, укытучы күрсәтмә әсбаплардан, аудиовизуаль техникадан файдалана, уен рәвешендә төрле ситуацияләр барлыкка китерә ала. Алар дәреснең төп өч этабының теләсә кайсында — белемнәрне актуальләштергәндә, яңаларын үзләштергәндә, аларны гамәлгә куйганда, ягъни практикада кулланганда булырга мөмкин. Мәгълүм ки, һәр материалны да проблемалы рәвештә бәян итеп булмый, кайчакта алай эшләүнең кирәге дә чыкмый. Иң әһәмиятлесе — укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештырып, укытуны активлаштыру. Мөстәкыйль эшләрне оештыру укытучы өчен шактый катлаулы һәм, дәреснең максатына, укучыларның укытулы — тәгълим һәм укытучының методик осталык дәрәҗәсенә карап, алар барлык тип дәресләрдә һәм аның теләсә кайсы этабында кулланыла. Мөстәкыйль эшләрнең проблемалылык дәрәҗәсе,

[2] Уку-укыту методларын без өч төрле итеп аңлатабыз: аларны теория итеп караганда — дидактик методлар дибез (монологик, күрсәтмәле, диалогик, эвристик, эзлнүле алгоритм һәм программалаштыру методлары); методика дәрәҗәсендә уку һәм укыту кагыйдәләре (аңлату, дәртләндерү, эзләнү һ.б. методлар) һәм технология дәрәҗәсендә конкрет алым, ысуллар итеп аңлатабыз (мәсәлән, хәбәр итү, сорау кую, бирем бирү, фильм күрсәтү, мәсьәлә чишү һ.б.ш.).

типлары һәм төрләре төрлечә: башкару характерында, ярым иҗади, иҗади, конструктив-техник һ.б. булырга мөмкин (карагыз: М.И. Махмутов. Проблемное обучение. М., 1975).

Әлбәттә, югарыда әйтелгән факторларга бәйле рәвештә, яңа материалны укытучының сөйләп аңлатуы белән мөстәкыйль эшләрнең нисбәте төрлечә була.

Укытуның **репродуктив** (монологик, алгоритмик һ.б.) методлары үзенә бер төрле ысуллар (сөйләм, хәбәр итүле әңгәмә, типик мәсьәләләр, күнегүләр эшләтү, эшләү үрнәген күрсәтү һ.б.) белән, **продуктив** (диалогик, күрсәтмәле, эвристик, тикшерү-эзләнүле) методлар башка ысуллар (проблемалы лекция, проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү һәм проблемалы танып-белү мәсьәләләрен чишүне оештыру, укучыларның эксперименты һ.б.ш.) белән тормышка ашырыла.

Дәреснең нәтиҗәлеген күтәрү ысулларының берсе — укытучының методларны оста чиратлаштыра, төрләндерә белүе. Ә бу исә өйрәтеләсе материалның эчтәлеген өлешләргә дөрес бүлүгә һәм укытудагы кирәкле алымнарны, ысулларны сайлый белүгә бәйле. Укыту методлары системасы укытучыларның һәм укучылар эшчәнлегенең барлык төрләрен дә үз эченә ала; дәрестә **дискуссияләр, уеннар,** укучыларның **лаборатор** һәм **практик эшләрен, тәҗрибә** һәм **экспериментальэшләрне оештыру да** җитди роль уйный.

Табигый, дәреснең нәтиҗәлеге аңа ничек әзерләнүгә, дәреснең планына, укыту методларының ничек сайлап алынуына бәйле. Ләкин ул болар белән генә чикләнми, практика күрсәткәнчә, дәрес башлану белән үк, укыту һәм уку процесслары үзара **тәэсир итешә** башлый, билгеле бер психологик атмосфера (берәр төрле «кәеф» кебек нәрсә) барлыкка килә, максатлар, мотивлар, кәефләр капма-каршылыгы килеп чыгарга мөмкин. Шуңа күрә укытучы, үзенең

профессиональ осталыгына, белем һәм тәжрибәсенә таянып, дәресне нәтиҗәле, яки, киресенчә, укытучының үзенә дә, укучыларга да кызыксыз, уңышсыз итә торган барлык факторларны да алдан ук белеп-сизеп торырга тиеш. Укыту методларын дөрес сайлап алу һәм оста чиратлаштыру, тәрбия методларыннан уңышлы файдалану, йомшак өлгерүчеләргә теләсә кайсы моментта ярдәм итәргә әзер булу, аларда үз көчләренә ышаныч тудыру, эшкә дәрт уяту, элеккечә авторитар (мәҗбүр итеп эшләтү) түгел, ә демократик стильдә (В.Ф.Шаталов, Е.И.Ильин, И.Х.Бикбулатова тәжрибәләрендәге кебек) эш итү — болар барысы да дәреснең яхшы сыйфатлы булуы өчен мөһим шарт булып тора (карагыз: Р.Х.Шакуров. Директор школы и микроклимат учительского коллектива. М., «Знание», 1979. № 3).

Югарыда санап узылган укыту эшчәнлеге һәм уку эшчәнлеге дәреснең барлык этапларында: белемнәрне актуальләштергәндә, яңа материалны үзләштергәндә һәм практикада куллланганда баштан алып ахырынача дәвам итә.

А. Терәк белемнәрне һәм эш-гамәл ысулларын актуальләштерү, гадәттә, дәрес башында була һәм дәреснең ничек узуына йогынты ясый. Дәресне башлап җибәрүдәге шикелле, белемнәрне актуальләштерү алымнары да күптөрле. Дидактик һәм методик әдәбиятта, мәсәлән, «оештыру моментының», белемнәрне, өйгә эшнең үтәлешен тикшерүнең ничек булырга тиешлеге шактый тәфсилләп тасвирланган. Бу, әлбәттә, яшь укытучылар, педагогия уку йортлары студентлары өчен әһәмиятле (карагыз: **И.К.Яковлев, А.М.Сохор**. Методика и техника урока в школе. М., 1985).

Ләкин эшнең асылы «оештыру моментында» түгел. Дәрес үткәргәндә аның башында ук, гадәттә, укучыларның тиешле кәефе булмый; материалны гадәти истә калдыру, шуны кабатлау укытучының дәрестәге материалны коры гына сөйләп чыгуы,

кайвакытта укучыларга тактсыз гына кисәтү ясавы — болар һәммәсе дә укучыларда тискәре эмоцияләр (үзенә бер төрле кәефсезлек) барлыкка китерә. Шундый хисләр исә укучыларның кызыксынып, теләк-дәрт белән укуына, акыл эшчәнлеген тулысынча эшкә җигүенә комачаулый. Укучыларның хисләре дөньясына кагылмый торган белемнәр инануларга әверелми, аларның дөньяга карашын формалаштыруга йогынты ясамый. Укыту процессын әнә шулай оештыра башлау яшь буынны тәрбияләүнең хәзерге максатлары һәм бурычлары белән кискен **каршылыкка керде.** (Карагыз: Хәзерге дәрес. «Народное образование» журналы, 1985 ел, №1, 106 бит.)

Шуңа күрә иң мөһиме — дәреснең беренче минутыннан ук укучыларда тиешле эмоциональ халәт (кәеф) булдырырга, кызыксыну уятырга, аларны киеренке эшчәнлеккә әзерләргә, дәресне үзләштерелә торган яңа материалда, яңа күнекмәләрдән канәгатьләнү хисе алырлык итеп оештырырга кирәк. Башкача әйткәндә, дәрес укучыларны кызыксындырудан, дәрт уятуда, интенсив аралашудан, укытучыларның укучыларга тәрбияви йогынты ясавыннан башлансын. Беренче сүзләрдән үк материалны укучыларга аңлаешлы, аларның фикерләү дәртен һәм хисләрен уята алырлык проблемалы-эмоциональ бәян итү, проблемалы сораулар, мәсьәләләр бирү һәм аларны чишүне оештыру бик әһәмиятле.

Укучыларда эшкә дәрт-теләк уятуның, ягъни мотивациянең алымнары күп. Әйтик, башлангыч классларда укытучының дусларча елмаеп алуы, өлкән классларда җае туры килгәндә җиңелчә генә шаяртып, уен-көлке сүз әйтеп җибәрүе дә монда артык түгел. Укытучылар еш кына 2-3 минутлык мөстәкыйль эш эшләтәләр. Ул телдән яки язмача була. Проблемалы сорауны оста бирү, өйрәнелә торган мәсьәләнең кыскача гына тарихын сөйләү, шигъри кереш ясау, сәнгать чараларыннан файдалану, яхшы сочинение яки изложениене анализлау, укучылар ясаган әйбәт әйберләрне күрсәтү

h.б. шундый эшләр дә дәресне уңышлы башлап җибәрергә, белем һәм күнекмәләрне актуальләштерүне җиңеләйтергә ярдәм итә.

Беренче тип дәреснең иң мөһим функциясе — белемнәр системасы, эш-гамәл ысуллары һәм **фәнни караш** формалаштыру. Укыту-тәрбия эшенә яңача якын килү укучыларның **диалектик фикерләвен** үстерүне таләп итә. Хәзерге дидактикада нәкъ әнә шул диалектик фикерләүне дөньяга фәнни караш тәрбияләүнең нигезе һәм логикасы, зиһенгә алу һәм үсештәге реаль чынбарлыкны аңлы рәвештә танып-белү методы итеп карарга кирәк. Шуңа күрә укучыларда диалектик (проблемалы) фикерләү диалектик каршылыкларны, ягъни уку-өйрәнү проблемаларын хәл итү ысулларын күрсәтү нигезендә генә формалаштырырга мөмкин (карагыз: М.И.Махмутов. Проблемное обучение. М., 1975).

Дәреснең өч төрле максатына («Совет мәктәбе» журналының 1987 елгы 1 нче санын карагыз) туры китереп, терәк белемнәрне һәм күнекмәләрне актуальләштергәч (алда әйтеп үтелгәнчә, моның алымнары күп), укытучы яңа материалны өйрәнүне оештыруга күчә: «ә хәзер яңа теманы өйрәнә башлыйбыз...»). Бу күчеш кинәт яки салмак кына, укучыларга сизелмәслек тә (мәсьәләләр чишү, проблеманы хәл итү, тәҗрибә эшенең h.б. дәвамы) булырга мөмкин.

Б. Яңа төшенчәләр һәм эш-гамәл ысуллары формалаштыру (барлыкка китерү). Яңа төшенчәләр һәм эш-гамәл ысулларын формалаштыру — дәреснең иң мөһим өлеше, этабы, аның дидактик структурасының әһәмиятле компоненты ул. Бу этап ничек башлана? Гадәттә, укытучы яңа теманы яки дәреслекнең яңа бүлеген өйрәнергә керешү турында әйтә. Ләкин укучыларның белемнәрен актуальләштергәндә үк, үзләре дә сизмәстән, яңа материалны өйрәнүгә күчә башлавы әйбәтрәк булып тора.

Дәреснең икенче этабы яңа материалның эчтәлеген **тасвирлаудан** яки аны сөйләп **аңлатудан**, яки күрсәтмә әсбап (шул исәптән

кинофильм) **күрсәтүдән**, яисә танып-белү мәсьәләсе (бурычы) **куюдан** һәм **укучыларның мөстәкыйль эшен** оештырудан (язмача эш, мәсьәләләр чишү, тәҗрибә үткәрү, текстларны уку һәм анализлау һ.б.) башланырга мөмкин.

Яңа материал, әгәр андагы төшенчәләр кабатлауны таләп итмәсә, билгеләмәләр ярдәмендә генә аңлатырлык булса, җыйнак итеп кенә тасвирлап бирелергә мөмкин. Билгеләмәне әзер көенчә әйтергә һәм укучыларга аны истә калдырырга кушыла. Мәсәлән, физика дәресендә: «Фарадей законы нәрсәдән гыйбарәт?» — дигән сорау куйгач, укытучы: «Дәреслектә менә болай диелгән»,— дип, законның билгеләмәсен укый. Билгеләмәне укытучы ярдәмендә укучылар үзләре дә бирә ала, тик моның өчен башта проблемалы ситуация барлыкка китерергә, төшенчәләрнең билгеләмәсен табу-эзләү буенча укучыларның акыл эшчәнлеген оештырырга кирәк.

Әгәр уку материалында билгеләмәләр белән генә аңлатып булмаслык, ә танып-белү өчен барлык төп охшаш һәм аерымлык билгеләрен сурәтләүне таләп итә торган катлаулы төшенчәләр күп икән, ул чагында укытучы яңа материалны киң итеп тасвирлап сөйләргә мөмкин. Бу сөйләмнең шулай ук вариантлары бар: кайчакта укытучы, төшенчәнең барлык сыйфатлары турында фактлар һәм мисаллар китереп, үзе сөйли яки, проблемалы ситуацияләр барлыкка китереп (сорау биреп), төшенчәнең аерым сыйфатларын ачыклау эшенә укучыларны җәлеп итә, үз фикерләрен тормыштан, фәнни-популяр әдәбияттан алынган мисаллар белән дәлилләргә куша һ.б. шундый эшләр оештыра.

Аңлату логика фәнендә фикерләүнең бер формасы булып исәпләнә һәм һәрвакыт чагыштыру; анализ, синтез; гомумиләштерү һ.б. шундый акыл (хәрәкәтен) операцияләрен үз эченә ала. Тасвирлаудан аермалы буларак, ул һәрчак ике өлештән: раслау һәм исбатлау өлешеннән тора. Беренче өлешенә раслау җөмләләре рәвешендә

әйтелгән барлык төшенчәләр керә. Мәсәлән: әгәр һәркем үз вазифасын намус белән үтәсә, ул вакытта илебезнең казанышлары тагын да югарырак була; үз белемеңне даими рәвештә күтәргән очракта гына, тормыштан артта калмыйсың һ.б. Раслауларның һәммәсе дә аның дөрес, закончалыклы булуын нигезләү-дәлилләүне, исбат итүне сорый. Теге яки бу бәйләнешнең закончалыклы күренеш икәнлеген дәлилләгәндә исбат итүләрнең төрле системасы (индуктив һәм дедуктив, тәҗрибә-эксперименталь һәм теоретик, логик һәм тарихи, математик һәм сүз белән сөйләп-логик) кулланыла.

Объектлар, күренешләр яки төшенчәләрне тасвирлап биргәннән, аңлатканнан соң ук, укытучы аларны ничек куллану яки үзгәртеп кору турында рекомендацияләр бирә. Шул рәвешчә, укытучының бәян итүе күрсәтмә бирү характерын ала, ул күрсәтмәләрдә тасвирланган, аңлатылган төшенчәләрне, объектлар яки күренешләрне үзгәртеп кору буенча практик эшчәнлекне ничек оештыруның принциплары, кагыйдәләре яки рекомендацияләре чагылыш таба.

Әгәр раслаулар һәм исбатлаулар укытучы тарафыннан гына башкарылса, мондый укыту укучыларның акыл сәләтен үстерми, дибез, чөнки алар үрнәк буенча гына эш итәргә өйрәнә-гадәтләнәләр (чынбарлыкта ул, әлбәттә, күпмедер үсә) әгәр укытучы укучыларны раслаулы җөмләләр төзүгә җәлеп итсә (мәсәлән, ул үзе дәрестә: «Әгәр җәмгыять антагонистик сыйныфлардан торса, ул чакта... нәрсә булырга мөмкин?»— ди, укучыларны сыйнфый көрәшнең котылгысыз булуы турында уйланырга этәрә), ул чакта аларның танып-белү эшчәнлеге һәм укытучы сөйләгәнне тыңлау активлыгы арта. Әгәр раслауларны укытучы үзе әйтеп, укучыларга шуларны дәлилләргә, исбатларга кушса, фикерләү эшчәнлеге тагын да ныграк активлаша. Моның өчен ул проблемалы ситуация китереп чыгара

яки үзе проблема куя, укучыларга эзләнү эшен фараз итүләрдән башларга куша (бусы, әлбәттә, эшне проблема куюдан башлауга караганда, алар өчен җиңелрәк).

Яңа материалны үзләштерү буенча укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру аларның акыл сәләтен үстерүдә бик тә әһәмиятле роль уйный. Әгәр яңа материал логик эзлеклелектә булса (аның иң мөһим законнары сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешләре, аналогия, индукция һәм дедукция тиешле тәртипкә китерелсә) һәм фактик материалны, аны өйрәнү шартларын, ориентирларын, күзәтүләрнең нәтиҗәләрен бирсә, ул чакта укучылар мөстәкыйль рәвештә:

объектлар һәм күренешләрне (төшенчәләрне) тасвирлый, билгеләмәләрне әйтә-чагылдыра һәм хикәяләр төзи беләләр;

объектлар һәм күренешләрне (төшенчәләрне) аңлата, законнарны, теоремаларны, үзлекләрне үзләре әйтә-китереп чыгара;

принципларны, кагыйдәләрне әйтә-чыгара һәм аларны практикада куллана алалар.

Фәнни әдәбиятта укучыларның мөстәкыйль эшләренең берничә классификациясе бар. Практикада куллану өчен И.И. Малкин классификациясе (башкару, ярым ижади, ижади һ.б. шундый характердагы мөстәкыйль эшләр) һәм П.И. Пидкасистый классификациясе уңышлырак булып тора. Соңгысы мөстәкыйль эшләрнең дүрт төрен күрсәтә. Кыскача гына әйткәндә, алар түбәндәгедән гыйбарәт:

шушы предметны өйрәнгәндә турыдан-туры аналогик яки элегрәк шуңа аналогик булган предмет эчендәге ситуациядән файдаланып, үрнәк буенча мәсьәләләр эшләү (укытучы ничек эшләргә икәнлеген күрсәткән яки дәреслектә чишү үрнәкләре җентекләп аңлатылган мисал һәм мәсьәләләр чишү);

башка предметларны өйрәнгәндә турыдан-туры аналогик яки элегрәк шуңа аналогик булган предметара ситуациядән файдаланып,

үрнәк буенча мәсьәләләр эшләү (беренче үрнәктән аермалы буларак, биредә башка предметлар буенча мәсьәләләр чишү ысулларын белү таләп ителә);

мәгълүм эш ысулларын гадәти булмаган шартларда предмет эчендәге яки предметара проблемалы ситуацияне хәл иткәндә реконструктив-вариатив рәвештә файдалану (мәсәлән, физикадан мәсьәләләр чишкәндә математик мәсьәләләрне чишү ысулларын куллану һ.б.);

— предметның үз эчендә һәм предметара фәнни-тикшеренү характерындагы мөстәкыйль эшләр (максатны, эшнең эчтәлеген укучылар үзләре билгелиләр, мәсьәләләрне чишүнең яңа ысулларын табалар һ.б.).

Мөстәкыйль эшләрнең барлык типлары һәм төрләре дәреснең өч максатыннан чыгып оештырыла, алар аның өч этабында да булырга мөмкин, ләкин барыннан да бигрәк яңа төшенчәләргә һәм эш-гамәлләрне үтәү ысулларына өйрәткәндә кулланыла.

Дәреснең икенче этабы (ул — дидактик структураның икенче компоненты булып тора) еш кына проблемалы ситуация барлыкка китерүдән, проблемалы сораулар куюдан башлана. Терәк белемнәр белән яңа төшенчәләр арасында, шулай ук предметның үз эчендә һәм предметара бәйләнешләр урнаштырыла, дәреснең тиешле темпта узуына, анда җитди эш атмосферасы (тиешле кәеф) булдыруга әһәмият бирелә. Болар һәммәсе дә яңа материалны өзлексез белем системасы рәвешендә үзләштерергә, укытуда дәвамчылык принцибын тормышка ашырырга ярдәм итә. Предметара бәйләнешләр, дәреснең белемнәрне актуальләштерү этабыннан башлап, йомгаклау өлешенә кадәр һәм төрле предметлар буенча дәресләр системасының ахырынача «үтәли» дәвам иттерелә.

Гомумән, дәреснең яңа теориясе теге яки бу предмет (физика, химия һ.б.) чикләрендә генә түгел, ә төрле фән нигезләре буенча

укучыларда белемнәр системасы булдыруга зур әһәмият бирә. Җитештерүчән хезмәт белән бәйләнгән фәнни һәм политехник белемнәр системасы гына табигать, җәмгыять һәм фикерләү, дөньяны танып-белү турында тулы бер күзаллау булдыруга ярдәм итә. Башкача әйткәндә, дөньяның физик, химик һ.б. шундый үзлекләре турында өзек-өзек белемнәр түгел, ә **белемнәр, күнекмәләр** һәм **эш-гамәлләрнең бердәмлеге** генә шәхесне һәрьяклап үстерү, аның дөньяга фәнни карашын формалаштыруның нигезе булып тора.

В. Белемнәрне практикада, эштә куллану — дәрес структурасының өченче компоненты; башка компонентлар кебек, ул да укыту эшендә зур әһәмияткә ия. Традицион дәреснең кимчелекләреннән берсе — белемнәрнең практикада кулланылмавы. Укучылар кагыйдәләрне, законнарны беләләр, әмма еш кына аларны практикада куллана алмыйлар; теореманы беләләр, ә аны исбатларга кыенсыналар; күренешләрне, фактларны истә калдыралар, әмма аларны гомумиләштерергә яки конкретлаштырырга читенсенәләр һ.б.

Мәгълүм ки, теләсә нинди белем, әгәр ул инануга әверелмәсә, эшли белүгә һәм эш-гамәлгә ярдәм итмәсә, «коры» белем булып кына кала. Бу әверелеш белемнәрне практикада кулланганда гына уңышлы бара. Беренче тип дәресләрдә белемнәрне гамәлгә кую, ягъни практикада кулланга укучылар яңа төшенчәләр һәм эш-гамәл ысулларын үзләштергәч керешелә, һәм ул озак вакыт алмый. Белемнәрне камилләштерү, гомумиләштерү һәм аларга контроль ясау дәресләрендә белемне куллану дәреснең төп компоненты (этабы) булып тора. Анда белемнәрне камилләштерү, укучыларның танып-белү осталыгын һәм күнекмәләрен ныгыту буенча мөстәкыйль эшләр оештырыла.

Дәрес структурасының дидактик, белемнәрне гамәлгә кую — практикада куллану компоненты да берничә методик элементны үз эченә ала. Анда күнегүләр, практик эшләр өстенлек алып тора. Мәсәлән, дәреснең икенче этабында текстка логик анализ ясау буенча мөстәкыйль эшләр өченче этапта алгоритм, үрнәк буенча эшкә күчә — текстны анализлау күнекмәсен нығыту эше алып барыла. Проблемаларны хәл итү проблемасыз мәсьәләләрне чишү белән алмашына (җае туры килсә, укытучы проблемалы мәсьәләләрне дә тәкъдим итәргә мөмкин). Белемнәрнең ничек үзләштерелүенә контроль дә, дәрестә укучының эшенә билге кую, өйгә эш бирү дә өченче этапта (дәреснең азаккы өлешендә) була.

Беренче мәкаләдә әйтелгәнчә, дәреснең дидактик структурасы өч өлештән (компоненттан) гыйбарәт. Һәр компонент методик яктан үзе тагын берничә ваграк өлештән (элементтан) тора; шул элементлар конкрет алым һәм ысуллар җыелмасыннан гыйбарәт.

Контрольне укытучы дәреснең һәр этабында игътибар үзәгендә тота; укучыларның яңа материалны ничек үзләштерүен, мөстәкыйль эшләрне ничек үтәвен, проблемаларны ничек хәл итүен күзәтә; болар белән генә чикләнмичә, проблемалы сорауларның ни дәрәҗәдә катлаулы булуын, укучыларның аларны мөстәкыйль рәвештә хәл итә, фараз-гипотезаларны дәлилли алуын һ.б. тикшерә; белемнәр системасының һәм дөньяга карашның ничек формалашуын тикшерүгә аеруча әһәмият бирә.

Өйгә эш бирү мәсьәләсе һәрчак бәхәсләр китереп чыгара иде, чөнки ул укучыларга артык эш йөкләү белән дә бәйле. Элегрәк өйгә эшне дәрес ахырында гына бирергә тәкъдим ителә иде. Укытуны активлаштыру тәҗрибәсе күрсәткәнчә (мәсәлән, Липецк өлкәсе һәм Татарстан АССР мәктәпләрендә), өйгә эшне дәреснең теләсә кайсы этабында, хәтта башында да бирергә яки бөтенләй бирмәскә мөмкин (мәсәлән, Е.И.Ильин һәм И.Х.Бикбулатова тәҗрибәсендә).

Ләкин, кагыйдә буларак, укытучылар өйгә эшне дәрес ахырында бирәләр. Бу өйгә эшнең күләмен билгеләүгә, укучыларның (яки аерым төркемнең) яңа материалны ничек үзләштерелүенә бәйләнгән. Галимнәр өйгә бирелгән эштә дүрт компонент (белемнәрне кабатлау, аларны куллана белү күнегүләре эшләү, иҗади эшләр башкару, белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру) булган очракны иң яхшы вариант дип саныйлар. (Карагыз: Н.М.Скаткин, И.Я Лернер. Современный урок. «Народное образование», 1985, №1) Әлбәттә, бу компонентлар барысы да бер дәрестә булмаска, алар бергә кушылырга, бу бирем һәр компонентны да үз эченә алган булырга һ.б. мөмкин. Укучыларга өйгә эш бирүгә һәр очракта да укытучы иҗади якын килергә тиеш.

3) Дәреснең нәтиҗәлеген күтәрү

(Хәзерге дәрес. "Совет мәктәбе", 1987, №3, 28 б.)

Аңлашыла ки, дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә торган барлык дидактик шартларны аның һәр этабында да күрсәтеп бетереп булмый; тагын шунысы бар, мәсәлән, технологик яктан, ягъни дәресне үткәрү алымнары дәрәҗәсендә бер укытучы — үзенә генә хас булган бер төрле, икенчесе исә башка төрле шартлар тудыра. Шуңа күрә, без нигездә хәзерге дәреснең һәркайсына караган дип әйтерлек, шул исәптән азкомплектлы мәктәпләрдә дә, мәгълүм бер күләмдә, теге яки бу уңайдан килеп чыга торган иң мөһим шартларга гына кыскача тукталып узабыз. Биредә дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрүнең күпчелеккә мәгълүм шартларына тукталып тормыйча, берничә иң мөһим күренгән шартка гына тукталып үтик.

Укыту формалары. Укучының шәхесен, аның дөньяга карашын һәм иҗат сәләтләрен тәрбияләү һәр баланың яшенә һәм индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле. Укучының **гомуми** (ягъни белем запасы, дөньяга карашы, әдәп-әхлак һәм мәдәни үсеше) һәм **махсус**

(мәсәлән, математик фикерләвен үстерү һ.б.ш.) үсешенә ирешү бурычы никадәр конкретрак итеп куелса, **укыту формасы**[3] проблемасы да үзен шулкадәр ныграк сиздерә бара.

Гадәттә укытучы дәрестә фронталь эш алып бара: барлык укучылар өчен дә материалны бертөрле бәян итә, аларга бертөрле биремнәр бирә, бертөрле бурыч куя. Ә һәркемнең эш нәтиҗәсе башкаларныкыннан аерылып тора һәм, кагыйдә буларак, индивидуаль рәвештә бәяләнә. Бу традицион, элек-электән килгән хәл һәм бүген дә шулай дәвам итә. Укучыларның уку эшчәнлеге процессы (уку, язу, мәсьәләләр чишү, лаборатор эшләр башкару, һ.б.), гадәттә, коллектив (кайчакта — группалап) формада бара. **Танып-белү эшчәнлеге**, үзләштерү, яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру — үзенең табигате буенча укучының индивидуаль эшчәнлеге ул. Шуңа күрә укытучының белемне фронталь рәвештә (һәммәсенә берьюлы) бәян итүе белән һәр аерым укучының аларны индивидуаль формада үзләштерүе арасындагы каршылыкны (М.А.Данилов) җиңеп чыгу — һәрвакыт педагоглар алдында торган җитди бурыч ул.

Укытуны индивидуальләштерүнең (ягъни укучыга аерым игътибар итүнең) методик алымнары күп, ләкин укытуның эчтәлеге, состав өлешләре, төшенчәләренең нинди эзлеклелектә бирелүе һ.б.ш. мәсьәләләр аеруча мөһим булып тора. Дәрес турында хәзерге теория уку-укыту материалын анализлаганда (дәрескә әзерләгәндә) катлаулылык дәрәҗәсе (һәм билгеле бер төркем укучылар өчен нинди кыенлыкта булуы) буенча аны дифференциацияләштерергә (аерырга, бүләргә) тәкъдим итә. Төрле дәрәҗәдәге проблемаларны

[3] «Укыту формасы» төшенчәсенең (коллектив, группа, аерым укучы белән эшләүнең һ.б.) «укытыны оештыру формасы» (дәрес, аерым фәннәрдән түгәрәкләр, физкультура занятиеләре һ.б.) төшенчәсеннән аерылуын исегезгә төшерәбез. — Автор.

хәл итү процессы оештырып материалны төрле катлаулылыктагы[4] **танып-белү** мәсьәләләре формасында (хәтердә яңарту-искә төшерүгә, элек үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне таныш яки яңа ситуациядә куллану, мәсьләләр чишү, биремнәр үтәү һ.б.) бирергә мөмкин. Уку-укыту материалын әнә шулай дифференцияләштерү — укытуны индивидуальләштерү ысулы ул. Һәр укучыга аерым игътибар итеп, аның шәхси үсешен тизләтеп була.

Әмма бүгенге көндә укучыларда шәхеснең бер сыйфаты буларак **коллективизм** хисе һәм аңлылыгы тәрбияләү элеккегә караганда да җитдирәк проблема булып тора. Үз вакытында Н.К.Крупская язганча, бергәләп эшләү генә түгел әле ул, фәкать бердәм танып-белү бурычын бергәләп чишкәндә — хәл иткәндә генә мөстәкыйль коллектив эш оештырылуы турында сөйләргә мөмкин; барлык укучыларны да эшкә җәлеп иткән, аларның хисләр дөньясын уяткан проблемалы ситуация дә коллективизм хисе тәрбияли.

Укыту формасына карап бу эш парлап-парлап, звенолап, группалап оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш. Бер-береңне укыту элементлары, бигрәк тә азкомплектлы мәктәпләрдә, һәрвакыт булды һәм хәзер дә бар: яхшы укучы балалар материалны йомшак, акрын үзләштерүче иптәшләренә ярдәм итәләр; шул рәвешчә, алага дәреснең гомуми темпына өлгерергә булышалар. Класс коллективында бер-береңне укыту идеясен

[4] Без «катлаулылык», «кыенлык» һәм «проблемалылык дәрәҗәсе арасында зур аерма бар дип саныйбыз. Уку-укыты материалының катлаулылыгы яңа төшенчәләр (һәм эш-гамәл ысуллары) санына, терәк төшенчәләрнең буду-булмавына, мәсьәлә шартында бирелгән зурлыклар микъдарына һ.б. бәйле. Кыенлык дәрәҗәсе укучыларның мәсьәләләр чишү күнекмәләре булу-булмавына, текстны анализлый, гомумиләштерә белүләренә һ.б.ш. бәйләнгән. Проблемалылык дәрәҗәсе материалда каршылыклы мәгълүматларның булу-булмавына, элек үзләштерелгәннәр белән яңа төшенчәләрнең нисбәтенә һ.б.ш. бәйле булып тора. Шулай ук мәсьәләне «чишү», проблеманы «хәл итү» дип язабыз, чөнки беренчесе конкретрак мәгънәгә ия.

Н.К.Крупская да яклап чыккан: «Һәр укучы бер үк вакытта укучы да, укытучы да булып торырга тиеш, шунысы факт, бала үзенә педагог ролен бик теләп ала», —дигән ул (Н.К.Крупская. Соч. в 10 томах, IV том, с. 177).

Укыту методларын сайлап куллану шулай ук укытуны дифференциацияләштерү һәм индивидуальләштерүне көчәйтү мөмкинлеге бирә: әйтик, кайбер укучыларга — репродуктив (башкару, хәтердә яңарту, искә төшерү), икенчеләренә исә продуктив (өлешчә эзләнүле, эзләнүле) методлар белән эшләүне таләп итә торган биремнәрне үтәргә кушыла.

Дәрестә дидактик уеннар. Дидактик уеннар укытуның яңа коллектив формасы итеп санала. «Бу өйрәнелә торган системаларны, күренешләрне, процессларны, шулай ук булачак профессиональ эшчәнлекне имитацион модельләштерү[5] буенча актив уку эшчәнлеге булып тора» (П.И.Пидкасистый, Н.К.Ахметов, Т.С.Хайдаров. Игра как средство активизации учебного процесса. «Советская педагогика», 1985, № 3, с. 22).

Психология күзлегеннән караганда, бала-чага һәртөрле уенга һәвәс була. Дидактика күзлегеннән караганда, уен мавыктыргыч, кызыклы ситуацияләрдә укытуның диалогик һәм эвристик (ягъни продуктив) методларының бергә берләштерелүеннән гыйбарәт ул. Проблемалы укытуның конкрет технологиясе сыйфатында берьюлы берничә методтан файдалану аерым методка караганда билгеле бер өстенлеккә ия. Чөнки укучы зур теләк белән уенда үзе актив катнаша (бу исә аны мөстәкыйль рәвештә конкрет фикергә килергә этәрә, чөнки җитди уен эш-хәрәкәтне таләп итә), вакытка экономия

[5] Тормышта, чынбарлыкта булган процессны уку-укыту процессында «уйнап күрсәтү», чагылдыру. (Мәсәлән, язгы чәчү алдыннан колхоз идарәсендә үткәрелгән фикер алышуны яисә кибетче һәм сатып алучы арасындагы әңгәмәне һ.б.ш.).

ясала (уен уку-укыту барышын тизләтә), нәтиҗәләр шунда ук билгеле була.

Тарих фәненнән проблемалы дәресләрдә, мәсәлән, дидактик уеннардан **политбой** оештырырга мөмкин. Анда укучылар идеологик дошманны («идеологик дошман»ның карашларын укытучы үзе әйтә) фаш итәләр. Укучылар ике төркемгә бүленә. Идеологик дошманның «тәгълиматы» ялган, ялгыш булуын дәлиллерәк, нигезлерәк итеп аңлаткан төркем җиңеп чыга.

Тарихи алдан күрү уенын да кызыклы итеп үткәреп була. Эволюциясе берничә тарихи чор барышында күзәтелгән нинди дә булса бер күренешнең үсеш тенденциясенә нигезләнеп, укучыларга ул күренешнең киләчәктә нинди булачагын әйтергә тәкъдим ителә. Мәсәлән, производство нигезләре курсын алыйк. Укучыларга бирем бирелә: шушы гасыр ахырында социалистик ярышның нинди үзлекләргә ия булачагын (нинди төскә керәчәген) уйлап табарга кирәк. Җавап биргәндә укучылар ярышның ул үзлекләре, сыйфатларының бүгенге көнгә чаклы ничек үсә баруы тенденцияләрен исәпкә алырга тиеш. Әйтик, һәрчакта да хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү социалистик ярышның төп күрсәткечләреннән берсе булып килде; киләчәктә дә ул шулай булып калачакмы, яки андый рольне табыш алу уйнаячакмы, дип фараз итәргә мөмкин; хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең яңа чыганаклары турында сүз алып барырга була. Мәсәлән, фән-техника революциясе казанышларыннан киңрәк файдалану, эшчеләрнең белем һәм квалификациясе дәрәҗәсен, производствоның тулаем нәтиҗәлелеген күтәрү киләчәктә социалистик ярышны киң җәелдерүдә тагын да мөһимрәк роль уйнаячак. Бәлки, үз-үзен финанслауга күчә барган производствода хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү көче булып табыш саналыр?

Әдәбият курсыннан нинди материалларны, дидактик уен рәвешендә үзләштерү өчен, уку-укыту проблемасына (мәсьәләсенә) әйләндерергә мөмкин? Иң элек биографик материалны; әдәби текстны (тормыштагы ситуацияләр, әдәби геройларның эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы, үзара мөнәсәбәте һ.б. сурәтләнгән өзекләрне), әсәрдәге әдәби төр һәм жанр формасының үзенчәлекләрен, ягъни әсәрнең художество структурасын әнә шундый проблемага әйләндерергә була.

Тәрбия эшендә үрнәкнең көче гаять зур. Бу җәһәттән язучыларның биографиясе бик әһәмиятле. Ләкин биографияне гади сөйләп чыгу гына укучыларның күңел кылын тибрәндерми. Моның өчен дидактик уеннар файдаланырга була. Мәсәлән, үткәннәргә күңелдән сәяхәт ясау, биографиясе өйрәнелә торган язучы белән «пресс-конференция үткәрү»; аның замандашлары, бергә эшләгән, бергә яшәгән иптәшләре белән күңелдән «очрашулар оештыру», язучы йөргән эзләр буенча күңелдән генә «сәяхәт итү» һ.б. шундый уеннар, һичшиксез, укучыларның танып-белү эшчәнлеген, активлыгын күтәрәчәк, дәрес-уенны җанлы, мавыктыргыч һәм хисләргә бай итәчәк. Мәсәлән, укучылар Маяковский «юллары буйлап атлый», ди. Бу —революцион поэзияне, совет культурасын армый-талмый пропагандалаучы шагыйрь юлы. Шул «юлга аяк баскач», укучылар шунда ук үзләре дә үзгәрәләр: әдәби тәнкыйтьчеләр, язучылар, әдәбият-сәнгать белгечләренә әвереләләр; шагыйрь, аның дуслары, дошманнар исеменнән сөйлиләр, яклыйлар, тәнкыйтьлиләр һ.б. Кыскасы, һәркемне кызыксындырырлык ижади эш — уку эше дәвам итә.

Әдәби текст белән эшләгәндә дидактик уеннарның педагогик мөмкинлекләре тагын да ныграк ачыла. Мәсәлән, биредә шундый эшләр оештырырга була: а) әдәби әсәрне рольләргә бүлеп уку, уйнау; б) билгеле бер тип әдәби геройлар барлыкка китерү («артык

кеше», «кечкенә кеше», «яңа кеше», «бунтарь» һәм «революционерлар»; в) әдәби персонажларның үз-үзләрен ничек тотуы сурәтләнгән эпизодларны сәхнәләштерү; г) төрле фикердәге һәм караштагы персонажларның каршылыгын уен барышында күрсәтү; д) төп коллизияләрне (бәрелешүләрне) тикшерү.

Әсәрнең әдәби формасын, эчтәлеген тикшерүгә багышланган дәресләрдә дә дидактик уеннар үзен аклый. Бу очракта укучылар тәнкыйтьче, хәбәрче, редактор, корректор, рәссам, күзәтүче, комментатор һ.б.ш. рольләрне башкара алалар. Андый дәресләрдәге дидактик уеннарның максаты — әсәрдәге әдәби архитектониканың (гармонияле төзелеш-бәйләнеш), сурәтләү чараларының идея-эчтәлекне тулырак ачудагы ролен аңлауда укучыларга ярдәм итү. Үрнәк итеп, Казандагы 79 нчы мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы И.Х.Бикбулатованың шундый дәресләрне кызыклы итеп уздыруын китереп була (карагыз: И.Х.Бикбулатова. Пробуждая чувства добрые (Нравственное воспитание на уроках литературы). Казань, 1986, 122 с).

Дидактик уенны оештыруның төп этаплары нидән гыйбарәт? Әлегә түбәндәгеләрен күрсәтеп үтик:

а) уенга әзерләнү, төп бурычны билгеләү, өйрәнелә торган объектның имитацион моделен төзү (мәсәлән, борынгы Болгар шәһәре буйлап сәяхәтне сурәтләү һ.б.); укучыларны уенда катнашу өчен кирәкле теоретик белемнәр, төрле мәгълүматлар белән тәэмин итү (мәсәлән, укучыларга Идел буендагы борынгы Болгар дәүләтенең барлыкка килүе, аның экономик үсеше һ.б. турындагы тарихи мәгълүматлар бирү);

б) уен ситуациясе барлыкка китерү; укучыларны уен шартлары һәм үзара аралашу кагыйдәләре белән таныштыру; рольләрне бүлешү, максатны һәм уен барышында чишелергә тиешле бурычларны аңлату;

в) уен барышында шул бурычларны үтәүгә ирешү. Шул процесста уку-укыту проблемалары куела һәм чишелә, хәл ителә; фараз-гипотезалар әйтелә һәм дәлилләнә, нәтиҗәләр чыгарыла (монда диалогик һәм эвристик методларның дөрес нисбәттә булуы бик мөһим);

г) чишелешнең дөреслеген тикшерү һәм нәтиҗәләргә бәя бирү. Нәтиҗәләрне туплау — тәртипкә китерү. (Кайвакытта бу цикл (а, б, в, г) уен барышында ике яки өч мәртәбә кабатлана; боларның барысы да уенның шартларына һәм дәвамлыгына бәйле).

Уен ахырында укучыларның активлыгына, проблемаларны хәл итү осталыгына, үз фикерләрен дәлилли, башкаларныкын инкарь итә, нәтиҗәләр чыгара белүенә бәя бирелә.

Дидактик уеннарны нәтиҗәле үткәрү өчен, проблемалы сорауны, мәсьәләләрне «үткен» (оста), барлык укучыларны да кызыксындырырлык итеп куярга кирәк. Мәсәлән, кайбер галимнәр Идел буендагы татарларны, Алтын Урда таралгач, шунда килгән килмешәк халык дип саныйлар; икенчеләре исә, татарларның борынгы бабалары — болгарлар булган, алар, монгол-татарлар бу җирләрне басып алганчы, 600 еллар элек үк Идел, Кама буенда үз дәүләтләре белән яшәгән, дип дәлиллиләр. Шул каршылыклы мәгълүмат нигезендә «Бу ике гипотезаның кайсысы дөрес?» — дигән проблемалы сорау куярга була.

Укытучы укучыларга уендагы төп проблеманы «кабул итәргә» һәм аны хәл итү юлларын табарга булышырга мөмкин. Шунысы мөһим: проблеманы хәл итү мавыктыргыч, уен стилендә булырга тиеш. Әлбәттә, дәреснең өч компонентлы дидактик структурасында (өч төрле дидактик бурыч — актуальләштерү, яңа белем алу, куллану) уен үзенчәлекле бер методик астструктурага (эзлекле рәвештә төзелгән алымнарга) ия. Аны дәрес белән бәйләп класстан тыш эш

вакытында да дәвам иттергәндә, уенның нәтиҗәлелеге тагын да арта.

Алдынгы укытучылар мәктәпләрдә һәм профтехучилищеларда дәрестә һәм класстан тыш вакытта күп кенә фәннәрдән **КВНнар** үткәрә. Бу кызыклы ярышлар гади күңел ачу гына түгел, ә укучыларга белем бирә, аларны күп нәрсәгә өйрәтә һәм акыл сәләтен үстерә торган дидактик уен. Әлбәттә, ул һәр укытучыдан, укучыдан, гомумән, педколлективтан ник әзерлек таләп итә. Шигырьләр сайлап алу яки ижат итү, кызыклы сораулар табу, эмблемалар ясау һ.б. шундый эшләр барысы да зур тырышлык һәм зирәклек сорый, укучыларны дәреслек, фәнни-популяр әдәбият белән эшләүгә, күңелләрен фәнгә җәлеп итә, мавыктыра, аларга стимул бирә (карагыз: Н.Антипов Клуб Веселых и Начитанных. «Профессионально-техническое образование» журналы. 1985. № 3).

Дәрестә дидактик уеннар оештыру — укытуның нәкъ мәктәп реформасы документларында әйтелгән актив формалары һәм методларыннан файдалану ул.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге кимчелекләрне («пробелы») бетерү өстендә эшләү — укытучының җитди бурычы. Әмма бу эшнең, беренчедән, методикасы камил түгел, икенчедән, һәр фәннән диярлек программалар зур, катлаулы. Шулай да аңа вакыт табарга, эшне шактый уңышлы оештырырга була. Бигрәк тә дәреснең белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү этабында. Бу вакытта шушы дәрестә яңа теманы өйрәнү өчен кирәкле белем (проблемалы ситуацияләр тудырып яки алардан башка) искә төшерелә, ныгытыла. Үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне практикада куллану этабында да кимчелекләрне бетерү өстендә җитди эш алып барырга мөмкин (карагыз: Л.Засорина, А.Назаров Педагогическая диагностика; И.Голдин, М.Горбачевская. От двух до

пяти (О критериях оценки и знаний учащихся в ПТУ), «Профессионально-техническое образование» журналы. 1985, № 1).

Алдынгы урта мәктәпләрдә укучылар белемдәге кимчелекләрне бетерү юлында эшләүнең билгеле бер системасы барлыкка килде. Ул, мәсәлән, түбәндәгеләрдән гыйбарәт булырга мөмкин:

— укучыларның VI—VIII класс материалын ни дәрәҗәдә үзләштерелүен, күнекмәләрен билгеләү;

— аерым фән буенча һәм конкрет укучыларга (теге яки бу группага) хас типик кимчелекләрне ачыклау;

— сигезьеллык мәктәптә укытыла торган материалның эчтәлегенә анализ ясау һәм киләчәктә теге яки бу фәнне һәм сайлап алынган белгечлекне өйрәнгәндә нигез булачак белем һәм күнекмәләрне билгеләү;

— белем һәм күнекмәләрне тулыландыру өчен аерым алымнар, чаралар һәм формалардан гына түгел, ә аларның һәммәсен дә бергә (төрле чагыштырмада) эзлекле рәвештә файдалану;

— төзәтелә торган кимчелекләрне төгәл исәпкә алу;

— материалны йомшак үзләштерә, күнекмәләрне авыр өйрәнә торган укучыларда үз көчләренә ышаныч уяту.

Биредә баштагы өч юнәлешне бергә берләштереп тикшерергә кирәк, чөнки барыннан да бигрәк укучыларга алга таба укуда, һөнәр үзләштерүдә нигез булып торган белем һәм күнекмәләрдәге кимчелекләрне ачыклау һәм аларны бетерү өстендә эшләү аеруча мөһим. Һәр фәннән шундый типик кимчелекләр ачыклангач, укучылар белән эшләүнең формалары, вакыты билгеләнә.

Укыту-өйрәтү төсендәге биремнәр дә практикада киң кулланыла. Ул биремнәрдә төшенчәләрне, законнар, теорияләр һәм башкаларны үзләштерүнең яисә тәҗрибә эшләп күрсәтүнең, мәсьәлә чишүнең

алгоритмнары[6] (карагыз: Р.Хәлиуллин. Химиядән мөстәкыйль эшләр. «Совет мәктәбе», 1987, №1); приборны, машина һәм механизмны тасвирлап бирү, күренеш яки процессны һ.б. модельләштерү буенча күрсәтмәләр дә була. Андый биремнәр, мөстәкыйль эшләр укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге типик кимчелекләрне исәпкә алып төзелә; алар чагыштырмача тиз вакыт эчендә, максатчан эш алып бару нәтиҗәсендә, балалардагы шундый җитешсезлекләрне бетерергә ярдәм итә.

Укыту-өйрәтү төсендәге биремнәр дәрестә белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү, һәм шулай ук практикада куллану этапларында еш файдаланыла. Укытучылар, гадәттә, шундый биремнәрдән дидактик материаллар комплекты әзерлиләр, аларны, яңа теманы өйрәнә яки шул тема буенча төп биремне үти башлаганчы, укучылар белән индивидуаль эш оештырганда кулланалар.

Укыту процессында электроник хисаплау машиналары (компьютерлар) куллану да укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге кимчелекләрне бетерү өчен зур мөмкинлекләр ача, чөнки андый машиналар өчен төзелгән укыту-өйрәтү программасында белемнәрне актуальләштерү юнәлешендә эшләү процессы органик рәвештә бергә берләшкән, алар бер дәрәҗәдә оештырыла.

Уку-белем алуга теләк, омтылыш (ягъни һәвәслек, уку мотивациясе) булдыру хәзерге педагогикада иң мөһим проблемаларның берсенә әйләнде. «Балалар укырга теләми», — диләр башлангыч класс укытучылары. Моны хәтта өлкән класс педагогларыннан да ишетергә була. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, укуга омтылыш, һәвәслек, дөрестән дә, әллә ни зур түгел. Бу бигрәк тә VI—VII класслардан сизелә башлый. Гомуми урта белем бирүгә күчкәнче,

[6] Бер типтагы мәсьәләләрне чишү кагыйдәләре җыелмасы, кагыйдәләр системасы.

укучыларның тик бер өлеше генә (30 %ы чамасы) укуын югары классларда дәвам иттерә, башкалары ПТУга яисә производствога эшкә керә иде. Хәзер исә һәркем урта белем алырга тиеш. Теория белән кызыксынмаучылар да мәктәпкә йөри. Бу бер хәл. Икенчедән, укыту процессын оештыру дәрәҗәсе түбән. Шактый укытучылар искечә, традицион, пассив методлар кулланып эш итәләр, балаларда белем алуга, теорияне үзләштерүгә омтылыш уятмыйлар. Дөрес, галимнәрнең тәкъдимнәрен искә алып һәм үзләренең уңай педагогик табышларын кулланып, иҗади эшләүче, укучыларда белемгә кызыксыну уятучы укытучылар да байтак. Алар балаларны танып-белү алымнарына, проблемаларны мөстәкыйль рәвештә куярга һәм хәл итәргә өйрәтәләр; белем алуга омтылыш тәрбиялиләр.

Уку материалындагы яңалыкны дөрес күрсәтү, аның кыскача тарихын сөйләп алу, сәнгать чаралары куллану, дидактик уен оештыру, табигатьтә һәм кеше тормышында гадәти булмаган очраклар турындагы мәгълүматлар китерү һ.б. материалны өйрәнүгә кызыксыну уята, дәреснең эмоциональлеген арттыра, укучыларда кичерешләр барлыкка китерә, теге яки бу мәсьәләләрнең «үзәген» күңел күзе белән дә күрергә өйрәтә. Өстәвенә, дәреснең структурасы яңача булса һәм проблемалы укыту методлары киң кулланылса, болар һәммәсе дә укучыларда белем алуга теләк-омтылыш һәм танып-белү ихтыяҗы уята.

Кайвакытта традицион дүрт элементлы дәрестә дә яисә материалны гади генә сөйләп биргәндә дә укучыларны активлаштыру ысуллары табыла. Бер мисал китерик. Мәгълүм ки, дәрес башында укучыларның белемен тикшерүгә кайбер укытучылар күп вакыт сарыф итәләр. Аның сәбәпләрен һәркем яхшы белә. Куйбышев шәһәрендәге бер ПТУ укытучысы К. Лисецкий, мәсәлән, андый очракта белемне тикшергәндә укучыларны активлаштыруның яңа һәм кызыклы бер ысулын куллана: ике кнопкалы шахмат сәгатеннән

файдалана. Янәшә ике рәттә утырган балалар арасында үзенә күрә бер блиц-турнир үткәрә. Укытучы сорау бирә һәм, кнопкага басып, 5 минутка сәгатьне җибәрә. Һәр рәттәге үсмерләр, чиратлап җавап бирәләр. Кайсы рәттәгеләрнең флагчыгы алданрак төшсә (5 минуттан соң) шулар оттыра. Бөтен бер группа укучыларының белемнәрен тикшерү ун минут эчендә әнә шулай дәвам итә.

«Укучылар дәрестә мондый ярышны бик ошаттылар,— дип яза К.Лисецкий. — Белем тикшерүгә каралган вакыт — минутлар стимул булып хезмәт итте. Һәр җавапны бөтен рәт тын да алмыйча тыңлый. Элегрәк укучылардан иң оста сөйләүче дә үзенә шундый игътибар булыр дип уйламагандыр. Элегрәк акрын гына җавап бирү, сөйләмдәге төгәлсезлек бетә, тиз, кыска һәм дөрес җавап биргән укучылар өстенлек ала башлады. Әгәр укучы җавап бирә алмыйча торса, бөтен рәт аңа текәлә, аның өчен борчыла. Әлбәттә, иртәгә инде укучы андый хәлгә калмаска тырыша. Йомшак өлгерә торган укучы әйбәт җавап бирсә, бөтен коллектив чын күңелдән шатлана. Сәгатьтәге икенче контроль флагчыкның төшүен, ягъни көндәшләрнең җиңүен кул чабып каршы алалар...»

Укучылар акрынлап вакытка экономия ясарга, тиз һәм төгәл җавап бирергә гадәтләнәләр; бер рәттән икенчесенә күчүләр башлана, тигез көчтәге командалар төзелә. Белемнәрне үзара тикшерү мөмкинлеге дә туа. Укучылар алдан ук каршы як командага (рәткә) четерекле сораулар әзерләү хәстәрлеге күрә башлыйлар. Сорау-җавап барышында укытучы еш кына арбитр ролен үти. Шул рәвештә, дәрес башындагы 10 минут укучылар арасында көч сынашуга әверелә. Яңа материалны да алар зур игътибар белән тыңлыйлар. Дәрес ахырында көндәш рәткә (командага) четерекле, катлаулы сорау бирергә омтылу алардагы ялкаулыкны җиңеп чыга.

Шунысы әһәмиятле, беренчедән, һәр укучыда белемгә омтылыш, ярышта җиңү теләге артса, икенчедән, аларда коллективизм хисе

көчәя. Үзара яңа мөнәсәбәтләр урнаша. Һәркемнең үзе өчен генә җаваплылыгы команда (рәт) өчен дә җаваплылыкка әверелә. Уку процессында уртак шатлык мөмкинлеге туа. Ә коллективның шатлыгы исә һәркемнең шәхси куанычына әйләнә. (карагыз: К.Лисецкий. Ход конем. «Профессионально-техническое образование» журналы, 1985, №3).

Гомуми һәм профессиональ белемнең үзара бәйләнеше бу ике төр мәгарифнең якынаюы, ә киләчәктә исә, бергә кушылуы өчен нигез булып тора. Андый бәйләнеш төшенчәсе предметара бәйләнеш төшенчәсеннән киңрәк һәм хәзерге дәрестә мөһим урын алырга тиеш. Ул — укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү, проблемалылык, политехнизм, профессиональ ориентация бирү, дәвамчанлык, предметара бәйләнеш, уку һәм хезмәтнең мотивациясе, укыту һәм тәрбияне бердәм процесска кушу принципларын тормышка ашыруны үз эченә ала. Әлбәттә, бу — катлаулы эш. Аның теоретик нигезләнүе дә, бу өлкәдә тупланган тәжрибә дә әлегә тиешле дәрәҗәдә түгел.

Укытуны җитештерүчән хезмәт белән кушу принцибы техника һәм производство процесслары өйрәнелә торган фән дәресләрендә җиңел тормышка ашырыла. Техника-технология буенча белемнәрнең күп өлеше инструктив характерда була, шуңа күрә алар билгеле бер хезмәт операцияләрен башкарганда файдаланыла. Ә ул инструктив материаллар исә техника һәм технологиягә караган теоретик, гадәттә, политехник белемнәргә нигезләнеп төзелә. Химия, физика, биология, математика дәресләрендә укучылар нинди фәнгә караган законнарның техникада, технологик процессларда, агрономиядә куллануы белән танышалар. Производствога өйрәтү дәресләрендә исә турыдан-туры җитештерүчән хезмәттә файдаланыла торган практик белем һәм күнекмәләр үзләштерәләр. Теге яки бу техник җайланманың (машина, агрегат, аппарат,

приборлар һәм детальләрнең) төзелешен физика, химия, математика теле белән аңлату политехник белем бирү таләпләрен тормышка ашыруның төп ысулы инде ул.

Укучыларда эшче һөнәре, производствода эшләүнең гомуми алымнарын үзләштерү һәм профессия сайлау өчен кирәкле политехник күнекмәләр тәрбияләү политехнизм принцибын гамәлгә ашыруда мөһим шарт булып тора. Бу принцип укучыларның техник фикерләвен үстерүгә хезмәт итә. Әмма моның өчен проблемалылык принцибыннан да файдаланырга кирәк. Мәсәлән, беренче чиратта, техника, технология, экономика турындагы белемнәрне әзер килеш бәян итү белән мавыкмаска, ә укучылар алдына проблемалы сораулар куярга, үз белемнәренә һәм тормыш тәҗрибәсенә таянып, шуларга җавап таптырырга кирәк. Дәрескә мастерларны, производство алдынгыларын чакыру, алардан фән һәм производствоның үзара бәйләнеше турындагы конкрет мисаллар китереп сөйләтү дә бик әһәмиятле.

Дәрестә **компьютерлардан** файдалану да укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле оештыру, укытуны индивидуальләштерү өчен зур мөмкинлекләр ача. Хәзер бу өлкәдә җитди тикшеренү эшләре алып барыла, билгеле бер тәҗрибә туплана.

Укучыларның танып-белү мөстәкыйльлегенә һәм эзлекле рәвештә үз белемен күтәрүенә ирешү өчен, дәреслекләр, политик һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләү зур әһәмияткә ия. Хәзерге дәрестә моның яңалыгы нәрсәдә соң? Беренчедән, укучыларның 70-80 %ы текстны тирәнтен аңлап укымый, шуңа күрә аларны текстка **логик анализ** ясарга һәм аны аңлап укырга өйрәтергә кирәк. Икенчедән, укучыларны интенсив (тизләнешле; сүзләп түгел, ә төшенчәләп) укырга, текстны иҗади үзләштерергә һәм шуңа карап фикер йөртә белергә өйрәтү таләп ителә. Һәр фәннән теләсә нинди дәрестә укучыларга текстның логик структурасын аңлату, аларны текстка

логик анализ ясарга (субъект һәм предикатларны, алар арасындагы бәйләнешләрне аерып күрсәтергә) өйрәтү — яшь буында акыл хезмәте культурасы тәрбияләүнең, әдәбият белән мөстәкыйль эшләргә өйрәтүнең мөһим шарты. Текстка логик анализ ясау исә — аны аңлап үзләштерүнең нигезе ул.

Ләкин текстны аңлап үзләштерү — аның мәгънәви өлешләрен аерып күрсәтү генә түгел, ә барыннан да бигрәк тексттагы мәгънәви кыенлыкларны — проблемалы ситуацияләрне чишү, хәл итү дигән сүз (карагыз: Л.П.Доблаев. Психологические основы работы с книгой. М., 1970). Фәнни-педагогик әдәбиятта тексттагы проблемалы ситуацияләрдән котылу алымнары шактый тулы яктыртылган (мәсәлән, үз-үзеңә сораулар кую һәм аларга җавап эзләү; элек укыган текстка яңа фикер тәэсирендә кабат әйләнеп кайту һ.б.), укытучы укучыларны шулар белән таныштырырга тиеш (карагыз: М.И.Мәхмүтов. Мәктәптә проблемалы укытуны оештыру. К., 1980).

Интенсив (тизләнешле) уку гади рәвештә тиз укудан нык аерыла: гадәти тиз укый торган кеше бер минутта 150-200 сүзне, ә тизләнешле укыганда 800-1000 сүзне «күздән үткәрә». Хәзер әдәбиятның нык артуы гына түгел, укыту эшендә компьютерлардан файдалану да «тизләнешле» укуны таләп итә, чөнки дисплей экраннарындагы текстларны сүзләп түгел, ә символлар һәм төшенчәләр буенча укырга, истә калдырырга кирәк була. Укуның бу методын үзләштерү өчен, һәр фәннән барлык дәресләрдә диярлек эзлекле рәвештә махсус шөгыльләнергә кирәк.

Хәзерге дәрестә күрсәтмә әсбаплар һәм техник чаралар куллану функциясе дә элеккечә түгел. Хикмәт шунда: элек алар, нигездә, теоретик положениеләргә иллюстрация булып тора иде, хәзер исә, гадәттә, яңа мәгълүмат чыганагы итеп файдаланыла. Аның методологик нигезе шуннан гыйбарәт: укучыларның фикер йөртүен

үстерүгә, проблемалы укытуга игътибарның нык артуы укыту процессында дедукциянең өлешен һәм балаларның логик зиһенгә алуын, укытучы сөйләменең әһәмиятен көчәйтү (проблемалы бәян итү, диалог, текстка логик анализ ясау һ.б.) зарурлыгын китереп чыгарды. Мондый шартларда хиссиятле һәм рациональ зиһенгә алу нисбәте үзгәрә. Шунлыктан күрсәтмәле-образлы зиһенгә алуны интенсивлаштыру, активлаштыру бурычы алга чыкты. Гомумән, проблемалы укыту теориясе күрсәтмә әсбапларны проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү чарасы сыйфатында файдаланырга, дәрестә динамик (хәрәкәтчел, үзгәрә торган) һәм рациональ (схематик) күрсәтмә әсбапларның ролен арттырырга тәкъдим итә. Моны тормышка ашыруда техник чаралар куллану аеруча әһәмиятле.

Дәресне интенсивлаштыруда аның методик структурасының төрле-төрле булуы һәм укытуда демократик стильдә эш итү, ягъни укытучы һәм укучылар арасында үзара ышанычка, ихтирамга нигезләнгән әйбәт мөнәсәбәтләр урнаштыру, билгеләрне балаларның белеменә генә карап кую (җәза бирү өчен түгел), дәрестә әдәп-әхлак саклап, ачы күңеллелек тудырып, яхшы эмоциональ фон булдыру гаять зур роль уйный. Әнә шул рәвештә, педагогика һәм психология фәне казанышларын, алдынгы укытучыларның тәҗрибәсен үз эшеңдә иҗади файдаланганда, дәреснең нәтиҗәлелегенә ирешергә мөмкин.

1.2. Укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү теориясенә карата

Мәктәп реформасының Төп юнәлешләрендә гомуми белем мәктәпләре укучыларын җитештерүчән хезмәткә тарту, һөнәргә өйрәтү, бердәм гомуми белем бирү, укыту процессында актив форма

һәм методларны, хисаплау техникасы, компьютерларны киңрәк куллану бурычы куела.

Шулай итеп, безнең алга фән-техника прогрессы шартларында, һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү белән бергә, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү теориясен үстерү зарурлыгы килеп баса. Әмма шәхес үсешенең, аңарда дөньяга фәнни караш булдыруның нигезен акыл үсешен арттыра һәм тәрбия бирә торган укыту тәшкил итә. Шулай булгач, укыту процессында тулы, бербөтен белем бирү системасы гамәлгә ашырылырга тиеш. Ләкин, укучыларның гомуми белем структурасына анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, аларның аңында, кагыйдә буларак, бербөтен белем системасы хасил булып бетми.

СССР Педагогия фәннәре академиясенең профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институты галимнәре бу өлкәдә тикшеренү эшләре алып бардылар. Тикшеренү нәтиҗәләре профтехучилищеда уку дәверендә кайбер яшьләрдә дөньяга фәнни караш тиешенчә хасил булмавын, аларда гадәти аң дәрәҗәсе генә (тар карашлылык) тәрбияләнүен ачыкларга ярдәм итте. Табигать һәм җәмгыять законнары турындагы белемнәрне бәйләнешсез, аерым мораль-этик кагыйдәләрне өстән-өстән генә үзләштерүләре балаларның дөрес юнәлеш алуларына, профессия сайлауларына комачаулый.

Безнең институт галимнәре күп кенә укучыларның акыл үсеше белән белем алу омтылышы дәрәҗәсендә зур аерма булуын ачыкладылар. Югарыда күрсәтелгән сфераларның берсендә генә психологик үсеш тиешенчә булмаса да, мондый хәл «гармониясезлек»кә һәм уку эшенең кирәгеннән артык күбәюенә китерә. Мәсәлән, VII класс укучыларның шактыенда акыл эшчәнлеге һәм хәтерләүнең механик төрләре өстенлек итә, аларда уку эше күнекмәләре җитәрлек түгел. Өлкән класс укучыларында исә акыл сферасы көчлерәк үсә, ә белем алу ихтыяҗы һәм хисләр

дөньясы, шәхес булып үсү процессы акрынрак бара. Бу исә шәхеснең хезмәткә дөрес мөнәсәбәттә булмавыннан килә.

Югарыда күрсәтелгән кимчелекләрнең төп сәбәбе нәрсәдә соң?

Беренче чиратта, фән нигезләрен укытканда бербөтенлек булмавын төп сәбәп итеп санарга кирәктер. Бу система күренешләрнең кайбер үзлекләрен (физик, химик һ.б.) генә чагылдыра, ә дөнья табигать һәм җәмгыять турында тулы белем бирми. Мәсәлән, марксистик философия кешене биосоциаль зат дип караса да, мәктәптә бары тик кеше анатомиясе һәм физиологиясе генә өйрәнелә. Күптөрле фән укыту системасының кимчелекләре педагогикага күптән билгеле. Моннан 300 ел элек Я.А.Коменский укучыларда дөньяга караш хасил итүдәге кыенлыкларны әйткән. Предметара бәйләнеш урнаштыру идеясы дә әнә шул вакытта ук күтәрелгән. Педагогика тарихында аның берничә «актив» үсеш чоры булган. Совет педагоглары соңгы 10 елда бу проблеманы өйрәнүгә бик күп көч куйдылар. 80 нче елларда предметара бәйләнешне укыту программаларына да керттеләр. Ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә, ул укучыларда бербөтен белем системасы хасил итүдә хәлиткеч шарт булып әверелмәде.

Укыту программаларының артык тыгыз, дәреслекләрнең һаман да камилләшеп җитмәве һәм укучыларның күбесенчә белем алу теләгенең кискен рәвештә кими баруы — балаларның гомуми белемендә системалылык булмавының икенче сәбәбе.

Кирәгеннән артык эш йөкләү укучыларның сәламәтлегенә зур зыян китерә, аларның буш вакыты бөтенләй калмый. (IX–X класслардагы тырышып укучыларның атнага 60 сәгать вакыты уку хезмәтенә сарыф ителә.) Укыту программалары артык катлаулы, дәреслекләрнең һәм укыту процессының сыйфаты түбән булуы — моның төп сәбәбе.

Профтехучилище укучыларына аеруча күп эш йөкләнә. Монда һәр дәрестә фән нигезләреннән уртача 3,2 яңа төшенчә бирелә (гомуми белем бирү мәктәбендә һәр дәрестә — уртача 2,8 төшенчә); IX–X классларда — 10 фән, ә ПТУда 20 фән өйрәнелә. Училищеда укучыларның күбесенә мәктәптә сигез ел уку дәверендә төпле белем бирелмәве, аларның танып–белү күнекмәләре дә аз булуы ачыкланды. Мондый укучылар ПТУда IX–X класслар программасын үзләштерә алмыйлар. Шуңа күрә укыту материалын киметергә кирәк. Әмма физика, математика, химиядән һ.б. фәннәрдән укыту материалларын киметү гомуми урта белем дәрәҗәсен төшерүе ихтимал, бу исә югары белем алуны, укучы шәхесенең һәрьяклап үсешен тәэмин итмәскә мөмкин. Шулай итеп, дәреслекләрдәге һәм программалардагы кайбер темаларны кыскарту кирәклеге белән укытуның фәнни–теоретик дәрәҗәсен күтәрү зарурлыгы арасында каршылык барлыкка килә.

Димәк, урта мәктәпләрдә һәм профтехучилищеларда фән нигезләрен күппредметлы итеп укытуның традицион системасын үзгәртү турында сүз алып барырга тиешбез. Шәхесне һәм аңарда дөньяга фәнни караш тәрбияләү иң кимендә ике шарт булуын:

а) белем бирү эчтәлеге структурасының «суммативе» (төрле фән белемнәрен арифметик кушу) белемне түгел, ә бәлки бербөтен белем системасын;

б) бербөтен белем системасының укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын истә тотып гамәлгә ашыруны таләп итә.

Хәзерге вакытта мәктәптә укытыла торган гуманитар фәннәр техник һәм технологик белемнәрдән аерып бирелә. Политехник белемнәр минимумы гына бу бушлыкны тутыра алмый.

Укучыларга техник белемнәр профессиональ мәктәптә аерым фәннәрне (гомум техник фәннәрне — электроника, материалларның

үзенчәлекләрен өйрәнү, машина төзелеше материаллары һәм технологиясе), шулай ук махсус технологияне (токарь, слесарь эшен һ.б.ш.) өйрәнгәндә һәм җитештерүчән хезмәт процессында җиткерелә. Боларның берсе дә гомуми урта белем бирү мәктәбенең укыту планына кертелмәгән. 1958—1964 елларда урта мәктәпкә җитештерүчән хезмәт кертүне исәпкә алмаганда, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибы ярты гасыр буена гамәлгә ашырылмады.

Табигать турындагы, шулай ук техник һәм гуманитар фәннәрнең үзара тыгыз бәйләнеше җитештерүчән хезмәттә, практикада аеруча ачык чагыла. Хезмәт коллективында исә укучыларның дөрес аралашу һәм әхлакый, гуманистик, производство мөнәсәбәтләре күнекмәләре камилләшә, монда шәхеснең социальләшү процессы тулысынча гамәлгә ашырыла. Шуңа күрә нәкъ менә җитештерүчән хезмәт (анда укыту һәм тәрбия бирү бердәмлеге гамәлгә ашырыла) бербөтен белем системасын барлыкка китерүче фактор булып тора. Индустриаль төрдәге җитештерүчән хезмәт объектив фикер йөртү нигезендә без өч төрле белемнең (табигать турындагы белем, техник һәм гуманитар белем), кешенең танып-белү һәм практик күнекмәләрен, иҗтимагый һәм эмоциональ мөнәсәбәтләренең үзара табигый бәйләнешен күрәбез.

Бербөтен белемле шәхес тәрбияләү проблемасы берничә төрле юл белән хәл ителә. Шуларның беренчесе — предметара бәйләнешне тагын да көчәйтү, икенчесе — хәзерге белем бирү эчтәлеге структурасы нигезендә укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү. Өченчесе профессиональ мәктәп бурычларына һәм максатына нигезләнә. Ул, гомуми һәм профессиональ-техник белем бирүнең үзара бәйләнеше нигезендә, яңа фәннәр (предметлар) системасы булдыруны күздә тота. Без моны ике төрле мәктәпне

якынайтуда да һәм аларны киләчәктә берләштерүдә дә иң кулай юл белән дип саныйбыз.

Ә хәзер укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибына кыскача тукталып үтик.

Билгеле булганча, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү идеясе капитализмның башлангыч чорында ук утопик социализм вәкилләре Томас Мор һәм Томазо Кампанелла хезмәтләрендә чагылыш тапкан. Әлеге идея бөек социалист-утопистлар Шарль Фурье һәм Роберт Оуен хезмәтләрендә тагын да үстерелгән.

К.Маркс һәм Ф.Энгельс укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү мәсьәләсенә элегрәк булган фикерләргә тәнкыйть күзлегеннән чыгып якын килгәннәр. Алар акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы аерманы бетерү, шулай ук тәрбия эшендә теория һәм практиканың бердәмлегенә ирешү, акыл хезмәте белән физик хезмәтне, теоретик һәм практик занятиеләрне аралаштырып алып бару турындагы фикерләргә югары бәя биргәннәр. Шуның белән бергә, марксизмга нигез салучылар иҗтимагый үсешнең яңа чорына туры килә торган элекке таләпләрне конкретлаштырып, утопик, реаль булмаган арттырып җибәрүләрдән һәм фантастик уйдырмалардан, шулай ук коммунизмны тәфсилләп аңлату кебек башка күрәзәчеләрдән ваз кичү юнәлешендә күп кенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткәннәр, ягъни социализмны, беренче мәртәбә буларак, утопиядән фән дәрәҗәсенә күтәргәннәр. Бу уңайдан иң әһәмиятлесе шул: К.Маркс һәм Ф.Энгельс пролетар революция җиңүен тулысынча гамәлгә ашыру турында уйлаучы пролетариатның иң мөһим социаль-экономик һәм политик таләбе буларак, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын алга куйганнар. Капиталистик производствоның машиналы фабрика системасы шартларында К.Маркс һәм Ф.Энгельс балаларны 9 яшьтән хезмәткә тартуны таләп иткәндә, барыннан да бигрәк кул

хезмәтен түгел, ә бәлки индустриаль хезмәтне күздә тотканнар. Алар капитализм шартларында ук, берьяклы гына үсешне кисәтү, берничә төрле хезмәтне башкару сәләтенә ия булуга ирешү өчен, барлык кешеләрне дә һәрьяклап үстерергә кирәк дигән фикердә торганнар. К.Маркс һәм Ф.Энгельс укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын җитештерү ысулына, ягъни җитештерү көчләренә һәм җитештерү мөнәсәбәтләренә тамырдан үзгәреш ясарлык чара итеп караганнар. Шулай итеп, белем бирүне хезмәт белән бәйләү өчен машинага, шулай ук ят иҗтимагый көчләргә һәм шартларга буйсынудан азат итеп, аны шул машиналар, шул көчләр, шартлар белән идарә итүчегә әйләндерә. К.Маркс һәм Ф.Энгельс укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләүне социализм өчен көрәш идеясе белән бергә бәйләп караганнар, аннары аны аеруча мөһим гомум-педагогик принцип иткәннәр. Чөнки укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләгәндә генә, коммунистик җәмгыятьнең һәрьяктан камил кешеләрен әзерләү өчен нигез булдырырга мөмкин.

XVIII гасырда яңа фән — технология барлыкка килә. Ул, куллану әйберләре җитештерү өчен, төрле материалларны эшкәртү һәм кабат эшкәртү ысулыннан файдалануны фәнни нигезли. К.Маркс әйткәнчә, политехник белем табигать фәннәренә һәм техникага өйрәтүне күздә тотарга тиеш (карагыз: К.Маркс, Ф.Энгельс. Сочинения, 2 нче басма, 23 т., 449 бит). Мондый укыту җитештерү процессларының төп принциплары белән таныштыра һәм бер үк вакытта балага яки яшүсмергә иң гади хезмәт кораллары белән эшләү күнекмәләре бирә.

В.И.Ленин укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү, шулай ук политехник белем бирү турындагы марксистик принципны тагын да үстерә, конкретлаштыра. В.И.Ленин «Народникларның прожектерлык үрнәкләре» дигән мәкаләсендә: «...укытуны яшь

буынның җитештерү хезмәте белән кушудан башка, киләчәк җәмгыять идеалын күз алдына китерергә мөмкин түгел: җитештерү хезмәтеннән башка укыту-өйрәтү һәм белем бирү дә, параллель рәвештә укыту-өйрәтүдән һәм белем бирүдән башка җитештерү хезмәте дә техниканың хәзерге дәрәҗәсе һәм фәнни белемнең торышы таләп иткән югарылыкка куела алмас иде», — дип, укытуны җитештерүчән хезмәт белән кушуның әһәмиятен аңлатты (В.И.Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 2 нче том, 463 бит).

К.Маркс, Ф.Энгельс һәм В.И.Ленин политехник белем кешене хезмәт процессын рациональләштерергә сәләтле итүен, аның берьяклы, тар социальләшүдән коткаруын, хезмәт характерын үзгәртүен һәм хезмәтнең тормыш ихтыяҗына әверелүенә булышуын күрсәттеләр.

Хәзер производствоның технологик процесслары җитди үзгәрешләр кичерә — магнит, нур, радиация технологиясе кертелә, технологик процесслар компьютерлаштырыла. Табигать турындагы фән төшенчәләренә нигезләнеп һәм күренешләрнең эчке механизмына үтеп кереп, инженерлар һәм галимнәр технологик процессларның яңа параметрларын эзлиләр.

Шуңа күрә, социаль-экономик, социаль-психологик факторларны һәм хезмәтне фәнни оештыру, идарә итү (үзидарә) принципларын, шулай ук социаль-экология, эргономика һәм дизайн таләпләрен искә алып, укытуның, җитештерүчән хезмәтнең эчтәлеге, аларның структурасы һәм методикасы җентекләнеп анализланырга тиеш.

Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирүне оештыруда гомуми һәм махсус әзерлекне бер-беренә бәйләү дәрәҗәсе турындагы мәсьәлә дә гаять зур әһәмияткә ия. Монда педагогика фәне өйрәнергә тиешле гомуми, шулай ук вакытлы һәм башка конкрет шартларга бәйле аспектлар да бар. Ләкин хезмәт —тәрбия чарасы буларак, нейтраль

процесс. Шуңа күрә җитештерүчән хезмәтне, политехник һәм профессиональ укытуны, әхлак тәрбиясе бирүне үзара бәйләп алып бару мәсьәләсенә тагын да зуррак әһәмият бирергә кирәк. Чөнки хезмәткә бәя бирү өчен, эштә уңышка ирешү мөмкинлеген белү зарури.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: мәктәпнең һәм производствоның тәрбия эшендә уңышка ирешүе өчен, укучыларны тәрбияләүгә, хезмәткә әзерләүгә комплексы якын килергә кирәк.

1.3. Һөнәр — ил канаты

1) Һөнәрилек

Болгавыр заман уй-фикерләребезгә, аңыбызга үзгәрешләр кертте: барчасы акча хакында сөйлиләр, *хезмәтнең сыйфаты* турында гына түгел, үзе турындагы сүзләр дә онытылды. Мөгаен, гадәтсезлеге белән адәм баласын шаккатырган бу дәвер үтәр әле. Тик җәмгыятькә генә чиксез күп төзелмәс яралар ясалыр, намуслы һәм тыйнак, «якты киләчәк» кә ышанган миллионнарча кешеләрнең язмышлары гына бозылыр. Җитештерү һәм товар ясап чыгару да яңадан җайга салыныр, кешеләр бәйгесе һәм товарлар көндәшлеге, бөлү һәм уңышка ирешү аша юньлерәк тормыш та килер. Әлегә моның кайчан буласын гына әйтүе кыен...

Үсеш принциплары арасында *кирәкле* һәм *җитәрлек* шартлар бар. Татар халкының тәрәккыятенә иң зарури шартлар нәрсәдән гыйбарәт соң?

Кешелек дөньясы туплаган тәжрибә күрсәткәнчә, бихисап казылма байлыклары (нефть, руда, күмер һ.б.) булган милләт тә бары тик үз хезмәте хисабына гына исән кала һәм тәрәккыят итә. Ләкин «абстракт» хезмәт кенә җитәрлек түгел, җитештерүчәнлекне арттыру өчен төп шартлар да — хезмәтне, конкрет эшне яхшы

оештыра алу, теләсә кайсы өлкәдә эшләүченең хезмәте максатлы булу, аны башкарырга теләк, мотив булу мөһим...

Җитештерүдә һәм кеше эшчәнлегенең аңа бәйле өлкәләрендә элек күз алдына да китермәгән үзгәрешләр бара һәм аларның дөньякүләм тенденцияләре бар. Бүген инде теориядә генә түгел, гамәлдә дә хезмәтнең интеллектуальләшүе, җитештерүнең мәгълүматлашуы, роботлашуы һәм компьютерлашуы бик ачык күзәтелә. Алар, кирәкле һәм җитәрлек шартлар буларак, бүгенге социаль–икътисади тәрәккыят нигезе булып торалар. Электроника әле кичә генә фән булса, бүген инде алга киткән илләрдә төп җитештерү чараларының берсенә әверелеп бара: һәр гаиләнең өендә телевизор, суыткыч, микродулкынлы мич, видео һ.б.ш. күренеп тора.

Чит илләрдә, мисал өчен, технологик эрага кереп баручы Япониядә, «караңгы», ягъни утсыз, яктыртылмаган цехлар һәм заводлар бар. Алар продукцияне кеше катнашыннан башка гына чыгаралар! Мәсәлән, телевизорларны автоматлар, роботлар ясый. Кеше цехка үзеннән сизгеррәк булган һәм детальләрне төгәлрәк эшкәртә алган автоматларның эшен тикшерү өчен генә керә. Анда «агымга» салынып эшләнгән товар күбрәк һәм арзанрак кына түгел, югары сыйфатлы да, дөнья базарында өстен дә булырлык. Ә бу — милләтнең яшәү һәм алга китү шартларының иң мөһиме.

Табигый ки, мондый җитештерүгә тирән белемле кешеләр генә хезмәт күрсәтә. Бу очракта профессия төрләре үзгәрәме соң? Әлбәттә, чөнки анда төп һөнәр — көйләүче, кул хезмәте күп кулланылган безнең предприятиеләрдәге кебек токарь һәм слесарь түгел. Алга киткән илләрдә кайсы инженер һөнәрләре киңрәк таралган соң? Проектчы, электрончы, диагнозчы, программачы һ.б., ягъни күбесенчә яңа технология, ноу–һау (беләм-ничек дигән сүз) белән эш итүчеләр.

Һөнәрләр структурасы үзгәрәме? Әйе, галимнәр әледән-әле яңа технологияләр уйлап табалар һәм гамәлгә кертәләр. Фәнни җитештерү зуррак урын ала барган саен, һөнәрләр исемлеге дә тизрәк үзгәрә. Мәсәлән, алга киткән илләрдә өстенлек иткән, технологик яктан яхшы җиһазланган машина төзү тармагын 60–70 нче елларда ук инде гади токарь, слесарь яки фрезерчы кебек тар профильле эшче канәгатьләндерми башлады. Җитештерү автоматлаша, роботлаша барган саен, оста һәм киң профильле эшчеләр — күп төрле кыру, фрезерлау, револьвер станокларында эшли торган токарь-универсал, электр һәм ацетилен белән, төрткеләп эретеп ябыштыручылар (сварщиклар) күбрәк кирәк була башлады. Конвейерларны, автомат станокларны һ.б. көйләүче киң профильле слесарьларга да ихтыяҗ бик тиз артты. Хәзер инде җитештерү өчен гади техник кына ярамый, оста эшчене алыштырырлык техник кирәк. Шуңа күрә дә санлы программа белән идарә ителгән станоклар янына — эш урыннарына — эшчеләр түгел, күбрәк техниклар, хәтта инженерлар баса. Хезмәтнең интеллектуальләшүе тизләнә... Монысы безнең Казан һәм Чаллы заводларында да күренә башлады иде.

Бүген югары җитештерүчәнлекне һәм көндәш булырлык товарларны гади эшче, гади техник, гади инженер түгел, югары дәрәҗәдәге *һөнәр иясе* (профессионал) гына бирә ала... Димәк, кадрларны әзерләгәндә *һөнәрне дөрес сайлау, махсуслашу* (специальләшү) төп мәсьәлә булып тора... Демократлашу шартларында идарә итү мәсьәләләре дә һәр кимәлдә (дәүләт белән идарә итүдән алып, эшче яки хезмәткәрләрнең кечкенә төркемнәре белән идарә итүгә кадәр) күпкә катлаулана.

Хәзерге техника һәм технологиянең бүгенге уку йортлары белгечләр әзерләгәнгә караганда тизрәк үзгәрүе, инженер-техник фикернең инженер алган белемнән узып китүе шартларында

хезмәткәрләрнең *функциональ белемсезлеге* күзәтелә. Белем — корал ул. Халык әйтмешли, «корал кемнеке — заман шунысы». Димәк өзлексез белем бирү системасын төзергә, һөнәри белем бирүне тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Ул массакүләм һәм һәр кеше өчен өзлексез булырга тиеш. Хәзер педагогикада «өйрәнүчәнлек» (обучаемость) төшенчәсе бар. Шәхесләренең төп сыйфаты — *өйрәнүгә сәләт* булган милләт кенә алга чыга алачак. Шуның өчен, шәхеснең фикерләү сәләтен үстерү белән бергә, аның ошбу сәләтен дә тәрбияләргә кирәк.

Бу очракта яшьләрне хезмәткә ничек әзерләргә? Аларны кайсы һөнәрләргә җәлеп итәргә? Токарь яки инженергамы? Сәүдәгәр, коммерсант яки электрончы, системачыгамы?.. Нидә булса эшләү һәм башкарудан тыш, төрлечә тәрбияләнгән кешеләр белән аралашуны, тиз элемтә урнаштыра белүне, әдәпле, инсафлы, шәфкатьле булуны таләп иткән, гел киңәя барган хезмәт күрсәтү өлкәсендә ни эшләргә?

Бәлки без илебездәге хәл-әхвәлне исәпкә алмыйбыздыр? Әле аны гына түгел, бөтендөнья үсү тенденциясен дә исәпкә алу зарури. Без җәмгыять үзгәрүнең гомуми тенденциясенә дә бәйле. Марксизм тәгълиматы киләчәкне иң күп санлы һәм оешкан эшчеләр сыйныфы белән бәйләп, XIX гасыр азагында һәм XX гасырның өч чирегендә булган хәлне генә чагылдыра алды. Ә безнең гасыр азагында алга киткән илләрнең ижтимагый структурасы үзгәрде. Мәсәлән, XX гасыр башында АКШның авыл хуҗалыгында кешеләрнең 87% эшләсә, хәзер 5% кына. Гасыр урталарында сәнәгатьтә 70% эшләсә, хәзер 15%тан кимрәк. Кул хезмәте кими барганлыктан, белемнең роле арта. XXI гасыр башында 75% халык тәгълимгә (укуга, өйрәнүгә) тартылачак (World almanac, 1996, USA). Шундый тенденция Россиядә дә күзәтелә. Димәк, тимер, нефть, күмер түгел

— интеллект (гакыл, ягъни акыл байлыгы, фикерләү сәләте) һәм технология якын киләчәктә иң зур капитал булачак.

Бүген җәмгыять һәм дәүләт эшмәкәрләрчә булдыклы, кыю, иҗади фикерләүче кешеләргә мохтаҗ. Аларны балачактан, мәктәптә үк тәрбияли башларга кирәк. Бу эш Япониядә, АКШта һәм алга киткән башка илләрдә күптән эшләнә инде. Безгә гади җитәкчеләр, элеккечә оештыручылар түгел, кешеләрнең мәнфәгатен аңлап, аларның күңелен күрә белүче заманча мәнәҗерләр (менеджерлар) кирәк. Димәк, хәзерге җәмгыятьне «татар халкын рухи тергезү» кебек гомуми лозунглар түгел, иртәгәге җитештерүнең мәгълүматы-технологиясенә, кешеләр белән әдәпле-тәртипле аралашу гадәтенә туры килә торган, шәхеснең рухи һәм акыл сыйфатларын үстерүне күздә тоткан программа кызыксындыра.

Татар милләтенең иртәгә буласы язмышы турында сөйләгәндә, аның үсү перспективасы югарыда әйтелгән хезмәт шартлары белән тыгыз бәйләнгән. Шуннан чыгып, Татарстанда шәхеснең нинди сыйфатлары, тәгълимне үстерүнең кайсы юнәлешләре өстен икәнен билгели алабыз.

2) Әйдә, татарча укытыйк

Бәйсезлек өчен көрәш юлына баскач, без аңа ирешү, аны үстерү өчен иҗтимагый-сәяси шартлар да тудырырга итеш. Иң мөһим шартларның берсе — татарча һөнәри белем бирү. Тел үсү законнары татар теленең һәрбер хезмәт өлкәсендә уңышлы эшләвен, барлык һөнәр кешеләренең анда сөйләшүен, фикер алышуын, татарча лекцияләр уку һәм тыңлау, кинофильм һәм телетапшырулар карау кирәклеген һ.б. таләп итә.

Җәмгыять үсүне исәпкә алганда, заманча белемле милли кадрларны Татарстанда әзерләү өчен шартлар бармы? Беренче карашка — бар. Республикада гомуми һәм һөнәри белем бирү системасы бар. Планлы икътисад һәм тоталитар режим

шартларында ул, У.Черчилль әйтмешли, «чабаталы Россияне атом кораллы итте» һәм үзен аклады. Татар телендә ярыйсы гына урта белем бирә торган мәктәбебез бар... Тик бу системаны үзгәртү, аны югарыда аталган демократик юнәлешкә, тәрәккыять шартларына, базар икътисадына һәм кешеләр арасындагы күркәм мөгамәләгә җайлаштыру таләп ителә. Кешене һөнәрле итәрлек мөһим шартларның берсе булуга карамастан, әлегә бу мәсьәләне читтә калдырып торыйк.

Бу мәкаләдә башка — татар телендә иртәгәсе көн һөнәриләрен әзерләү мөмкинме? дигән мәсьәлә карала. Теоретик яктан, әйе, мөмкин. Ә гамәлдә ничек соң? Мәгълүм булганча, һөнәри белемнең өч кимәле бар: *башлангыч* (эшче, кече хезмәткәр); *урта* (җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүдә катнашучы барлык урта һөнәр ияләре); *югары* (бакалавр һәм белгеч). Татар теле дәүләт теле булуга карамастан, хәзерге вакытта Татарстанда, берничә (7%) авыл хуҗалыгы һөнәр училищеларында кайбер фәннәрне укытудан башка, татарча һөнәри тәгълим (уку-укыту, мәгариф) юк.

Нигә юк икән? Чөнки элек-электән булмаган, оешмаган. Татарларның милли мәгарифе, кайбер мәдрәсәләрдә приказчик һәм хисапчылар әзерләүне исәпкә алмаганда, гомуми белем генә биргән. Игенче һөнәре гаиләдә, хезмәт шартларында үзләштерелгән. XX гасыр дәвамында Россиядә барлык рус булмаган балалар өчен һөнәри белем русча гына бирелде. Ә бүгенге мөмкинлекләр нинди? Алар берничә проблемага бәйләнгән. Мәсәлән, татар теле индустрия шартларында элек бер дә кулланылмады. Аның функциясен, ягъни куллану өлкәсен киңәйтүгә икътисади ихтыяҗ бармы? Халыкта мондый тәгълимгә омтылыш сизеләме? Матди-техник шартлар һәм кадрлар бармы? һ.б.

«Мөмкинме?» дигән сорауга җавап — укытучы кулында. Бүген, татар мәктәпләре челтәре киңәю сәбәпле, гомуми белем бирүче

мәктәпләрдә дә татар теле укытучылары җитешми. Һөнәри белем бирү өчен татарча укыта алган укытучылар — инженерлар, химиклар, агрономнар, технологлар, медиклар, электрончылар, программачылар, экономистлар, мәнеҗерләр һ.б. кирәк. Бу эшчәнлек өчен әзерлекле, техник, экономик, юридик, технологик фәннәрне сыйфатлы итеп укытучылар юк дисәк дөрес булыр. Мәсәлән, заманча мәнеҗерләр әзерләүгә илдә зур ихтыяҗ туды. Ләкин аларны вузларда һәм техникумнарда русча укытырлык кешеләр дә юк. Дөнья экономикасы фәнен рус телендәгечә үк татарча да укыта алган белгечләр кайчан булырлар? Мондый сорауга әлегә җавап юк. Ун ел үткәч дигән сүзләр ишетелә. Укытучыларны бүген үк әзерли башларга кирәк диләр. Дөрес, кирәк. Ләкин кайда, ничек, кемнән? Алар киләчәктә кирәк булырлармы, шул турыда кемнәр уйлана икән?

Безнең җәмгыять демократиянең кайбер сыйфатларын үзләштерә бару нәтиҗәсендә татарча укуга күп дистә мең татар балаларын, хәтта бераз рус балаларын да тарту мөмкин булды. Әмма, милли хәрәкәт дулкыннары кими барган саен, татар теле белән кызыксыну русларда гына түгел, татарлар арасында да сүнә бара. Кайбер ата-ана үз баласын рус мәктәбенә күчерә башлады һәм моны татар мәктәбендә начаррак укыту белән аңлата (монысы да бар). Шулай булгач, безнең энтузиазмның кая хәтле алып барасын фараз итми булмый. Аерым кешеләр уйлап чыгарган, татар теленең базар мөнәсәбәтләрендә булачак роле турындагы кайбер утопик фикерләр нигезендә үзгәрешләр кертергә маташу — кеше язмышы белән уйнау булып чыкмас микән?

1997 елны Республикада гомуми белем мәктәпләре өчен меңнән артык татар теле укытучылары җитмәвен исәпкә алсак, һөнәри белемне татар теленә күчерүнең никадәр катлаулы булуын аңларга мөмкин. Әлбәттә, педагогик университетта, архитектура-төзелеш,

мәдәният һәм сәнгать академияләрендә татарча укыту буенча бераз тәҗрибә тупланган, энтузиаст галимнәр тарафыннан программалар эшләнгән һәм кайбер дәреслекләр язылган (хәтта «материаллар каршылыгы» буенча да бар). Сүз дә юк — ВУЗ мөгәллимнәренең тырышлыгы бушка китмәячәк, гәрчә тәҗрибәле аерым очраклар гына, системасыз һәм Казан өчен генә (ә татарның дүрттән өче Татарстаннан читтә яши) булса да.

Бу турыда бер-ике генә сүз әйтмичә булмый, чөнки галимнәр кыю теоретик фикерләр белән бергә зур тәҗрибә эшләре дә алып баралар. Мәсәлән, «Татар телендә югары белем бирү мәсьәләләре» (Казан, 1997) исемле фәнни-методик җыентыкта төрле-төрле мәкаләләр урнаштырылган. Авторлар үзләренең укыту тәҗрибәләре һәм шуның нигезендә «Сызма геометрия», «Теоретик механика» һ.б.ш. китаплар, дәреслекләр, кулланмалар бастырып чыгару турында язалар.

Милләт өчен янып йөрүчеләрнең берсе — Рәшит Шакир (Шакиржанов Р.Ә.) теоретик мәкаләсендә татар телен торгызу, үстерү һәм куллану кирәклеген исбатлый. Аны өйрәнү диалектик фикер йөртү мәктәбе ди, дөньяны дөрес танып белүгә, фәнне үстерү һәм җәмгыятьнең тәрәккыятенә ярдәм итәчәген күрсәтергә тырыша.

Р.Шакир, телгә лингвистик анализ ясап һәм рус теле белән чагыштырып, «философия фәненә таянып», татар телендә фикерләү һәм танып белү тәртибе үзгә дигән нәтиҗәгә килә. Мәсәлән, ул Г. Тукайның «чыктым аркылы күпер» җөмләсенә таянып, логик фикер йөртә. «Мин күпер аша чыктым» җөмләсендә алдан фикер, аннары гамәл булуын танып белү өчен зур өстенлек дип карый, чөнки рус телендә алдан гамәл, аннары фикер булу («я перешел через мост») диалектикага бик үк туры килми, имеш. Автор «...татарча фикерләү хәрәкәтне төрле яктан, ныклап, төгәлрәк өйрәнергә мөмкинлек бирә» дигән нәтиҗәгә килә.

Минемчә, монда формаль логика (мантыйк) авторны бераз саташтырган шикелле, чөнки хәбәрнең җөмлә азагында булуы гына берәүнең фикерләү сәләтен киметми дә, арттырмый да. Шул ук җөмләдә, мәсәлән, гарәп телендә дә хәбәр алда килә («зәхәбтү габра альжиср»); инглиз телендә дә шулай (I passed over the bridge). Телләрдә синтаксик яки морфологик аерма булу табигый, ләкин ул аларның сыйфатларын билгеләми. Теге яки бу телнең өстенлеген сүз байлыгы, синонимнар, терминнар күплеге һәм телнең функциональ активлыгы күрсәтә. Татарча укытабыз дигәндә дә «каш ясыйм дип, күз чыгарудан» сакланырга кирәк.

Татар телен үстерергә омтылучы энтузиастлар вузларда татар телендә һөнәри белем бирү кирәклегенә һәм мөһим булуына инанганнар, әлбәттә. Тик әле югарыда әйтелгәннәрдән башка сораулар да туа. Беренчесе: демократия, кешенең ихтыярын, теләген хөрмәт итеп, аңа сайлау мөмкинлеген бирү (һөнәрне, эш һәм яшәү урынын, телне һәм уку йортларын һ. б. ш.). Мондый шартта без татар яшьләрен ана телендә белем алырга мәҗбүр итә алабызмы? Икенчесе: шәкерт (студент) төркемнәрен милләткә карап тупларгамы һәм алар авылдагы татар мәктәпләрен бетерүчеләрдән генә тормасмы? Өченчесе: уку йортын тәмамлаучылар хезмәттәшләре белән аралашканда, документлар белән эшләгәндә, эш кагәзьләре, сызымнар, техника һәм технология, технологик карта һ.б. белән танышканда кайсы телдә аралашырлар? Дүртенче сорау: һөнәр иясе, татарча укыган белгеч эшне Татарстанда гына таба алганга, базар икътисады (һәм аның юлдашы — эшсезлек) шартларында без аның мөмкинлекләрен чикләмәбезме һәм кеше хокукын бозмабызмы икән? Мондый сорауларның күбрәк булуы да ихтимал.

Һәркемгә аңлашыла: кирәкле терминнар булса да, дәреслекләр һәм яхшы укытучылар җитсә дә, акыл хезмәте арту, фән күп

кулланылган җитештерү шартларында татар теле белән генә чикләнергә һич тә ярамый. Ярамый, чөнки татар телендә рус телендәге кебек (рус телендә инглиз телендәге кебек) бай фәнни һәм техник әдәбият беркайчан да булмаячак.

Ни өчен «инглиз телле булмаган» күп илләрдә чит телдә укытучы мәктәпләр ачыла? Яки шул ук Төркия меңләгән яшьләрен Европа илләренә, АКШка укырга җибәрә? Ни өчен үз телеңдә генә уку-укыту күпләрне канәгатьләндерми? Мәсәлән, АКШта гына да ел саен 350 меңнән артык читтән килгән студент укый. Әлбәттә, инглиз телендә. АКШның үзендә дә Латин Америкасыннан чыккан балаларны испан телендә укыта торган гомуми белем мәктәпләре оештырыла. Ләкин һөнәри тәгълим барысында да инглиз телендә бара.

Һичшиксез, тел өйрәнү өчен акча һәм вакыт бирелсә, безнең вуз студентлары инглиз телен рус теле белән бер үк дәрәҗәдә өйрәнә алырлар иде. Ләкин шартлар юк, уку йортларыбыз ярлы, техник чаралар җитәрлек түгел, студентларның телгә сәләте дә төрлечә.

Яшьләр өчен «тел мәйданы» дигән җитди сәбәп тә бар. XX гасыр азагында дөнья берлегендә икътисад һәм мәгълүмат хезмәттәшлеге, интеграция һәм миграция (күчеп йөрү) өчен яңа шартлар, мөмкинлекләр туды. Шуңа күрә «мәйдан», «фәза» (пространство) кебек социаль-икътисади төшенчәләр туды. Мәсәлән, «икътисади мәйдан» диләр. Соңгы ике дистә ел эчендә дөнья базарында «технология» дигән товар күренү белән, хезмәткәрләрне чит илдә укыту һәм яңа технологияләр үзләштерү ихтыяҗы туды. Дөнья базарында махсус товар — мәгълүмат та хасил булды. Шуның өчен күп илләр, мәсәлән гарәп дөньясы, Африка, Азия илләре яшьләрне үз телләрендә генә түгел, башка телләрдә дә эш алып барырга өйрәтәләр. Шулай иткәндә алар яңа технологияне җиңелрәк үзләштерәләр. 30 ел элек бик аз француз яки немец кешесе инглиз

телен белә иде. Бүген Париж яки Берлин урамнарында еш кына инглизчә сөйләшү ишетелә. Бөтен халыкара оешмалар, француз, кытай һ.б. телдә эш алып баралсалар да, инглиз телендә эшлиләр.

Шулай итеп, һөнәри белемнең халыкара (регионара) стандарты турында сүз бара. Ансыз кеше эш урынын сайлау хокукыннан мәхрүм була. Монысы инде демократия принципларына каршы килә.

3)Татарча терминнар турында

Татарча һөнәри тәгълим булмаганга, табигый һәм техник фәннәр өлкәләрендәге белем дөньясының татарча терминологиясе эшләмәгән, сыналган (тәжрибә аша тикшерелгән) программалар юк. Табигый ки, дәреслекләр дә юк.

Тел белгечләребез терминнар турында күп яздылар. Махсус комиссия дә төрле карарлар чыгармый калмады. Тик терминнар проблемасы бер генә көнлек эш түгел, аны тәртипкә салу өчен еллар кирәк.

Татарстанда яшәгән башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирелә башлады дип фараз итик. Моны башкару өчен беренче нәүбәттә кирәк булган шарт — телне белүче мөгаллимнәр һәм терминология бармы соң? Дөнья үзгәрү белән яңа терминнар да туып торалар. Рус телендә бик күп сәяси, икътисади, техник терминнар бүген дә чит телләрдән алыналар («согласие» урынына «консенсус», «секретно, скрытно» урынына «конфиденциально», «управление» урынына «менеджмент», «вычет» урынына «дисконт» һәм йөзләрчә башкалар).

Татар телендә сүз байлыгы шактый зур. Саф төрки сүзләрдән гайре, рус теле аша алынган чит тел сүзләре дә, иске татар теленә үз вакытында гарәп һәм фарсы телләреннән кергән меңләгән сүзләр дә кулланыла. Бу юлны тарих хуплаган инде, ләкин һәрнәрсәдә чама

булырга тиеш. Мәсәлән, бүген берәүләр «республика» сүзен, икенчеләре «җөмһүрият» сүзен куллану яклы.

Кайсы термин төгәлрәк — «икътисад»мы, «экономика»мы? Кайсы дөресрәк — «мөхәррир»ме, «редактор»мы? Ә бәлки икесе дә кирәктер? «Җиһан» һәм «дөнья» белән дә шул ук хәл. Мондый синонимнарны рәткә салырга, кайсы термин, ә кайсы киң мәгънәле сүз икәнен ачыкларга вакыт җитте түгелме соң?

Гуманитар фәннәр өлкәсендә (һәрберсеннән булмаса да) шактый үскән терминология бар кебек. Ул ни дәрәҗәдә эшләнгән һәм телне үстерү өчен яраклы? Мәсәлән, дәреслектә «королевство» дигән сүзе татар теленә ничек тәрҗемә ителә? «Короллек»ме? Ләкин бу гади алынма ич! Татар матбугатында мәмләкәт сүзен «дәүләт» сүзенең синонимы итеп кулланалар. Иске татар телендә «мәмләкәт» сүзе «корольлек», «патшалык», «ханлык» төшенчәсен аңлаткан. Һәм ул дөрес тә, чөнки аның тамырында «малик» сүзе ята (гарәпчә «король» төшенчәсен аңлата). Гуманитар фәннәрдә мондый эшкәртелмәгән терминнар җитәрлек.

Элек рус сүзен «бозып» әйтү «сәяси» яктан килешми иде шикелле. Шуңа күрә татар теле фонетикасын ватып-сындырып сөйли идек. Хәзер татарча әйтү өчен уңайсыз булган сүзләрне алмаштырырлык яңа сүзләр табыла тора. Мәсәлән, «председатель» сүзе бик уңышлы итеп «рәис» сүзе белән алмаштырылды, «власть» сүзен хакимият диләр. «Больница» сүзе татар теленә күптән кергән, халык аны белә һәм аңа күнеккән, ләкин ул да, «председатель» сүзе кебек үк, татар теленә ятышмый, аны «бүлнис» дип әйтәләр. «Станция» сүзе дә гадәттә «ыстанса» дип әйтелә.

«Больница» сүзе урынына журналистлар «хастаханә», «дәваханә», «шифаханә», «сырхауханә», «сихәтханә» сүзләрен тәкъдим итәләр. Тик башта һәр яңа терминның мәгънәсен ачыклыйсы иде, чөнки авыру да, табиб та бер-берсен аңламаслык булмасын инде. Минем

фикеремчә, «больница» дигән рус сүзе татар телендә «хастаханә», «сырхауханә» дип бирелә ала, ә «шифаханә» — «поликлиника»га, «дәваханә» — «профилакторий»га күбрәк туры килә. «Маяда» тагын ике сүз бар әле. Әлбәттә, бу терминнар әле урнашмаган, ләкин еш һәм бер мәгънәдә куллану нәтиҗәсендә алар сәламәтлек саклау һәм медицина өлкәсендә кабул ителгән термин булып китәчәкләр. Моның өчен иң кулае — медицина уку йортларында татарча укыту. Тик әлеге дә баягы: дәреслекләр, мөгаллимнәр, татарча сөйләшүче табиблар, медицина әдәбияты кайда соң?

Төгәл фәннәрдә, техник терминнар белән ни эшләргә? Без күбесенчә рус теле аркылы кергән терминнарны кулланабыз. Татарча техник терминнар юк дәрәҗәсендә. Бу күпчелек телләр өчен уртак хәл. Кайбер авторлар терминнарны башка телләрдән күчерә башладылар. Югарыда аталган җыентык авторлары, техник терминнар турында фикер йөрткәндә, татарча атамаларга мисаллар китерәләр. Мәсәлән, Юлдашев А., Әфләтонов Ә. рустан кергән «герметизация» сүзен, минемчә, бик уңышлы итеп «томалык» сүзе белән аңлаталар; «герметичный» — томалы, «шток поршня» — пешкәк таягы, «шестерня» — чарык, «лебедка» — чыгыр, «педаль» — табын һ.б.ш. терминнар кулланалар. Тик менә «деформация» сүзен татарча «имгәнү» сүзе белән аңлатып булыр микән?

Мифтахетдинов И.Х. архитектурадагы «пространственные оболочки» терминын «фәзаи түшәмәләр» итеп бирә. Р.Шакир «компьютер»ны «санак» сүзе белән бик матур тәрҗемә итә. «Компьютер технологиясен» авторлар «санак технологиясе» дип биргәннәр. Әмма, терминологик сүзлексез яңа терминнарны аңлавы кыен.

Татарча һөнәри белем бирелмәгәнгә күрә, «профессия» сүзе дә, гәрчә сөйләм телендә булса да, татар сүзе саналмый. Саналмагач, аны «һөнәр» сүзе белән тәрҗемә итәләр. Ләкин «профессия» сүзенең

мәгънәсе киңрәк. Профессия — кеше шөгыленең кайсыда булса конкрет хезмәт белән бәйләнмәгән аерым бер төре (мәсәлән, вуз мөгаллиме, табиб, мәнеҗер, проектчы профессияләре). Ә «һөнәр» — татарда «кул эше ул». Аның бу мәгънәсе мәкальләрдә дә чагыла: «һөнәрленең кулы алтын, акыллының акылы алтын», «һөнәр — кулдагы алтын беләзек» һ.б.ш. Димәк, һөнәрнең төп мәгънәсе — «ремесло». Хәзерге җитештерү өлкәсендә акыл көче күбрәк таләп ителгән профессияләр бар, аларны да «һөнәр» сүзе белән билгеләп булыр микән? Мәсәлән, ясалма сүзләр белән, мисал өчен «профессионализм» сүзе белән ни эшләргә? «Һөнәрилек» сүзе аны алыштыра алыр микән? Профессия сүзен төшереп калдырсак, телебезне баетасы урынга, аны ярлыландырмабызмы? Минемчә, ике сүз дә урынлы, тик мәгънә төсмерләрен аерырга кирәк. «Магазин» сүзе белән дә кызыклы хәл килеп чыкты. Бу сүзне рус теленнән алынган дип уйлап, аны «кибет» дигән татар сүзе белән алмаштырдылар, ә ул элек «лавка» мәгънәсен аңлаткан. «Магазин» сүзе руснык түгел, ә гарәпнеке, башта Европа телләренә кергән, ә алар аша — рус теленә. Әгәр магазинны «кибет» сүзе белән алмаштырсак, «лавка» сүзе татарча ничек булыр?

Телебездә башка кызык күренешләр дә күп. Без кайчакта хәтта үз сүзебезне дә (күптән онытылган сүзне) рус теленнән тәрҗемә итәбез. Мәсәлән, барыбыз да «товарищ» дигән рус сүзенә ияләштек. Ләкин аның төрки сүз (товар ише) булуын, шулай ук «товар», «таможня» «деньги» «сундук» һәм башка күп сүзләрнең кайчандыр татар теленнән рус теленә алынганын күп кеше беләме? Аларны да «татар сүзләренә» алмаштырыргамы?

Күпчелек телләр алынмалар исәбенә баетыла. Алар күбесенчә терминнар. Үсеш алган телләрдә аларны алмаштырмыйлар. Тик төрекләр генә, ялгышып, яңа буынны картлардан аердылар. Әле дә үкенәләр... Шул ук вакытта, һәр кешегә таныш булган кайбер

нәрсәләр милли исем алалар (дөрес, ешрак сөйләм телендә). Әгәр машина — бөтен Европа телләре өчен диярлек урта термин булса (хәтта гарәп телендә дә — «макина»), «автомобиль» сүзен күп кенә Европа һәм хәтта Азия телләрендә дә «авто» диләр. Ләкин французлар үз эквивалентын — «вотюр» сүзен тапканнар, гарәпләр — «сәйярә» дип атыйлар, ләкин сөйләшкәндә ешрак «гарәбия» диләр (гарәбә – арба сүзе). Берәүләр, татарча сөйләгәндә «арба» сүзен «автомобиль сүзе белән алмаштыралар: «арба» функциональ мәгънәсе буенча «авто»га якын, ә фонетик яктан исә «автомобиль» сүзеннән ятышлырак, чөнки үзебезнеке.

4) Йомгаклау

Русча һәм татарча укыта торган урта мәктәпләр ел саен меңнәрчә яшь кешеләрне укытып чыгаралар. Җитмешенче еллардан ук мәктәпне тәмамлаучыларның күбрәк өлеше укуларын дәвам итү тенденциясе күзәтелә. Алар кайсы һөнәрне үзләштерергә хыялланалар соң? Кайда укырга телиләр? Күбесе, аеруча татар авыл мәктәпләрен тәмамлаучылар һәм шәһәрдә иренеп кенә укыганнар, профтехучилищега яки техникумга (16 дан артык уку йорты бар) керәләр. Чиректән артыгы укуларын югары мәктәптә дәвам итәләр (Татарстанда 20 вуз бар). Анда татар яшьләре 50 нче елларда студентларның 27% тәшкил итсә, 70 нче елларда 43%ка җитте. Һәрбер вузда һөнәри белем рус телендә бирелә. Әлбәттә, югары белем биргән «мәдрәсәләрнең» абруе зур, анда татар галимнәренең саны да ишәйде. Бүген алар татарча югары белем турында кайгырталар. Ә урта һәм башлангыч һөнәри белем турында сүз дә бармый. Инженер гына сукалый яки итек тегә, очкыч һәм авто эшләп чыгара диярсең! Дөрес ПТУ һәм техникумнарда галимнәр юк, шуңа күрә тел проблемасы да «күренми».

Шуның өчен бу мәкаләдә автор югары белем хакындагы фикерләрен генә түгел, ә проблемага гомуми мөнәсәбәтен, һөнәри

белем бирүгә тулаем карашын аңлатмакчы булды. «Корал кемнеке — заман шуныкы» диләр. Иркен тормышка юл ярып баручы халкыбызның коралы — аның һөнәре, аның белеме. Татарча һөнәри белем бирергәме, бирмәскәме дигән сорауга катгый рәвештә - «бирергә» дип була. Ләкин һәрбер кеше үз язмышын үзе сайласын иде: бу кеше хокукы һәм демократия дигән сүз. Шуны исәпкә алып, педагогның татар телендә һөнәри белем бирү мөмкинлеге һәм максаты турында уйлануларына җәмәгатьчелек игътибар итми калмас әле. Һәм һәрбер кеше үз фикерен туплар.

1.4. Базар һәм һөнәри белем

Хәзерге икътисади төшенкелектән чыгу, базарлы экономикага күчү, товарларның сыйфатын яхшырту, дефицит бетерү... Боларның һәммәсен дә кем эшләргә тиеш? Якындагы 3–5 елны күздә тотканда, хәзер производствода эшли торган кешеләр. Чит илләргә хезмәт күрсәтү өлкәсенә «акыл агышы» тизләнү инженерлар сафының сыйфатын яхшыртуга китермәячәк. Кооперативларда чамадан тыш эш хакы алудан бозылган югары квалификацияле эшчеләр предприятиеләргә кире әйләнеп кайтмаячаклар.

Ил буенча уртача алганда, бүген эшчеләр квалификациясе, эшнең катлаулыгы белән чагыштырганда, бер бөтен разрядка артта кала. Алга киткән илләрдә, эшчеләр квалификациясе 0,4 процентка гына түбән булганда да, предприятие рентабельсез, яшәргә сәләтле түгел һәм бетерелергә тиеш, дип санала (Богачев И. Лицом к рынку — спиной к образованию? «Литературная газета», №49, 1990).

Производствода тиз арада чиле-пешле эшчеләр әзерләү бу мәсьәләне беркайчан да хәл итә алмады, ә бүген профтехбелем системасы җан бирергә тора, шулай булгач, без хезмәт

җитештерүчәнлеген нинди җитештерү көчләре белән күтәрергә җыенабыз соң?

Бүген эшсезләр 6-7 миллион булса, базарлы экономикага күчкәч һәм рентабельсез предприятиеләр ябылгач, бу санның 15-18 миллионга җитүе ихтимал. Хезмәт министры иптәш Щербаков шушы күчеш чорында 40 миллион эш урыны бетү мөмкин, дип саный («ЛГ», 1990 ел, 21 декабрь). ПТУ тәмамлаучылар инде бүген үк эш таба алмыйлар, ә киләчәктә аларны ни көтә соң?

Парламентчылар власть өчен көрәшә-көрәшә, экономистлар халык хуҗалыгын үзгәртеп кору юлларын эзли-эзли, мәгариф хакында, эшчеләр сафын яшьләр белән тулыландыру турында бөтенләй онытып җибәрделәр. Соңгы 5 елда гына да аның сафларына 20 миллионнан артык яшь эшче, техник, инженер, укытучы, врач һ.б. басты бит. Аларның әхлакый рухы нинди? Профессиональ әзерлеге ни дәрәҗәдә? Гомуми мәдәният дәрәҗәсе нинди? Алар үз иңнәрен экономиканың ава торган баганалары астына куярга, аларны терәтергә әзерме?

Дистәләрчә еллар дәвамында зур авырлыклар белән төзелгән профтехбелем системасы — квалификацияле эшчеләр әзерли торган төп чыганак — гел Дамокл кылычы астында яшәп килде. Үзгәртеп кору башлангач, Профтехбелем комитетын бетерделәр, ПТУларны Мәгариф министрлыгына бирделәр. Ә ул нигездә гомуми белем мәшәкатьләре белән мәшгуль. Аннары, акчага экономия (эшчеләр әзерләүгә?) ясау өчен, 3 мең ПТУны предприятиеләргә тапшырырга булдылар. Ләкин, системаның бик тиз таркалуын күреп алып, бу карарны гамәлдән чыгардылар. Хәзер системаны үзәкләштерелгән тәртиптә финанслауны туктаттылар, аны урыннарда таркаталар, чөнки җирле Советларның аны тотар өчен акчасы юк. Тагын үзгәрешләр көтелә...

1990 елда байтак профтехучилище укучылар туплый алмады. Аларның абруе төшә бара. Профтехбелем системасы инде миллионнан артык укучысын югалтты. Былтыр техникумнарга керүчеләрнең белем дәрәҗәсе аннан алдагы еллар белән чагыштырганда шактый түбән булды. Профессиональ белем базар мөнәсәбәтләренә нинди хәлдә килеп керә. Квалификацияле эшчеләр һәм урта буын белгечләр әзерли торган бөтен системаны үзгәртеп коруның социаль-экономик шартлары нидән гыйбарәт?

Илебездә профтехбелем һәм махсус урта белем системасының нинди булырга тиешлеге турында тәгаен сүз әйтүе кыен. Сәяси, икътисади хәл турында да шулай дияргә була. Демократик дулкында зур һәм кечкенә суверен дәүләт барлыкка килә, аларның һәркайсы үзе өчен кадрлар әзерләүнең теге яки бу системасын сайлаячак. Шуңа күрә үзәкләштерү һәм гомумсоюз системасы үзеннән-үзе юкка чыгачак.

Экономика базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында профтехбелем системасы кайда һәм нинди кадрлар әзерләргә тиеш? Бу экономика һәм фәннең торышына бәйле. Әлегә исә социаль-экономик каршылыклар махсус урта белем системасына тискәре йогынты ясый, аның төп функцияләрен һәм структураларын җимерә. Кадрлардан югары нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә тиешле базарлы экономикага күчү генә эшне җайга салу мөмкинлеге ачачак.

Алдынгы практика һәм педагогика фәне профессиональ мәктәпне инде күптәннән индивидуальләштерү идеясе белән яши иде. Профессиональ мәктәп абруен күтәрү һәм аларга үсмерләрне җәлеп итү максаты белән, педагоглар профтехучилище базасында техник колледжлар оештыра башладылар. Узган ел алар илледән генә артык булса, хәзер аларның саны тиз үсә. Кызганыч, күбесен

башлангыч әзерлексез ачтылар, яңа типтагы уку йортларын фәнни яктан нигезләү эше дә соңара.

Казандагы мотор төзү предприятиесе базасында ачылган техник лицей 1990 елда беренче укучылар — киң профильле станокчы һөнәренә өйрәтергә 120 кеше кабул итте. Лицейның төп идеясе — квалификациясе төрле дәрәҗәле эшчеләрне этаплап әзерләү. Тулы курс үтеп, аны уңышлы тәмамлаучы һәркем югары квалификацияле — үз квалификациясе буенча теләсә нинди катлаулы эшне башкарырга, рационализаторлык һәм уйлап табу эшчәнлегендә актив катнашырга сәләтле эшче булып чыга.

Техник лицейда уку вакыты 5 ел чамасы. Ул өч этапка бүленгән. Беренчесендә — кыручы, фрезерчы, тишүче, шомартучы һөнәренә өйрәнәләр. Икенчесендә — катлаулы катнаш группалы һөнәр иясе — урта белемле киң профильле станокчылар, өченчесендә — инженер белеме нигезләре булган югары квалификацияле эшчеләр әзерләнә. Алар программалы идарә ителә торган станоклар һәм манипуляторларны көйләү, материаллар эшкәртү белән бәйле катлаулы производствода эшли алачак.

Һәр баскыч укытуның тәмамланган циклын тәшкил итә, укучының сәләтенә һәм уңышларына карап, тиешле квалификация бирелә. Югарыдагы баскычларда укучылар үзләренә квалификация бирелгән документка карап һәм психо-физиологик диагностика ярдәмендә сайлап алына. Техник лицейның өченче баскычын тәмамлаучы укучылар КАИның төрдәш факультетында 2 нче курста ук укуларын дәвам иттерә алалар. Институтта шушы максатта махсус программа төзеләчәк.

Һөнәр мәктәбе абруен ничек күтәрергә? Бу уку йортларын ничек итеп чын мәгънәсендә гуманитар һәм профессиональ белем бирү үзәкләренә әверелдерергә? Моның өчен училище исемен «лицей»га алыштыру гына җитми. Югары квалификацияле

укытучылар һәм мастерлар кирәк, бу исә аларга югары эш хакы түләүгә бәйләнгән. Укыту-производство процессын техник җиһазландыруны бик нык яхшырту сорала. Бу мәсьәләләрне хәл итү өчен лицейның үз счетында җитәрлек акча булырга тиеш. Ләкин ул юк, проблеманы үзәкләштерелгән тәртиптә хәл итү перспективасы да күренми.

Квалификацияле кадрларны хуҗалык исәбе тәртибендә әзерләү һәр лицейның укыту-производство комплексы базасында кечкенә предприятиеләр төзү өстәмә финанслау чыганагы була ала. Яшьләрне кечкенә предприятиеләрдә матур әйберләр ясарга гына түгел, маркетингка, менеджментка, коллективта эшлекле аралашуга да өйрәтү — аларны базар мөнәсәбәтләре шартларында тормышка әзерләүнең нәтиҗәле бер адымы да.

Уку йортларының кечкенә предприятиеләре республика халык мәгарифе министрлыгы яисә өлкә мәгариф идарәсе составындагы укыту-производство берләшмәләренә берләшергә, кооперацияләштерелергә тиеш. ПТУ җитәкчеләре берләшмәнең үз юридик статусы, банкта счеты, һ.б. булырга тиеш дип саныйлар. Берләшмәләр төзү училищеларга тармак идарәсе принцибыннан вертикаль бәйлелектән котылырга, яңа экономик мөнәсәбәтләр шартында ныклап аякка басарга мөмкинлек бирәчәк. Илебезнең Красноярск, Свердловск, Самара өлкәләрендә һ.б. урыннарда мондый берләшмәләр беренче елын гына эшләми инде.

Экономиканың базар мөнәсәбәтләренә күчүе, кадрлар әзерләүгә якын килүне таләп итү белән беррәттән, һөнәр бирү мәктәпләрен турыдан-туры шушы мөнәсәбәтләргә дә алып керәчәк. Яңа типтагы уку йортлары төзеп, профтехбелем хезмәткәрләре техник лицей һәм колледжларның үзләрендә тулы хуҗалык исәбендәге рентабельле производство оештыралар. Алар үз продукцияләрен һәм эчке, һәм халыкара базарга да чыгара башладылар.

Мәсәлән, Минскидагы 1 нче лицейны алыйк. Анда тулысынча уку срогы – 7 ел (8 класс базасында) Укучылар конкурс белән сайланып алына. Лицейның уникаль производство базасы, заман җиһазлары бар. Ул укучыларга махсус урта белем бирергә һәм алардан югары квлификацияле станокчы (хәтта станоклар көйләүче) әзерләргә җыена. Мондый лицейлар киләчәктә техник колледжларга әверелергә мөмкин.

Минскидагы бу лицей укучылары үзләренең производство базасында хуҗалык исәбе нигезендә куллануга әзер продукция җитештерәләр. Ул база предприятиесе («Беларусь» тракторлары чыгару берләшмәсе) планына кертелгән һәм дөнья базарына да чыгарыла. Әлеге продукция тракторларның тапшыру тартмаларыннан гыйбарәт. Менә шулардан лицей елына 2 миллион сум чамасы табыш ала, ул производствоны, лицейның матди базасын үстерүгә һәм әлегә производствода эшләүчеләргә эш хакы түләүгә тотыла.

Югарыдарак телгә алынган Казан лицеенда табыш алуның ике чыганагы билгеләнде һәм ул гамәлгә ашырыла. Шуларның беренчесе — база предприятиесе өчен (бәлки башка заводларга да) детальләр әзерләү заказын үтәү; икенчесе — халык кулланыу товарлары җитештерү өчен лицейның үз производствосын булдыру, анда җитештерелгән продукцияне ирекле сату.

Укыту-производство мастерскойлары базасында төзелгән кечкенә предприятиедә лицей укучыларының 30-40 проценты эшли ала. Алар специальләшкән бригадалар группаларыннан тора. Квалификацияләре күтәрелү һәм производствоны оештыру дәрәҗәсе яхшыруга карап, бер-ике ел дәвамында катлаулырак детальләр җитештерүгә күчә бару да күздә тотыла. Халык яисә аерым оешмалар һәм предприятиеләр ихтияҗы зур булган катлаулы әйберләр чыгару табыш китерүе белән җәлеп итә. Әлбәттә,

коммерция уку йорты өчен үзмаксат түгел, ә укытуның нәтиҗәлелеген күтәрү чарасы, укучыларда эшлекле сыйфатлар һәм тормышта үз урыныңны табу сәләтә тәрбияләү методларының берсе.

Бу язылганнарда яңалык бик аз, дип әйтүләре ихтимал. Әйе, яхшы профтехучилищелар элек тә булачак эшчеләрне производствога өйрәтү чорында товар җитештерә иделәр. Ләкин, беренчедән, моны һәр ПТУ да эшли алмый иде. Икенчедән, аларның күпчелеге мәктәпләрдә ясала торган вак-төяк әйберләрне хәтерләтә һәм промышленность товарлары белән «тартыша» алмый иде. Өченчедән, кагыйдә буларак, андый производство училищеларга сизелерлек файда китерми иде.

Базар безгә үзенең законнары ярдәмендә кешенең нәтиҗәле, файдалы эшкә булган мәнфәгатен кире кайтару өчен кирәк. Профессиональ белем эчтәлеге иң элек менә шундый бурычны күздә тотып билгеләнергә тиеш.

Сәясиләштерелгән митинглар һәм парламент көрәше, биш ел дәвамында тарихыбызны каралту яшьләрне дә начар якка үзгәртте. Хәлне ничек төзәтергә? Моның өчен тәрбия бирүнең яңа стратегиясе һәм аны оештыруның яңа формалары кирәк.

Киләчәктә техник лицей яшьләрнең ял һәм микрорайон үсмерләренә эстетик тәрбия бирү үзәге, мәдәни юнәлештәге, спорт, тамаша, күңел ачу характерындагы төрле салоннар берләшмәсе итеп тә күз алдына китерелә. Болары да беркадәр табыш бирүе мөмкин.

Техник лицей базасында хуҗалык килешүе нигезендә яңа белгечләр әзерләү һәм элеккеләренең квалификацияләрен күтәрү планлаштырыла.

Техникумнар базасындагы техник колледжлар үз вазифалары белән лицейлардан бераз аерылып торалар. Дөрес, алар бер үк — кадрлар әзерләү сыйфатын яхшырту максаты белән төзеләләр.

Кайбер гуманитар урта белем бирү йортлары да колледж итеп үзгәртелә (Подольск педагогия, Казан медицина училищелары һ.б.). Илебездәге фәнни-укыту берләшмәләре дә барлыкка килде. Мәсәлән, Тольятти политехника институты һәм техникум берләштерәләр.

Безнең институт тәкъдиме белән, Татарстан ССР Министрлар Советы Түбән Кама техникум базасында яңа тип уку йорты — региональ колледж ачарга тәкъдим итте. Соңыннан аның составына шәһәрдәге барлык сигез ПТУ да кертеләчәк. Биредә дә кадрлар әзерләүгә баскыч принцибы саклана, ләкин тармак принцибы булмаячак. Мондый колледж вак профессиональ мәктәпләрнең, тармак кысалары белән чикләнгәнлекнең һ.б. бетүенә китерәчәк. Ул квалификацияле эшчеләр, урта буын белгечләре, вак предприятиеләр өчен .

Базар мөнәсәбәтләренең төрле этапларында профтехбелемнең нинди булырга тиешлеге хакында күп фикер йөртергә мөмкин. Әмма шунысы ачык, беренче чиратта эшчеләр һәм урта буын белгечләр әзерләүнең бердәм бизнесменнар (эшкуарлар), укучыларны вузга керү өчен әзерләячәк һәм, шулай итеп, шәһәр кешеләренең белемнәрнең теләсә кайсы төренә булган ихтыяҗын канәгатьләндерәчәк. Дәүләт программасы кирәк, анда бу гаять мөһим мәсьәләне хәл итү бурычлары һәм алымнары төгәл күрсәтелгән булырга тиеш.

1.5. Заводка кем килер?

(Соц. Татарстан, 1990, 3 октябрь)

Эшчеләр сыйныфы хәзер нинди чыганаклар исәбенә тулылана? Бу сорауга, бары тик уку йортлары исәбенә, дип җавап бирергә мөмкин. Илебез училищелары ел саен 2,5 миллион яшь эшче

әзерләп чыгара. Ә бу бишъеллыкта производствога мәктәпләрдән дә яшьләр күп киләчәк. Бу хәл үзгәртеп коруга сизелерлек йогынты ясармы, яки яңа килүчеләр озак вакыт буена өйрәнчелектә йөрерме? Мәктәптә һәм профтехучилищеда укыту һәм тәрбия бирүнең сыйфатына бәйле нәрсә бу.

Токарьга физика кирәкме? — дигән сорауга эшчеләр, кагыйдә буларак, кирәк, дип җавап бирәләр. Әмма профтехучилищеда укучылар алай дип санамый. Гәрчә ПТУ укытучылары өч ел буена үсмергә физиканы да, математиканы да тирәнтен төшенүдә ярдәм итү өчен тырышлыкны кызганмасалар да, училище тәмамлаучыларның 80 проценты барлык гомуми белем фәннәре буенча нигездә өчлегә укып чыгалар, аларның да бер өлеше «ялган» билге. Урта белем алу турындагы «ялган» аттестатлар да шуннан килеп чыга.

Хәзер инде беркемгә дә сер түгел, сигезенче классларны тәмамлап чыгучы балаларның 40 проценттан 80 процентка кадәре профтехучилищеда контроль эшләрне башкара алмый. Күпләр бирегә фән нигезләрен белмичә килә. Алар теорияне яки бөтенләй өйрәнергә теләми, яисә аларның моңа көче җитми. ПТУ укучылары арасында үткәрелгән сорашып белешү мәгълүматлары шуны күрсәтте: укучыларның 11,4 проценты фән нигезләре, 93,2 проценты профессиональ белемнәр кирәк дип исәпли, ә разрядны барысы да иң мөһиме дип саный.

Укуның беренче көненнән үк үсмерләргә мастер шушы фикерне тукый. Чынлап та, ПТУның бурычы — чын эшче әзерләү. Училищены тәмамлап чыгучының күпчелегенә, хәтта урта белем турындагы аттестат формаль документ булса да, өченче разряд бирелә. Хәер, производствода аңардан беркем дә аттестат сорамый. Иң мөһиме — разряд.

Казан предприятияләренең берсендә 26 цехта сорашып белешү үткәрелде. Кайсы белгеч яхшырак — ПТУны тәмамлаганымы яки берничә ай буена турыдан-туры эш урынында профессия алганымы? Мастерларның 74 проценты ПТУларда профессиональ әзерлекнең йомшак булуын әйтте. Һәм аларның өчтән бер өлеше генә училище тәмамлаучыларның цехка килгәч тә мөстәкыйль эшли алуларын раслады. Калганнары исә, бу балаларны профессиягә өр-яңадан өйрәтергә кирәк, дигән фикердә. Ә шул ук вакытта предприятиенең техник уку бүлекләрен тәмамлаучы эшне үзләренә бирелгән разряд нигезендә башкаралар. «Әгәр ике яшь кешенең берсен сайлап алырга туры килсә, сез үз коллективыгызга аның кайсысын алыр идегез?» — дигән сорау бирелгән иде. Техник уку бүлекләрен тәмамлаучыларны сайлап алырга теләүче мастерлар 87,9 процент, ПТУ ны тәмамлаучыларны сайлап алучылар 12 процент булды. Профтехучилищеда укыган үсмерләрнең эш күнекмәләре дә, дисциплиналары да йомшак, җаваплылык хисе юк, диләр алар.

«Производство» вариантына өстенлек бирелүнең сәбәбе күп. Производствода эшкә иң заманча җиһазлардан файдаланып өйрәнәләр. Үсмер хезмәт коллективына тиз кереп китә һәм аның психологик климатын үзләштерә. Өйрәнчек бары тик профессиональ әзерлек белән генә мәшгуль. Унынчы классны тәмамлаучыларның, кагыйдә буларак, белемнәре яхшырак, танып-белү интересы тотрыклырак, алар техника яңалыкларына күбрәк игътибар итәләр, өйрәнелә торган процессны тиз эләктереп алалар.

Шуны ассызыклап әйтергә кирәк, ПТУ тәмамлаучыларның хәзерлек сыйфаты күп яктан мәктәпләргә бәйле. Нәкъ менә мәктәпләр ПТУларга белемнәре түбән булган, укырга теләмәүче контингентны җибәрә. Училищеларның инженер-педагогия коллективы алардан эшче сыйныфына лаеклы алмаш әзерли алырмы соң?

Балаларның үзләренә бәйле булмаган башка сәбәпләр дә күп. Беренче чиратта, ПТУларда гомуми белем фәннәре буенча биредәге үзенчәлекләрне исәпкә алып төзелгән үз программалары юк. Билгеле булганча, мәктәп программаларында физика, математика, химия, тарих һәм башка фәннәр буенча искереп беткән материаллар тулып ята. Дәреслекләр өйрәнелә торган профессия белән, гомумән, техника, технология белән берничек тә бәйләнмәгән. Биредә әле тагын «күп предметлылык» та бар. Профтехучилищеларда уку планнары артык киеренке, аларда 22 предмет укытыла (ә гомуми белем мәктәпләренең өлкән классларында 12 генә). Өстәвенә, аларны өйрәнү өчен сәгатьләр дә аз бирелә. Мондый шартларда балаларда нинди тирән белем булсын.

Яшьләрнең укуга интересы кимү мәктәптә тәрбия эшенең начар торуы белән генә түгел, бигрәк тә белем алуда экономик стимулларның тулысынча юкка чыгуы белән аңлатыла. Тигезләүчелекнең тамырлары бик тирән әле бездә. Ничек кенә укысаң да, училищены түбән билгеләр белән тәмамласаң да, разрядны барыбер бирәләр.

Мәҗбүриме?

Безнең институт галимнәре, мәктәп реформасының барышына бәя биреп, аның кайбер проблемалары вакытыннан алда куелмадымы икән, дигән фикердә торалар. Я мәсәлән, тулы урта белем алу профтехмәктәптә укучыларның күпчелеге өчен мөмкин булмаган эш булып чыкты. Урта белемне мәҗбүри итеп кую процент артыннан кууны тудырды. Шунысы әйбәт, халык мәгарифе турындагы законнарның яңа редакциясендә «мәҗбүри» дигән сүз төшереп калдырылды.

СССР Мәгариф министрлыгы урта белем концепциясен игълан итте. Борылыш сизелә, әмма мәктәп кинәт кенә яңага әверелмәячәк. Профтехучилищега иртәгә кемнәр килер? Тагын икелегә

укучылармы? Ике ел инде укытучы-новаторлар арасында сүз уйнату бара, ә массакүләм укытучы, электәге кебек үк, урта кул дәресләр бирүен белә. Урта мәктәп әлегә балаларны алты яшьтән укыту, шулай ук өлкән класс укучыларының җитештерүчән хезмәте өчен эш урыннары эзләү мәсьәләләрен генә актив хәл итә. Башка мәсьәләләрдә алга китеш юк.

Шулай итеп, гомуми белем дәрәҗәсенең түбән булуы сәбәпләре аңлашыла. Ни өчен соң производствода ПТУ тәмамлап чыгучыларның профессиональ әзерлеге белән дә риза түгелләр? Моның сәбәпләре тагын да күбрәк. Барыннан да бигрәк, укучыларда белем алуга, китап өстендә эшләү күнекмәләренә омтылыш, кызыксыну юк. Ләкин укучылар контингентын планлаштыру кебек гаять катлаулы проблема да яшәп килә. Укучыларны туплауга һәм укытып чыгаруга сан ягыннан гына якын килү училищеларны тупикка китереп кертте: эшчеләрне «вал» буенча әзерләү шуңа китерде ки, барлык училищелар яшь алмаш чыгару планын үтиләр, ә эшчеләр, бигрәк тә төзү трестларында, һаман да җитми. Профтехбелем системасының функцияләре һәм структурасы үзгәрә аламы?

Училищеларга эшне база предприятиесенең (яки тармакның) киләчәген искә алып та үзгәртеп корырга кирәк. Әмма күпчелек предприятиеләр кадрлар перспективасы мәсьәләсендә агымдагы бишьеллыктан ары уза алмыйлар. Алар уку йортларына хәтта якындагы елларга да ориентация бирә алмыйлар.

Үзгәрүчән планлаштыру кирәк, диләр. Хәзер планлаштыруның яңа принципларын эзләү бара: «вал» буенча да түгел, «ирешелгәннәр»дән чыгып та түгел. СССР Профессиональтехник белем дәүләт комитеты кыю адым ясады: предприятиеләр белән турыдан-туры договорларга күчте. Предприятиеләр үзләренә кирәк санда эшчеләр әзерләүгә заказ бирәләр һәм моның өчен чыгымнар

түлиләр. Урта профтехучилищелар предприятиеләр белән төзелгән договорлар буенча эшчеләрне яңадан әзерләү үзәкләре дә, дип килешенде.

Киләсе елдан башлап эшчеләрне турыдан-туры договорлар буенча әзерләүгә күчү планлаштыруда сыгылмалыкны тәэмин итә һәм профтехбелем системасына яңа шартларга җайлашырга мөмкинлек бирә. Моның уңай нәтиҗә бирәчәге бәхәссез. Беренчедән, база предприятиеләре училищелар төзеп кенә калмыйлар, ә аларга яңа җиһазлар да, мастерлар да бирәләр һ.б. Икенчедән, хезмәт коллективы яшә алмашны тәрбияләүдә үзе катнаша. Илебездә уңай мисаллар күп. Берничә ел элек без Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсенең Түбән Кама шәһәрендәге 44 нче ПТУ белән хезмәттәшлек тәҗрибәсен игълан иткән идек. Башка тармактан, мәсәлән, «Ждановтяжмаш» производство берләшмәсенең 4 нче ПТУ белән хезмәттәшлеген үрнәк итеп күрсәтергә мөмкин. Бик яхшы хезмәттәшлек! Киң профильле станокчылар әзерләү өчен база предприятиесе яхшы җиһазларны үзеннән генә биреп калмый, ә аларны читтән дә китертә (ГДРдан)! Производствога өйрәтүнең һәр дәресендә училище мастеры белән бергә предприятиедән беренче класслы белгеч катнаша. Шунлыктан ПТУның авторитеты югары. Конкурс та зур. Аны тәмамлап чыгучыларның 35 процентына югары разряд бирелә. Яшь алмашның предприятиедә төпләнеп калуы 85 процент тәшкил итә.

Профессиональ укыту дәрәҗәсе түбән булуның икенче сәбәбе — училищеларның күп профильлегендә. 20 төрле һөнәргә өйрәтә торган училищены күз алдына китерегез! Нәрсә дигән сүз бу? Күпләгән уку планнары, дистәләрчә уку фәннәре, программалар һәм дәреслекләр кирәк ич моңа. Шулардан чыгып, яхшы расписание төзеп кара! Барлык профильләрне дә квалификацияле укытучылар

белән тәэмин итеп булмый. Аларның методик эше турында нинди сүз булырга мөмкин? Бүгенге көндә училищеларның 40 процентында диярлек үз профильләренә яраклы укыту материаль базасы юк. Әгәр дә инде төзелеш училищесында ташчылар һәм малярлар белән бергә үк вакытта кулинарлар, парикмахерлар, электромонтерлар һәм слесарьлар да әзерлиләр икән, аларның барысы өчен дә бердәй яхшы укыту-материаль базасы булдырырга мөмкин түгел, билгеле.

Бригада подрядына күчү гадәттә эш урынында бер-берсен алыштырып торырга сәләтле эшчеләр әзерләүдән башка мөмкин түгел. Димәк, «тар профиль» (бары тик токарь, бары тик фрезерчы, бары тик бораулаучы һ.б.) яраксыз хәзер. Техниканың һәм җитештерү технологиясенең яңартылуы эшчеләрне теоретик әзерләү дәрәҗәсенең тагын да югары булуын таләп итә. Димәк, өчле һәм икелегә укучылар үзгәртеп коруны тоткарлыйлар.

Бөтенсоюз профбелем фәнни-тикшеренү институты белгечләре исәпләгәнчә, катлаулы профессияләрнең һәм киң профильле профессияләрнең тар даирәсенә специальләшкән ПТУлар гына югары нәтиҗә бирә ала. Институт галимнәре аларны группаларга бүлү белән инде күп еллар шөгыльләнә. Әмма әле эш акрын бара. Чөнки мәсьәлә катлаулы булып чыкты. Хәзер һөнәрләрнең яңа исемлеге әзерләнде. Аларның саны профтехучилищелар өчен 1400 дән 1200 гә калдырылды. Бу да күп әле. АКШта профессиональ мәктәптә 440 һөнәргә, ГДРда — 260, Болгариядә — 26 һөнәргә генә өйрәтәләр. Безнең өчен оптималь вариант нинди — 400–500 профессияме? Уйланыйк.

Барлык укучыларга киң профиль, бер-берсен тулыландыра торган (интеграцияле) һөнәрләр бирергә кирәклекне беркем дә бәхәскә куймый. Әмма моны укыту сроклары белән ничек бәйләргә? Хәзер алар киң профильле станокчы өчен дә, слесарь өчен дә, ЭВМ

операторы өчен дә, маляр өчен дә бертөрле. Тигезләүчелек принцибы биредә дә гаҗәеп хәлләр тудырды. Бары тик бердәм өчьеллык урта профтехучилищелар булдыру һәм урта белем бирми торган училищеларны бетереп ашыкмадык микән без? Экономикабызның үсеш дәрәҗәсе әлегә үзләштерелә торган һөнәрнең катлаулыгына бәйле рәвештә уку срокларының төрле булуын таләп итә. Кайбер илләрдә катлаулы профессияләргә 57 шәр ел укыталар, ә гади профессияләргә вакытны да, акчаны да күп сарыф итмиләр.

Бер калыпка кермәскә

СССР Профессиональ-техник белем дәүләт комитетының барлык үсмерләрне «оҗмахка күсәк белән» куып кертмәскә карар бирүе экономиканы үзгәртеп кору бурычларыннан килеп чыкты. Гуманлы да, максатчан да бу. Укучыларның бер өлеше профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институтында эшләгән психология-педагогия критерийлары нигезендә, педсовет карары буенча, ата-аналарның ризалыгы белән, урта белеме булмаган балалар группаларында профессия үзләштерәләр. Демократияләштерү биредә дә һөнәрне ирекле сайлауны күздә тота. Илебезнең кайбер училищеларында, мәсәлән, Татарстанда, Пермь өлкәсендә һәм башка урыннарда, бу идея инде тәҗрибә тәртибендә сынала. Хәзер укучыларны сайлап алу укуның беренче елы йомгаклары буенча үткәрелә. Яңа елдан башлап укучыларны инде сентябрь — октябрьдә үк группаларга бүлү максатка ярашлы булыр.

ПТУларда укытуны дифференциацияләүнең төрле вариантлары булырга мөмкин. Бу очракта укучылар сигезьеллык белем базасында ике ел эчендә бары тик профессиональ әзерлек кенә алалар (аерым программалар буенча иҗтимагый-гуманитар белем бирү мәҗбүр итеп куела). Икенче бер очракта алар тар профессия буенча укуның ике елы эчендә «берләштерелгән» программалар буенча гомуми

белем алуның берьеллык программасын үзләштерә алалар. Һәр ике очракта укыту мотивларын тәрбияләүгә, хезмәт һәм аралашу культурасына, үзлегеннән өйрәнү күнекмәләренә зур игътибар бирелә. ПТУны тәмамлаучылар өзлексез белем алу ситемасында укырга әзер булырга тиешләр.

Укучыларның киң профильле профессияне үзләштерү проблемасы шактый катлаулы. Беренчедән, аларның күбесен үзләштерү өчен гомуми белемнәрнең яхшы булуы кирәк, ә катлаулы профессияләрне үзләштерергә 45 ел вакыт сорала. Икенчедән, квалификацияле, киң профильле эшче әзерләү фәнни нигезләнгән уку планнарыннан һәм программаларыннан башка мөмкин түгел. Ашык-пошык әзерләнгән документлар бернигә дә ярамый.

Мәсәлән, үткән уку елында безнең институт хезмәткәрләре, Казан шәһәрендәге 3 нче ПТУның производствога өйрәтү мастеры белән бергәләп, Бөтенсоюз профтехбелем фәнни методик үзәгендә эшләнгән программа буенча киң профильле станокчы (токарь, фрезерчы, бораулаучы, кыручы) әзерләүнең нәтиҗәлелеген тикшерделәр. Нәтиҗә мастерны куандырмады: укучыларның профессиональ күнекмәләре бернигә дә ярамый. Ныклы күнекмәләр алу өчен вакыт кирәк, җитди шөгыльләнергә кирәк. Әгәр тар профильдә токарьлыкка өйрәнүгә 161 сәгать бирелсә (фрезерчыга да шулкадәр үк), киң профильдә исә токарьлыкка 46 сәгать, ә фрезерчыга — 32 сәгать бирелә. Ә бу – биш тапкырга кимрәк.

Мондый хәлдән чыгу юлы кайда? Киң профильле төп белгечлеккә (мәсәлән, токарьлыкка) күнекмәләрне яхшы үзләштерү өчен вакытны тар профильле белгечләргә караганда кимрәк бирмәскә кирәктер. Ә бу вакытны кайдан алырга? Ничек кенә кыйммәткә төшмәсен, укыту срокларын озайту исәбенә алыргадыр, мөгаен. Белем бирүгә капитал салу иң файдалы эш, бу инде бөтен дөньяда танылды. Япониядә, мәсәлән, 50 нче еллар уртасыннан

башлап эшче көченең бәясе 16,6 тапкыр күтәрелде. Моннан, эшчеләр әзерләүгә дә капитал салуны арттырырга кирәк, дигән фикер тумыймы? Әйе, туа. Унбиш тапкыр ук булмаса да, барыбер арттырырга кирәк аны.

СССР мәгариф министрлыгы укытучыларның август киңәшмәләренә урта белем концепциясен игълан итте. Анда мәктәпләрне үзгәртеп коруга яңа карашлар, мөмкинлек һәм интересларын һәм аларның ата-аналары теләген исәпкә алып, белем бирүне иртәрәк дифференциацияләү (группаларга аеру) күздә тотыла. «...Өйрәнелә торган фәннәрнең гомуми саны шактый кыскартылачак, профессияне сайлау буенча курслар кертеләчәк. Яңа планда мөстәкыйль курслар сәгатьләре башка төрдәш фәннәр белән тулылындырыла». Укытуның эчтәлегендә һәм мәктәпләрнең уку планы структурасында җитди үзгәрешләр бу.

Бу принциплар профессиональ мәктәп эшендә ничек чагылыр? Профтехучилищеда фән нигезләре буенча уку планнары һәм программалары профессияләргә бәйле рәвештә дифференциацияләнәчәк. Бу исә бирелә торган профессиягә органик төстә бәйле булган предметларның бер өлешен тирәнтен өйрәнү өчен шартлар тудырачак.

Хәзер СССР Педагогия фәннәре академиясенең профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институтында, автомат линияләрне көйләүче һәм ЭВМ операторы профессияләренең эчтәлегеннән чыгып, физика һәм математика буенча интеграцияле программаларны эшләү төгәлләнеп килә. Гомум-техник фәннәр саны икеләтә кыскарак: материалның шактый өлеше физикага (мөгаен бу фән «техник физика» дип аталыр), химия һәм математикага күчереләчәк.

Өч «вак» (сәгатьлек) гуманитар предметтан «Яшь эшче культурасы» дигән бердәм курс (этика һәм гаилә тормышы

психологиясе) оештырыла. Аңа 35 сәгать, эстетик тәрбиягә — 50 сәгать, хокук белемнәре нигезләренә 25 сәгать вакыт бирелә. Җәмгыять белемнәрен экономик белем нигезләре курсы белән тулыландыру юлларын эзләү бара. Бу программалар СССР Профтехбелем дәүләт комитеты карары белән яңа уку елында Мәскәү өлкәсенең, Татарстан, Эстония һәм башка өлкәләрнең кайбер училищеларында сыналачак. Интеграция һәм дифференциация буенча эш профессияләрнең эреләндерелгән төрле группаларында алып барылачак. Ә бу — физика токарь өчен аерым, слесарь өчен аерым булачак, дигән сүз түгел. Әмма физика буенча профтехцикл эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән 3–4 дәреслек эшләнер. Тик безне бүген интеграция нигезендә профессияләрнең группаларга бүленмәве тоткарлап тора. Бөтенсоюз профтехбелем фәнни-тикшеренү институты бу эшне тизләтер дип ышанабыз.

Балачактан өйрәтик.

Иртәгә профтехучилищеларга үсмерләр нинди хезмәт күнекмәләре белән килерләр? Реформаның асылы укуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләүгә нигезләнгәнлектән, училищега килүченең эшне чүкечтән түгел, ә станокта деталь эшкәртүдән иң гади сызымнарны укый белүдән, үлчәү приборлары һәм инструментлар белән эшли алудан башлавы кирәк. Моның өчен V–VII классларда хезмәткә өйрәтү VIII–IX классларда мәктәп балаларына профессиягә кадәр әзерлек бирү белән тулыландырылырга тиеш. Төп игътибарны үсмергә хезмәтнең тәрбия йогынтысын көчәйтүгә, гомум-хезмәт һәм политехник күнекмәләр тәрбияләүгә, профессиональ ориентация бирүгә юнәлтергә кирәк. Шунлыктан мәктәптә гомуми хезмәт культурасы бирүнең дәрәҗәсе ПТУда профессиягә өйрәнүнең сыйфатын күп яктан билгеләячәк. Безнең институт, УПКларда хезмәт тәрбиясе һәм профессиональ ориентация бирү максатына ирешү өчен укучыларны

моңа 9–10 классларда түгел, ә 5–8 классларда өйрәтергә кирәк, дип исәпли. Чөнки үсмерләр, беренчедән, машиналарны, механизмнарны һәм технологияне үзләштерүгә түгел, ә чүкеч тотарга өйрәнүгә никадәр кыйммәтле вакытны югалталар. Фикер йөртүдә анахронизм бу. Электроника гасырында үсмерләрдә хезмәткә мәхәббәтне искереп беткән ысуллар белән тәрбияләп булмый. Үсмерләр өчен бары тик җәмгыятькә файдалы хезмәт нәтиҗәсе генә кызыклы һәм мавыктыргыч. Ә әлегә хәтта Брежнев шәһәренең Автозавод районында да сигезенче классны тәмамлаучыларның 15 проценты, унынчы классны тәмамлаучыларның 35 проценты гына үз киләчәген КамАЗның машина төзү профессияләре белән бәйли. Ә завод гигантлар эшче кадрлар җитмәүдән интегә.

Икенчедән, өлкән класс укучылары, ягъни сигезенче классны тәмамлап тугызынчы классларга күчкән егетләр һәм кызлар, вузда яки техникумда укуны дәвам иттерү өчен гадәттә профессиональ юнәлеш алган булалар инде. Әмма эшче профессияләренә юнәлешне күпләр формаль төстә генә кабул итә. Димәк, мәктәп мәгънәсез эшкә вакыт сарыф итә. Әле үз юлын һәм һөнәрен сайламаган үсмерләргә генә юнәлеш бирергә мөмкин. 5–8 класс укучыларының барысы да завод цехларына бармаячак, әлбәттә (шөкер!), ә инде аңлы рәвештә эшче професссиясен сайлап алучылар училищеда яхшы укыячак.

Шунлыктан өлкән класс укучыларын (шартлар булган урыннарда) УПКдан чыгару һәм предприятиедә, ПТУ мастерскойларында эшкә өйрәтү максатка ярашлы. УПКларда 5 класс укучыларын укытырга кирәк. Казан шәһәренең Мәскәү районында, мәсәлән, еллар буе сыналган яхшы тәжрибә бар. Профессиональ юнәлеш бирү эшенең нәтиҗәләре сокландыра. 1981 елда 8 классны тәмамлаучыларның нибары 8 проценты эшче һөнәрен сайласа һәм ПТУларга керсә, ике елдан соң бу 18 процент,

1987 елда исә 33 процент булды. Безне сан күрсәткечләре кызыксындырмый. Производствога өйрәтү мастерлары әйткәнчә, УПК–2 не тәмамлап чыгучылар токарь станокларында кыюрак эшлиләр, инструментлар белән эшләү күнекмәләре бар, сызымнарны һәм технология документларын яхшырак укыйлар; брак җибәрүләре дә аз. УПКларда профессиональ юнәлеш бирү эшенең иң мөһим йомгагы шунда, аларны тәмамлап чыгучыларның күпчелегендә (94 процентында, ә районның башка мәктәпләрендә –36) һөнәргә ныклы омтылыш формалашкан була. Казан шәһәрендәге УПК-2 тәҗрибәсенең кыйммәте шунда.

Әлбәттә, сүз мәсьәләгә принципиаль якын килү турында бара. Кайдадыр иске методлар белән дә уңышлы эшлиләр. Барысы да җирле шартларга бәйле.

XXI гасырның үрнәк кешесе булуда, балалар һәм аларның ата-аналары өчен кызыклы, укучыларны белем серләренә төшендерү өчен тылсымлы көчкә ия булуда укытучыларга һәм производствога өйрәтү мастерларына ничек ярдәм итәргә? Киңәшләрнең иң мөһимен әйтеп китәргә кирәк: андый биеклеккә ирешү өчен укытучыларга проблемалы фикерләүне беренче планга куярга, үзеңдә балаларга карата мәхәббәт һәм тагын бер тапкыр мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Беренче чиратта шундый биеклеккә ирешергә укытучы үзе омтылырга тиеш. Белемеңне туктаусыз күтәрүдән, үз-үзеңне тәрбияләүдән башка берни дә, беркем дә ярдәм итә алмаячак. Политик яктан актив булырга, классик һәм заман поэзиясеннән, прозадан аерылмаска, балалар интереслары белән, үз җәмгыятең, үз чорың проблемалары белән яшәргә кирәк. Үз фәнеңә — математика һәм физикага һаман тирәнрәк керә белү кирәк. Иң мөһиме — һәр укучыны өйрәнү һәм белү. Укытучы һәм мастерны ахыргы нәтиҗә өчен тиешенчә түләү белән дә кызыксындырырга мөмкин. Яхшы укыткан һәм тәрбияләгән өчен күбрәк түләргә кирәктер.

Профессиональ мәктәп укытучыга ижади эшләү өчен мәйдән ачарга тиеш. Моның өчен уку программаларының, дәреслекләр һәм мәсьәләләр җыентыкларының яңа вариантлары кирәк. Барлык уку предметлары буенча фәнни-популяр брошюралар һ.б. кирәк.

Бүген укытучыга нәрсә белән ярдәм итеп була? Беренчедән, аңа җәмгыятьтә үзгәртеп кору атмосферасы, дәүләт, Мәгариф министрлыгы һәм Профтехбелем дәүләт комитеты тудыра торган материаль һәм мораль шартлар булышачак. Икенчедән, нинаять, фән рекомендацияләрен кертүдә эшнең уңышлы баруның 90 проценты укытучының үзенә, профтехучилище дирекциясенә бәйле булуын аңлау кирәк.

Ә бәлки новаторлар тәжрибәсеннән башка берни дә кертмәскәдер? Әгәр шулай икән, зур ялгышу бу. Профпедагогика фәнни-тикшеренү институтында эшләгән һәм практикада ахырынача үзләштерелмәгән мәсьәләләр күп әле. ПТУда үсмерләрнең үзидарәгә һәм үзфинанслауга күчә торган предприятие өчен кирәкле нәрсәләргә өйрәнергә тиешлеген һәркем белә. Димәк, аларны демократиягә, хәбәрдарлыкка, экономикага, үзидарәгә, аралашу осталыгына өйрәтергә кирәк. Мөстәкыйль карарлар кабул итәргә өйрәтергә, производство, этика, идарә итү проблемаларын чишәргә өйрәтергә кирәк. Моны проблемалы укытудан башка эшләп булмый.

Проблемалы укытуны без теория дәрәҗәсендә дә, аерым предметларны укыту методикасы дәрәҗәсендә дә эшләдек. Әмма иске карашлы укытучылар һәм директорлар укытуның яңа тибын кабул итмиләр. Чөнки проблемалы укытуны кертү укытучының күбрәк хезмәт куюын, тагын да ижадирак эшләвен таләп итә. Әмма бит В.Ф. Шаталов, Н.П.Палтышев тәжрибәсе — зур хезмәт ул, ачы да, татлы да ижат газабы ул. Педагогикада тәжрибәне кабатлау

мөмкин түгел, ә тәҗрибә идеясен, эзләнү юнәлешен ачыкларга һәм **иҗатны кабатларга** мөмкин.

1.6. Фикерләргә өйрәтәбезме?

(“Соц. Татарстан”, 9 октябрь, 199О ел)

Ләкин «иҗат» дип әйтү генә ансат. Берәү тумыштан шагыйрь була, икенчесен йөз ел әлифне таяк дип өйрәтсәң дә белә алмый. Бу проблеманы ничек хәл итәргә соң?

Иҗади фикерләү нәрсә ул? Кыска гына әйткәндә фикерләү нәтиҗәсендә элек кешеләргә мәгълүм булмаган яңалык килеп чыкса, ниндидер бер ачыш, уйлап табу булса, шул иҗат җимешенә санала. Ләкин кешеләр төрлечә уйларга күнегә. Бер ишесе мәгълүмат туплап канәгатьләнә, икенчеләре тикшерә торган мәсьәләләрнең уңай якларын гына күрә (оптимист кешеләр), өченчеләре аның кире якларын гына алга сөрә (писсимистлар, димәк) һ. б.

Кешенең табигый уйлау сәләтенә карап, фикерләү процессын америка психологлары берничә «баскычка», стильгә бүләләр. Алгоритмик фикерләү, ягъни мәгълүмат туплап кына уйлану, тәнкыйти фикерләү, конструктив фикерләү, логикага таянып проблеманы хәл итү, эмоциональ фикерләү тойгысы, хиссияткә таянып уйлану һәм креатив (эзләнү) фикерләү. Менә бу стильләр барысы бергә булганда иҗади фикерләү килеп чыга. Боларның һәрберсенә кешене өйрәтеп, күнектереп була. Проблемалы укытуның хикмәте дә шунда.

Хәер, педагогиканың бөтен тарихы мәктәптә балаларны ничек укытырга кирәклеге турында бәхәсләр белән тулы. Илленче елларда җәмәгатьчелек гомуми белем мәктәбенең баланы хезмәткә, тормышка әзерләү дәрәҗәсе җитешмәвен сизде. Бу исә 1958 елдагы реформага китерде. Шул уңайдан совет педагогикасында аңлатма-

күргәзмә укытуга йөз тоткан белем бирү процессын активлаштыру алымнарын эзләү башланды.

Галимнәр теория һәм методикалар эшләделәр. Ә укытучыларның күбесе, җитди теоретик хәзерлекләре булмаганлыктан, аңлату-күргәзмә укыту принцибы буенча эшләүләрен дәвам иттеләр.

Шул ук вакытта талантлы мөгаллимнәр, укытуның нәтиҗәлерәк алымнарын эзләп табып, укучыларның аңлатып бирелгән материалны ятлауларына гына түгел, бәлки аларның биремнәр, мәсьәләләр өстендә мөстәкыйль эшләүләренә ирештеләр. Алар уңышының сере нәрсәдә, нинди принципка юнәлгән соң?

Тора-бара алдынгы тәҗрибәне, практиканы анализлау һәм дидактика казанышларыннан файдалану, активлашу һәм фикерләү психологиясе нигезендә укытуның яңа теориясе билгеләнде. Баштарак ул да укучыларның белем алу эшчәнлеген активлаштыру юнәлешендә алып барылды. Әмма соңыннан анда фәнни принциплар өстенлек итә башлады. Философиянең төп формасы булып проблема тора, чөнки кешенең фикерләве һәрвакытта да проблемаларны хәл итү юлы белән үсә (Э.В.Ильенков) дип күрсәтте. Чит ил һәм совет психологлары кешенең фикер йөртүе, аның нинди дә булса проблема белән очрашуыннан, проблемалы ситуация килеп чыгудан (С.Л.Рубинштейн) башлана дигән карашта торалар.

Табигый, бәлки, укыту процессын проблемалы ситуация тудырып, укучыларны даими рәвештә алар белән очраштырып, аларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү мөмкинлеге бирергә кирәктер, дигән сорау туа. Ләкин проблемалы укыту идеясе чит илләрдә гасыр башында ук туган булса да, психологиядә дә, дидактикада да теоретик яктан эшләнмәгән иде. Педагоглар аңа әкренләп якынлаштылар.

Проблемалы укыту теориясе бөтен тулылыгы белән җитмешенче еллар башында «Проблемалы укытуның теориясе һәм практикасы» (Казан, 1972 ел) дигән рус телендә чыккан беренче монографиядә дөнья күрде. Бу теория совет һәм чит ил галим-педагоглары тарафыннан алдынгырак теория дип танылды.

Яңа педагогик технология укучыларның зиһеннәрен генә түгел, ә бәлки фикерләү сәләтләрен дә үстерүне күздә тота иде. Ләкин монда тагын бер «ләкин» бар. Укучыны ятлатырга мөмкин, фикерләтергә мөмкин түгел. Кеше үзе теләсә генә фикер йөртә. Укытучы билгеле, һәрвакытта да укучыларын яхшырак укытырга тели. Ләкин бөтен бәла дә шунда команда администраторлык системасы мәгариф өлкәсендә дә тамырларын тирәнгә җибәрергә өлгергән иде. Мәсәлән, укытучыларга өлгермәгән укучыларны классында икенче елга калдыру да рөхсәт ителмәде. Бу укучыларның җаваплыгын киметте, ә укучыларның икенче елга калу хурлыгын бетерде. Өлгерүчеләрне дә класстан класска күчерү гаделсезлеге балаларда гомумән белемгә омтылышны киметте. Шул рәвешчә, укучылар арасында укуга битараф караш таралды.

Укытучының эш хакы түбән, ким. Ул акча эшләү максатыннан үзенә күбрәк нагрузка алды. Укучыларны уйларга, фикер йөртергә өйрәтүгә караганда, сөйләү, аңлату җиңелрәк, әлбәттә.

Ә ил буенча гомуми хәл менә болайрак: предприятиеләр техник яңалык таләп итмәделәр, чөнки аларның үзләреннән дә сыйфат түгел, күләм генә таләп иттеләр. Халык хуҗалыгы элеккечә галимнәрнең яңа идеяләренә, технология һәм эшләнмәләренә мохтаҗ булып кала бирде. Яңалык кертү яки аны куллану юлында предприятиеләрне экономик кызыксындыруның берәр төрле механизмы әле дә эшләмәгән. Мәктәпләр дә педагоглардан яңалыклар таләп итмәделәр.

Әмма ләкин укучыларның танып-белү сәләтен үстерү методының киң күләм практикада кермәвенең төп сәбәпчесе укытучылар түгел. Укыту процессының узган 20 елына ясалган анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, моның җитдирәк сәбәпләре дә булган.

Мәктәптәге торгынлык чорының нигезендә педагогика түгел, ә социаль-экономик мәсьәләләр ята. Һәрхәлдә аларның икесен һич шикләнми әйтергә була. Беренчесе - үсеш һәм тәрбия теориясен тоткарлап торучысы, педагогиканың артык идеологияләштерелгән булуы, икенчесе - мәгарифтә экономик стимул булмавы. Алар дидактиканың үсешен, аның уңышларын киң практикага кертүне тоткарладылар. «Вал»га, санга исәпләнгән экономик система техник яңалыкларны да, үз хезмәткәрләренең техник һәм социаль иҗатларын да кабул итмәде.

Бәлки, без вакыйгаларны артык күпертеп, күңелдәге нәрсәләрне чынбарлык итеп күрсәтергә тырышабыздыр? Һич юк. Бөтен система һәм сәяси, һәм экономик эшченең югарыдан төшерелгән планнарны үтәү инициативасына исәпләнгән иде. Җитештерүне оештыручыларның, инженерларның, урта һәм югары буынының эшчәнлеге инструкцияләр, күрсәтмәләр рәвешенә билгеле бер алгоритмнар аша башкарылды. Ул инструкцияләрне дистә еллар дәвамында министрлык һәм ведомстволар чиновникларының күп буыны эшләде. Байтак кына конструкторлык биналарында инженерларның фикерләре агымдагы технология кысаларында йомылып калды, технология өлкәсендә яңалыклар кертелмәде, чөнки промышленность җиһазлары искерде, ул алдынгы техник фикердән уннарча елга артта калды. Производствода кул хезмәте һаман да күп урын алды. Ул хәзер дә әле 40 процентка якын тәшкил итә. Ә төзелештә һәм авыл хуҗалыгында кул хезмәтен куллану 70 – 80 процентка җитә.

Сыйфатка түгел, санга йөз тоткан авыл хуҗалыгы, мәсәлән, «зур сөтне» сыерларның нәселен яхшырту хисабына түгел, ә бәлки аларның санын арттыру хисабына алырга тели. Мул уңыш өчен көрәштә дә шулай. Югары агротехника чараларын һәм ашламаларны белеп, дөрес итеп куллану турында уйламыйлар, ә чәчү мәйданын ничек арттыру турында баш ваталар. Хәзер бездә тракторлар Америка Кушма Штатларындагыга караганда шактый күп, ә икмәкне без барыбер алардан сатып алабыз.

Промышленностьта да шундый күренеш. Җитештерүне яңа техника һәм технологиягә нигезләнеп арттырасы урында, яңа предприятияләр төзү һәм эшче кулларның санын арттыру исәбенә эшләргә тырышабыз.

Мәгарифкә килгәндә исә, ул һәрвакытта да финанслауның калдык принцибында көн күрде. Сугышка чаклы укытучыларның эш хакы ил буенча уртачадан югары иде. Хәзер ул 60–80 сумга түбән. Әгәр Көнбатыш Европада мәгариф кирәк ярагына тотыла торган уртача дәүләт бюджеты проценты 7–10 процентка тигез булса, бездә соңгы ике елда әкрен генә 2,8 дән 3,4 процентка күтәрелде. АКШта укучы башына 4–5 мең доллар тотылса, бездә 240 сумнан да ким. Безнең мәктәпләр бер баланы укыту максатына елына 35 сум тотарга тиешләр, ә чынбарлыкта исә ул 3 сумнан артмый. Укучыларны тукландыру өчен елына 90 сумга якын акча каралган. Ләкин ул 5 сум гына тотыла. СССР Югары Советына боларның барысы да билгеле.

Боларга өстәп, мәктәп алдында торган мөһим бурычларның берсе – укучыларда марксистик-ленинчыл караш формалаштыру булганлыгын әйтергә кирәк. Партиянең идеология эше үзе бөтен кешене марксизмның теоретик вәгъдәләрен, хакыйкатьнең соңгы баскычы буларак, догматик рәвештә ятлауга юнәлдерелде. Шуңа

укучылар арасында да шикләнүләр, бәхәсләр турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Шулай итеп, без, фәнни-тикшеренү нәтиҗәләрен практикага кертергә бөтен система тоткарлык ясады, дип әйтә алабыз. Бу язмыш мәктәпкә дә, педагогикага да турыдан-туры йогынты ясады.

Менә инде хәзер үзгәртеп корулар мәктәп алдына яңа проблема куя. Ничек итеп балаларда укуга, фәнни белемгә кызыксыну уятырга? Бу – бүген төп сорауларның берсе. Методик юл белән генә аны чишеп булмый, чөнки бу социаль педагогик проблема. Укытуның мотивын торгызу өчен гадел хезмәт мотивын да яңадан торгызырга кирәк. Мәгарифнең экономик стимулын яңадан кайтарырга кирәк. Инженер, укытучы, врач эш хакын 8 класс белеме эшчедән азрак алганда, түләүле уку кертелмәгәндә яшьләр китап тотып каңгыраеп утырмаячаклар. Техник вузларда конкурс бетү шуның ачык мисалы түгелмени?! Илдә 3,5 миллион инженерның, үз белгечлеге буенча эшләмичә, станок артына басуы да очраклы хәл түгел. Моның сәбәбе бармы? Бар, әлбәттә, ПТУларда эшчеләр әзерләү сыйфаты ифрат дәрәҗәдә түбән, һәм алар заман техникасына хезмәт күрсәтә алмыйлар. Ә инженер-көйләүче эшченең югары хезмәт хакын кулайрак күрә.

Ләкин моннан кем оттыра? Дәүләт, халык? Инженерлыкка укыту эшчене хәзерләүгә караганда күп өлеш кыйммәткә төшә; ә инженерлары баш белән түгел, кул белән эшләнгән җәмгыять беркайчан да алга китмәячәк. Бәлки шуңа безнең илдә хезмәт җитештерүчәнлеге дәрәҗәсе АКШка караганда өч тапкырга, ГФРга караганда 3,5 тапкырга кимрәктер.

Мәктәпне идарә итүдә күп еллар буена барган административ-команда стиле нәтиҗәсендә югары класс укучылары укырга да өйрәнмәгән, укуга кызыксыну да уянмаган килеш һөнәр мәктәбенә киттеләр. Биредә мәктәптәге күренеш яңадан кабатланды, ләкин

инде тагын да начаррак вариантта: кабул ителгән укучыларны исән-имин саклап калу нияте белән, укытучылар хәтта иҗтимагый фәннәр дәресенә йөрмәгән укучыларга да сихри көчкә ия булган «3»не куйдылар, программаны аз-маз «сукалаган» укучыларга югары разряд, хәтта «кызыл диплом» да биреп чыгардылар. Билгеле, производствога килгәч, үсмер бу «ышаныч»ны аклый алмый иде.

Хәер, әгәр илленче елларда халык хуҗалыгы хезмәтне оештыру, кадрлар структурасын һәм үз функцияләре буенча илдә гомуми сигезьеллык белем, ә җитмешенче елларда гомуми мәҗбүри урта белем кертергә әзер булмаган бер чорда, мәгарифнең алга китүе турында нинди сүз булырга мөмкин соң. Җитештерү техникасы һәм технологиясе түбән белемле эшчеләргә дә риза иде. Хезмәт базары сигезьеллык һәм тулы булмаган урта белемлеләр белән тулды. Белемнәре төрле дәрәҗәдә булган үсмерләрне эш хакы бертигез түләнә торган эшкә алдылар, бер төрле үк һөнәрләргә өйрәттеләр һәм өйрәтәләр. Мәсәлән, мин үзем моннан ун ел элек шундый күренешкә тап булдым. Тарту шәһәрендәге төзүчеләр әзерли торган 16 нчы училищеда ун класс белемле үсмерләр ярдәмче мәктәп (акылга зәгыйфь) укучылары үзләштерә торган төзүче, балта остасы һөнәрен үзләштерәләр иде. Ун класс белемле яшьләр акылга зәгыйфь булган балалар белән бер үк хезмәт хакы алдылар. Шулай булгач, аларның хезмәткә карашы ничек буласы билгеле түгелмени? Бер очтан, мәктәпкә, дәүләткә карашлары да.

Без биредә экономик мәсьәләләргә тукталдык. Чөнки бүген техник прогресс белем алу белән никадәр тыгыз бәйләнгән булса, алга китеш, искечә әйткәндә тәрәккыять тә белем белән шулай тыгыз бәйләнгән. Белем бирү системасы җәмгыятьтә экономик үсеш һәм хезмәт культурасы дәрәҗәсенә тиң булырга тиеш. Әгәр бу тигезлек булмаса, ул вакытта система үз бурычларын үти алмаячак. Кызганычка каршы, безнең педагогика бервакытта да диярлек бу

бәйләнештән чыгып эш итмәде. Ул өстенлек итүче идеология буйсынуында булды. Хәер, ул гына да түгел, экономика үзе дә шулай иде.

Яңадан, мәктәп һәм аның фәне өчен тупиктан чыгу юлы кайда соң? Иң мөһиме – халык мәгарифе системасын калдык принцибыннан чыгып финанслауны бетерүдә. Бөтен укытучылар корпусын җитди хәзерләү кирәк, шул исәптән югары педагогия уку йортларында да. Башта укытучы үзе мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнсен иде. Профессиягә өйрәтү, һөнәр бирү өчен уку йортларының структурасын да, укыту программаларын, планнарын, дәреслекләрне һәм укыту методларын да үзгәртү мөһим һәм мәҗбүри.

Боларның барысы өчен фундаменталь тикшеренүләр үткәрергә, замана баласының, үсмерләрнең кызыксынучан психологиясен, аның табигать биргән сәләтен, кызыксыну, мавыгуын өйрәнергә кирәк. Укытучы-мөгаллимнәр психологиясен, аның тормыш көнкүреш таләпләрен һәм профессиональ кызыксынучанлыгын өйрәнергә вакыт җитте түгелме соң? Шуннан башка фәнни-техник революция турында, яхшы товарларны, азык-төлекне җитәрлек дәрәҗәдә җитештерү турында, үзара мәдәни, әхлакый мөнәсәбәтләр, иҗади хезмәттәшлек турында сүз дә алып бару мөмкин түгел.

1.7. Мәгърифәтче Шиһап Әхмеров

Мәгърифәтче дигәч, культурабыз тарихында аерым дәверләр тәшкил иткән Хәлфиннар династиясе, Каюм Насыйрилар күз алдына килеп баса. Бездә исемнәре әле киң катлау укучыларга яхшы билгеле булмаган, халык мәгърифәте, мәктәп-мәдрәсә, китап, журнал, театр өлкәсендә җиң сызганып эшләп килгән зыялылар аз түгел. Татар мәгърифәтчелегенә багышланган хезмәтләрдә, күп очракта, халык

мәгарифенә зур өлеш керткән кешеләрне искә алып үтү белән чикләнәләр, аларның шәхес буларак тормышы һәм эшчәнлеге турында җәелеп тормыйлар. Ә бит фәннең, сәнгатьнең, әдәбиятның, шул исәптән мәгърифәтчелекнең һәр өлкәсендә теге яки бу уңышлар аерым шәхесләр эшчәнлегенә барып тоташа. Шуңа күрә теге яки бу шәхеснең тормышын, иҗатын, аны тәрбияләп үстергән мохитнең аның формалашуындагы ролен өйрәнү — шул өлкәнең тарихын өйрәнү булып саналырга тиеш.

Биредә сүз исеме югарыда искә алынган, киң катлау укучыларга аза билгеле булган, культурабызның төрле өлкәләрендә эшләп килгән Шиһап Әхмәров турында. Шиһап Шәрәфетдин улы Әхмәров 1882 елның 30 декабрендә элеккеге Сембер губернасы Буа өязе, Чүпрәле волосте Яңа Задур авылында крестьян гаиләсендә туган. (Вафаты Казанда, 1966 елның 30 апрелендә.)

Шиһап Буа мәдрәсәсендә укып белем ала. Ул шәхес буларак XIX йөзнең ахыры һәм XX йөз башында илдә, шулай ук татар тормышында зур үзгәрешләр барган елларда формалаша. XIX йөз ахырында мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә башлаган Буа мәдрәсәсендә уку елларында ук Шиһап Әхмәровта халыкка хезмәт итү юлына керешү хисләре туа. Беренче рус революциясе, илдә барган революцион-демократик хәрәкәт, милли азатлык өчен көрәш идеяләре көчәйгән иҗтимагый шартлар аны мәгърифәтчелек өлкәсенә алып кереп китә.

Мәдрәсәне тәмамлаган яшь Шиһап мәгърифәткә хезмәт итү юлын Әлмәттә укытучы булудан башлап җибәрә. Биредә схоластик тәртипләргә корылган мәктәп-мәдрәсәләрнең нәрсәгә китерүен тагын да тирәнрәк аңлый башлагач, ул дөньяви юлга корылган мәктәпләргә юл ачу өчен дөньяви фәннәр буенча уку китаплары, дәреслекләр җитештерү кирәклеген бик яхшы төшенә. Дөрес, татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен дөньяви дәреслекләр инде XIX гасырның

икенче яртысында, бигрәк тә аның соңгы чирегендә шактый басыла башлаган була. Ләкин андый дәреслекләр әле җитәрлек түгел, күп кенә фәннәрдән исә бөтенләй булмаган. Менә шушы нәрсә Ш.Әхмәровта үзе дә дәреслекләр язып карау хисе тудыра, шул өлкәдә беренче тапкыр тәҗрибә дә ясап карый. Һәм аның «Мөнтәхиб әлифба» дигән ике кисәктән торган хезмәте 1908 һәм 1909 елларда аерым китап булып басылып та чыга.

1908 елны Шиһап Әхмәров Әлмәттән Казанга килә. Мәктәп-мәдрәсәләр өчен уку китаплары басу белән шөгыльләнә торган «Сабах» көтепханәсе дигән нәшриятта эшли башлый. 1902 елда бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәдуллиннар тарафыннан оештырылган, вакытында «Көтепханәи иптидаия» исеме белән билгеле булган бу нәшриятның төп максаты дәреслекләр китаплары басу була. Ш.Әхмәров «Сабах» нәшриятының китап кибетендә эшли, шул ук вакытта мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр һәм матур әдәбият авторлары белән элемтәгә керү, алар язган әсәрләрне сайлау, типографиядә бастыру эшләре тулысынча аңа йөкләтелгән була. Ш.Әхмәровның турыдан-туры катнашы белән «Сабах» нәшрияты 1912 елның 21 июнендә үзенә типография ача, соңыннан бу типографиягә И.Н.Харитонов типографиясе дә кушыла. Татар китаплары басу буенча бу типография Казанда иң алдынгы басмаханәгә әйләнә.

Бу типографиядә Октябрь революциясенә хәтле миллион ярым тираж белән 400 дән артык татар китабы бысылып чыга. Аларның төп өлешен татар мәктәпләре өчен басылган китаплар тәшкил итә. Бу дәреслекләрнең авторлары арасында без күренекле татар әһелләре, галимнәре, педагогларының хезмәтләрен күрәбез. Алар Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, М.Корбангалиев, Н.Думави, М.Галәү, Г.Алпар һәм башкалар. «Сабах» нәшрияты чыгарган мәктәп китаплары арасында рус педагоглары дәреслекләре дә аз түгел.

Ш.Әхмәров инициативасы белән «Өмед» нәшриятында да күп кенә башка татар язучыларының китаплары — Г.Камал, М.Фәйзи, Ш.Әхмәдиев, Ф.Кәримов һәм башка әдипләрнең әсәрләре дөнья күрә. Татар укучыларын башка халыклар әдәбиятлары белән таныштыру йөзеннән татар теленә тәрҗемә ителеп Л.Толстой, И.Куприн, Г.Гейне кебек классикларның хикәя, повесть, шигырьләре басыла. Нәшриятның репертуарында киң халык массаларына адресланган фәнни-популяр характердагы, шул исәптән авыл хуҗалыгына караган басмалар да очрый. Бу басмалар нәшриятының халыкка дөньяви белем тарату буенча да эшләнгәнлеген күрсәтә. Китап репертуарының халык мәгърифәтенә буйсындырылуы Шиһап Әхмәровның эшчәнлегенә турыдан-туры бәйләнгән диярга була. Ул нәшриятка килгәч Әхмәдуллиннар нигездә типография осталары буларак кына эшли башлыйлар дип әйтергә мөмкин, китап басу өчен әсәрләр сайлау, аларны чыгару юлларын таптау Ш.Әхмәров җилкәсенә төшкән.

Нәшрият тарафыннан мәктәпләр өчен дөньяви дәреслекләр, төрле өлкәләргә караган фәнни-популяр хезмәтләр, прогрессив язучыларның әсәрләре бастырылып килүе — нәшриятның һәм аның басмаханәсенең мәгърифәтчелек позицияләреннән чыгып эшләвенә тагын бер дәлил булып тора.

Китап дөньясына килеп кергән Ш.Әхмәров басмачылык тарихы белән дә кызыксына. Бу кызыксынуның нәтиҗәсе буларак аның «Матбагатчылык тарихы» дигән китабы дөнья күрә. Бу хезмәт авторның матбагатчылык тарихы буенча заманы өчен зур эрудицияле зыялы булуын күрсәтә. Бу хезмәт татар китабы тарихы буенча язылган иң беренче зур хезмәт буларак та үзенең тарихи әһәмиятен әле дә югалтмаган. Анда төрле вакытта эшләп килгән, татар телендә китап басу белән шөгыльләнгән һәр басмаханәнең диярлек кыскача тарихы яктыртылган. Татарларда басмачылык эшенең тарихын өйрәнү шушы хезмәттән башлана диярга була. Дөрес, бу темага Риза Фәх-

ретдинов язган хезмәтләрне дә кертергә кирәк, ләкин алар икенче планда язылганнар.

Менә бу фактлар Ш.Әхмәровның китапчы гына түгел, шул ук вакытта китап тарихы, басмачылык тарихы буенча да белгеч булуын күрсәтәләр

Татар китабының үсешендә зур роль уйнаган рус типографы И.Н.Харитонов исеме китап белгечләренә яхшы билгеле. Ул, бертуган Әхмәдуллиннар белән университет типографиясендә бергә эшләп үскән полиграфист, шул ук вакытта Ш.Әхмәровның да дусты булган. Бертуган Әхмәдуллиннар инициативасы белән үзләренең дусты И.Н.Харитонов турында язылган бер китап дөнья күрә. Аның авторы күрсәтелми. Бу хезмәтнең авторы Ш.Әхмәров булу мөмкинлеген әйтми үтеп булмый. Моның шулай булуын күп нәрсәләргә таянып якларга була, бу урында без шул гипотезаны кую белән чикләнәбез.

Шиһап Әхмәров күренекле редактор, журланист та иде. Ул 1913 елда Казанда татар телендә чыга башлаган беренче педагогик журнал «Мәктәп»нең редакторы була. Әхмәдуллиннар хисабына чыга башлаган бу журналны оештыруда иң актив катнашкан кеше дә Ш.Әхмәров булуына шикләнер урын юк.

Бу журналның дөньяга килү тарихы гомумән өйрәнелмәгән. Шул уңайдан без биредә кайбер фактларга игътибар итеп үтәргә булдык. Билгеле булганча, журналның беренче саны бөек шагыйребез Габдулла Тукайның шигыре белән ачылып китә. Менә шушы факт журналны оештыруда Г.Тукайның да катнашы булуы мөмкинлеген күрсәтә. Бу фикерне куәтләүче башка дәлилләр дә китереп булыр иде. Мәсәлән, 1912 елда 15 декабрьда чыга башлаган «Аң» журналының беренче саны да Г.Тукай шигыре белән ачыла. Архив документларыннан күренгәнчә, бу журналны оештыруда да Г.Тукай актив катнашкан. Аның нәшире һәм редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни

белән дус булган, аралашкан, киңәшләшкән тукай, күп тапкырлар редакциягә, Ә.Хәсәни янына килеп йөргән.

Ш.Әхмеров та, Әхмәтгәрәй Хәсәни дә — Габдулла Тукайның дуслары. 1908 елдан башлап әдипнең вафатына хәтле аның белән аралашып, фикерләшеп, чәйләшеп, көн саен диярлек очрашып яшәгән. Ш.Әхмеров белән Г.Тукайның күп теләк, уйлары, хыяллары бер булган дип әйтергә була. Алар бер чорда, бер шәһәрдә генә түгел, бер кунак йортында, «Болгар» номерларында (хәзерге Татарстан белән Киров урамнары чатындагы бина) бергә яшәгәннәр. Әнә шунда яшәү елларында алар нык дуслашканнар. Ш.Әхмеров өйләнгәч, «Болгар»дан квартирага китә. «Болгар» номерларында торып калган Тукай шуннан соң да Әхмеровлар гаиләсендә еш була. Менә шул киңәшүләр, халык мәгърифәте турындагы бәхәсләрдә педагогик журнал оештыру мәсьәләсе, һичшиксез, күп тапкырлар кузгатылган булырга тиеш. Ш.Әхмеровның педагогия өлкәсендәге эшчәнлеге турында сүз барганда, ул редакцияләгән «Мәктәп» журналы турында да бер-ике сүз әйтми үтү мөмкин түгел, чөнки ул журнал Ш.Әхмеров эшчәнлегенең көзгесе бит. Журналның программасы гаять киң була. Бу журнал чыгаруның максатын тулырак күз алдына китерү өчен әнә шул программа белән бераз танышып үтик.

Ул программа 28 бүлектән тора. Анда педагогик тәрбия мәсьәләләре, урта һәм түбән классларда укытыла торган фәннәрне укыту методикасы, мәктәп-мәдрәсәләргә карата руханилар һәм җәмәгать-челекнең тоткан урыны, аларда гомуми белем бирү һәм аны дәүләт гимназиясе программасына яраштыру, мөселманнарга техник белем бирү, мөселман балаларына мәҗбүри башлангыч белем бирү, хатын-кызларны укыту кебек пунктларны күрәбез. Алардан тыш «Мәктәп» журналының программасы буенча журналда аерым фәннәрдән лекцияләр, мәкаләләр, авыл хуҗалыгына караган яңалыклар, татар мәктәпләренең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге, татарларда башлангыч

белемнең торышы, татар мәктәпләре системасы, мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллим һәм мөгаллимәләр хәзерләү, татар уку йортлары һәм аңа хөкүмәтнең карашы кебек темалар яктыртылырга уйланыла. Болардан тыш программа буенча журнал битләрендә хөкүмәт уку йортларында укучы татар яшьләренә туган телне, татар әдәбиятын һәм тарихын йөртү, мәктәп-мәдрәсәләренең материаль ягын ничек кайгырту, шул исәптән бу мәсьәләдә җирле властьлар һәм земство, мәктәп-мәдрәсәләргә карата хөкүмәтнең рәсми боерык һәм күрсәтмәләре дә чагылырга тиеш була. Шул ук вакытта журнал мәктәп-мәдрәсәләр, педагогия, методика буенча төрле телләрдә чыккан хезмәтләр турында очерклар басуны һ.б. шундый күп нәрсәләрне яктырту бурычын алган. Бу программа, һичшиксез, Ш.Әхмеровның актив катнашында төзелгән, чөнки ул алдан ук журналның җаваплы редакторы булу вазифасын үз өстенә алганда аның программасын белмичә, бу эшкә алынмас иде. Дөрес, журналны чыгару өчен үтенеч белән губернаторга инде әйтеп үтелгән Әхмәдуллиннар, дөресрәге Габделвәли мөрәҗәгать итә. Югарыда билгеләп үтелгәнчә, алар нәширлек эше белән түгел, полиграфия эше белән шөгыльләнгән затлар. Прогрессив карашлы, татар китабы үсешенә зур өлеш керткән Әхмәдуллиннар журнал чыгарырга рөхсәт сорап Ш.Әхмеров һәм аның якыннары үтенече белән мөрәҗәгать иткәннәр. Алар арасында Г.Тукай да булган дип уйлый алабыз.

Бу журнал озын гомерле булмый. Беренче империалистик сугыш башлангач, 1914 елның көзендә басылудан туктый. Үз алдына куйган зур программасын тулысынча үтәп чыгып җитә алмый. Бу журналда татар мәктәбе, мәдрәсә турында, аны заманча оештыру турында һ.б. күп кенә мәкаләләр басылып чыга. Анда басылган мәкаләләрнең авторлары арасында без атаклы педагог, галим, М.Корбангалиев, язучы һәм педагог Н.Думави, тарихчы галим Г.Гобәйдуллин, язучы һәм педагог Ф.Сәйфи-Казанлы һәм башкаларны күрәбез. Шул

ук вакытта Ш.Әхмеров үзе дә, редактор буларак кына түгел, автор буларак та журналда катнаша башлый, аның татар хатын-кызларына гимназия ачу кирәклеге турында мәкаләсе шунда дөнья күрә. Журналда әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә караган материаллар да күренгәли башлый, атаклы артист Г.Кариевның да мәкаләсе басылып чыга. Г.Тукай вафат булгач, журналның бер саны аңа багышланып чыгарыла.

Татар иҗтимагый тормышында иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булган һәм иң зур бәхәсләр барган өлкә — «мәктәп-мәдрәсә» мәсьәләсе. Әнә шул катлаулы мәсьәләдә арадашчылык ролен алган редакторы булу заманы өчен гаять җаваплы хәл булган. Ш.Әхмеровның культурабыз, мәгърифәтчелек өлкәсендә эшчәнлеге турында сүз алып барганда без моны онытмаска тиешбез.

Ш.Әхмеров Октябрь революциясеннән соң да журналистлык эшен тәмамлады. Аның Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев турында язган истәлекләре әнә шуны сөйли. Салих Сәйдәшев исемен искә алгач, тагын бер нәрсәне әйтергә кирәк. Кечкенәдән ятим калган Салихны, Ш.Әхмеров үз улы итеп тәрбиягә ала. Салих Әминә ханымның — Ш.Әхмеровның хатынының — бертуган энесе була. Шиһап Әхмеров малайның гадәти булмаган бай, нечкә күңелен, музыкага сәләтен һәм омтылышын бик тиз сизеп ала һәм аңа төрлечә ярдәм итәргә тырыша. Шул максат белән ул Салих өчен музыка укытучысы чакыра. Сәйдәшнең бәхетенә каршы, бу укытучы татар халкының беренче халык композиторы Заһидулла Яруллин була. Салих Сәйдәшевның композитор булып формалашуына Әхмеровлар гаиләсе игелекле йогынты ясый. Инде танылган композитор булгач та Салих Сәйдәшев Шиһап ага Әхмеровны үз әтисе кебек хөрмәт итә, олылый.

1908 елдан башлап Г.Тукай белән аралашып килгән, аның соңгы минутларында янында булган кеше буларак та Ш.Әхмеров шәхе-

се кызыксыну уятыр иде. Чит кешеләр белән тиз якыная алмый торган Тукайның якын дусты булу үзе генә дә аның шәхес буларак киң күңелле, чын кеше булуын сөйли. Үлем түшәгендә яткан шагыйрьнең соңгы рәсемен алдыручы да ул булган.

Халкыбызның ике гиганты — бөек Г.Тукай белән киләчәктә шулай ук бөек композитор булачак Салих Сәйдәшевне үзара таныштырган кеше дә — Шиһап Әхмеров.

Ш.Әхмеровны күреп белүчеләр һәм аралашкан кешеләр аның кече күңелле, гаять кешелекле, ярдәмчел булуын хөрмәт белән искә алалар. Бу Ш.Әхмеровның тумыштан ук педагоглык таланты булуыннан килә. Аның өчен кешенең бәхете — кешегә яхшылык эшләүдә, ярдәм итүдә, кешенең бөтен зурлыгы хезмәттә, халкына хезмәт итүдә. Аның аңлавы буенча, Г.Тукай әйтмешли, «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә» — кеше тормышының мәгънәсе шунда. Шул ук вакытта Әхмеровлар гаиләсе гаять кунакчыл да булган. Алар квартирасына күренекле кешеләр еш килеп йөргәннәр. Алар арасында артистлар да, язучылар да, педагоглар а булган. Г.Тукайдан башка алар торган йортның сукмагын Фатих Әмирхан, артист Г.Кариев, язучы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, революционер Г.Ибраһимов, шагыйрәләр Ш.Бабич, Ф.Бурнаш, педагог М.Корбангалиев, рәссам Әхмәт Урманчеев һәм башкалар яхшы белгәннәр. Әхмеровлар фатирында яңа шигырь укыйлар, яңа пьесалар тыңлыйлар, укыту-тәрбия, мәктәп-мәдрәсә, музыка, театр турында әңгәмәләр, бәхәсләр еш булып тора. Болар үз чиратында эзләнүләргә, халыкның культурасы һәм мәгърифәте турында уйлануларга, шул өлкәдә эшләү өчен дәрт һәм дәрман бирә. Менә шундый кичәләр оештырылган Ш.Әхмеров квартирасы һәм аның хуҗасы ни өчен полиция күзәтүе астында торган дигән сорауга җавап булып тора.

Пәһлеван гәүдәле, мөлаем дә, җитди дә карашлы, һәр сүзен үлчәп кенә әйтүче, һәр хәрәкәтендә тормыш һәм ижат дәрте кайнап

торган бу күркәм кеше — үзенең китаплары, чыгарган журналлары, мәкаләләре белән генә түгел, халык мәгърифәте өчен көрәшүе белән дә, халык тудырган педагогик алымнарны оста файдаланучы, аны киләсе буыннарга җиткерү өчен көрәшүче педагог буларак та үзенчәлекле шәхес.

Зур эрудицияле, тумыштан педагог җанлы Ш.Әхмеров, күреп үткәнчә, үзенең хезмәтләре белән Каюм Насыйрилар күтәреп чыккан мәгърифәтчелек идеяләрен практик рәвештә тормышка ашыручылар отрядының күренекле вәкиле.

Без еш кына традицияләргә караш, педагогиядә халык традицияләренең уңай якларын өйрәнү һәм яшь буынны тәрбияләүдә аларны куллану турында сөйлибез. Шул ук вакытта халык педагогиясенең бер өлеше булган, махсус белемнәр алмыйча практикада үзен зур педагог итеп күрсәткән шәхесләрнең тормышына һәм иҗатына һәрвакытта тиешле әһәмият бирмибез. Без моны Ш.Әхмеров тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә карата да әйтә алабыз.

Шиһап Әхмеров хезмәте ул тәрбияләгән Салих Сәйдәшев иҗатында, аның рухи тәрбиясе астында үскән балаларында, оныкларында да чагыла. Алар әтисеннән мирас итеп аның хезмәт сөючәнлеген, туган илгә, халыкка хезмәт итү, ярдәмчел, кече күңелле булуны алганнар. Ш.Әхмеровның олы улы Үзбәк Шиһапович Мәскәү транспорт инженерлары институтын уңышлы тәмамлый, аннары берничә ел буе заводта инженер-конструктор булып эшли. Хезмәт ияләре арасында яшәп, эшче сыйныфының төп әхлакый һәм этик нормаларын үзләштерә. Булган сәләтен тагын да киңрәк кулланып кешеләргә күбрәк файда китерү нияте белән Казан медицина институтын тәмамлый. Медик буларак Казан ГИДУВында уналты ел авырулар дәвалый. Медицина фәннәре кандидаты, аннары биология буенча доктор Үзбәк Әхмеровны фәннең яңа тармагы — бионика үзенә тарта. Ул илебездә беренче буларак Казан университетында ачылган био-

ника фәнни лабораториясен оештыра. Ул теоретик эзләнүләр белән беррәттән бионика фәненең уңышларын тормышта куллану буенча да зур эшләр алып бара. Аның магнитлы суларны промышленностьта куллану, Татарстан халык хуҗалыгына керткән практик тәкъдимнәре әнә шул турыда сөйли. Аның тормыш девизы — кеше өчен яшәү, кешеләргә ярдәмчел булу. Бу максатны тормышка ашыруда, әлбәттә, аның медик булуы, Гиппократча фикер йөртүе дә ярдәм итә. Болар барысы да — совет мәгариф системасы һәм һичшиксез, демократ педагог, халык өчен янып яшәгән әтисенең йогынтысы нәтиҗәсе.

Казан дәүләт университеты профессоры Ү.Ш.Әхмеровның өлкән улы да — шул рухта тәрбияләнгән кеше. Ул — Татарстан буйлап санитар самолетларда очып, аерата авыр хәлгә калган кешеләргә ярдәм күрсәтүче табиб. Нияз Үзбәк улы Әхмеров Казан медицина институтын тәмамлый, соңыннан университетта укып белем ала. Хәзер медицина фәннәре кандидаты, кешеләрнең сәламәтлеген саклау юлында яңа ысуллар эзли.

Шиһап Әхмеровның икенче улы Җанбәк Бөек Ватан сугышыннан яраланып, инвалид булып кайта. Әтисендә булган фәнгә, белемгә җитди караш аның да күңеленә сеңгән. Сугыштан кайткач, Җанбәк ветеринария институтын тәмамлый, аннан озак еллар ветврач булып «Красный ключ» совхозында эшли. Җанбәк, әтисе кебек үк, хезмәткә бирелгән, кешеләргә һәрвакыт яхшылык эшләргә әзер торучы кеше. Тора-бара ул, үзенең практик эштә җыйган тәҗрибәләренә таянып, кандидатлык, аннан ветеринария фәннәре буенча докторлык диссертациясе яклый.

Үзбәк һәм Җанбәк Әхмеровларның кызлары һәм уллары бабаларның һәм аталарның гүзәл сыйфатларын дәвам итәләр.

Бөек Октябрьнең беренче көннәреннән үк илебездә культура революциясе үткәрү өчен зур көрәш башланды. Хәзер без — ныкүс-

кән социалистик җәмгыятьне камилләштерү өчен көрәшәбез. Партиябез күрсәткәнчә, беренче максатларның берсе булып барлык кешеләрдә дә югары дәрәҗәдә әдәп-әхлак тәрбияләү алда тора. Бу уңайдан без фәнгә генә түгел — халык педагогиясенең уңай традицияләрен безнең көннәргә хәтле китереп җиткергән аерым шәхесләрнең педагогик мирасларына да таянабыз. Бу бай мирас, кешелек җәмгыятенең язылмаган кагыйдә-кануннары формасында безнең тормышыбызда, эшебездә яшәп килә. Хезмәт халкы арасында гаилә тәрбиясенең уңай традицияләре яшь буынны тормышка, коммунизм төзүгә хәзерләүнең нигезен тәшкил итә.

Бүген партия һәм хөкүмәтебез яшьләрне әхлакый яктан тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә икән, моның өчен барлык резервларны: педагогик мирасны, халыкның интеллектуаль мөмкинлекләрен киңрәк файдаланырга кирәк.

Хезмәт кешесе — безнең җәмгыятьнең нигезе. Без эшчеләр династияләре хасил булуы һәм үсүе белән горурланабыз. Шулай ук совет заманында барлыкка килгән эшче-крестьян интеллигенциясе династияләре үсүе дә безнең җәмгыятьнең зур казанышы. Әнә шул династиянең бер буыны булган Әхмеровлар нәселе моңа ачык мисал.

Әгәр безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез XX йөз башында ук көр тавыш белән башлаган икән, мәгърифәтчеләр кабызып җибәргән чаткы ялкынга әйләнә башлаган икән — монда Шиһап Әхмеров һәм киң масса укучыларга аз билгеле булган икенче буын мәгърифәтчеләрнең хезмәте аз булмаган.

Укытучы, педагог, журналист, китапчы, матбагат тарихы белгече, Г.Тукайның якын дусты, С.Сәйдәшевның тәрбиячесе Шиһап ага Әхмеровның исемен һәм хезмәтен зур ихтирам белән искә алабыз. Ул Тукайлар, Сәйдәшләр кебек кешеләрне тудырган иҗтимагый-мәдәни мохитнең аерылгысыз өлеше, бөек мәгърифәтчеләребезнең

максатларын тормышка ашыруда җиң сызганып эшләгән зыялы буларак та безгә кадерле, безгә газиз.

1.8. Педагогика фәне үсештә

«Бөтендөнья капитализмы һәм Россиянең 1905 ел хәрәкәте Азияне тәмам уятты. Изелгән, урта гасыр торгынлыгында кыргыйланган йөзләрчә миллион халык яңа тормышка һәм кешенең элементар хокуклары өчен, демократия өчен көрәшкә уянды»[1] , — В.И.Ленин.

1917 елда тарихта яңа чор башланды. Бөек Октябрь татар халкы тормышына да зур үзгәрешләр алып килде. Берничә дистә ел эчендә ул урта гасырның схоластик мәктәбеннән университетка кадәр юл үтте, элекке сука һәм сабан урынына зур йөк күтәрешле «КамАЗ» машиналары, «Ил-62» һава лайнерлары эшләп чыгара башлады.

Хәзер республика халык хуҗалыгында 255 меңнән артык инженер, 40 мең техник эшли. 1913 елда бөтен Россиядә 14 мең чамасы фәнни хезмәткәр булган. Бүген Совет Татарстанында гына да алар 18 меңнән артык.

Моңа ничек ирешелгән? Үтә кыска вакыт эчендә шундый сикереш ясауның сере нәрсәдә? Әлбәттә, политика һәм экономикада. Ләкин мәгърифәтнең, аның фәне — педагогиканың да әһәмияте зур.

Белгәнебезчә, патша Россиясендә рус булмаган халыкларның күпчелегендә фәнни-педагогик фикер XIX йөзнең икенче яртысында формалаша башлый. Ул чор капитализмның барлыкка килүе, сәүдәнең көчәюе һәм шуның нәтиҗәсендә мәгариф эшенең шактый активлашуы белән характерлана. Завод-фабрикаларда, сәүдә һәм

[1] В.И.Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 15 т., 67 б.

финанс учреждениеләрендә эшләр өчен укый-яза белгән эшчеләр һәм хезмәткәрләр әзерләүгә ихтыяҗның арта баруы милли мәктәпләргә дә реформа үткәрүне көн тәртибенә куя. Мәктәп-мәдрәсәләрдә рус телен өйрәнүгә омтылыш көчәя, табигать фәннәре, тарих, география һ.б. предметлар кертелә. Реакцион дин әһелләренең каршылык күрсәтүенә дә карамастан, прогрессив фикерле эшлеклеләр җәдит мәктәпләре ачалар. Болар барысы да яңа укыту планнары һәм программалар, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр төзүне таләп итә.

Татарларда педагогик фикер үсешенең икенче чыганагы һәм стимулы итеп рус педагогикасы фәнен санарга кирәк. Тарихи шартларга бәйле рәвештә төрле халыкларда педагогик фикер төрле вакытта активлаша башлый. Мәсәлән, рус педагоглары һәм Казан галимнәре йогынтысында татарларда дөньяви белем тарафдарлары үсеп чыга, Ульяновлар гаиләсенең турыдан-туры йогынтысында һәм ярдәмендә чуваш укытучысы И.Яковлев күренекле педагог булып таныла. XIX гасырда педагогик белемнәр таратуда рус миссионерлар да билгеле бер роль уйный. Алар мөселманнар арасында, бигрәк тә керәшен татарлары арасында зур эш алып баралар: мәктәпләр ачалар, рус теле өйрәтәләр, алар өчен дәреслекләр төзиләр.

Татарларда дөньяви белем алуга омтылышның көчәя баруына 1804 елда ачылган Казак университеты да зур этәргеч ясый. Рус фәне һәм культурасының иң көнчыгыш үзәге саналган бу уку йортында 19 ел буе Н.И.Лобачевский ректор була, Лев Толстой шунда укырга керә, Максим Горький биредә белем алу турында хыяллана, Илья Николаевич Ульянов монда фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала... Казан марксизмны тарату үзәкләренең берсе була, Ленинның революциягә үз юлын биредә башлавы да очраклы түгел.

Университет мөгаллимнәре И.Хәлфин, М.Мәхмүдов, Х.Фәесханов, К.Насыйри һ.б., беренчеләрдән булып, руслар өчен татар теле дәреслекләре һәм программалары, шулай ук грамматикадан ярдәмлекләр, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр, тел укыту буенча күп кенә методик кулланмалар төзиләр. Узган гасыр ахырына инде К.Насыйри, К.Д.Ушинскийның дидактик системасы тарафдары һәм пропагандисты булып җитлегә.

1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәбенең ачылуы татар интеллигенциясе вәкилләре арасында педагогик фикер таратуда гына түгел, бәлки аларда революцион аң тәрбияләүдә гаять зур роль уйный. Рус телен һәм әдәбиятын өйрәнү педагогика фәне белән танышу татарларда әкренләп демократик һәм марксистик әдәбиятка юл ача. Танылган татар педагог-революционерлары Г.Колахметов, Х.Ямашев, педагог-марксист Г. Сәйфетдинов шушы уку йортында белем ала. Алар XX йөз башында татар интеллигенциясе һәм яшьләре арасында алдынгы педагогик идеяләрне таратучылар булып әвереләләр.

1907 елда Х.Ямашев редакциясендә чыга башлаган большевистик «Урал» газетасында да марксистик педагогика мәсьәләләре шактый киң яктыртылган. Х.Ямашевның дусты Галимҗан Сәйфетдинов 1912–1914 елларда Н.К.Крупская белән хат алышкан. Педагогика проблемалары буенча ул язган күп кенә публицистик мәкаләләрдә Н.К.Крупская карашлары чагылыш таба. Педагог-марксистның хатлар алышуы татар халык педагогикасында марксистик идеяләр формалашуына йогынты ясаган. Укучылар һәм татар эшчеләре арасында ленинчыл «Искра»ны пропагандалаган

укытучылар, агалы-энеле Колахметовлар бу турыда хәбәрдар булганнар[2] .

Танылган совет педагогы М.Х.Корбангалиевның революциягә кадәрге хезмәтләрендә үк билгеле бер дәрәҗәдә марксистик идеяләр урын ала, укыту һәм тәрбиянең буржуаз идеяләренә сыйнфый позициядән чыгып анализ ясала. Күренекле татар революционеры, язучы Г.Ибраһимовның эшчәнлеге дә педагогик фикер формалашуга җитди йогынты ясый[3].

Совет Татарстанының танылган педагоглары һәм татар совет мәктәбен башлап оештыручылар Ш.Әхмәдиев, М.Корбангалиев, Г.Ибраһимов, М.Фазлуллин, В.Горохов, Н.Надиев, Г.Сәгъди һ.б. марксистик педагогика классигы Н.К.Крупская идеяләренең шифалы йогынтысын тоеп хезмәт итәләр.

Шулай да 1917 елга кадәр татарларда педагогика теориясе буенча махсус хезмәтләр бик аз була. Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң, Владимир Ильич «бөтен бер переворот, бөтен халык массасының культура үсешендә бөтен бер полоса»[4] дип бәяләгән культура революциясе башлана. Аны тормышка ашыру өчен бик күп киртәләрне җиңәргә, җимереклекне бетерергә, халык хуҗалыгын торгызырга, шовинизмга һәм милләтчелеккә каршы кискен көрәш алып барырга туры килә. Әмма «партия шуңа иреште, интернационализм бер төркем коммунистлар идеалыннан барлык милләтләрдән һәм халыклардан булган миллионнарча совет кешеләренең тирән инануына әверелде. Бу — иҗтимагый аңда чын революцион поворот һәм аның әһәмиятен бәяләп бетерүе кыен»[5].

---

[2] Ханбиков Я.И. XI–XX йөзләрдә татар халкында педагогик фикер үсешенең төп юнәлешләре. Докторлык диссертациясе автореферaты (рус телендә), М., 1968, 12-13 б.

[3] Мансур Хәсәнов, Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1969, 309-330 б.

[4] В.И.Ленин. Әсәрләр, 4 нче басмадан тәрҗемә, 33 т., 455 б.

[5] Л.И.Брежнев. Ленин юлыннан, 4 т., 69 б.

Бөек Октябрь революциясеннән соң ук яңа педагогика фәне юк, ә искесен яңа җәмгыятькә механик рәвештә күчерергә ярамый иде. Ул елларда Н.К.Крупская, иске педагогиканы элекке хәлендә куллану мөмкин түгел[6], дип ассызыклап күрсәтте. Элекке мирастан яңа социалистик педагогика эчтәлегенә органик рәвештә кереп китәрлек иң мөһим өлешләрен генә сайлап алу, бер үк вакытта педагогика һәм мәктәпләрнең үткәне турындагы белемнәрдәге бушлыкны бетерү бурычы да куелды. Әмма ул чорда әле яңа төзелгән милли республикаларда үз галим-педагогларын хәзерләү мөмкинлеге дә булмаган. Аннары ликбез һәм башлангыч мәктәпләрнең ихтыяҗлары да башка иде. Россиянең хокуксыз халыкларына мәктәп һәм мәгариф үсеше тарихын соңыннан гына өйрәнү мөмкинлеге туды.

Элекке миллион окраиналарда педагогика фәне Совет властенең беренче елларында, нигездә, гамәли юнәлештә үсте. Бу чорда кайбер халыкларда ана теле һәм рус теле буенча оригиналь дәреслекләр төзелде, икенчеләрендә мәктәпләр челтәре үзгәртеп корылды, гамәлдәге дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр камилләштерелде. Барлык халыклар да рус телен өйрәнү юлларын актив эзли башладылар. Мөселман халыклары исә дини мәдрәсәләр нигезендә дөньяви мәктәпләр коруга керештеләр.

Рус интеллигенциясенең ярдәме белән барлык союздаш һәм автономияле республикаларда гаҗәеп зур эш башкарылды. Профессорлардан В.М.Горохов, Я.И.Ханбиков, М.З.Тутаев монографияләре һәм тугандаш республика галимнәренең хезмәтләре республика халыкларында мәктәп, мәгариф һәм педагогик фикер үсеше тарихын тикшерү өчен дә җирлек булып хезмәт итте.

Егерменче елларда башлыча, яңа мәктәпләр төзү, наданлыкны бетерү, кече яшьтәге мәктәп балаларын башлангыч белем алуга

[6] Крупская Н.К. Педагогические сочинения, 3 т., с. 255

тарту кебек эшләр башкарылды. Яңа тип мәктәпләр булдыру, укытуның яңа методларын эзләү, белем бирүне демократик нигезгә салу, яшьләрне хезмәткә әзерләүне һәм алар аңында пролетар идеология тәрбияләүне көчәйтү мәсьәләләре төп бурыч итеп куела. Утызынчы елларда инде мәктәпләрнең материаль базасы шактый ныгый, күп кенә дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр басылып чыга.

Милли мәктәпләрнең методик кулланмалар белән тәэмин итүдә нәшриятлар һәм педагогик матбугат зур роль уйный. Менә бер генә мисал: I һәм II баскыч татар мәктәпләре өчен 1919 елның беренче яртысында Казанда 70 исемдә дәреслек бастырып чыгару планлаштырыла. Алар арасында, мәсәлән, татар әдәбияты тарихы, әдәбият теориясе, Көнбатыш Европа әдәбияты тарихы, социологиядән хрестоматия, социализм тарихы, рус революциясе тарихы, геометрия, алгебра, тригонометрия, физика һ.б. дәреслекләр була. Профессиональ әзерлек буенча да дәреслекләр бастырыла. 1919 елда барысы 3365000 данә тираж белән 75 исемдә дәреслек һәм ярдәмлек бастырып чыгу күздә тотыла[7].

Газета һәм журнал битләрендә яңа методик рекомендацияләр, халык мәгарифе өлкәсендә дәүләтнең политикасы, укытуның яңа методлары һәм яңа орфография кагыйдәләре, ана теле һәм рус теле укыту мәсьәләләре турында дискуссион материаллар урнаштырыла. 1918 елда Казанда Бөек Октябрь социалистик революциясенең 1 еллыгына «Мәгариф» (хәзерге «Совет мәктәбе») журналының 1 нче саны чыга. Илебезнең төрле өлкәләрендәге татар мәктәпләре укытучылары аның һәр санын көтеп ала торган булганнар. Анда яңа программалар, методик күрсәтмәләр, мәктәптә эшне оештыру турында инструкцияләр урын алган.

[7] Тутаев М.З. Октябрь һәм мәгариф (рус телендә). Казан, 1970, 409 б.

Кырыгынчы-илленче елларда милли республикаларда педагогика фәне үсешенең төп үзенчәлеге алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм таратудан, мәктәпләр практикасындагы методик яңалыкларны педагогика фәне казанышларын искә алып кулланудан, хезмәткә өйрәтү һәм рус теле укытуның иң кулай юлларын эзләүдән гыйбарәт була.

Алтмышынчы-сиксәненче елларда исә мәктәпләр тарихын түгел, бәлки педагогик психология һәм педагогиканың теоретик проблемаларын өйрәнү күздә тотыла. Бүген педагог-галимнәр, КПССның XXV һәм XXVI съездлары карарларын кулланма итеп алып, түбәндәге проблемалар буенча тикшеренү эшләре алып баралар: укучыларда дөньяга фәнни караш тәрбияләү; хезмәт тәрбиясе, мәктәп балаларына политехник белем, профессиональ ориентация бирү; укучыларда актив тормыш позициясе тәрбияләү һәм аларны әдәп-әхлакка өйрәтү; милли мәктәпләр, пионер оешмалары һәм халык мәгарифе тарихы; мәктәп һәм профессиональ-техник училище балаларының ижади сәләтен, рационализаторлык һәм уйлап табу эшчәнлеген үстерү проблемалары; укытучы белән укучы арасындагы үзара мөнәсәбәтнең социаль-психологик аспектлары һ.б.

Милли мәктәпләрдә ана теле, рус теле һәм әдәбиятларын укыту методикасын эшкәртү педагогик тикшеренүләрнең аерым тармагын тәшкил итә. Бу өлкәдә милли республика педагоглары теоретик тикшеренүләрдә зур уңышларга ирештеләр.

Милләтнең традициясе, тарихи тәҗрибәсе һәм яшәү шартларына бәйле рәвештә, кайбер республикаларда төп милләт халкыннан беренче педагогия фәннәре докторлары һәм беренче фәнни хезмәткәрләр 20 елларда ук барлыкка килә, ә икенчеләрендә исә фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен беренче диссертацияләр 30 нчы елларда, ә докторлык диссертацияләре 60–70

нче елларда гына яклана. Күренгәнчә, педагогика фәне өлкәсендә милли республикаларны тигезләү экономика өлкәсендә тигезләүгә караганда акрынрак барды. Моның сәбәбе дә бар. Чөнки «кеше формалаштыру, аны тәрбияләү" турындагы фәннән дә кыенрак фән юк. Аны үзләштерү фикер тирәнлеген, аның рекомендацияләренә аналитик якын килүне һәм һәрьяктан укымышлы булуны таләп итә»[8]. Педагогика буенча докторлык диссертацияләренең әле хәзер дә зур читенлек белән генә якълануы очраклы түгел. Илебездәге педагогия институтларының тик өчтән берендә генә педагогия фәннәре докторлары булуда иң элек әнә шуның белән аңлатыла.

Наданлыкка каршы көрәшнең беренче көннәрендә үк укытучылар җитешмәү проблемасы килеп баса. Россия губерналарында, шул исәптән татар мәктәпләрендә дә укытучылар җитешми. Ә Урта Азиядә алар бөтенләй диярлек булмый. Карандаш тота һәм иҗекләп укый белгән һәр кеше грамотага өйрәтү эшенә тартыла. Чөнки ул елларда башлангыч белемле укытучылар хәтта урта мәктәпләрдә дә бармак белән генә санарлык иде. Укытучылар әзерләү өчен оештырылган кыска сроклы курслар да сизелерлек нәтиҗә бирми. Шуңа күрә, союздаш һәм автономияле республикалар төзелү белән бергә, педагогия институтлары һәм техникумнары ачыла башлый.

Беренче татар революционерлары Х.Ямашев, Г.Колахметов, Г.Сәйфетдинов укыган татар укытучылар мәктәбе нигезендә 1919 елда Казан педагогия институты оештырыла.

Баштагы елларда анда татарлардан студентлар саны бик аз була. (Моның төп сәбәбе революциягә кадәр дөньяви мәктәпләрнең булмавы белән аңлатыла.) Мәсәлән, 1921 елда студентларның нибары 3%ын татарлар, 7%ын чувашлар тәшкил иткән. 1931 елда,

[8] Прокофьев М.А. Советское просвещение навстречу 60-летию СССР — Советская педагогика, 1982, №6. 10 б.

бу уку йорты Татар педагогия институты дип исемләнә башлый. Россия Федерациясендә барлык татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү төп бурыч булып куела. 1934 елдан ул Казан дәүләт педагогия институты дип йөртелә. Шәһәрләрдәге һәм район үзәкләрендәге татар мәктәпләре русча укытуга күчкәнлектән, татар мәктәпләре саны кимесә дә, студентларның яртысыннан күбрәген институт милли мәктәпләр өчен әзерли.

Совет власте елларында Педагогия институты 25 меңнән артык укытучы әзерләде. Алар арасында танылган укытучылар, галимнәр, журналистлар, язучылар, партия һәм совет работниклары бар. Институт чын мәгънәсендә милли кадрлар әзерләү үзәгенә әйләнде. Монда Советлар Союзы Герое Муса Җәлил укый, татарлардан беренче педагогия фәннәре докторы, профессор М.Х.Корбангалиев, РСФСР Педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты М.Ә.Фазлуллин, профессорлардан В.М.Горохов, Н.Надиев, О.Ж.Курмаев, М.И.Әлмөхәммәтов һәм башкалар белем ала. СССР Педагогия фәннәре академиясенең беренче президенты булып эшләгән В.М.Хвостов та заманында биредә укый.

Институтта фәнни тикшеренүләр нинди юнәлештә алып барыла соң? Беренче чиратта, болар — яңа совет мәктәбе теориясе, психология һәм педагогика фәннәрен өйрәнүнең яңа системасына күчү, авыл мәктәпләрендә укыту-тәрбия процессын оештыру үзенчәлекләре, укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү, татар мәктәбендә рус теленә өйрәтүнең эчтәлеге һәм методикасы, укучыларга педагогик профессияләргә ориентация бирү.

Институт галимнәре проблемалы укыту теориясен, Татарстан укытучыларының алдынгы тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерүгә дә зур әһәмият бирәләр.

Соңгы елларда профессорлардан Я.Ханбиковның «Татар халык педагогикасы тарихы», М.Мәхмутовның «Проблемалы укыту теориясе һәм практикасы», Л.Шакированың «Татар телендә рус фигылен өйрәнү», Н.Половникованың «Укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү турында», М.Тутаевның «Октябрь һәм мәгариф», доцентлардан Ж.Велькеевның «Мәктәптә укытканда фәнни танып-белү методлары» (фән нигезләрен проблемалы өйрәнү логикасы), А.Кирсоновның «Укучыларның уку эшчәнлеген индивидуальләштерү» дигән күләмле монографияләре басылып чыкты.

Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм фәнни нигезләүдә галим-педагоглардан Р.А.Низамов, Г.Г.Жданова, И.И.Малкин, Н.М.Хәсәнов, Г.А.Петрова, Г.С.Закиров һәм башкаларның да тырыш хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

Педагогик кадрлар әзерләүдә һәм Татарстанда педагогика фәнен үстерүдә В.И.Ульянов Ленин исемендәге Казан университеты галимнәренең дә өлеше зур. Революциягә кадәр үк монда төрле фәнни мәктәпләр, шул исәптән профессор В.А.Богородскийның телләрне өйрәнү методикасы мәктәбе барлыкка килә. 1944 елда биредә педагогика һәм татар теле кафедралары оештырыла. Аларда укучыларга һәм студентларга эстетик тәрбия бирү, татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы өлкәсендә эшләүче зур белгечләр үсеп чыкты. Профессор Б.П.Рождественский эстетик тәрбия мәктәбе оештырды, хәзер Казан дәүләт педагогия институты ректоры булып эшләүче профессор М.З.Зәкиев татар синтаксисын укыту методикасына зур өлеш кертте, профессор Д.Г.Тумашева татар теле морфологиясен өйрәнү методикасын эшләде.

Татарстанда педагогик тикшеренүләрнең өченче үзәге булып Алабуга педагогия институты санала. Авыл мәктәбендә пионер эшен оештыруның теоретик нигезләре — институтның педагогика кафедрасы әнә шул тема буенча тикшеренүләр алып бара.

Педагогия институтларыннан тыш, һәр союздаш республикада диярлек педагогика буенча фәнни-тикшеренү үзәкләре төзелә. (Шуларның берсе, Украинадагы Фәнни-тикшеренү институты турында берничә генә сүз әйтик: 1928 елда монда А.С.Макаренконың фәнни доклады тикшерелә. Павлыш мәктәбе директоры, соңыннан совет педагогикасы классигына әверелгән һәм СССР Педагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты итеп сайланган В.А.Сухомлинский 1955 елда биредә кандидатлык диссертациясе яклый.) Автономияле республикаларда фәнни-тикшеренү үзәкләре исә РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының филиаллары формасында 60 еллар башында ачыла. Татарстан филиалы 1961 елда оештырыла. Аның беренче мөдире итеп милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасында эшләүче иң зур белгечләрнең берсе Л.З.Шакирова (хәзер Казан дәүләт педагогия институты профессоры, доктор) билгеләнә.

20 ел эчендә Филиалда күп кенә кадрлар үсеп чыкты, 5 докторлык диссертациясе әзерләнде һәм 10 нан артык кандидатлык диссертациясе якланды. Инде менә аңа озак еллар буе Г.Г.Ждановa җитәкчелек итә. Филиал сотрудниклары 4 монография, 12 фәнни җыентык, 30 дан артык методик рекомендация, төрки мәктәпләр өчен 8 исемдә әлифба, рус һәм татар телләре дәреслекләре әзерләп чыгардылар. Барсы 400 басма табактан артыграк фәнни-методик продукция бастырылды.

Татарстандагы педагогик тикшеренүләрнең бишенче үзәге — СССР Педагогия фәннәре академиясенең Профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институты. 1976 елда гына ачылган бу фәнни үзәктә урта профессиональ-техник училище укучыларына белем һәм коммунистик тәрбия бирүнең гомуми проблемалары тикшерелә. Хәзергә ул — илебездә бу типтагы беренче институт. Инде монда 150 дән артык фәнни работник, шул исәптән 55 тән артык доктор һәм

фәннәр кандидаты — руслар, татарлар, эстоннар, украиннар, еврейлар, башкортлар һ.б. милләт вәкилләре эшли. Институт аспирантурасында 60 кеше укый. Махсус гыйльми советта гомуми һәм профессиональ-техник педагогика буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклана. Оештырылуына берничә ел гына булса да, Институт күп кенә фәнни хезмәтләр бастырып чыгарды. Мәсәлән: «Хәзерге дәрес. Теория мәсьәләләре» (М.И.Махмүтов), «Яшь эшчеләрнең профессиональ формалашуы» (Р.В.Мөрсәлимов), «Профессиональ педагогикада тикшеренү методлары» (А.А.Кыверялг), «Укучыларга эшче профессиясенә ориентация бирү буенча мәктәп, профтехучилище һәм предприятиенең бергәләп эшләве» (А.А.Вайсбург), «Директор һәм мәктәп коллективы» (Р.Х.Шәкүров), «Остазлыкны оештыру» (Н.М.Таланчук һ. б.). Институт галимнәре Куба галимнәре белән бергәләп — бер, Чехословакия, Болгария һәм Польша коллегалары белән бергә ике китапның кулъязмасын әзерлиләр. Якындагы 5–6 елга Институт профтехбелем системасының иң актуаль проблемалары буенча 10 докторлык, 54 кандидатлык диссертациясе әзерләүне бурыч итеп куйды.

II. ҖӘМГЫЯТЬ, МИЛЛӘТ ҺӘМ СӘЯСӘТ

2.1. Әйдә, халыкка хезмәткә...

Матбугатта инде хәбәр ителгәнчә, шушы елның февралендә Казанда, киң җәмәгатьчелек катнашы белән, республика «Ватан» җәмгыятен оештыруга багышланган тантана булды. Бу яңа җәмгыять нинди ихтыяҗларны күздә тотып төзелде соң? Аның эчтәлеге, максаты, милләтебез хәятендә тоткан урыны нидән гыйбарәт булачак? Күпсанлы журнал укучыларыбызның да кызыксынуларын истә тотып, бу сораулар

белән без җәмгыятьнең рәисе академик Мирза әфәнде Мәхмүтовка мөрәҗәгать иттек.

М.И.Мәхмүтов:

— Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә карата соңгы ике-өч ел эчендә татар җәмәгатьчелегенең игътибары артканнан-арта бара. Бу — без татарларда гына түгел, башка күпсанлы милләтләрдә дә шулай. Дистәләрчә еллар гел «дошман» итеп саналган кешеләр белән хат языша, кунакка йөрешә дә башладык инде. Бу халәтнең, бу күренешләрнең сәбәбе нәрсәдә соң? Үзгәртеп кору уңаеннан хәбәрдарлык, демократиянең җәелеп китүеме, әллә башка сәбәпләр дә бар микән? Татарстан Министрлар советы карары нигезендә, «Ватан» җәмгыяте оешып, яңа ижтимагый хәрәкәт башланып киткәч, мин бу хакта ешрак уйлана башладым. Безгә ни җитмәгән, әллә үзебездә булган проблемалар азмы, әллә буш вакытыбыз күбәеп киттеме? Юк, хикмәт боларда түгел, әлбәттә. Җәмәгатьчелекнең теге яки бу мәсьәлә белән кызыксынып китүен җентекләбрәк өйрәнсәң, аның нигезендә элек башка да килмәгән әллә ничаклы сәбәпләр ятканын күрербез. Сүз уңаеннан мин аларның берничәсен әйтеп китәр идем.

Беренчесе — безнең илебездә тормыш күп еллар буе чикләнеп, башка дөньядан «тимер пәрдә» белән капланып килде. Ике капма-каршы идеологиягә корылган мондый яшәеш, матди һәм рухи яктан да нык аерылып, ике төрле эздән барды һәм җәмәгатьчелекнең аңына, психологиясенә көчле тәэсир итте. Ниһаять, үзгәртеп кору чорына аяк бастык. Капма-каршы басып торган дөньяны ничек килештерергә? Ике яктагы халыкларны ничек якынлаштырырга? Нинди юллар белән кешеләрнең күңелендә тынычлык, дуслык хисләрен ныгытырга? Безгә таныш булмаган дөньяны, аның кешеләрен яхшы белергә кирәк иде, әлбәттә. Моның өчен рәсми дипломатия генә түгел, гайре рәсми халык дипломатиясе дә кирәк.

Бездә тормыш шартлары чагыштырмача авыр булганга күрә, «Анда» халык ничек яши икән?», «Анда» тормыш шартлары нигә безнекеннән яхшырак?» шикелле сорауларга җавап эзләп, халык уяна һәм уйлана башлады. Дөньяда тынычлыкны нығыту җәһәтеннән чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тормыш-көнкүреше белән табигый кызыксыну тагын да артты.

Икенче сәбәп тә бар. Ул ике өлештән тора: берсе — дөньяви кызыксынудан тыш, багланышларга өмет белән дә каравы, икенчесе — таррак даирәләрнең хыялы. Дөньяви төшенчәсен мин ахирәткә бәйләмим: матди тормыш, көнкүрешне күздә тотып әйтәм. Анда бездән яхшырак яшиләр, тормышларын бездән әйбәтрәк оештырганнар икән, без алардан үрнәк алып, тормышыбыз вә җәмгыятебезне яхшырта алмабызмы микән? Андагы татар кардәшләребез бездән хәллерәк икән, алар безгә үзгәртеп коруның кайбер мәсьәләләрендә булышмаслар микән? — шикелле сорауларга җавап эзләп, өмет баглап, күп кенә кеше «теге» якка күз ташлый. Бу сәбәпнең икенче өлеше — татар интеллигенциясе, хәзерге зыялылар күңелендә милләтне агарту өмете. Мондый фикер белән янып йөргән кешеләрнең хыялы — совет чорында югалып, төшеп калган мәдәни байлыкларның билгеле бер өлешен кире кайтарып булмас микән дигән уйлар...

Бу процесс русларда көчле бара. Алар читтә яшәгән милләттәшләрен илебезгә чакыралар, радио-телевидениедән сөйләтәләр, аларның китапларын бастырып чыгаралар. Әйтик, март башында Мәскәү Галицын, Шереметьев, Пущиннар һ.б. шундый борынгы князьләр, графларның токымнарын зур хөрмәт белән каршы алды, кунак итте. («Известие» 2.03.90).

Өченче сәбәп — илдәге уянуны күреп, теге яктан да безнең тормышыбыз белән кызыксынуның көчәюе. Илне демократияләштерү андагы үзгәрешләргә дә киң юл ачты. Әлеге

кызыксыну, «перестройка» белән генә чикләнмичә, милли хисләрнең, туган телне саклап калу теләгенең, рухи тормыш һәм мәдәни мәнфәгатьләрнең кузгалышына да ярдәм итте. Ят мохиткә сеңеп бетмәс өчен көрәшә чит илдәге кардәшләребез. Тагын шунысын онытмыйк: Ватанныннан читкә чыгып киткән кешедә «ностальгия» чире була. Туган якны, үз өммәтеңне сагыну — безнең халыкта күптән инде «милли» бер сыйфатка әверелгән. Мәсәлән, 1670 елларда татар шагыйре Мәүла Колый гарибләр (ватанныннан читтә яшәүчеләр) турында болай дип әйткән:

Хак[1] бирмәсен һичбер кемгә гариблекне,

Гариблек барча хальдә михнәт иркән;

Би мәкян[2] вә би чара горбәт[3] чигеп,

Йөрәкендә хәсрәт уты йанар иркән...

Гомумән, узган гасырда татар шагыйрьләре гарәп, фарсы, төрек илләрендә күп еллар укып йөргән. Анда, үз илләрен сагынып кайту көннәрен көтеп яшәгән чакта, күңелләрендәгене кәгазьгә бушата торган булганнар. Бу тойгылар гасырлар үтү белән дә үзгәрмәгән. «Туган илне, туган җирне төштә күрсәм дә файда», — дип җырлыйлар хәзерге Япониядә яшәүче татарлар («Япониядәге кардәшләребез», «Социалистик Татарстан», 4/III90). Шуңа күрә, бездән берәү дә чит илләргә барып татар кешесен очратса, анда аны иң кадерле кунак итеп каршы алалар, хөрмәт итәләр, көннәр буе сөйләшеп утырырга ризалар. Үзләрен исә совет татары кунакка чакырса, шулай ук шатланып риза булалар. Бу турыда чит илләрдә йөреп кайткан фәннәр докторы Әбрар Каримуллинның кат-кат сөйләгәне бар.

Андый очрашулар берәр рәсми сәбәп булганда бигрәк күбәеп китәләр. Мәсәлән, былтыр татар халкы ислам динен кабул итүгә

[1] Хак — Алла

[2] Би мәкян — урынсыз

[3] Горбәт — читкә тибәрелеп йөрү

1100 ел тулу уңае белән Казан, Уфа һ.б. шәһәрләрдә булган тантанага чит илләрдән йөзләгән татар килде. Шуннан соң ватандашларыбызның чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән тагы да ныгыды, хат-хәбәр аша бер-берсенең хәл-әхвәлләрен белешү белән беррәттән, кунакка йөрүләр дә күбәеп китте. Дуслашу, очрашу — кирәкле шәйдер.

Алдарак әйтелгән фикергә кайтыйк. Мәдәни мирас дигәндә без рухи байлыкны күздә тотабыз. Философиядә «җисемләшкән» һәм «җисемләшмәгән» яки «тере» белем бар дип исәпләнә. «Җисемләшкән» белем — кеше уйлап чыгарган кагыйдәләр нигезендә теге яки бу әйбер, машина, җиһаз ясалса, бу белем, кулланышка, гамәлгә кергән, дип санала. «Тере» белем исә әйберләрдә түгел, кешенең акылында, зиһенендә, башында булган белем, ягъни физик, химик, әдип һәм филологлар белеме, осталык, маһирлык, фикерләү сәләте, дигән сүз.

Мәдәни мирас та, шул җәһәттән караганда, ике өлешкә бүленә. Берсе аның «теге» якта милләттәшләребез тарафыннан язылган китаплар, картиналар, рәсемнәр, кул сәнгате әйберләре (төрле-төрле зиннәтләр, бизәнү, киенү әйберләре һ.б.). Шул исәптән элек монда — Россиядә язылып та читкә чыгарылган китаплар саны аз түгел. Мәсәлән, профессор Ибраһим Нуруллин язмаларыннан без бөек язучы, әдип Гаяз Исхакыйның мирасы нихәтле зур һәм бай икәнлеген белдек. Аны халыкка кайтару үзе бер шатлык булыр иде, чөнки башкорт яисә казакъ халыкларының кайбер өлгер вәкилләре Кол Галиләрдән калган мәдәни мирасыбызга хуҗа булмакчы булып йөргәндә, без үзебезнең хәзинәне «безнең халыкныкы» дип вакытында әйтеп калмасак, тарих битләрендә һаман да «кыргый татар» булып калачакбыз.

Югарыда сөйләгәннәрем «җисемләшкән» белем-мираска керә. Аның «тере» өлеше дә шактый зур. Чит илләрдә татарлардан эшче-

крестьян гына түгел, зыялылар да байтак. Алар арасында дөньякүләм танылган галимнәр, дипломатлар, мәҗлес-парламент депутатлары, зур эш (бизнес) башында торучы талант ияләре, артистлар һәм әдипләр бар.

Чит илдә яшәүчеләрнең бер өлеше татарча яхшы сөйләшә, үз телләрен сакларга тырыша. Алар туган телләрен югалтудан куркалар, чөнки җәмәгатьчелектә татарча сөйләшү юк. Тел бетсә, кешенең милли үзенчәлеген бетә, ерактан килгән күп кенә сыйфатлар югала. Чит илләрдә түгел, Россиянең төрле төбәкләренә сибелгән үзебезнең татар кардәшләребез дә күңелләре белән һәрчак Казан ягына карыйлар.

Чит илләрдә яшәүче кардәшләребезгә үзебез нәрсә бирә алабыз соң? Совет елларындагы тарихыбыз төрле вакыйгаларга бай. Мәдәниятебез дә, бигрәк тә аның язма өлеше, элекке алфавит-әлифбаларын югалтуга карамастан, шактый тәрәккыят итте: китап дөньясы киңәя бара, музыкада Сәйдәшев, Яруллин, Җиһанов, Мансуровлар, гуманитар фәннәрдә Зәкиев, Тумашева, Кәримуллин, Хаков, Халиковлар кебек дистәләрчә профессорлар, дөньякүләм танылган Сәгъдиев, Вәлиевлар кебек академиклары бар. Әдәбиятта исә мәшһүр әдипләр Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Әмирхан Еники, Гомәр Бәшировлар башлап киткән исемлекнең зурлыгы да бәхәссез. Башка илләрдә яшәүчеләр җиткерерлек мәдәни үрнәкләр, шул исәптән «...тел, лөгать вә әхлак» алмашырлык белем ияләребез, шөкер, җитәрлек.

Халык дипломатлары сыйфаты да аларны бары тик юллыйсы гына бар. Сөйләшсеннәр, дуслашсыннар, зур Ватаныбызның башка илләр белән дуслыгын ныгытырга булышсыннар гына... Шул изге хәрәкәттә «Ватан» җәмгыяте, һичшиксез, прогресс, тәрәккыят сукмакларының берсе булыр.

2.2. Тарихи бу бергәлек

«Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез «халык шигырьләрен» туплар да ватмады, уклар да кадамады... Алар сәламәт әле; алар яңгырый әле»... Бөек шагыйребез Габдулла Тукай тарих катламнарыннан күтәрелгәндә, тормыш-көнитеш карурманнарын кичеп чыкканда сау, саф көе калган халык рухы турында менә шулай тыгыз, олы мәгънәле итеп әйткән. Шәһәрләрен яулар җимерсә дә, китапларын ут ялмаса да, уртак ватанда күршеләре белән «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгән халкыбыз үз күңелендәге зур культура мирасын җуймыйча гасырлар тирәнлегеннән килә. Аның әкиятләрендә сакланган өметхыяллары чынга аша бара, уллары-кызларының батырларча хезмәте риваять-эпос каһарманнарына тиң. Аның җыр-моңнарында күңел яктысы, уйлар сафлыгы.

Бүген Бөек Союзның күпмилләтле гаиләсендә чәчәк атучы татар халкы үз шәҗәрәсен тарихның кайсы катламнарыннан башлый? Кемнәр соң алар татарлар, кайдан килеп чыкканнар соң алар?..

«Татарлар килә!» Әледән-әле Европаны сискәндереп уяткан шушы аваз, Уралдан алып Вислага хәтле илләрне, халыкларны шомга салып, гасырлар күкрәгендә яңгыраган, үз юлындагы шәһәр һәм авылларны көл итеп, талау, көчләү һәм үтерүләр өермәсе булып узган.

«Татарлар килә!» Атылган ук кебек ашкын, кылыч йөзе кебек рәхимсез яуларның канлы юлын тарих әнә шундый яңгыравыклы исем белән теркәп калдырган. Күп кенә халыклар хәтеренә «татар» сүзе хәтәр булып, усал һәм вәхши көч мәгънәсендә уелып калган. Шул заманнардан башлап төрле телләрдә татарга каршы мәкаль-әй-

темнәр, такмак-такмазалар ижат ителгән, буыннан-буынга, «явыз татар» турында әкият һәм риваятьләр күчеп килгән.

Кызганычка каршы, аныклык урынына хата фикер тудыручан кайбер галимнәр, башка халыклар тарихына йөз чөебрәк караучы, тарихи вакыйга һәм фактларны сыйнфый күзлектән чыгып бәяли белмәгән кайбер хезмәтләр әле дә эшен эшли: акны карадан аера алмаган, чикләнгән карашлы кайберәүләрнең хәтта бүгенге татар халкына да үпкәсе бар шикелле.

Куликово кырындагы тарихи сугышның 6ОО еллыгын бәйрәм иткән вакытта бер танышым, шаярган-көлгән булып кына миннән: «Безнекеләр анда сезне кыйнаганнармы соң?» дип сораган булды. «Юк шул, безне түгел!» — дидем мин. Шаярып кына әйтмәдем, йөзем җитди иде.

Әйе, безне түгел! Тарихны яхшы белгән, үз халкын һәм башка халыкларны хөрмәт иткән кеше болай шаярта алмас иде.

... «Һуннар килә!» Ачыргаланып кычкырган шул авазны басып, халыкларның тыныч тормышын сытып-изеп Европада тояк тавышлары яңгырый.

Диңгез булып кан ага, шәһәрләр җир белән тигезләнә. Татарлардан күп гасырлар элек (V гасыр урталарында ук) зур кабилә берләшмәсе төзеп, һуннар башка халыкларны буйсындыру юлы белән көн күрәләр.

Европада, гомумән, дәһшәтле еллар күп була. Килмешәкләрдән дә уздырып, бишенче йөздә вәхши герман кабиләләре Көнбатыш Рим империясен талыйлар, антик осталар тудырган гүзәллек дөньясын җимерәләр...

Ләкин халыклар тарихы сугышлар тарихы гына түгел. Һуннар кузгаткан Бөек күчеш вакытында Идел-Чулман буйларына да үз җирләреннән аерылып киткән төрле кабиләләр килеп урнаша. III–IV йөзләрдә үк бу төбәктә яшәгән төркиләр нәкъ менә Идел–Урал җир-

ләренә үтеп кергән һәм шунда төпләнеп калган һуннарның варислары булырга тиеш. Һуннар Җиһангире кыю Атилланың да исемендә «Идел» (Әтилле, Иделле) сүзенең ерак кайтавазы яңгырамый микән әле?

Гасырлар үткән, күп сулар аккан, дистәләгән халык һәм кабиләләр «бер дә булмаган төсле кырылганнар да беткәннәр»: берәүләрен көчлерәк йоткан, икенчеләре яшәү өчен тигезсез көрәштә һәлак булган. Өченчеләре, үзләре тарих комына күмелеп калмасалар да, исемнәрен җуйганнар, нәсел-нәсәпләре очын югалтканнар. Әйе, борынгылык эзе шәһәр казылмаларында һәм кабер ташларында гына түгел, исем-атамаларда да уелып калган. Мәсәлән, һуннардан соң күп заманнар алышынгач, кире үз яклары, Керулен ярларына кайтып китүче монгол яуларыннан аерылып, кайбер кабиләләр Иделнең уң як ярында калган. Төркичә «калу» — «калмак» сүзенең әлеге кабилә исеменә («калмык») күчүендә, әнә шулай итеп, тарих тамгасы ята.

Иделнең урта агымында исә, Идел белән Урал арасында IX гасырның соңгы чирегендә хәзерге венгрларның бабалары мадьярлар яшәп яткан. Төрки телле болгарлар, чувашлар, угрофин кабиләләре — мордва, мари, удмуртлар үзара тел-лөгать алмашып, яу килгәндә бер-берсенә калкан булып көн күргәннәр. Идел буе киңлекләреннән башка бик күп халыкларның да юллары, язмышлары үткән: баскынчылык итүчеләр дә, күчмә тормыш белән яшәүчеләрнең дә.

Болгарлар кайдан килеп чыккан соң бирегә? Аларның борынгы ватаны VII гасыр башында Кубань һәм Азов диңгезе буйларында төзелгән Бөек Болгар иле түгелме соң? Тарихтан мәгълүм: бу төрки телле илнең башкаласы Таман ярымутравы булган. Кубрат хан заманында Бөек Болгар чәчәк ату, көчәю чорын кичерә һәм Төрки каганлык йогынтысыннан котыла. Ләкин беркадәр вакыт үтү белән, аны Төньяк Кавказ итәкләренә ыргылучы гарәпләр һәм күрше хазарлар кысрыклый башлый. Шуның өстенә кабиләара тарткалашулар, фео-

дал-тарханнарның этле-мәчеле яшәүләре бу дәүләтне шактый хәлсезләндерә. Кубрат ханның үлеме кабиләләр бердәмлеген тагын да йомшарта. Болгар иле, корт анасы үлгән күч сыман, таркала-туза башлый.

«Болгарлар килә!» Азов ярларында яшәп яткан «вәхшиләр», Византиялеләрне гаҗәпкә калдырып, бөтенләй көтелмәгән яктан Кара диңгезнең кояш баешы ягыннан пәйдә булалар. VII йөз ахырында Кубратның улы Аспарух хан байрагы астында, болгар кабиләләренең бер өлеше күчмә халыкларга таныш юллар буйлап Көнбатышка таба кузгалып китә һәм, бара торгач, Дунайның түбәндәге агымы белән юылучы җирләрдә туктап кала. Җирле славян кабиләләре белән иңгә-иң торып, болгарлар куәтле Византия империясенә каршы торалар, аның майлы калҗа эзләп сузылган кулларын «кыскарталар». Тора-бара, славян кабиләләре белән аралашып-кушылып, төрки телле болгарлар әлегәчә булмаган яңа халыкка әверелеп яши башлыйлар. Славян телен кабул итсәләр дә, исемнәре «болгар» булып кала, вакытлар узу белән мәҗүси аллаларын онытып, Византия православиясенә күчәләр... Дунай буйларындагы Болгария дигән илнең яңа шәҗәрәсе әнә шул заманнардан килә.

Кубратның икенче улы Батбай, кабиләдәшләрен үз тирәсенә туплап, төп нигездә, ата-бабалары туфрагында торып кала. Ләкин хазарлар һәм гарәпләр басымы астында әлеге кабиләләр («кара болгарлар») шулай ук шәһәр һәм авылларны ташлап, Төньяк Кавказ таулары арасына күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Шул төбәктә яшәүче төрки телле балкарларны, карачайларны галимнәр нәкъ менә шул кабиләләрнең варисы дип уйлыйлар.

Ниһаять, хазарларның эзәрлекләп торуына түзә алмыйча, болгарларның өченче төркеме, Кубрат ханның өченче улы Котраг җитәкчелегендә, Кубань һәм Дон буйларыннан кузгалып, озын юл

үтеп, Идел һәм Чулман (Кама) буйларындагы урман-далалар куенына килеп сыена.

Төрки телле, мәҗүси динле болгарларны Идел белән Кама кушылган урында элек-электән яшәп яткан төрки кардәшләре каршы ала. «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява» торган төбәкне, уңдырышлы кара туфракны болгарлар үз итәләр: иген игә, бакча утырта башлыйлар, авылларга нигез салалар. Күршедә генә яшәгән күчмә мадьярлар аларга иген игүдә комачауламыйлар: яңа хуҗалар үстергән икмәктән аларга да өлеш тия. Мадьяр кабиләләре бу төбәктә туктап кына калмыйлар, далалар буйлап сәфәрләрен дәвам итеп, Көнбатышка барып чыгалар, һәм, ниһаять, Европаның үзәгендә, Тисса һәм Дунай сулары арасындагы уңдырышлы туфраклы, чәчәккә күмелгән үзәнлектә торып калалар. IX гасыр ахырында анда артык зур булмаган мадьяр дәүләте (Венгрия) барлыкка килә.

IX гасыр азагында болгар, суар, берсула, эсегел кабиләләре үзара якыная башлап, кабилә берләшмәсе төзиләр, үз тирәләренә башка кабиләләрне дә туплыйлар. Төрле кабиләләрнең үзара дошманлашып алулары бөтенләй бетмәсә дә, көнчыгыш Европада Киев Русе шикелле беренче дәүләтләрдән булган Идел-Кама Болгар иле барлыкка килә. Тарихи язмаларда ул заманына күрә көчле, бай, мәдәниятле, ил буларак билгеләп үтелә. Биләр, Суар, Болгар шәһәрләре гасырлар дәвамында чиратлашып Болгар иленең башкаласы булып торалар.

Шилке халкы Болгар падишаһлары нәселенә нигез сала, бу династия аның варислары — Шилкенең улы Алмыш, Алмышның улы Әхмәт һәм башка ханнар тарафыннан ныгытылып килә. Көчле дәүләт белән ерак һәм якын күршеләре дә исәпләшергә мәҗбүр булалар. Марилар, башкортлар һәм чувашлар белән генә түгел, ерак Киев Русе белән дә дуслык элемтәләре җайга салына. Алмыш хан заманында ук куәтле Багдад хәлифәлеге белән дипломатик мөнәсәбәтләр

урнаша һәм алга таба тагын да ныгый төшә. 922 елда Болгар рәсми рәвештә ислам динен кабул итә, Алмаш хан үзенә әмир Җәгъфәр бине Габдулла дигән гарәпчә исем ала.

Шул заманда Көнчыгыш Европада телгә алырлык ике генә дәүләт булган: Киев Русе һәм Идел-Кама Болгары.

Гасырлар үтә, Идел, Кама, Чирмешән буйларында туктап күчмә халыклар, дала сугышчылары атларын сугаралар, болгарлар тыныч кына уртак тормыш белән яшәүләрен дәвам итәләр, елъязмалар билгеләп үткәнчә, гадел сәүдә итәләр, хәрәмләшүне кичермиләр, үзләре төпләнгән җирнең хәзинәсен арттыралар, яңа шәһәрләр салалар һәм авыллар төзиләр.

Болгарлар терлекчелек, җир һәм бакча эшләре белән генә шөгыльләнмичә, булдыклы аучылар һәм балыкчылар, оста һөнәрчеләр дә булалар. Гарәп тарихчылары болгар тимерчеләре, күнчеләре, көмешчеләре һәм тукучыларының зур осталыгын билгеләп үтәләр. Халыкның күпчелек өлеше кабилә башлыклары (биләр), тарханнар, ханнар өчен бил бөгеп тамагын туйдыра. Фарсы иле һәм Һиндстан белән, кыпчаклар һәм руслар белән сәүдә итешүдән дә ханнар хәзинәсендә байлык ишәя бара. Безнең бабайлар ни белән генә сәүдә итмәгәннәр! Зур һәм кечкенә абзарларда Болгар осталары иҗат иткән алтын-көмеш әйберләре, кыйммәтле күн һәм мех әйберләр күз явын алган, болгар сәүдәгәрләре биредә югары сыйфатлы ашлык, бал, тукыма, чимал тәкъдим иткәннәр. Болгар маллары зур сәүдә үзәкләрендә хөрмәтле урыннарны биләп торганнар, ерак төбәкләргә барып ирешкәннәр. «Булгари» читекләрнең фарсылар һәм гарәпләр арасында даны таралган. Болгарның үзендә дә, хәзерге телдә әйткәндә, халыкара ярминкәләр оештырылган.

Шул ук базарларда, әлбәттә, әсирләр һәм коллар белән дә сәүдә иткәннәр. Байгуралар хәзинәсенә көмеш тәңкә булып ятимнәр һәм

ярлы-ябагайның күз яше тамган, кол кызларның гүзәллеге салкын бизмәннәргә салынган...

Әнә шул ерак чорларда күршедәге рус җирләре белән Болгар арасында аеруча тыгыз, тотрыклы сәүдә-экономика мөнәсәбәтләре урнаша. Киев һәм Чернигов, Владимир һәм Суздаль, Новгород һәм Псков купецлары зур-зур сәүдә көймәләре һәм олау кәрваннары төзеп Идел һәм дала буйлап болгар шәһәрләренә киләләр. Аларның кайберләре болгар җирендә даими сәүдә йортлары тота. «Русларның товарлар төягән кораблары килеп болгар пристанена туктыйлар», — дип X гасыр башында ук Ибн Фадлан язып калдырган. Рус сәүдәгәрләре алып килгән төп товарларын — урман бүләкләрен икмәккә, тукыма, корал, кыйммәтле савыт-саба һәм бизәнү әйберләренә алыштырып алалар. Мәскәүдәге Корал палатасында һәм Ленинградтагы Рус музеенда бизәкләп-сырлап эшләнгән сугышчан баш киемнәре, түгәрәк калканнар, алтын басма белән коръән аятьләре төшерелгән кәкре кылычлар әнә шул ерак заманнар төсе булып саклана; алар арасында әле болгар осталары ясаган үрнәкләр дә юк түгелдер дип әйтергә мөмкин.

Хезмәтчел Болгар иле төрле диннәрнең бер төбәктә яшәвенә дә тыныч караган, аның күгенә мәчет манараларына ияреп, рус һәм әрмән чиркәүләре дә үрелгән. Аксөякләр башка милләтләрнең байбәтчеләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырганда хәтта туганлашудан да тайчынмаганнар! Шул заманның көчле хакимнәреннән, мәсәлән, Владимир князе Андрей Боголюбский — төрки телле кыпчак хатынының улы — Болгар патшаның кияве була. Нәкъ шул заманда, 1170 нче елларда, Казан каласы да («Кальга» «крепость» мәгънәсендә кулланылган) салына.

Урта гасырларның борынгыдан килгән гадәтләре, «көчленеке — замана» принцибы күрше белән күрше, туган белән туган арасында низаглар кабынып тору, көч хакимияте рәвешендә чагылган.

Ыруг, кабилә, халыклар бер-берсенә зур бүләкләр һәм башкодалар, илчеләр генә түгел, баштанаяк кораллы яу да җибәргәннәр. Ләкин, тарих сәхифәләрен актарып карасаң, тыныч көннәр барыбер күбрәк булыр иде.

985 елны беренче рус-болгар килешүе төзелә, егерме елдан соң ул янә яңартыла: болгар сәүдәгәрләре рус шәһәрләрендә, рус купецлары исә Болгар җирләрендә иркен алыш-бireш итү мөмкинлеге алалар. Рус елъязмасында бу хезмәттәшлекнең күркәм нәтиҗәләрен сурәтләгән сәхифәләр җуелмаган әле... Рус сәүдәгәрләренә төрки телне яхшы белүнең файдасы тими калмый. Бәлки нәкъ менә шул заманнардан рус теле хәзинәсе товар («туар»дан), товарищ, кумач, аргамак, курган, сарай, башлык, башмак кебек төрки сүзләр белән баеп калгандыр...

«Тел, лөгать вә әхлак илә...» генә алмашып калмаганнар. Суздаль князьлеге җирләрендә борынгы руслар арасында «хлебный ларь» дип аталган иген игелгән «Ополье» бар. Шул җирләрдә 1024 елны гомер булмаган корылык нәтиҗәсендә ачлык кешеләргә сөякчел кулларын суза. Болгар икмәген — бодай, арпа, тары төягән сәүдә кораблары Идел буйлап Суздальгә күтәрелә. Бабаларыбыз күршеләргә килгән авырлыкны үз иңнәренә дә алалар, аларны ач үлемнән йолып калалар. 1228—1229 елларда бөтен Русьта, бигрәк тә Новгород һәм Белозерскийда ике елга сузылган көчле ачлык вакытында болгарлар Идел һәм Ока сулары буйлап кәрван-кәрван ашлык озаталар, ә болгар ханы Новгород князенә утыз көймә икмәкне бүләк итеп җибәрә. Бу вакыйгалар Болгар иленең явыз дошманга каршы торган иң дәһшәтле чорга туры килә.

Болгар иленең, болгар халкының үсешенә Шәрык белән мөнәсәбәтләр ничек тәэсир иткән соң? Мәктәп дәреслекләреннән үк һәркемгә билгеле булганча, бу чорларда инде гарәп философлары, математиклары, астрономнары, тарихчылары, тел һәм география га-

лимнәре ирешкән уңышлар, аларның хезмәтләре бөтен дөньяда танылырга өлгерә. Европалылар Платон һәм Аристотель хезмәтләрен гарәпләр тәрҗемәсендә укыйлар, гарәп фән-гыйлем үзәкләренә белем алырга баралар. Дөнья әдәбияты хәзинәсе Мөслехетдин Сәгъди поэмалары, Әбугалисина, Әбунаср Фараби, Әбурәйхан Бируниларның үлемсез хезмәтләре, Гомәр Хәйямның нәфис робагыйлары белән байый.

Болгарга сәүдә киңәю һәм ислам дине белән бергә гарәп язуы системасы һәм шәрык культурасы үтеп керә. Экономик, политик ихтыяҗлардан чыгып һәм дин уртаклыгы нигезендә гарәп дөньясы һәм Урта Азия белән тыгыз экономик, культура багланышлары урнаша, Болгар шәһәрләрендә һәм авылларында бер-бер артлы мәчетләр һәм мәхәллә мәдрәсәләре ачыла. Кулдан язган китаплар тарала башлый, фәлсәфи фикер уяна. Шәрык архитекторлары Идел буенда мәчетләр һәм сарайлар салырга булышалар. Болгарлар үзләре дә биек ташпулат торгыза, күпер суга, керамик сыман көпшәләр буйлап су куа, чуен коя белгәннәр, мәгърифәткә һәм фәнгә омтылганнар, шул заманча югары культурага ирешкәннәр. Аларның үз галимнәре һәм әдипләре булган. Бу хакта Багдад хәлифәсенең илчесе сыйфатында Болгарга килгән Әхмәт ибн Фадлан, аңа кадәр үк тарихчы һәм философ Фарави, ә соңыннан сәяхәтче ибн Батута язып калдырган. Кызганычка каршы, Болгар чоры әдәби ядкарьләреннән безнең көннәргә бер генә кулъязма — XIII йөз шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре генә килеп җиткән.

...Әйе, безнең бабаларыбызның беренче ватаны — Дон һәм Кубань буйлары булса да, Урта Идел урман-далаларына алар монгол яуларына чаклы күп гасырлар элек килеп утырган. Төньяк Кавказдагы балкар, карачай кебек икенче тармак болгарлар тел ягыннан да, антропологик яктан да Идел-Урал төркиләреннән аеруча бүгенге татарларга якынрак. Гасырлар буе күп үзгәрешләр, кушылулар булган

— төп охшашлык, туганлыкны исбатлаучы билгеләр барыбер җуелмаган. Һәм мондый охшашлыкны очраклы хәл дип кем әйтә ала. Тарих катламнарында кеше гомеренең иң соңгы символы — кабер ташлары калган. Арада гомумтөрки (чөй) язулары да (болгарларны әле Идел буена килгәнче үк шундый язуга ия булуы бик ихтимал), Болгар ислам диненә күчкәч — гарәп хәрефләре белән эшләнгәннәре дә бар. X гасыр Болгар акчаларында (кабер ташлары гына түгел, фани дөнья малыннан алтын-көмеш тәңкәләр дә озын гомерле икән!) шундый ук гарәп язулары аерым-ачык укыла. Кабер ташларындагы язулар теләсә кайсы төрки телгә караганда да татарга якынрак. Бу да очраклы хәл түгел.

«Яу килә!» Болгар иленең тыныч шәһәр һәм авылларын сискәндереп, коралга тотынырга чакырып, шушы аваз яңгырый. XIII йөз башында Идел буйларына көчле һәм шәфкатьсез илбасарлар монгол-татар яулары килеп җитә. Аларны инде күрше кыпчак даласында ук кансызлыгы белән яманаты чыккан Сүбүдәй исемле яубашы җитәкли. 1223 елда бу гаскәр Калька елгасы буенда русларның кыпчаклар белән берләшкән көчләрен җиңүгә ирешә. Бу уңыштан рухланып киткән монголлар, кыпчак җирләрен талап аргач, Идел буйлап, кара болыт булып, Болгарга таба килә башлыйлар. Чыңгыз туруны (оныгы) Бату ханның яулап алу ниятләрен һәм «аппетитын» чамалап өлгергән болгарлар, әлбәттә, үз дәүләтләренең чиген ныгыталар, дошманга каршы тору өчен ашыгыч чаралар күреп өлгерәләр. Эреле-ваклы һөҗүмнәргә һәрвакыт әзер торырга мәҗбүр булган Болгар яхшы коралланган, өйрәтелгән гаскәр тоткан. Моның өстенә илнең көньяк һәм көнчыгышында биек балчык өемнәре, тирән урлар дошманны лаеклы каршы алырга әзерләнеп торган. 1223 елның көзендә болгар сугышчылары Җигули таулары тирәсендә монголларны урап алып тар-мар итәләр. Илбасарларның бик азы гына качып котыла. Хәйләкәр Сүбүдәй, Иран һәм Кавказ арты илләреннән, кып-

чак җирләреннән талап алган малыннан колак какмас өчен, тәртәне тизрәк кире бору ягын карый. Бату хан урдасына монголларның беренче зур җиңелүе турында хәбәр кайтып җитә.

Болгарларның көче, күрәсең аз булмаган: алар унбиш ел буе дулкын-дулкын булып килгән монгол-татар яуларын зур югалтулар кичереп кире чигенергә мәҗбүр итәләр. Ләкин кояш баешына таба, «соңгы диңгез»гә ыргылучы вәхши илбасарлар, бәйләнчек усал эт кебек, Болгар эргәсеннән китмиләр. Кылыч һәм калкан тавышлары, уклар яңгыры көчәйгәннән-көчәя бара...

«Яу килә!» — чик буйларында кизү торучы җайдак угланнарның атлары күбеккә бата, Болгар өчен дә, руслар өчендә кара кайгылы унөченче йөзнең утызынчы еллары килә.

Ике ел буена махсус әзерләнеп, үзләренә буйсындырган төрки халыклардан да бик күп сугышчы җыеп, күп яуларда остарган монголлар гаять зур атлы гаскәр белән яңадан Идел — Кама буйларына килеп чыгалар. Бу юлы көчләр тигез булмый, ике яктан да бик күп кан коелып, берничә көчле бәрелештән соң, монголлар Суар, Җүкәтау, Кашан шәһәрләрен яулап алалар, Болгар дәүләтенең башкаласын талыйлар, яндыралар.

Ләкин болгар халкы дошманга баш ими, ата-бабалар туфрагын калдырып китәсе булса да, коллыкта яшәүдән баш тарта. Кайберәүләр төньякка — Кама аръягына качып китә, кайберәүләр «Руська киләләр һәм үзләренә урын бирүне сорыйлар»,— дип елъязмалар хәбәр итә.

Болгар иле ярты Азияне яулап алган рәхимсез һәм дәһшәтле дошман һөҗүмен үз күкрәге белән каршылап, монголларның Европадагы беренче корбаны була да, аларның алга таба юлын күпмедер вакытка тоткарлап, илбасарлык гайрәтен шиңдереп тора, ниһаять, ерткычларча өзгәләп ташланганнан соң да Бату ханның тылында баш күтәрә.

Искиткеч зур җирләр — Болгар иле, Киев Русе, Венгрия, Чехия, Адриатика...— монгол атларының тоягы астында кала. Иртыш елгасыннан Дунайга хәтле мәйданда яшәүче дистәләгән халыклар Батуга ясак түли. Коллыкта төшкән халыкларны буйсындырып тоту өчен төзелгән гаять зур Алтын Урда дәүләтенә бай, уңдырышлы болгар җирләре дә кертелә. Ярым мөстәкыйль рус җирләре авыр ясак түләп торырга мәҗбүр ителә. Хуҗалыгын, шәһәрен кабат торгызып, үз исемен саклап калса да, ике гасыр дәвамында баскыннарга үзе үстергән икмәкне, сугышчы ир-егетләрен, угланнарын, чибәр кызларын бирепяшәргә мәҗбүр булган борынгы Болгар.

Алтын Урдада хөкем сөргән монгол-татар гына түгел, халыкларның күбесе мәҗүси, динсез булган (1310 елларда гына Үзбәк хан ислам дине кабул итә). Күп гасырлар ислам дине тәэсирендә тәрбияләнгән болгарларны, руслар белән бер үк дәрәҗәдә ят күреп, рәхимсез изгәннәр: мәчетләрен җимереп, авылларын туздырып, китапларын утка ташлап, хатын-кызларын хур итеп, гореф-гадәтләрен кимсеткәннәр.

XIV гасыр урталарында ук буйсындырылган халыкларның көчле каршылык күрсәтүе, феодаль ызгышлар нәтиҗәсендә, Алтын Урда хәлсезләнә, әкренләп таркала башлый. Болгар җире, бигрәк тә аның хезмәт халкы еш кына феодаль тарткалашулар корбанына әверелә. Алтын Урда ханнары-тарханнары һәм рус князьләре бирегә әледән-әле яу чабып, талап китәләр, Болгарны һәм аның тирә-ягындагы шәһәр-авылларны җимерәләр. Болгар җире соңрак Туктамыш хан белән Аксак Тимер гаскәрләренең дә яу кырына әверелеп ала. Монгол яуларыннан көл-кисәү хәлендә калдырылган Болгар шәһәре үз халкының уңганлыгы, тырышлыгы нәтиҗәсендә генә яңадан аякка басып җиткәч, 1432 елда Федор Пестрый дигән Мәскәү князе шәһәрне талап, җимереп, яндырып китә. Бу вакыт болгар-татарларның Алтын Урда кул астыннан чыккан чоры була. Барыбер Болгар шун-

нан соң инде тернәкләнә алмый. Рус елъязмаларында Бөек шәһәр дип телгә алынган төбәктә хәрабәләр һәм кабер ташлары гына җәйрәп кала. Хәер, хәтта XVIII гасыр ахырларында да әле биредә 44 яхшы ташпулат һәм ике биек мәчет манарасы сакланып калган була...

«Татарлар килә!» Рус шәһәрләре һәм авылларына зур бәла килгәнен аңлатып, чиркәү чаңнары кага-кага, шул яман хәбәр тарала. Урдада властьны үз кулына алган Мамай хан, ясак түләми торуларын сылтау итеп, рус җирләренә яу белән барырга ниятли. Төрле милләт сугышчыларыннан тупланган чуар гаскәр Сарай җиреннән Идел буйлап өскә таба күтәрелә. Сары чин («сары ком») елгасы буенда көнбатышка таба борылып, Мәскәү ягына юл ала. Гасырлар үткәч бу урында Царицын дигән шәһәр үсеп чыгар, ул легендар Сталинград сугышлары белән тарихка керер һәм анда кыю татар егетләре башка халыкларның вәкилләре белән Мамай курганын штурмлауда, уртак Ватанны яңа чор илбасарларыннан саклауда катнашырлар...

Әлегә исә — тарихи 1380 ел бара. Мамай гаскәрен алуда Куликово кыры, күп заманнар бил бөгеп түзгән рус халкының көчле йодрыкка әверелгән нәфрәте көтеп тора...

Ике елдан соң Урданың яңа ханы Туктамыш Мәскәүне кабат яулап, яндырса да, беренче зур җиңүдән соң рус халкы инде үзенең көчен аңларга өлгерә. Алтын Урда әле бер яктан, әле икенче яктан югалтуларга дучар булып, көчсезләнә бара. Моны сизеп-күреп торган башка халыклар да баш күтәрә башлый. Тарихта билгеле ки, мондый очракларда иң алдан үз дәүләте, экономикасы, бердәм теле, дине һәм тарихы булган халыклар аерылып чыга.

Шул чорларда Алтын Урданың төньягында, элекке шәһри Болгардан да өстәрәк, борынгы кечкенә бер кала — «Яңа Болгар» көч ала башлый. XV гасырның беренче яртысында биредә морзалар Сарай ханнарына ачыктан-ачык буйсынмауларын белдерәләр. Шулай

итеп, үзенең яңа башкаласы исеме белән аталган Казан ханлыгына нигез салына. Биредә, рус елъязмачылары билгеләп үткәнчә, «казанлылар дип йөртелә торган болгарлар» яши. Ул вакытта, димәк, аларны Урда татарларыннан аерып караганнар, аерым халык итеп таныганнар. Шулай да еллар үтү белән Идел болгарлары әкренләп онытыла: ким дигәндә биш йөз еллап рус тарихчыларының игътибар үзәгендә торган болгарлар Алтын Урда чоры башлангач күз уңыннан төшә башлыйлар, елъязмаларда Алтын Урда халыклары, тел һәм кабилә аермалыкларына карамастан, уптым илаһи «татарлар» дип кенә йөртелә. XV гасырда «казанлылар» атамасы әйләнешкә керсә дә, әзербайҗан, нугай, балкар, кырымлылар, төрки телләрдә сөйләшүче башка халыклар белән беррәттән, Казан ханлыгы халкы да татар дигән гомуми исем астында йөртелә башлый. Тора-бара инде монгол яулары булып килгән «татар» белән Казан татарларын да бер үк халык дип карауга да ерак калмый... Н.Г.Чернышевскийның түбәндәге сүзләрен кайбер тарихчыларның да исләренә төшерү зарар итмәс иде: «Хәзерге татарлар — Батуга чаклы ул төбәкләрдә яшәгән һәм руслар кебек үк Бату тарафыннан буйсындырылган кабиләләрнең варислары»,— дип язган ул.

Билгеле булганча, Алтын Урдада монголлар азчылык булып, алар дәүләттәге төп халык — төрки телдә сөйләшүче кыпчаклар белән кушылып-аралашып китә. Монгол-татарлар кулындагы байлык, көч һәм властьтан өлеш чыкмасмы дип, буйсындырылган халыкларның аксөякләре дә Сарай тирәсенә ныграк елышалар, Урда ханнарыннан битек-ярлык эләктерә алганнары тәкәббер түшләрен тагын да киерә төшеп, үзләрен «татар» (власть иясе) дип хис итә, «татар» дигән исем ала башлый. Үзләренең татар шәҗәрәләре белән кайбер рус дворяннары да горурланалар, үз гербларына татар тарханнары — морзаларының нәсел тамгаларын төшерәләр. Князь Юсупов кебекләр хәтта хан нәселеннән чыгулары белән кәперәергә яраталар...

Казан ханлыгы чорында Касыйм ханлыгына һәм рус патшасына хезмәт итәргә китеп, кайберләре исемнәрен һәм диннәрен алыштырган морзалар да үзләренең нәсел-нәсәбен онытып бетермәгәннәр, әлбәттә. Еллар үтү белән, алардан рус-казагы шикелле хәрби хезмәт итүче «служивый татарлар» дигән тулы бер сословие барлыкка килгән. Аларның күбесе хәрби хезмәткә ялланып, Россиянең көнчыгыш чикләрен даладан килүче баскыннардан саклауда катнашкан. Граф Шереметьев (Ширәхмәт) кебек байгуралар гына түгел, тарихчы Карамзин, язучы Куприн, язучы Радищев һәм башка күпләрнең шәҗәрәсе әнә шулай ерактан — татар нәселеннән килә. Тәнендә Ибраһим Нурбәк морзалар каны йөгергән атаклы рус шагыйре Державин, төрле заманнарда Шәрык илләрендә Рус дәүләтенең мәнфәгатьләрен яклаган тәҗрибәле татар дипломатлар... Искә төшерсәң, безнең халыкларны бер җепкә теркәгән тарих сәхифәләре аз түгел...

Тарих кабатлана диләр. Дон–Кубань буйларыннан Дунай үзәненә килеп утырган болгарлар исемнәрен җирле славяннарга биреп, үзләре шулар арасында комга төшкән су кебек эреп бетәләр. Көнчыгыштан Идел буена чыккан татарлар җирле болгар халкына һәм күп кенә башка төрки телле халыкларга үз исемнәрен калдыралар.

Болгар иле Алтын Урда хакимлеге урнашкан җирләр арасында да үзенең дәрәҗәсен югалтмаган, һәрвакыт иң байлардан саналган. Бу байлык кешеләрне талау хисабына түгел, сабанчылар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм сунарчыларның тырыш хезмәте белән туплангган. Тикмәгә генә мени Алтын Урдага килгән яулар көнчыгыштан килсәләр дә, көнбатыштан кузгалсалар да, «эшне» Болгар халкын талаудан башлаганнар...

Күршеләргә каршы талау сугышлары алып бару белән бергә, монгол-татарлар яулап алынган җирләрдәге халыкны да ерткычларча изеп яшәгәннәр. Елъязмаларда — балаларын ясак итеп түләргә мәҗбүр булган аналар күз яше, чит-ят җирләргә сатып җибәрелгән

осталар сагышы. Италия, Франция, Мисырдагы коллар базарында — күндәм холыклы, алтын куллы, чибәр яшь болгар хатыннарының, ак тәнле сылу болгар кызларының бәясе зур булган...

Нинди генә авыр шартларда яшәсә дә, халыкның күңел күге аяз, табигате сабыр-йомшак булып калган. Ул иҗат иткән тарихи культура байлыклары, яхшы гореф-гадәтләр буыннан-буынга өзелми тапшырылган. Хезмәт сөючән болгарлар тирә-юньдә кунакчыллык белән аерылып торганнар. Тәмәке тартмаганнар, аракы эчмәгәннәр, сүгенү дә бик зур гаеп эш дип бәяләнгән. Хатын-кызлар пәрәнҗә астына качмасалар да, башларына яулык бәйләмәгән килеш кеше күзенә чалынмаганнар, хатын-кыз матурлыгын чит ирләргә күрсәтү әдәпсезлек саналган. Гомумән, гөнаһ, оят төшенчәләре хезмәт белән бергә халык педагогикасының төп чараларыннан булган. Әдәп-әхлак кануннарының үтәлүе өчен аксакаллар алдында бөтен ыруы, нәселнәсәбе, авылы белән җавап биргәннәр. Олысын-кечесен хөрмәтләү, арулык-пакълек, тыйнаклык, көнкүреш культурасы бүген дә татар халкы арасында югары бәяләнә, яшәү кануны булудан туктамый...

«Яу килә!» Казан ханлыгы өчен хәлиткеч вакытлар — XVI гасыр урталары әнә шул аваз белән тулы.

VII гасырда гарәп-хазар яулары һәм кабиләара килешә алмау болгарларның Дон һәм Кубань буйларыннан таркалып-аерылып китүенә сәбәпче булса, мең елга якын вакыт узгач, татар ханнары һәм биләренең власть өчен үзара якалашулары хезмәт халкы язмышын яңадан зур сынау алдына куя. Иван Грозный, Казанны алу өчен берничә тапкыр талпынып та максатына ирешә алмагач, бик зур әзерлек җәелдереп җибәрә. Өч мәртәбә Казан тәхетендә утырган Шаһгали бу әзерлек эшләрендә зур тырышлык күрсәтә — Казанны алуда җитди роль уйнаган Свияжск кальгасын төзүдә дәртләнеп катнаша. Аның бу хезмәте өчен Иван Грозный бәләкәй генә Касим шәһәрендә утырып калган «Экспадишаһ»ка яңадан Казан тәхетен вәгъдә итә. Ка-

занны өч ай блокадада тотып, ачлык һәм янгыннар белән халыкның түземлеген сынаган, соңыннан шушы ныклык, чыдамлыклары өчен рәхимсез кан кою юлы белән буйсындырган гаять зур гаскәрнең зур өлеше рус җирләренә электән үк күчеп утырган татарларның атаклы отрядларыннан, куштан князьләренә буйсынып ут эченә керергә мәҗбүр булган җәяүле башка милләт сугышчыларыннан гыйбарәт була...

Тарих тузаны сарыла башлаган вакыйгаларны бер сүз белән аңлату җиңел түгел. Казан алынудан алты ел узуга 30 мең татар «оланнары» рус гаскәре белән бергә, уртак ил, яңа туган Россия (аңа чаклы «Русь» дип аталган) мәнфәгатьләрен яклап, Ливон сугышында катнаша. Тагын утыз елдан Тәтеш морзасы Сәлим татарларны «кяфергә каршы, дин өчен изге сугышка» күтәрелергә чакырып чыга. Ләкин гади халык кан коюлардан, җылы туннарына төренгән байларның «дин-ислам өчен газаватка» өндәүләреннән дә туеп, әтәчләнгән морзаның башын кисеп (чынмы, риваять кенәме), Казанга рус воеводасына бүләк итеп җибәрә.

Болгар-татар һәм рус хезмәт ияләренең язмышы әкренләп бербөтенә үрелә башлый һәм Россия тарихының уртак үзәнендә аерылгысыз бер агымга әверелеп китә. Гасырлар буе бергә көн күрү дәверендә ут күрше булып яшәгән халыклар яңа мөнәсәбәтләргә керәләр, үзләрен талаучы байларга һәм илбасарларга каршы да бергәләп көрәшәләр. Уртак Ватанга кулын сузган дошманнар — XVII гасырда «Ялган Дмитрий»ларны яклаган булып патша тәхетен, рус җирләрен яулап алырга кызыккан полякларны алар, XVIII йөздә Полтавага хәтле килеп кергән шведлар короле Карл гаскәреме, XIX гасыр башында Европаны буйсындырып килгән Наполеон яуларымы, Россия белән ничә ел сугышып һаман да сабак алып җиткерә алмаган японнар яисә немецларны, — аларга рус халкы тирәсенә тупланган, төрле телдә сөйләшүче россияннар белән дә эш итәргә туры килгән.

Рус дәүләте бөтен көчен җигеп, поляк илбасарларына каршы торганда, боярлар һәм дьяклар татар морзаларына: «... без сезне туганнарыбыздан якын күреп ышанабыз, бу авыр вакытта, «фетнәле чорда» сез баш күтәрмәссез, безгә каршы яу ачмассыз...» — дип язалар. Казан өчен барган канлы сугышлар тынып калганга әле күпме генә гомер узган, әмма «Рәсәй»не уртак ватан дип тану, аңа килгән авырлыкны бергә күтәрү билгесе булып, илне, Мәскәүне яклаучылар өчен Идел буеннан икмәк, атлар, корал килә. Тарих боларның барысын да яхшы хәтерли. Православиегә күчкән ике татар морзасы — бертуган Урусовларның 1610 елның декабрендә ялган Дмитрийның башын кылыч белән чабып өзүен дә, яисә:

Мәскәүгә дә кердек без, Наполеонны күрдек без,

Французны җиңгәндә җир җимертеп йөрдек без,—

дигән татар бәетен дә хәтерли тарих.

Һәм менә гомере буе изелеп яшәгән халыкның хыял байрагы җилфердәп үз канаты астына, изге яуга чакыра — крестьян патшасы Емельян Пугачев гаскәренә полковник Бәхтияр Канкаев, меңбашы Муса Мостафин, полковник Мәсәгут Гомәров кебек кыю егетләре җитәкчелегендә 85 мең татар килеп кушыла:

Пугачев патшаны күрсә идең,

Алларыннан бил бөгеп узса идең,

Аргамак менеп, дан тотып,

Җаек яуларында йөрсә идең!

...Сал кебек, Идел суында канлы мәетләр ага. Рус, татар, чуваш крестьяннарыннан Әби патша үч ала, Үлем җәзасыннан котылу юлын эзләп, Урал ягына, казакъ далаларына көтү-көтү татарлар качып бара.

Россиянең тышкы дошманнарына һәм үзендәге изүчеләргә каршы иңгә-иң торып көрәшү, урман кисүдә, рудникларда һәм шахталарда, шәһәрләр һәм юллар төзүдә бергәләп эшләү русларда

да, татарларда да бер-берсенә якынлык, кичерешләр барлыкка килүенә сәбәпче була. Бергәләп гомер итү, тәҗрибә уртаклашу тормышның күп кенә мәсьәләләренә, күренешләренә бер төрлерәк караш тудыра. Шул нигездә зур һәм күп милләтле Россиягә эчкерсез мәхәббәт хисләре бөреләнә. Ватаныбызның яңа тарихы, аның безгә аеруча таныш сәхифәләре менә шул чорлардан башлана. Диңгезгә исәпсез елгалар суы тулган кебек, руслар белән бергә еллар, гасырлар буе бергә яшәгәндә татарларның күңеленә «без Рәсәй халкы» дигән уй-тойгы тула. Моны безнең замандашыбыз Әхмәт Ерикәй болай белдерә: «Рус булмасам да мин — Россияле, рус шикелле аны яратам».

XIX гасыр — гаҗәеп бер чор. Әкияттәге каһармандай ул рус милли культурасын күккә чөеп бөтен дөнья рухи мәйданына чыгарып күрсәтә. Пушкин, Лермонтов, Лобачевский, Толстой, Бутлеровлар, Глинка, Чайковский, Айвазовский, Репиннар даһилыгы татарга да Европа мәдәниятенең якты нурын җиткерә. Шул нурлар ижат дәртен уята, Мәрҗәниләр, Тукайлар, Ибраһимовлар чоры юашлана. Руссо, Вольтер, декабристлардан кабынып киткән азатлык ялкыннары Чернышевский, Плехановлар хезмәтләре аркылы күпләрнең зиһененә бөек идеяләр булып сеңә. Данлы Казан шәһәрендә 1887 нче елда могҗиза булып тарихта (һәм татар тарихында!) Ульянов Ленин балкып чыга... XX гасыр бусагасыннан атлап Россиягә, марксизмга таянып, яңа заман сыйнфый көрәш килеп керә.

...1905 ел революциясе дулкыннарының иң югары күтәрелгән бер мәлне дә шовинистик матбугат, һәртөрле карагруһчылар: «Россия җирендә сез килмешәкләр. «Төркиягә китегез» — дип, шау-шу күтәрәләр. Ни өчен? Төркиягә бернинди кагылышы булмаган Идел буе татарларын туган җирләреннән сөргә азаплануның максаты ни? Революцион көчләрнең хәлиткеч бердәмлеген

булдырмау, демократик һәм милли азатлык көчләрен таркату. 1905 нче елда татар эшчеләренең нинди көчкә ия булуы мәгълүм. Тикмәгә генәме Донбасста һәм Бакуда, Казан, Мәскәү, Пенза, Уфа һәм Самарада революцион хәрәкәттә катнашкан татар эшчеләрен җәзалыйлар! Демократик юнәлештә татар интеллигенциясе революциягә шулай ук зур өметләр баглый, аның җиңүенә өлеш кертергә омтыла. Менә, фоторәсемдә, Гафур Колахметов үзенең якын кешеләре арасында, кулында Ленин «Искра»сы һәм бу — 1903 елда! Кара реакция тантана иткән 1907 елда да татар телендә большевистик «Урал» газетасының ялкынлы авазы яңгырый. Шул ук 1907 елда татар халкының алдынгы карашлы уллары, карагруһ реакционерларның йөзенә бәреп, Тукай сүзләре белән әйтәләр:

Иң бөек максат безем: — хөр мәмләкәт — хөр Русия!

Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сиях!

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:

Если лучше вам,

Туда сами пожалте, господа!

...1978-79 ел кышында зәмһәрир суыкларда алмагач кына түгел карт имән агачлары да чыдый алмады, өшеде, корыды. Әмма үз туфрагына тирән киткән тамырлардан ике-өч елдан соң зәгыйфь кенә үсентеләр күтәрелде. Еллар үткәч алар имән һәм алмагач булып үсәчәк әле...

Безнең тарихыбыз да шулай түгелме соң? Монголларның 200 ел хөкем сөрүе халкыбызның тәрҗемәи хәлен ике парәгә, ике өлешкә бүлде: беренчесе корыды, янды, кара төтен булып җилгә очты. Икенчесе Алтын Урдадан котылгач кына яшь үсенте булып күренде, ләкин «үләргә мәхрүм булган» культурабыз гасырлар буе күтәрелә алмады: беренче тарихыбызны Якуб ибн Ногман XI йөздә язган булса, икенчесен XIX йөзнең ахырында гына Шиһаб Мәрҗәни төзи

башлый. Әмма халкыбызның чын тарихы беренче рус революциясеннән генә башлана...

Без Бөек Октябрь революциясе һәм Совет властен ныгыту елларында, Бөек Ватан Сугышы һәм хезмәт фронтларында бөтен совет халкы белән бергә татар уллары һәм кызларының да фидакарьлек, батырлык үрнәкләре күрсәтүен яхшы беләбез һәм моның белән горурланабыз.

Бөек Ленин кулы белән төзелгән Татарстан Совет Социалистик Автономияле Республикасы тугандаш халыкларның бердәм гаиләсендә яңадан-яңа уңышларга ирешә, анда яшәүче төрле милләт кешеләрен бер уй, бер максат берләштерә: халыклар дуслыгы бакчасына әверелгән Ватаныбыз куәтен арттыру хакына, совет кешеләренең яңа буыннары тагын да матуррак тормышта яшәсен өчен, алар бөтен көчләрен, белем һәм тәҗрибәләрен салып хезмәт итәләр. Татар халкы үзенең бүгенге барлык казанышлары өчен кешелек тарихында яңа эра ачкан Бөек Октябрьга, социализм шартларында чәчәк аткан халыклар дуслыгына һәм, беренче нәүбәттә, талантлы дусты — рус халкына бурычлы.

Халыклар дуслыгы — тарихи төшенчә. Катлаулы һәм каршылыклы вакыйгалар, ачыктан-ачык дошманлык һәм бер-береңне аңларга теләмәү дәверләре аша, гасырлар дәвамында, бик зур авырлыклар белән, әкрен-әкрен генә тернәкләнеп килә ул нәфис дуслык чәчәге һәм уртак гамь белән яшәүче, татар халкының күңелендә үзенең тамырларын тирән җәя.

Ерак тарихның кайбер сәхифәләрен генә актарып караганда да, без бик ачык күрдек: бу дуслык турында гасыр башында ук татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай әйткән сүзләрдә гажәеп зур хаклык бар икән:

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,

Тарихында бер дә тапсыз көзге без.

...Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —

Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Халкыбызның Идел-Кама төбәгендә яшәп килгән «тузга язган» тарихы бер мең ике йөз елларга сузылган. Алты йөз «болгар», ике йөз ел — «болгар-казанлы», дүрт йөз елдан артык «татар» исеме белән тормыш Идел суы кебек агып бара. Шул исемнәр астында хасил булган тирән тамырлы тарих, ижат ителгән матур гореф-гадәт, хәзинә кебек рухи мирас, казанган дан-шөһрәт — халкыбызның өне, күзгә күренерлек, һич тә бетмәс байлыгы... Берсеннән дә ваз кичәрлек сәбәп юк, барысы өчен дә без Олы елъязмаларда күрше халыкларның күңелендә мөхтәрәм...

2.3. Милләтнең көче — гыйлемдә

(“Милләтнең көче – гыйлемдә”, Татарстан, 1992, №5-6, 36-46 б.)

«Ватан» җәмгыяте президенты, академик М.Мәхмүтов белән әңгәмә.

Ф.Б. — Без, Мирза әфәнде, бу әңгәмәгә бик тә «кайнар» көндә утырдык. Референдум узганга да ике генә атна үтте. Инде килеп, кабат берничә минуттан Россия Югары Советының алтынчы съезды башланырга тора. Мондый чакта күрәзәче булу теләге дә туып куя. Тарихның кай якка тәгәрәячәген абайлау бик кыен бит... Шулай да беләсе, алдан күрәсе килә! Бу әңгәмәбез журналда чыкканчы, дөнья күргәнче Татарстанда ниндирәк яңалыклар булыр дип уйлыйсыз? Күңелне тыеп тора алмыйсың: ул яхшыга да өметләнә, шикләнеп-шөбһәләнеп тә куйгалый. Чөнки империя, таралудан куркып, үрсәләнә, тотрыклыгын саклый алмый.

М.М.— Алдагы тормыш турында, минемчә, хәзер берәү дә төгәл фикер әйтә алмастыр. Бик атаклы экономистлар да, сәясәт кешеләре дә аптырашта хәзер. Чөнки үзгәреп тора дөньябыз. Менә хәзер иртәнге сәгать ун. Әйе, 6 апрель... Инде әлеге съезд башлангандыр да. Анда каралырга тиешле өч мәсьәлә бар диделәр: беренчесе — хөкүмәт язмышы, икенчесе — Конституция, өченчесе — Россия Президентының вәкаләтен киңәйтү яки кысу мәсьәләсе. Инде талашырга, чәкәләшергә керешкәннәрдер. Аларның үз кайгысы кайгы бу съездда. Татарстанга, безнеке сыман республикаларга эләксә дә таякның бер очы гына эләгер.

Ф.Б.— ***Арысланнар сугышканда төлкеләр, куяннар ял итә дисезме?***

М.М.— Әйе. Мәскәү күбрәк үз өстенә төшкән проблемалар белән мәж килә. Нинди генә гаугалар, тарткалашлар булса да, бу съездда көтелмәгән үк хәлләр тумас, хөкүмәт калыр, чагыштырмача тыныч үтәр. Ләкин ул тыныч үтүдән генә Россиянең икътисади ягы рәтләнсә икән! Яшереп булмый, икътисад упкынга тәгәри. Гади халыкка сәясәттән бигрәк ризык кирәк, көнкүреш товарлары кирә. Ул нишләр? Җәйне әле, бәлкем, әйбәт кенә үткәрербез. Ә көз көне кискенрәк, көтелмәгәнрәк хәлләр тууы ихтимал.

Ф.Б.— ***Менә шул «ихтимал» куркыта да. Мин, мәсәлән, Татарстан буйлап күп йөрим, республиканың авыл хуҗалыгыннан һәрчак хәбәрдар. Бездә икмәге дә, ите-сөте дә булыр, ач яшәү көненә калмабыз. Тик менә Россиядәге хәл шикле: чәчүлекләре дистәләрчә еллар буена тәрбиясез ятты, крестьяннары юк санында. Анда кытлык башланса, ак эт бәласе кара эткә, дигәндәй, авырлыкның зурысы, көнчелекнең зәһәре безгә юнәлер кебек. Әле шунысы да бар бит: безнең халык аз, каршы тору көче чамалы. Татарстанның биләмәсе дә, ялгышмасам, Россиянекеннән 250 мәртәбә бәләкәйрәк.***

М.М.— Ләкин хәзер биләмәнең зурлыгы-бәләкәйлеге белән, халыкның күплеге-азлыгы белән мөнәсәбәтләрне хәл итү искерде. Дөнья хәзер башкачарак бара. Дөньяда бит әле халкы йөз мең булган дәүләтләр бар. Кечерәкләре дә шактый. Һәркайсы мөстәкыйль. Берләшкән Милләтләр Оешмасында һәркайсының вәкилләре утыра.

Ф.Б.— ***Үзләрен басып алырга кыҗрап торучылар да юк...***

М.М.— Юк, юк! Һәм була да алмый. Чөнки дөньяга тәүфикъ урнашып барган шикелле хәзер. Сафлану бара. Әмма аң булу да кирәк. Империалистлар киләчәктә дә империализмча яшәүне куәтләр әле, үз якларына каерырлар, үз файдаларына тәртип урнаштырырга тырышырлар. Әнә күрдек бит инде, утызлап ил Гыйракны тар-мар иттеләр. Кувәйттән кысрыклап чыгарасы урында, Багдадны бомбага тотып, хатын-кызны, бала-чаганы кырдылар. Нәрсә генә димә, дөньяда әле көч хөкем сөрә. Ләкин акыл һәм гаделлек тә үз «урынын» киңәйтә. Минемчә, теге яки бу мөстәкыйль дәүләтне басып алу хурлык белән тамгалана башлаячак, оят гамәл булып саналачак. Шулай булгач, диверсияләр, провокацияләр кимер шикелле. Һәрхәлдә дөньяның сәламәт акыллы көчләре явыз көчләргә юл куймас дип беләм.

Ф.Б.— ***Референдумны кабат искә төшереп үтик әле. Аның нәтиҗәләре безнең Татарстанның суверенлыгын дөнья күләмендә танылуга китерергә тиештер инде. Чынлыкта танулар булырга тиеш, дип өметләнәм.***

М.М.— Шушы көннәрдә Америкадан килгән өч кенә кешелек төркем йөри Казанда: Илдар Агиш һәм тагын икәү... Алар белән без Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга кереп чыктык. Шунда сөйләшеп утырганда Татарстанны рәсми рәвештә тану булырмы-булмасмы дигән темага да кагылдык. Рәсми рәвештә тану булмастыр да, дигән нәтиҗә ясарга туры килде. Сәбәбе — Россия

белән ике арада каршылык бик табылмас. Чөнки бу илнең кулында атом бомбасы бар, ракеталар бар. Картада күренер-күренмәс, дөньяда сизелер-сизелмәс Татарстан хакына Америка да, Франция дә, Германия дә Россия белән низагка кермәс. Шуңа күрә башка юллары хакында уйланырга кирәк. Ягъни, үзебезнең барлыкны сәләтләребез, гамәлләребез белән исбатлау зарур. Кабатлап әйтәм, җир шарында 95 процент халык Татарстанны да белми, татар халкы турында да дөрес мәгълүмат белән яшәми. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Парижда булганда: «Менә мин татар, без — татарлар»... кебегрәк сүзләр ычкындырсаң: «Ә-ә, татарлар!.. Теге... атка атланып, камчы селтәп, сызгырып йөрүчеләрмени?».. дип гаҗәпләнәләр иде. «Сезнең бабаларыгыз атка, сыерга атланып йөргән заманда безнекеләр дә шулай йөргәннәр. Ләкин без дә хәзер Европача яшибез, безнең дә культурабыз, әдәбиятыбыз бар», дип аңлата башласам. Хәйран кала иделәр. Бу бит әле ЮНЕСКО бүлмәләрендә! Ә инде түбәнрәк төшсәң, гади халык арасында сөйләшсәң, анда татарны белүче дә юк. Россия чыгарган тарих китаплары аша гына хәбәрдар булган халыклар татарны кыргый кабилә яки басмачлар дип беләләр. Үзебездә дә ныгый башлаган иде бит инде бу фикер. Башлангыч класслардан ук мәктәпләрдә: «Чыңгыз хан килгән, Бату хан килгән, өч йөз ел безне изеп яшәгәннәр, татарлар — шуларның монда калган вәкилләре», дип аңлаттылар, ләбаса!

Ф.Б.— ***Унбишләп ел элек «Танки идут ромбом» дигән бер әсәр укыган идем. Анда бер майор фашистларга каршы штыклы-пычаклы сугышта дошманнарны «татар» дип күз алдына китереп сугыша. Рәхимсезрәк, усалрак булу өчен...***

М.М.— Нәкъ шулай! Әле хәзер дә татарны фашисттан да яманрак дип санаучы урыслар күп. Бу исә күп еллар буена ялган

тарих укытуның «җимеше». Менә шуңа күрә дөньяның безне таный башлавы шикле.

Ф.Б.— ***Сез мине сөендермәдегез әле бу сүзләрегез белән, Мирза әфәнде. Күңелнең җилкенеп торган өмет канатлары бар иде...***

М.М.— Ләкин канатларны салындыру ярамас. Халык дипломатиясе дигән нәрсә бар дөньяда. Әле шушы арада »Ватан» җәмгыятенең җыелышы булды. Әлеге америкалыларны да чакырган идек. Хәзер безгә үзебезне халык дипломатиясе юлы белән таныта башларга вакыт. Ул ни дигән сүз? «Без — татарлар, безнең борын-борыннан ук дәүләтчелегебез булган, шундый-шундый тарихыбыз, гамәлебез, танылган шәхесләребез бар», ди-ди сөйләргә, аңлатырга, язарга тиешбез. Ә моның өчен нигезебез бар. Зыялы һәм мәшһүр шәхесләребез дә җитәрлек. Америкага киткән галим академик Сәгъдиев белән генә чикләнми бездә талантлар. Менә Франциядә бик атаклы вулканолог бар. Ничек әле фамилиясе, Лоуренсмы? Француз булып йөри, ләкин тамыры татардан. Әле менә һәркайсыбызга мәгълүм фактлар: өч ел элек шахмат буенча дөньяның иң яшь гроссмейстры татар иде. Мин монда Алисә Галләмованы күздә тотам. Инде менә 17 яшьлек Гата Камскиебыз да иң яшь гроссмейстр! Икесе дә татар балалары! Сүз уңаенда искә алдым аларны, мисал өчен... Дөнья җәмәгатьчелеге фикерен туплау, ныгыту максатында милләтнең шундый атаклы кешеләренә таянырга кирәк. Чөнки атаклы затларның кемлеген һәр халык белә, шуларга карап, аларның милләтенә дә бәя бирергә өйрәнә.

Ф.Б.— ***Мисалы башка милләтләрдә дә күренеп тора. Дагстан халкын, мәсәлән, Рәсүл Гамзатов күтәрде, дөнья каршында таныттты.***

М.М.— Шулай шул, шулай!.. Бик дөрес! Ягъни: «Кем син? Дагстанлымы? Беләм, беләм: син Рәсүл Гамзатов халкыннан

буласың!..» Менә безгә дә тарихыбыздан гына түгел, бүгенге тормышыбыздан да кабилиятле кешеләребезне табып торырга кирәк. Табу өчен, әлбәттә, үстерә белү бик мөһим. Фуат Мансуров, мәсәлән, Большой Театрда дирижер. Аны беләләр! Инде тагын... Рудольф Нуриев заманында «теге якка» качып китәргә мәҗбүр булды. Балет биюләрен кую буенча иң зур оста икән. Аны Франция чакыра, Италия чакыра... Бөтен дөнья белә! Ул да татар баласы. Менә Ирек Мөхәммәтов китте хәзер. Лондонда калды. Ул да атаклы!.. Татарстанны, татар халкын әнә шундый шәхесләр күп булган саен ныграк таныячаклар.

Ләкин халык дипломатиясе атаклыларны санап утырудан гына гыйбарәт түгел. Уйларга, төпле программалар булдырырга кирәк: нәрсә мөһимрәк, кемнән башларга, ничек дәвам итәргә? Мәсәлән, «Ватан» җәмгыяте чит илдә яшәүче татарларны эзли, таба, дөньяга таныта, алар белән элемтәдә тора. Монда да, чит илләрдә йөргән вакытта да үзара ярдәмләшеп яшәү турында сөйләшүләр алып барабыз. Ләкин алар очраклы түгел, бәлки даими булырга тиеш. «Ватан»ның гына аралашуы белән канәгатьләнмичә, бөтен халкыбызны аралаштырырга кирәк.

Ф.Б.— ***Татар җанлы татарларны!***

М.М.— Татар җанлы булу бер хәл. Ә менә татарлыкны куәтләү өчен файдалы эшләр кылу — мөһимрәк нәрсә. Горурлыгын күрергә телисең икән, мәшәкать һәм авырлыкларны күтәрә белү дә зарур. Бердәмлекне көчәйтүдән башка танылуга ирешү авыр нәрсә.

Ф.Б.—*«Бердәмлек» дигәннән, иҗтимагый хәрәкәтләр дә икегә аерылып китә кайчак. Әле күптән түгел, февраль башында, ТИҮ җитәкчелеге белән Милли Мәҗлес башлыклары арасына да «кара мәче» керде. Шушы җәһәттән сорау: иҗтимагый оешмаларның кайсысы мөһимрәк? Бездә әле «Иттифак» фиркасе дә бар...*

М.М.— Менә монысы авыр сорау. Аңа төп-төгәл итеп, кистереп җавап бирүне беркем дә үз өстенә алмастыр... Татар иҗтимагый үзәге үзенең эшен эшли, татар дөньясын азатлык өчен, мөстәкыйльлек өчен көрәшергә кирәк дигән фикергә халыкны җәлеп итә. Инде яхшы беләбез: татарларның җитмеш проценттан артыгы Татарстаннан читтә. (Әмма бу алар чит илләрдә дигән сүз түгел. Россиядә, мәсәлән, алар тарихи ватаннарында яшиләр. Мин бу хакта язып та чыктым.) ТИҮ бинаһая зур эш алып бара. Инде «Иттифак»ка килсәк, урыслар белән сөйләшүләр искә төшә. Алар: «сезнең Бәйрәмова экстремист, ул безне куарга лозунглар кычкырып йөри», диләр. Ә мин әйтәм: «Сез, җәмәгать, Бәйрәмованы гына күрәсез. Ник сез Жириновскийны онытасыз? Жириновскийның зәһәрлегенә каршы тору өчен йөз Бәйрәмова кирәк». Чөнки Жириновский сүздә генә түгел, басмада татар белән башкортны куу белән куркытмак булды. Кызу канлылар, тәртәдән чыгучылар һәр милләттә, һәм партиядә бар. Бәлки аларның уңай ягын да табу кирәктер. Алар сискәндермәсә, бер якка чәчрәп чыгып, кискен сүз әйтмәсә, халыкның фикере «ләббәйкә!» булып калыр иде, мөгаен. Коткы салу начар, билгеле, хуплап бетерергә ярамый. Дәлил белән көрәшү мәслихәтрәк. Анысы дөньяга да, демократиягә дә, кешелек законнарына да сыя.

Ф.Б.— ***Бер сәеррәк тоелырдай сорау да биреп үтәсе килә. Сез — академик, Сезне татар зур галим, акыл иясе дип таный. «Ватан» җәмгыяте Президенты икәнегезне дә белеп яшиләр. Форсат туса, Татарстан Президенты булып сайланырга теләрсезме?***

М.М.— Һай, теләмәс идем. Беренчедән, анда бик зур физик көч кирәк. Минем аңа түземем, көчем җитмәс иде. Анда көне-төне эшләргә кирәк. Әйтәләр бит: Югары Советларда утыручылар тәүлеккә 17 шәр сәгать тә эшлиләр, дип. Мин аңа ышанам. Күпме

документ әзерләргә кирәк, күпме бәхәскә, гаугага чыдарга кирәк!.. Меңләгән проблемалар анда. Президентлык — яшь кешене дә хәлдән тайдыра торган вазифа. Аның өчен минем әзерлегем дә юк. Шунысына да игътибар итик: Югары Совет сессияләрендә (халыкча әйтсәк) булыр-булмас депутатлар никадәр! Үзләре дә аңламастан гауга, бәхәс куптаручылар гына да ни тора... Ә чит илләр парламентларында юридик, социаль, экономик белемнәре булган тәжрибәләре булган депутатларны гына сайлыйлар. Алар сафсата сатып утырмыйлар. Алар белемгә таянып эш итәләр, белемгә таянып сүз сөйлиләр, һәм файдалы сүзне киребә сукалап вакыт үткәрмиләр. Дөрес аңлашылсын, мин үзебезнең депутатлардан көлмим, аларны гаепләмим дә. Чөнки сәяси яктан халкыбыз да сукыр иде диярлек. Халкы нинди — депутатлары шундый. Мисал кирәкме? Безнең районда галимгә 5 процент тавыш бирелде, ә шоферга — 15... Россия парламентында шофер файдалырак сүз әйтә аламы, әллә галимме? Мондый инану акылларга Лениннан сеңгән. Һәрбер кухарка җитәкче була ала дигән сүзләрнең чагылышы бит инде бу! Сүзне озайтмыйк. Президент булу турында уйламыйм да. Бигайбә!..

Ф.Б.— ***Күреп, сызланып яшибез: элекке «тугандаш халыклар» пычакка-пычак киләләр. Әрмәнстанда, Әзербайҗанда кан коеш бара, Молдавия болгана. Нинди көчләр болгатуын да бик яхшы беләбез: шовинистлар, империяне саклап калырга маташучылар. Шул бәрелешләр һәрвакыт бер сорау тудыра. Мөстәкыйль Татарстаныбызга каршы да кораллы провокацияләр оештырмаслар микән? Алай булса, безнең халык, коралсыз халык, арысланнарга каршы торырга ниятләгән куяннар хәлендә калачак бит.***

М.М.— Бу очракта дөнья жәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать итүдән башка чарабыз юк. Мәсәлән, Берләшкән Милләтләр Оешмасына,

төрле дәүләтләр җитәкчеләренә: “Карагыз әле, безне бер гаепсезгә кыйныйлар, вәхшиләрчә бетермәкче, таламакчы булалар!” диярга, яклау өмет итәргә тиеш булабыз. Үзегез дә беләсез, кораллы көчләребез юк. Булган нәбәттә дә хәлебез әллә ни үзгәрмәячәк.

Ф.Б.— ***«Ватан» җәмгыятенең дөньякүләм эш йөртүен беләбез. Бу җәһәттән «профилактик» чаралар күрәме ул?***

М.М.— «Ватан» әлегә бик зәгыйфь җәмгыять. Аның бюджеты да юк. Читтән килгән агай-энедән хәер-сәдака алып, шул исәпкә яши торган бәләкәй генә җәмгыять. Без хәзер аны көчәйтү, функцияләрен киңәйтү, вәкаләтен үстерү, чит илдәге милләттәшләр ярдәмендә матди хәлен дә ныгыту хакында уйланабыз. Безнең, мәсәлән, Төркиядә татарлар бар, әмма татар җәмгыяте юк әле. Чөнки берләшмәгәннәр. Кытайда һәм Германиядә дә шундый ук хәл. Ә менә Америкада бергәлек сизелеп тора. Андагы җәмгыятьнең рәисе Искәндәр Бадай дигән галим. Игътибар итегез: чын демократия, цивилизация булган җирдә берләшү бар. Безнең бурыч — дөнья буйлап сибелгән татарларыбызны табу, бердәмлеккә юл ачу. Киләчәктә төрле илләрдәге җәмгыятьләр үзара элемтәдә торып хәбәрләшеп яшәсеннәр иде дип тырышабыз. «Ватан»ның функциясе дә нәкъ шул. Инде менә җәмгыятебезнең «Дөнья» исемле газетасын чыгара башладык. Күргәнсездер, матур да, пөхтә дә булып чыкты, эчтәлеге дә бай сыман. Татарча мәкаләләрен латин хәрефе белән җыйдык. Бераз гына инглизчә язмалары да бар. Бар өлешен — Америкага, шактыен Төркиягә җибәрдек. Аның язмышы, дөнья җәмәгатьчелегенә йогынтысы нинди булыр — хәзергә өздереп әйтү кыенрак. Максат: аны халкыбызның зур трибунасы итү. Аңа ирешү өчен бер-ике ел гына җитмәс әле.

Ф.Б.— ***Кайчак күңелне өметсезлек тә билән ала, Мирза туган. Хуш, дисең үз-үзеңә, тырышабыз, кайгыртабыз, үзара берләшү өчен мәшәкать чигәбез, кайнашабыз... Ләкин 5 тиенлек***

куян, 10 тиенлек зыян гына түгелме бу омтылышларның, гамәлләрнең нәтиҗәсе? Әйтик, Америкада, Төркиядә, Финляндиядә һәм башка төбәкләрдә яшәүче татарлар тора-бара тегеләрнең генә теленә, гореф-гадәтенә күчеп бетмәсләрме? Аларның, минемчә, безнең якка кайтулары елдан-ел шиклерәк.

М.М.— Ул илләрдә төрле буын татарлары яши. Сөйләшкәндә, аралашканда шул сизелә: алар өчен Татарстан әкияттәге бер ил сыман тоела. Кайчандыр монда яшәп киткәннәре туган җирнең туфрак исенә кадәр сагыналар, ерактагы газиз моңны якынайтырга тырышкандай тоелалар. Читтә туганнары әти-әниләренең Татарстан, Россия турындагы истәлекләре белән яшиләр. Россия дип әйтүем гажәпләндермәсен, татарның җире хәзерге Татарстан белән генә чикләнмәвен үзегез дә беләсез. Идел буе да, Урал да, Себер ягы да татар җире булуын тарих раслап тора бит... Чит илләрдәге татарларның теләк-омтылышларын үлчәүгә салсаң, туган җир ягы ныграк тарта сыман. Монысы да бар: безгә килүчеләре тормышыбызның сүтек, таркау булуын күрәләр дә кәефләре төшә. «И, монда бездәгедән дә яманрак икән әле», дип кайтып китәләр.

Ф.Б.— ***Минем төп өметем — «СССРдагы» татарларда. Уңышлы үткән референдумыбыз, Татарстанның үз бәйсезлегенә баруы аларны бу якларга ныклап тарта башлар. Шушы җәйдә үк күпләр кайтырлар сыман. Бик үк ашкынып тормаганнары да күченер. Ник дисәң, белеп торабыз: һәр милләтнең үз илендә башка милләтләрдән арынасы килә, «килмешәк» милләтләрне кысыклыйлар, юньле эш яки фатир бирмиләр, Россиянең күп төбәкләрендә «антирусское движение»не тыю көчәя. Бу инде татар һәм башка милләтләрнең җәмгыятьләрен дә законсыз дип тану. Горурлыгы, милли хисе булган милләттәшләрнең күпләп кайтуын көтәм мин, Мирза әфәнде.***

М.М.— Юк, булмаячак андый хәрәкәт. Бик каты кыссалар да булмаячак! Үзбәкстанда, мәсәлән, үз милли интеллигенциясе үскәч, татарларны кыса башладылар. Мин 50 нче, 60 нчы еллар хакында сөйлим... Ләкин кайтучылар бик аз булды. Хәзер дә әллә ни аерма сизелмәячәк. Күреп торабыз, ләбаса: Татар иҗтимагый үзәге әһелләре татарларны шушы төбәккә туплап җыю өчен күп тырышалар, әмма күзгә ташланырлык нәтиҗә юк әле. Алабугада завод төзелү ихтималы күренгәч, Казакъстанда, Үзбәкстанда чыга торган газеталарда мөрәҗәгатьләр, игъланнар бастырдык, кайтырга димләп... Оештыру өчен вәкилләребезне дә җибәрдек. Әмма бик әз кеше кайтты. Үзенең еллар буе көйләгән оясын, күнеккән мохитен ташлап, булыр-булмас квартирга, шикле хезмәт хакына, ошар-ошамас эшкә өметләнеп кайтуны хуп күрүчеләр хәзер дә булмастыр. Күченеп йөрү җиңел түгел бит әле! «Кайту» дигән сүз дә ачыклык сорый. Самара, Сарытау, Әстерханда туып-үскән татарларның Татарстанны күрмәгәннәре дә күп. Алар бит буыннан-буынга шунда яшәгән кешеләр. Туган җирләре дә шунда.

Ф.Б.— ***Анысын мин дә беләм. Ләкин шовинизм белән агуланган урыслар белми бит ул чынбарлыкны. Тарихның бозып укытылуын да истән чыгармасак, урыслар, һичшиксез, куа башлаячаклар. Шовинистлар «татарның туган җире — Татарстан» дип кенә беләләр.***

М.М.— Андыйлар — наданнар...

Ф.Б.— ***Кызганычка каршы, бу чорда наданлыкның җиңү ихтималы зуррак. Күп очракта наданнар хәл итә бит.***

М.М.— Шуңа күрә хәзер пропаганда эшен көчәйтергә кирәк. Татар кем, Татарстан нәрсә? — урыслар да, чит илләрдәге башка халыклар да белсен. Бер мисал: әгәр сине чит җирдә, үзеңне белмәгән якта талый башласалар, бәлки, яклаучы да табылмас. Ә инде кемлегеңне белгән төбәктә кыйнарга, таларга керешсәләр һәм

син кычкырсаң, мөгаен, күпләр ачык тәрәзәдән булса да якларга теләрләр, тавыш бирерләр. Монда да шулай: татар турында дөньяда мәгълүматны күбрәк, киңрәк таратырга кирәк. Аның үзе яшәгән җирдә хакы да, хокукы да барлыгы һәркайда, һәр милләткә мәгълүм булсын.

Ф.Б.— ***Таралып яшәгән милләткә үз телен саклау, туган телдә белем алу да кыен бит. Бигрәк тә читтә, Россиядә, башка дәүләтләрдә...***

М.М.— Үзебездә дә җиңел түгел. Казанда, мәсәлән, 35 нче татар мәктәбе бар иде. Заманасында без аңа акчасын бирдек, җиһазын таптык, күтәрергә тырыштык. Татар бистәсе, татар балалары... Шушы бистәдә зур-зур йортлар сала башладылар. Табигый ки, яңа квартираларны Ленин, Киров районнарында яшәгән урысларга да бирә башладылар. Аларга аерым мәктәп юк. Кая барырга, нишләргә? Шушы ук мәктәптә укытырга туры килә. Урыс класслары ача башлауга, татар балаларының ата-аналары киләләр дә: «Мин дә баламны урысча укытырга телим», диләр. Чөнки (ул вакытта) татар теленең перспективасы түбән. Хәзер ул мәктәп саф татар мәктәбе түгел инде.

Ф.Б.— ***Димәк, мәктәптә дә, башка уку йортларында да татар телен имтихан дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк.***

М.М.— Фикерең дөрес, Фәнзаман әфәнде. Ләкин бу фикер Татарстанны гына күздә тотканда файдалы. Бу — җитмеш стимулның берсе генә бит. Ә Мәскәүдә нишләргә? Мәскәүдә дә татар укучысыннан яки студентыннан татарча имтихан алыргамы? Ике бала имтихан бирә икән, аерым комиссия утыртыргамы? Мөмкин түгеллеге күренеп тора. Нишлисең бит, Франциядә — французча, Англиядә — инглизчә, Россиядә — урысча сөйләшәләр.

Ф.Б.— ***Алай булгач, Татарстандагы халыклар да татарча сөйләшергә тиеш түгелме соң? Россиядәге татар урыс телен***

мәҗбүри белә, ә Татарстандагы урыс ике татар үз телендә сөйләшсә дә үпкәли. Гаделсезлек бит бу. Яшерен-батырын түгел, референдумда да урысларның шактый өлеше итәктән тартты.

М.М.— Урыс халкын, бигрәк тә гади урысларны гаепләргә ашыкмыйк. Бу очракта булып үткән хәлнең асылын, сәбәбен игътибарга алыйк. Референдум алдыннан Мәскәү радиосы һәм телевидениесе, газеталары Татарстан халкына шундый басым ясадылар ки, хәтта саф күңелләр дә гарипләнерлек булды. «Яңа Карабах» белән дә өркеттеләр, урысларның «икенче сортлы» булып калачагы, Татарстаннан куылачаклары белән дә куркыттылар. Ә информация берьяклы: Мәскәүне тыңлыйлар, Мәскәүне карыйлар, Мәскәүне укыйлар... Үзебездә чыга торган урыс матбугаты да, нигездә пропаганданы Мәскәүчә алып барды — икеләндереп, шөбһәләдереп торды. Әгәр урыслар татар телен белсәләр, татар матбугатын аңлый алсалар, төп халыкның күңеле изгелектә икәнен, һичшиксез, белерләр иде. Үзебездәге урыс матбугаты чынбарлыктан тайпылмаса, урыс телле кешеләрнең башын бутамаса, нәтиҗә тагын да күңеллерәк, гаделрәк булачак иде. Кабатлап әйтәм, ике халык ике төрле информация белән яшәде. Татар галимнәре, язучылары, җитәкчеләре, журналистлары чын тарихны, чын хәлне ничек кенә дәлилләп, тирәнрәк анализлап язмасыннар татар матбугатында, аларның язганы республика халкының шактый өлешенә барып җитмәде.

Ф.Б.— ***Урыс матбугаты дигәннән, Мирза әфәнде, Литва җиренә соңгы сәфәрем искә төшә дә тора. Литвача укый да белмим, аңламыйм да бит инде... Шуңа күрә аларда чыга торган газеталарның урысчаларын гына укып йөрдем. Гаҗәпләнүемнең чиге булмады: Литваның мөстәкыйльлегенә каршы бер генә дә җөмлә дә юк! Гади халык белән сөйләшкәндә, җитәкчеләр, галим-голәмә белән әңгәмә корганда да шушы гаҗәпләнүемне***

әледән-әле әйтә тордым. «Нәрсәсе гаҗәп аның?!— диделәр. — Суверенитет — азатлык дигән сүз. Ягъни, изге нәрсә. Азатлыкның капма-каршысы — коллык. Без бит инде коллыкны пропагандалауга юл куя алмыйбыз!». Шунысын да аңладым: анда Литва мәнфәгатьләренә каршы хәрәкәт итүче, күрше илләр (шул исәптән Россия) файдасына пропаганда алып баручы партияләр дә тыелган. Һәм бу минемчә, бик табигый: Татарстанда яшисең икән, Татарстанның тәрәкъкые өчен хезмәт ит!..

М.М.— Әле беркөнне, референдумга хәтле, кердем күршемә. Җитәкче кеше, аңлы кеше. Ләкин референдумга мөнәсәбәте шулкадәр тискәре — исем китте!.. Мин аңлатырга керештем. Ягъни теге мәсьәләнең, бу мәсьәләнең асылы нәрсәдә икәнен. Тора-бара ул аптырады: «Карале, малай, бу якларын белми идем», ди. Нинаять аңлады, карашы да яктырып китте, хәтта!..

Ф.Б.— ***Үзебездәге урыс матбугатына аптыраган инде... Гел киregә сукаларга бит. Узган ел түзмәдем, Президентның үзенә керергә булдым. Дөресен генә әйткәндә, дулкынлануымны, үртәлүемне дә сизгәндер. «Менә, Минтимер туган, матбугатны көчәйттек, яңадан-яңа урыс газеталары да ачып җибәрдек. Куанасы гына кебек. Ләкин карагыз: барысы да диярлек чынбарлыкны суялар, хәтта, үзегезнең изге ният белән әйтелгән сүзегездән көләргә, кире мәгънә чыгарырга маташалар. Йә, сөенечме шул?» — дидем... Минем фикеремчә, урыс газеталарының башына да изге ниятле, намуслы, хакыйкатькә хыянәт итмәүче мөхәррирләр куярга кирәк. Инде дә Президент җавабына килсәк, болайрак диде: «Матбугат төрлесен яза инде ул. Сүз иреге бит». Ә мин аның җавабы белән һаман да килешә алмыйм. Сүз иреге дигән төшенчә гаделлеккә дә хилафлык кылырга ярый дигән сүз түгел.***

М.М.— Әлбәттә, матбугат, кайсы гына телдә чыкмасын, гадел булырга тиеш. Әле менә сез Литва турында әйтеп үттегез. Балтыйк буе дәүләтләрендә хәл башкача шул: тормышны, тарихны аңлау да, иҗтимагый хәрәкәт тә, халыкның фәһемләве дә... Нык аерыла! Анда гомумхалыкның культура дәрәҗәсе югарырак дисәм дә, мөгаен, ялгышмамдыр.

Ф.Б.— ***Шулай шул. Алар бит бу империя коллыгында безгә караганда ун мәртәбә кимрәк булганнар...***

М.М.— Сәбәбе ул гына түгел. Нәрсә генә дисәгез дә, Европа цивилизациясе тәэсирендә үскән халыклар бит алар. Шуңа күрә психологиясе дә үзенчәлекле андагы гавамның. Тагын бер факт: ул илләр социализмда да безнең кебек 74 ел яшәмәделәр, 1940 елдан гына СССРга «керделәр», ягъни унсигезенче елдан кырыгынчы елга кадәр мөстәкыйльлекнең тәмен татып калганнар иде. Без аларны монда «милләтче буржуаз-фәлән» дип сүгеп яшәсәк тә, барыбер алар ирекле халык булып яшәделәр. Шул вакытта яшәгән, шул чакта азатлык хәрәкәтендә катнашкан шактый кешеләре хәзер дә исән! Алар азатлыктан авыз иткән шаһитлар. Истәлекләре дә, тәҗрибәләре дә җитәрлек һәм күбесе аңлату эшләре алып баралар. Бу яктан без мәхрүм. Безнең зыялы кешеләребез дә берьяклырак бит әле. Татар җанлы, милли хисле, гыйлемле шәхесләребез, нигездә, гуманитарийлар. Алар, сүз дә юк, азатлык хәрәкәтендә актив катнашалар. Табигать, техника фәне вәкилләре бу эштә күпме катнаша? Юклар алар, юклар... Юк дәрәҗәдә азлар. Шуның өстенә татарча да белмиләр. Татар тарихы, әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксынудан ерак йөриләр. Кызыксынганнары да үз телебездә укый алмыйлар. Күрәсез, интеллигенциябезнең мөмкинлекләре чикле. Димәк, аның дөньяга карашы, фикерләү сәләте дә таррак булып тора. Милли, иҗтимагый хәрәкәтебезне бөтендөнья яссылыгында барлап карасак, үсү мөмкинлеге көн кебек ачык.

Әйтик, экология проблемалары. Аларны гуманитар белемгә таянып кына хәл итеп булмый, ләбаса! Техник гыйлемгә, физика, химия, математика шикелле фәннәргә таяну да бик зарур. Экология проблемасы — ул промышленность проблемасы. Менә шуларны аңлаган хәлдә үзебезнең зыялыларыбызны барлап карасак, бер генә аякта басып торучыны хәтерләтәбез.

Ф.Б.— ***Димәк, бөтен карап торганыбыз гуманитарийлар...***

М.М.— Аларның да бер өлеше генә. Шактыеның фәһемләве коммунистик тәрбия, коммунистик сәясәт дәрәҗәсеннән узмый. Фәнни коммунизм кафедраларында алган белем белән ерак китеп булмавы инде аңлашылды... «Буа (Минзәлә, Бөгелмә...) районнарында башлангыч партия оешмасының хәрәкәте» кебегрәк темаларга диссертация яклаган галимнәрдән әлләни көтеп булмый. Фәкать марксизм-ленинизмны гына өйрәнеп үскән кешеләр ич! Көрәштә бик дәртле, милли җанлы булсалар да, белем кытлыгы комачаулап тора, дөньяны танып белүләре җитми.

Ф.Б.— ***Без шактый сөйләштек, киңәштек, Мирза әфәнде. «Татарстан» журналы укучыларын кызыксындырган күп темаларны кузгатып карадык, дисәм дә ялгыш булмас. Бу әңгәмәне тулырак, файдалырак итү хакына тагын нәрсә өстәр идегез? Мөһим сүзләрегез, фикерләрегез качып калмасын иде.***

М.М.— Милли хәрәкәтнең көчәюенә берничә ел үтте. Күп уйладык, төрле фразаларны чагыштырдык. Кирәкле дип саналган фикерләрнең дә әйтелми, язылмый калганнары юктыр инде шәт. Барысы да әйтелеп бетте. Һәр милләтне алга этәргән иң зур көч — белем ул. Сез миңа табып бирегез яһүдләрдән торган колхозны. Юк, дисезме? Әйе, юк! Алар да совет чорында яшәде, таралып яшәде. Ләкин үз милләтләрен югалтмадылар, белем белән ныгыттылар, үстерделәр, күтәрделәр. Югыйсә бит элегрәк итек чистартучы да булган яһүд, чәч алучы да, кара эшче дә... Алар совет властен дә

бушлай белем алу форсатыннан бик белеп файдаландылар. Ә безнең татар элек тә Донбасс шахтасына акча сугам дип барды, хәзер дә. Инде менә безнең татарыбыз акча хакына теләсә кайда нефть чыгарып йөри. Безнең милләт бүгенге акча, бүгенге ризык хакына тырыша, ә яһүд үз милләтенең киләчәген күздә тотып иҗат итә. Бездә күп кенә ата-аналар, баласы сигез сыйныфны бетерүгә үк: «Бар әле, акча эшләп кайт, акча юк», диләр. Ә акыллы милләттә алай эшләмиләр, тирән белемне һәр нәрсәдән өстен куялар. Чөнки дөньяда интеллектуаль потенциал дигән бик мөһим төшенчә бар. Белемнең, гыйлемнең кадерен белгән милләт кенә үсә.

Ф.Б.— ***Сезнең белән сөйләшкәндә әткәмнең васыятен үтәү хисе дә булды күңелдә, Мирза әфәнде. Үләр алдыннан хәер-фатиха биргәндә «Дөньяда гафил булып яшәмә» диде дә, авыр сулап: «Хәер, «гафил» сүзен аңлаучылар юктыр инде хәзер, син дә белмисеңдер», дип куйды. Ә мин «беләм» дидем, Сезнең катнашта чыккан «Гарәпчә-татарча-русча сүзлекне» күрсәттем. Сөенде мәрхүм: «Бетмибез икән әле, милләтне кайгыртучы кешеләр бар икән!» — диде. Болай дип тә өстәде: «Син, улым, шундый кешеләр белән аралашырга тырыш, шулар белән киңәшеп яшәү юлын тап...» Һәм менә, журнал укучыларының да теләген истә тотып, сезнең белән киңәшеп утырдым.***

М.М.— Хезмәтемне танучыларга, зурлаучыларга бер генә сүзем бар: рәхмәт!

2.4. Күрше белән гәпләшү: «Керү», «чыгу» һәм федерациянең киләчәге турында

(“Татарстан хәбәрләре”, 1992, 7 май)

Кайчак ялгызлык, шик-шөбһәләр баса да, шулардан котылу өчен күршегә керәсең. Күршем — рус, үзем татар. Референдум алдыннан барып керсәм:

— Юлга җыенасы булыр инде, — ди. Чемоданнарына карап-карап ала. Россия вице-премьеры Сергей Шахрайның сүзләре аның котын алган икән. Исегездәме, отставкага китәргә ике атна кала, безнең референдум алдыннан ул, Татарстан, мөстәкыйльлек алса, андагы русларга китәргә туры киләчәк, ә читтә яшәүче 5 миллион татар Россиядән Татарстанга кайтып китәргә мәҗбүр булачак, дип белдергән иде.

Без — татарлар үзебезнең тарихыбызны хәзер белә башладык. Аның турында күп уйланабыз. Ә менә күрше ишектә генә яшәүче күршебез — рус кешесе аның нечкәлекләрен белми, аның әле соңгы вакыйгаларга кадәр бу хакта уйлап та караганы юк иде. Шуны истә тотып, мин күршем тәгъдим иткән темага аның белән гәпләшергә утырдым. Максатым аның бу өлкәдәге мәгълүматын ачыклау һәм үзем теләгәнне аңа төшендерү иде. Менә шундыйрак гәп куерды ике арада.

Күрше: Соңгы вакытта бөтен тынычлыгым югалды. Шушы «керү», «чыгу» аркасында Карабахта, Грузиядә, Молдовада коточкыч сугышлар бара. Безне дә шул хәл көтәрмени?

Галим: Минемчә, һич юк. Мөстәкыйльлек алуның тыныч юлын үзебез сайладык бит. Аннан, үзегез беләсез, татар белән рус арасында аңлашылмаучанлык беркайчан да булмады. 440 ел без янәшә генә түгел, ә бергә яшибез. Дөрес, сезнең тарих безне яхшы сүз белән искә алмый. Яла белән бөтен мәктәп дәреслекләре тулган: авторлар тарих турында кешеләрдә нинди фикер, караш тудырганнарын аңлап та бетермиләр кебек. Руслар белән бу кадәр үк кушылган халык юк Россиядә. Телебез, динебез, гореф-

гадәтләребез башка, ә тормыш турында бер төсле уйлыйбыз. Безне бер-беребезгә каршы куярга, бүләргә маташмасыннар да.

Күрше: Син шулай дисең дә, ә «Иттифак» партиясенең рәисе Фәүзия Бәйрәмова безнең бөтенебезне куарга куша әнә.

Галим: Минемчә, ул, Татарстанның азатлыгына, бәйсезлегенә каршы булган русны да, татарны да тотмыйбыз, диде. Моның мәгънәсе исә бөтенләй башка. Кайсы халыкта юк ул уң һәм сул экстремистлар? Татар белән башкортны юк итү белән яңадан Жириновский бер үзе йөз Бәйрәмованы алыштыра. Ә бит сайлаулар вакытында Жириновскийны Президент итү өчен 6 миллион кеше тавыш бирде! Ә «Память»ның җитәкчеләре нәрсә генә сөйләми?! Хәзер бөтен җирдә казак ополчениеләре оеша. Сизми дә калырсың алар Казан янында да күренә башларлар. Алар инде Төньяк Осетиядә автоматлар болгыйлар. Атарга, таларга, үтерергә Молдовага ыргылдылар.

Күрше: Дөресен әйтим, безнең илдә яңадан ялланган үтерүчеләр булыр, дип бер дә уйламаган идем. Солдатларга 2 мең, офицерларга 5 мең түлиләр икән. Ият, биллəhи. Шулай да, кабат татарларга кайтыйк әле. Аларны руслар нәрсә белән рәнҗеттеләр соң?

Галим: Гади сорау түгел бу. Әйтик, ак тәнлеләр Американың төп халкын — индеецларны нәрсә белән рәнҗеттеләр? Ә португаллар анголаларны? Беренчеләре индеецларның хокукларын танырга, икенчеләре, 500 ел үткәннән соң, Анголага бәйсезлек биреп, аннан китәргә мәҗбүр булдылар. Ә руслар үзбәк, кыргыз, төрекмән, һәм казахларны, бу халыклар зур теләк белән тизрәк Мәскәүдән бәйсез булуларын игълан итәрлек итеп, нәрсә белән рәнҗеттеләр?

Күрше: Әйе, сораулар, чыннан да, җиңел түгел. Тик шулай да, мин җавап көтәм. Тарихтан мисаллар белән булсын иде ул. Әйтик,

Иван патша буйсындырган татарлар. Казанны коткару өчен нәрсә булса да эшләгәннәрме?

Галим: Әлбәттә. Фәнни әдәбиятта дәүләтне торгызу өчен барган көрәш мисаллары күп. Нәкъ шул каршылык татар дворяннары катлавын юкка чыгару өчен бер сәбәп булган.

Күрше: Татарлар демократик хәрәкәттә, әйтик, инде безнең гасырда ничек катнашканнар?

Галим: 1905 елгы революция аларны канатландырып җибәрә. Революциядә актив катнашкан өчен татар зыялылары хөкүмәт һәм карагруһчылар тарафыннан каты әзерлекләнәләр. Татарлар рус җирендә утыра, аларны Төркиягә җибәрергә кирәк дигән гайбәтләр таратыла. Татарның бөек шагыйре Г.Тукай ул вакытта:

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф итте ләр:

— сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр, — дип яза, һәм *«Китмибез!»* дип җавап бирә.

Моннан йөз елга якын элек үк әнә ничек дөрес әйткән шагыйрь! Безгә исә бүгенге заманның «демократлары» шундый ук язмыш, бу юлы инде Монголиягә китүебезне телиләр. Без ирекле Россия эчендә, үз нигезебездә яшәгән килеш, беркая чыкмыйча, бәйсезлек телибез. Хәер, кайбер рус өлкәләре дә үзәктән экономик бәйсезлек таләп итәләр, Мәскәү министрларының диктаты хәтта аларны да туйдырган.

Күрше: Бик күпләр татарларны монголлар белән килгән һәм рус җирләрендә төпләнеп калган, дип саный...

Галим: Мондый фикер — рәсми царизм тудырган «тарих белеме» һәм Сталинның «халыклар дуслыгы» чоры идеологиясе нәтиҗәсе. Шуңа күрә, татарның бәйсезлек турында сүз кузгатуы ук рус кешесендә эчке каршылык тудыра. Тарихны белмәүчеләр безнең хакта рус җирендә яшиләр һәм тагын әллә нинди таләпләр куялар,

дип уйлыйлар. Татарлар бу урыннарда бернинди славян кабиләләре булмаган чактан ук яшиләр. Бу аларның бабалары яшәгән җир.

Татарлар Пензадан Красноярск һәм Төмәнгә, Пермьнән Әстерхан далаларына чаклы. Россиянең 30 өлкәсендә һәм республикаларында компактлы булып районнарда, авылларда яшиләр. Алар бирегә бүгенге Татарстаннан күчеп китүчеләр түгел, алар үзләренең борынгы җирләрендә көн күрәләр. Шәһәрләрдә яшәүче татарларны да кушкач, Россия дигән зур океан уртасында урнашкан бу утраулардагы халык саны 5 миллионга якынлаша! Ә Татарстанда алар 2 миллионнан азрак. Идел буендагы шәһәрләр — Әстерхан, Саратов, Самара, Сембер — һәммәсе иске татар исемнәрен йөртәләр. Хәтта Царицын да, русча яңгыраган кебек тоелса да, татарның «сарычин» (сары ком) сүзеннән килеп чыккан. Шахрай әфәнде нинди тарихи мәгълүматларга таянганнардыр, белмим, әмма аның кебек дәрәҗәле сәясәтче авызыннан 5 миллион татарны Татарстан Республикасына, ә миллион рус кешесен Россиягә күчерергә, дигән сүзне ишетү көлке дә, гаҗәп тә.

Референдумны татарлар гына игълан итмәде, ул республикада яшәүче барлык халыклар өчен үткәрелде. Тарихи гаделсезлек өчен, кешенең рәнҗүен аңлату өчен, бик сизгер психолог булырга кирәк. Ә халык кадәр халыкның әкренләп язуын, телен, әдәбиятын, гореф-гадәтләрен, милли һәм кешелек, горурлыгын, бабалары җирен тартып алуны күрмәс өчен социаль сукыр эгоист булу җитә.

Күрше: Мин сезне аңлыйм, әмма мөстәкыйльлек өчен көрәшкә кешеләрне тарихи гаделсезлек кенә күтәрми. Без дә сезнең белән бергә сәгатьләр буе чиратларда торабыз, бәяләрнең артуын күреп хафага төшәбез... Шуңа да бу сорауларның нигә хәзер генә күтәрелүенә төшенүе кыен.

Галим: 1990 елның августында Татарстан Югары Советы депутатлары (руслары да, татарлары да) бертавыштан

республиканың суверенлыгы турында Декларация кабул иттеләр. Республика Президентын сайлаганда да халык бер сүздә булды. Ә Мәскәү, халык теләген күрмәмешкә, ишетмәмешкә салынып, дәшми кала бирде.

Ельцин, Россиянең союз үзәгеннән бәйсез булуы өчен көрәшкәндә, Казанга килеп, «Йота алган кадәр алыгыз мөстәкыйльлекне», — дигән иде. Хәзер Горбачев юк. Ә безнең өчен үзәк союзныкы булса да барыбер — тартып ала, бирми, рөхсәт итми, куша...

Күрше: Нәрсәне рөхсәт итмиләр соң?

Галим: Нәрсә рөхсәт итүләрен санап чыгуы җиңелрәк булыр. Әйтик, Татарстан — Россия арасында экономик килешү төзелде. Россия ягыннан аңа — Егор Гайдар, Татарстаннан — Мөхәммәт Сабиров кул куйдылар. Делегация әлеге хәбәрне Мәскәүдән алып кайткач русы да, татары да сөенде — нефть сатабыз да, картларга, авыруларга һәм балаларга азык-төлек сатып алабыз, дип уйладылар. Тот капчыгыңны дигәндәй, Мәскәү товарыбызны чит илгә чыгарырга ирек бирмәде. Бу республикадан, аның халкыннан көлү түгелмени?!

Рус булмаган кешенең күңелендә яткан рәнҗү нигезләренә инде төшелгәндер. Мөстәкыйльлек өчен көрәшкә халыкны милли мин-минлек түгел, тормышның социаль-экономик шартлары күтәрә. Бу еш кына милли бәйсезлек лозунгысы астында эшләнә.

Дөнья базарында нефтьнең 1 тоннасы 120–180 доллор тора. Ә Үзәк безгә 1 тонна нефть өчен 25 сум түләп килде! Хәзер 600 сум, ягъни 6 7 доллор түли. Ә 2 миллиард тонна нефтебезне бушлай диярлек алып бетерделәр... Нефтьтән тыш Татарстанда промышленность индустриясе дә көчле. Тик безгә монда да «җәелергә» ирек бирмиләр. Әйтик, Зеленодольск чыгарган 360 мең суыткычның 10 меңнән азрагы гына үзебездә кала. Миллиард

сумнарда җыелган салым да Мәскәүгә китеп бара. Аннан, бу акчаның бер өлеше бездә урнашкан югары уку йортларын, шифаханәләрне, техникаларны тоту өчен, кире әйләнеп кайта. Тик акчаның төп өлеше Мәскәүдә утырып кала.

Күрше: Татарстанның Экономик мөстәкыйльлеге турында сөйлисез дә, аның бөтен байлыгы мондагы халыкныкы түгел бит. КамАЗны, мәсәлән, бөтен ил төзеде...

Галим: Әйе, газеталарда шулай яздылар. Әмма аны, Татарстан нефтен саткан акчага, димәк безнең акчага, безнең җирдә, безнең кешеләр белән төзеделәр... Хәер, КамАЗ хәзер акционерлар кулында.

Күрше: Буш кул белән калуыбыздан куркам мин. «Вечерняя Казань» (4/3 — 92) язуы буенча, сатарлык әйберебез юк икән ич безнең.

Галим: Әйе, бу газета безне бөтенләй хәерче итеп күрсәткән. Имеш 47 исемдә товар үзебезгә кертәбез, ә үзебездән 17 төрлене генә чыгарабыз. Без соң әле исемлеккә кермәгән вертолетлар, ИЛ – 62 самолетлары, радиоаппаратура сатмыйбызмыни? Компрессорлар, мех әйберләре чыгармыйбызмы әллә? Безнең җәнлек совхозлары Петербургтагы халыкара аукционда кыйммәтле мехларны миллион доллорларга саталар түгелме соң?

Мөстәкыйльлегебез күбрәк зуррак булса, үзебездә телевизор, тузан суырткыч, кер юу машиналары һ.б. бик күп товарлар чыгаруны да җайга салыр идек.

Татарстанның сәяси бәйсезлеген дә, экономик бәйсезлеген дә танырга теләмәүләре аңлашыла. Үзәк өчен Россия империясен элекке хәлендә саклап калу мөһим. Ә бу тормыш кануннарына каршы килә: безнең чор — барлык халыкларның тулы ирек һәм мөстәкыйльлек өчен көрәше чоры ул. Союз милли дәүләтләргә бер кеше теләге буенча гына таркалмады — бу закончалыклы күренеш.

Югославиянең таркалуы да җәмгыятьнең үсеш законнарына буйсына. Словаклар һәм чехлар бүленештеләр. Ирландия Бөекбританиядән чыкты, хәзер бу хакта шотландиялеләр дә хыяллана. Хәтта Аляска да Америка Кушма штатларыннан чыгу турында сүз кузгата!

... Кечкенә Швейцариянең кантоннары мөстәкыйль булып менә 700 ел инде бик тыныч гомер кичерәләр: берничә кечкенә район, дүрт дәүләт теле, һәрберсенең үз мәктәбе. Чын демократиягә мисал түгелмени бу? Әмма моны аңлау өчен иске империячел фикерләү түгел, заманча уй йөртү кирәк шул...

Россия, цивилизацияле халыклар карашында үзенең абруен, йөзен саклап калырга теләсә, моңа «керү» яки «чыгу» мәсьәләсен хәл итеп түгел, ә «конфедерация»гә туплану аша гына ирешергә мөмкин.

Үзенең бер интервьюсында Россиянең киләчәге турында сораган корреспондентка Ельцин «Ул үзен федерация һәм шул ук вакытта элекке автономияләрнең конфедерациясе формасында саклап кына кала алачак», — дигән иде. Бу фикерне хупларга һәм алга таба үстерергә кирәк. Бу — Татарстанның бәйсезлеге һәм Россиянең бөтенлеге мәсьәләләрен чишүнең тыныч юлы да.

Кайбер депутатлар фикеренчә, Татарстанның ирек алуы Россияне җимерелүгә илтәчәк. Кечкенә Татарстан Республикасының мөстәкыйльлек алуы да аны таркалуга китергәч, димәк, Россия бик көчсез булып чыга түгелме? Ә без, азат халыкларның ирекле союзы, бер республикалар белән — федерация, икенчеләре белән конфедерация нигезендә төзелгән Россияне ныгытыр гына дип уйлыйбыз.

Күрше: Нәтиҗә ясыйк инде...

Галим: Нәтиҗә бер генә: Карелия, Бурятия һәм Татарстан өчен — конфедерация, ә федератив форма — моны теләүчеләр, мәсәлән, Чувашия, Якутия өчен.

2.5. Рөхсәт итәргәме, тыяргамы?

(“Татарстан яшьләре”, 1990, 3 март)

Сайлау алдыннан алып барыла торган агитация һәм пропаганда сайлаучыларга нинди генә вәгъдәләр бирми дә, алар алдында нинди генә яңадан-яңа проблемалар ачмый...

«Һәркемгә хезмәтенчә» дигән мәсьәләсендә А.Бабко, мәсәлән, («ВК», 1 февраль, 1990 ел) халык куллануы товарларын гадел бүлүнең төрле вариантлары турында сүз алып бара. Мәкаләне укып чыккач, уйга калдым: гаделлекнең төп шарты булып халык куллануы товарларын җитәрлек күләмдә җитештерү түгел, ә аларны дөрес бүлү тора микәнни? Сайлаучылар үзләренең булачак депутатларыннан нәрсә көтәләр соң?

Конкрет эш. Ә бездә ничек килеп чыга? Профессиясе буенча артист сайлау алды кампаниясе вакытында промышленностьны үзгәртеп кору турында сөйли, гәрчә ул бу турыда ишетеп кенә белсә дә, күз алдына ачык кына китерә алмаса да, җимереклекләрне юк итү турында сүз алып бара. Мәдәниятны үстерүгә кагылышлы сорауга: «Бүген бездә мәдәният кайгысы түгел» дип җавап бирә. Материаль байлыкларны бүлү турында иптәш Бабко тәкъдим иткән системага бәя бирүне укучы хөкеменә калдырып, балаларга һәм яшьләргә белем бирүне үзгәртеп кору буенча үз фикеремне белдерәсем килә. Әлбәттә, һәркем теләсә нинди сораулар буенча үз фикерен әйтә ала. Шуңа күрә плюрализм. Әмма таләпләр һәм тәкъдимнәр үз өлкәсендә компетентлы булган кешеләр тарафыннан кертелгәндә генә реальрәк була. Әгәр дә двигательләр җитештерүче белгеч мәктәпләр һәм бе-

лем бирү проблемаларын хәл итәргә алына икән, укучыда нинди фикер туарга мөмкин? Минем уемча, нәкъ И.А.Крылов әйткәнчә: «Эшләр харап, әгәр дә пешекче итек тексә, ә итекче пәрәмәч пешерсә...».

Иптәш Бабко үзенең сайлау алды программасында нәрсә тәкъдим итә соң? Төрле кешенең сәләте төрлечә, дигән мәгълүм хакыйкатьтән чыгып, автор: «Кешенең җәмгыять өчен кыйммәте... аның белемлегенә карап бәяләнми», — дигән беренче нәтиҗәсен ясый.

Бу шулаймы соң? Кешелек, мәдәниятның һәм производствоның үсешен билгеләүче беренче фактор буларак, һәрчак яшь буынның белем дәрәҗәсен мөмкин кадәр югарырак күтәрергә омтылды. «Бер белемле өчен ике наданны бирәләр, тик алмыйлар гына» — дигән рус мәкален, бераз үзгәртеп, шулай дип әйтергә була. Бүгенге дөньяда артта калган илләр үз җәмгыятьләренең белем дәрәҗәсен күтәреп алга чыккан бер вакытта, безне үз балаларыбызга белем бирүдән тыелып торырга өндиләр.

1989 елның ноябрендә БМОның Генераль Ассамблеясы балалар хокуклары турында Конвенция кабул итте. Советлар Союзы аңа кул куйды. Анда баланың (18 яшькәчә) белемгә һәм ялга, шәхес буларак үсүенә, экономик, политик һәм сексуаль эксплуатациядән саклауга хокуклары бәян ителә. Балалар мәнфәгатенең ата-аналар, хәтта дәүләт мәнфәгатьләренә караганда да өстенрәк торуы турында әйтелә. Безнең Югары Совет балаларның тулы дәрәҗәдә белем алуга хокукларын чикләүгә юл куймаучы Конвенцияне тиз арада ратификацияләр дип ышаныйк...

Белемлелек, тәрбиялелек. Без бер-беребезгә кечкенә генә остаханәдә дә, я булмаса ашханәдә дә ихтирамлы мөгамәләдә хезмәт күрсәтә белмибез — канәгатьсез килеш-килбәт, ачулы тавыш, боерулы тон, гауга, нервлар... Соңыннан барыбыз бергәләп әдәпле кешене, партияне, властьларны сүгәбез...

Эш нидә соң? Мондый психологиянең сәбәпләрен каян эзләргә? Әлбәттә, алар күп. Маркс хаклы: яшәеш аңлылыкны билгели. Хәзер еш әйтелә торган «казарма» социализмындагы ярым хәерчелек һәм хокуксызлык күпләрдә белем алу, мәдәният, фән дигән төшенчәләрнең асылын примитив аңлауга китермәдемени? Безнең дәүләтебез эшчеләргә үзләре җитештергән продукция бәясенең 30%тан кимрәген генә, ә капиталист исә 70%тан артыграгын түли. Күпләргә XX гасыр азагында ирекле кешенең нинди шартларда яшәргә тиешлеген күз алдына китерүе дә кыен. Миллионнар әле һаман да җимерек, элементар көнкүреш шартлары булмаган өйләрдә яшиләр, әгәр дә ашарга ипи белән колбасалары булса, алар шуңа да канәгать. Әйбергә кызыгу чире белән агуланган яшьләр андый түгел. Дистә еллар буена безнең аңыбызга капиталистик дөнья кешеләре турында ялган фикерне тукып килделәр. Баксаң, анда иң бай кешеләр дә үз фатирларын артык җиһазлар һәм әйберләр белән тутырырга омтылмыйлар, бик гади, дәрәҗәсен белеп киенәләр, күбрәк балалар сәламәтлеге турында кайгырталар. Аларда әхлакый гадәтләр, хезмәткә мәхәббәт, шәфкатьлелек тәрбияләргә тырышалар. Әйе, бүген беребез дә яланаяк яисә чабатадан йөрмибез, ачтан да үлгәнебез юк. Элеккеге чор, Европа илләреннән мәдәният һәм белем бирү өлкәсендә иҗтимагый аңыбыз үсү ягыннан артта калган чор белән чагыштырганда, бүген безнең ихтыяҗларыбыз да башкачарак. Ач-ялангач булмас өчен ата-бабаларыбызның, үзебезнең каныбыз аз коелмады. Сәләтебезне үстерү, тулы дәрәҗәдә белем алу өчен дә күп түләнгән. Җәмгыятьтә кешенең кыйммәте ничек бәяләнүенә тукталып тормастан, мәкалә авторы: «Әйткәннәрдән чыгып миңа калса, мәҗбүри урта белем бирүне бетерү һәм ПТУлар санын бик нык киметү, ә эшче һөнәренә өйрәтү функциясен турыдан-туры предприятиеләргә бирү дөрес булыр», — дигән тәкъдим кертә.

«Һәркемгә хезмәтенчә» бирергә омтылып, иптәш Бабко менә нинди мөһим нәтиҗәләр ясый! Мәҗбүри урта белем бирүне бетерү ул — яшь буынны сигез класс белем белән калдыру дигән сүз. Мәкалә авторына белем бирү дәрәҗәсе буенча илебезнең байтак Африка илләреннән дә арттарак булуы мәгълүм микән? Яшьләрнең гомуми белемен арттыра бару аркасында Япониянең техника, технология, югары сыйфатлы товарлар җитештерү өлкәсендә дөньяда иң алга киткән ил булып кына калмыйча, үз гражданнарының тормыш дәрәҗәсен, мәдәниятын яңа баскычка күтәрүгә ирешүен А.Бабко белә микән? Япония галимнәре хәзер илне гомуми югары белем бирүгә күчерү программасын булдыру өчен эш башладылар. (Хәзер аларда яшьләрнең 40%ы, ә бездә 18%ы гына югары белем ала). Шундый хәлдә безгә сигезьеллык гомумбелем белән чикләнергә тәкъдим итәләр. Бу «һәркемгә — хезмәтенчә» дип атала.

Бүгенге дөньяда сигезьеллык белем кемнәрне канәгатьләндерә ала? Польшада, мәсәлән, сигезьеллык белем башлангыч белем булып санала. «Биш-алты класс белемле кешеләрне кайбер алга киткән илләр укый-яза белүчеләр рәтенә кертмәгәндә һәм функциональ укый-яза белү таләпләре 8–10 класстан да түбән булмаган бүгенге чорда өченче-дүртенче класс укучыларын аңлы-белемлеләр дип каравы кыен», — дип бик дөрес яза ЮНЕСКО генераль директоры урынбасары профессор С.А.Тангян.

Димәк, 8 класс белем әле ул укый-яза белү дигән сүз генә. Сигезьеллык мәктәптән соң безнең ПТУларга килгән меңләгән яшьләрнең белеме бик түбән. Күпләр иҗекләп кенә укый, диктант язганда 60тан артык орфографик хата җибәрә һәм аларны таба алмый интегә. Яшүсмерләрнең әхлак дәрәҗәсе түбән, каты бәгырьле булулары турында сөйләп тә торасы юк. Менә шул примитив база белән без роботлаштыру һәм компьютерлаштыру чорында

иҗтимагый-политик яктан актив, югары таләпләргә җавап бирүче профессиональ эшчеләр әзерләргә омтылабыз. Хезмәт җитештерүчәнлеге эшчеләрнең иҗади табышлары бәрабәренә генә үсә һәм үсәчәк. Ләкин кешенең фикерләвен һәм аның техник иҗат мөмкинлекләрен 8 класс белем базасында гына формалаштырып булмый.

Яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр кебек артканнан-арта барган яртылаш надан яшьләр белән нишләргә? Әлбәттә, гомуми урта белем мәктәпләрендәге укыту һәм тәрбия эшләренең сыйфатын яхшыртырга, аңа милли мәдәни традицияләрне кертергә, балага йөз белән борылырга кирәк. Белем бирүне гуманлаштыру һәм дифференциацияләү зарури.

Әмма бу эшне түбән түләүле һәм яртылаш надан укытучыларның гаять зур армиясе белән «юрганыңа карап аякны сузарга мәҗбүр иткән» ассегнованиеләр ярдәмендә башкарып чыгып буламы соң? Бер укучыга белем алырга нормаль шартлар тудыру өчен елына күпме средство кирәк? Белгечләр исәпләвенчә, 680 сум. Хәтта минимум дип алганда да 500 сумнан ким булмаска тиеш. Чынлыкта исә бездә 240 сумнан кимрәк тотыла, бу бер укучыга нормада каралганнан өч тапкыр кимрәк дигән сүз.

Ә АКШта бер укучыга елына 3,5—4,5 мең доллор тотыла. Безнең мәктәпләрнең материаль базалары бик йомшак. Бер укучыга исәпләгәндә иң күбе 300 сум, ә минимум 200 сум кирәк. Без исә нибары... 51 сум, алты тапкыр кимрәк тотабыз. Уку чыгымнарына мәктәпләр ел әйләнәсе 30 сум урынына нибары 3 сум, ә балаларны ашатырга 90—100 сум урынына 5 сум гына тотарга мәҗбүр. Шулай булгач, мәктәп «урам балаларын» ничек үзенә җәлеп итә алсын?

Укытучыңның кемлеген әйт, мин синең кемлегеңне әйтермен, диелә бер мәкальдә. Безнең тормышның киләчәге булган балалар укытучылар кулында. Ә алар уртача аена 182 сум хезмәт хакы алып

эшлиләр, бу исә ил күләмендәге уртача хезмәт хакыннан 60 сумга кимрәк. Шуңа да зирәк яшьләребез педагогия институтларына атлыгып тормый, ә сәләтле педагогларыбыз атнасына ике ял көне, югары хезмәт хакы булган производствога күчә. Ирләр күптән китеп бетте, яшүсмерләргә үрнәк булырдай, «үз күреп» сөйләшердәй кеше юк.

«Педагогика фәне кая карый?» — дип шаулый кайбер журналистлар. Мин җитәкләгән СССР Педагогия фәннәре академиясенең профтехпедагогика институтында, мәсәлән, 70 хезмәткәр, 30 елдан артык аена 140 сум хезмәт хакы алганда һәм институт буенча уртача хезмәт хакы 172 сум тәшкил иткәндә кая карасын соң? «Се-ля-ви» (тормыш шундый) дип шаяртырга яраталар минем коллегаларым. Ә белем бирүнең сыйфаты турында гәпләшү, аның срокларын кыскарту өчен күп акыл кирәкми. Мин мәктәп турында, белем турында, балаларны, яшьләрне, мәктәп укучыларын социаль яктан яклауны гарантияләүче яңа законның кирәклегенә инанам.

Мин А.Бабконың ПТУлар санын бигрәк тә укыту-материаль базалары булмаган һәм һөнәрләргә иң примитив шартларда өйрәтүчеләр хисабына кыскарту турындагы фикере белән тулысынча килешәм. Әмма эшче көчләр хәзерләүне махсус уку йортларыннан предприятиеләргә, махсус белем алган белгечләр кулыннан алып, психология һәм педагогика өлкәсендә бернинди әзерлеге булмаган инженерлар кулына бирүне ничек табигый хәл дип кабул итәргә? Әлбәттә, күп кенә җитәкчеләр эшчеләрне һөнәргә предприятиеләрдә өйрәтү яклы. Финанс эшлеклеләре дә кыска сроклы укытуны хуплый — акчага экономия! Училищедагы өч ел урынына — 3-5 ай. Ләкин өч айда нинди һөнәр иясен әзерләп була соң? Бары тик билгеле бер операция башкаручыларны гына. Мондый примитив башкаручылар хәзерләүне конвейерга салырга да

була. Яисә гомере буена кыру станогында һаман да бер деталь очлап утыручы әзерләргә. Ә хезмәт җитештерүчәнлеге үсәрме соң? Ул һаман да бер ноктада, гасыр башындагыча булырга мөмкин. Капиталистик илләрдә эшче үзенең профессиональ осталыгына 25—30 яшьтә, ә бездә исә 40 яшькә җиткәндә генә ирешүен мәкалә авторы белә микән? Шулай булгач, без эшчеләребезнең балаларын кайчан профессиональ белемле итә алачакбыз?

Мәкалә авторына АКШ эшчеләренең һөнәргә тулы 12 еллык белем базасында өйрәнүләре мәгълүмме? Узган ел Америка Кушма Штатларының өч штатындагы өч һөнәр колледжларында булып мин шуларны күреп кайттым. Ә безне 2–3 класс белем белән өйрәнчектән эшче һөнәренә өйрәткән 20 нче елларга кире кайтырга өндиләр. Бәла ПТУлардагы тәртипләрнең начар булуында, ата-аналарны куркытуда түгел, ә социаль–экономик шартларның белемгә кызыксындыруын юк итүдә. Тигезләү сәләтле, талантлы эшчеләр кесәсенә генә сугып калмады, ә яшьләрнең һәм өлкәннәрнең намуслы хезмәткә карашын да үзгәртте. Яшьләр ПТУга барырга теләми, чөнки бездә белемгә карап түләнми, белемнең бәясен обывательләр генә түгел, кызганычка каршы, министр да, партия җитәкчеләре дә белми.

Бездә капиталистик илләргә караганда эшчеләрне әзерләү биш тапкыр арзангарак төшә. Бәлки, шуңадыр, АКШ белән чагыштырганда югары квалификацияле эшчеләребез өч тапкыр азрак! Хезмәт җитештерүчәнлегебезнең өч тапкыр түбән булуы да, кыйммәтле импорт җиһазларының еш ватылуы, механизмнарның эшсез торуы, заманча технологияләрнең булмавы, технологик тәртипләрнең еш бозылуы да шуңа бәйле түгелме икән?

Гомуми белем бирү өлкәсендә белгеч буларак шуны раслый алам: яшүсмергә карата гуманистик мөнәсәбәт урнаштыру илдә

бернинди мәҗбүр итүләрсез, кадерен бетерми генә гомумбелем алу белән бәйләп алып барылырга тиеш.

Безгә, бернинди мәҗбүр итүләрсез, эшче һәм белгеч гаиләләре мәнфәгатеннән чыгып, гомуми профессиональ хәзерлек турындагы закон кирәк. Мәктәптә хезмәткә өйрәтергә кирәк, чөнки хезмәт — беренче тәрбияче ул. Дәүләтнең мәктәп һәм мәктәптән тыш хезмәт учреждениеләре өлешенә кереп экономия ясавы кайтарып булмаслык әхлакый югалтуларга китерә, меңләгән яшүсмерләр өерләре белән шәһәр урамнары буйлап йөгерәләр, эшсезлектән бер-берсен тукмыйлар. Ә бит алар мәктәптә хезмәт белән, спорт белән, сәнгать белән шөгыльләнә алырлар иде. Меңләгән балаларны производство кооперативларына тартырга мөмкин булыр иде.

Йомгаклап шуны әйтергә телим: бары тик башлангыч белем белән генә хезмәт культурасының югары булачагына ышануы кыен. Ә болардан башка кирпечне дә туры итеп салу мөмкин түгел, «Һәркемгә — хезмәтенчә» дигән гадел бүлү системасын гамәлгә кертүе бигрәк тә. Балаларны һәм яшьләрне әхлакый таркалудан коткару чарасы лозунгларда түгел, ә аларны тулы белемле итүдә.

2.6. Без нинди мираска мохтаҗ?

(“Мирас”, № 2/92, 3-6 б.)

— «Мирас» журналы... Нигә кирәк булды әле бу? Әллә башка журналларда чын сүз әйтергә урын да калмады? Әллә аларда буш сүзләр күбәеп киттеме? Яисә галимнәр эзләнүе безне халык бердә белмәгән мәгълүматка ия иттеме? Мондый сорауларны күп итеп куеп була һәм аларга уңай йә тискәре җавап та эзләп торасы юк. Сер нәрсәдә соң?

Совет чорында гасырга якын вакыт татар халкы үзенең чын тарихын өйрәнә алмыйча килде. Халык тарихы урынына без Татарстан АССР дигән харитада (картада) карандаш белән уратып алынган, чикләнгән бер җирнең, кечкенә бер территориянең тарихын өйрәнү белән мәшгуль булдык. Анда яшәгән халыклар турында алар большевиклар җитәкчелегендә революция ясадылар, колхозлар төзеделәр һәм коммунизмга таба баралар, дип өйрәтелде.

Татар халкының бер мең дүрт йөз елга якын тарихы барлыгын да юньләп белмәдек, аның үзенчәлекле рухи дөньясы, аның хыяллары, уй-фикерләре турында бөтенләй диярлек әйтелмәде. Шушы халыкның монгол-татар килгәнче үк алты йөз ел үз дәүләтләрендә яшәгән дәвере турында нәрсә белдек соң? Ә бит шул дәүләт Көнчыгыш Европада заманына күрә иң зур, бай һәм көчле ил булган, күршесендә шулай ук көчле Киев Русе — бердәнбер славян дәүләте белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә яшәгән.

Вакыт үтү белән кешеләр дә, илләр дә үзгәрә. Кайчандыр чиксез көчле һәм мәһабәт Рим дәүләте ярты дөньяны биләп, күрше халыкларны тетрәндереп торган. Аннары яңа мәдәнияткә, христиан диненең яңа юнәлешенә нигез салучы Византия барлыкка килгән һәм русларга да мәҗүсилектән христиан диненә күчергә ярдәм иткән. Шәркый якта әллә ничә эреле-ваклы дәүләтләр йөзәр еллар яшәп юкка чыкканнар. Рим һәм Византия дәүләтләренең «туе узып, туны тузгач» Византия җирләрендә Төрек империясе мең елдан артык яшәп ала. Хәзерге Италия белән Төркия аларның пыяла ватыклары шикелле ялтыравыклы тарихи калдыклары гына.

Шулай да мондый илләрнең тарихта эзләре бик тирән. Әмма борынгы грекларның фабрикалары, җитештерү ысуллары, җир казып металл җиткерү юллары кайда соң? Алар я бик нык үзгәрә, яисә юкка чыга. Ә инде адәм баласының теге яки бу стильдә фикер йөртү ысуллары, дөньяга карашлары, табигать күренешләренә

үзенчәлекле бәя бирү методлары, әдәбият һәм сәнгатьнең, рухи дөньяның асылына нигез салу юллары мәңгегә кала. Философ Аристотель, шагыйрь Эсхилларның әсәрләрен һаман да укыйбыз. Халыклар бер-берсеннән өйрәнеп, бер-берсенә ияреп кыргыйлыктан бердәм көч белән алга, югары мәдәни хыялларга таба баралар.

Безнең татар халкының да шулай үсеп барган тарихы бар. Ул да, Рим һәм Византия кебек үк булмаса да, дөнья мәдәниятенә үзенең өлешен керткән. Менә шул тарихны без бик аз беләбез. Аны өйрәнер өчен галимнәребез дә әлегә бик аз.

Нигә алар аз, нигә җитәрлек түгел? Бу сорауга ап-ачык бер җавап бар: изелгән халыкларның тарихы язылмый, аларның биләре, ханнары, патшалары турында язарга түгел, сөйләргә дә хаким халык һәм аның җитәкчеләре тарафыннан ирек бирелми. Шуңа күрә безнең бабаларыбыз кайсы Киев князе кайсы елда тәхеткә утырган, кайсы рус шәһәре нәрсә җитештергән, кайсы рус патшасы нинди җирләрне үз халкыннан «азат» иткәнне, ягъни яулап алганны беләләр, әмма үзләренең кайдан килеп чыкканлыгы, кайсы бабадан туып кем булганлыгы турында сүз әйтә алмыйлар...

Мирас ул буыннан-буынга күчеп килә торган байлык. Матди байлык ул — фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, фикер байлыгы, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең үзара инсафка нигезләнгән мөгаләмәсе, гореф-гадәт — бакый, мәңгелек. Мирасның иң кадерлесе — халыкта сакланып килгән азатлык рухы, хөррият хыялы.

Андый мирас аерым шәхестә булмаса да, бербөтен халыкның гомуми җанына сеңеп кала, аның телендә, әдәбиятында, иҗатында, әдәп-тәртибендә, гореф-гадәтендә, фикерләү сәләтендә, буыннан-буынга күчеп килгән риваятьләрендә саклана. Азатлыкка, читлектәге кош кебек канат кагып иреккә чыгарга омтылу — татарларга ата-бабадан хас мирас ул. Һәртөрле золымга булган

күңел каршылыгы ачы сүзләр булып бүген мәйданнардан күккә күтәрелә... Бай мирасыбызны өйрәнеп, үстереп киләчәк буыннарга түкми-чәчмичә генә тапшырасы иде. «Мирас» журналы нәкъ менә халкыбызның тарихи, рухи байлыгын саклап калу, аны халыкка яңадан кайтару өчен кирәк.

2.7. Мәдәни автономия кирәкме

(“Соц. Татарстан”, 1989, 2 апрель)

Украинада булган М.С.Горбачев милләтара мөнәсәбәтләрнең шәхес культы һәм торгынлык чорында фаҗигале хәлгә килүе, аларның халыклар дуслыгына киртә булуы, КПСС Үзәк Комитетының ул турыда борчылуы хакында: «...Милләтләрне тергезү үзгәртеп коруның органик состав өлешләреннән берсе булып әверелде», — диде. Бу өлкәдә җанлы хәрәкәт башлануын күрү кыен түгел.

Матбугатта һәм конференцияләрдә хәзер культура автономиясе мәсьәләсе тирәсендә кайнар бәхәсләр бара. Аны бик нык яклаучылар да, бөтенләй кире кагучылар да бар. Аның яклылар үзгәртеп кору ихтыяҗлары, тормыш логикасы милли экстерриториаль төзелмәнең шундый формасын үстерүне көн тәртибенә куйды дип саныйлар.

Әмма тәкълиди, догматикларча фикер йөртүчеләр җәмгыятьне демократияләштерү өчен көрәшүчеләрнең дәлилләре белән килешмиләр, аларның үз туксаны туксан: Бөек Октябрьгә чаклы ук В.И.Ленин үз хезмәтләрендә милли-культура автономиясен тәнкыйтьләгән дип, юлбашчы артына ышыкланалар. Берничә ел буена барган үзгәртеп кору, яңача политик фикерләү дәвере аларны бернәрсәгә дә өйрәтмәгән, күрәсең. Социализм турында тәгълиматның асылы түгел, хәрефе кыйммәт микәнни?

«Үзеңне генә хөрмәт итмәскә» («Вечерняя Казань», 15 февраль, 1989 ел) дигән мәкаләсендә А.Каримов милли культураны яклаучы татар иҗтимагый хәрәкәте активистларын тәнкыйтьли. Янәсе, алар «Татар милли культурасын саклау һәм үстерү турында сөйләгәндә, кайвакыт экстерриториаль милли культура автономиясе позицияләренә авышалар, аны илнең башка төбәкләрендә яшәүче татарларны культура ягыннан тәэмин итү белән бәйлиләр. Әмма татар культурасын саклау дип моңа бару татар милләте кешеләренең шул төбәктәге халыктан аерылуына, үзләре яши, эшли, ял итә торган мохиттән читләшүенә китермәсме?»

Менә бит А.Кәримовта нинди катлаулы сорау туган: янәсе татар кешеләре Тоболда, Мәскәүдә, яисә Саратовта татарча сөйләп җибәрсә, бу аның мохитеннән читләшүе булмасмы? Шуның өстенә алар, бергә җыелып, гармунда үз көйләрен дә уйный башласалар? Әйләнә-тирәдәгеләр бит аларны аңламас һәм... «читләшү» килеп чыгасын көт тә тор!

Бүген мәсьәлә иптәш Кәримов уйлаганга караганда «гадирәк» итеп куела: татар теле бетәрме, калырмы? Ун-унбиш ел элек Татарстанда 200 меңләп татар баласы туган телендә укый иде. Бүген — 60 мең. Элек Казанга читтән килеп татар мәдәниятына зур өлеш керткән Такташлар, Җәлилләр, Аббасовлар, Бурнашлар күренми инде. Халкыбызның иҗат чишмәләре корый. Бөтен илдә татар балаларының 7 проценты гына татарча укый. Тагын ун елдан ике-өч процент калыр, ә унбиш елдан бай һәм үзенчәлекле әдәбиятыбызны картлар да укый алмас. Инде хәзер илебездәге татарларның ярты сы үз телен белми, белгәне дә ярым-йорты рус-татар диалектында сөйләшә. Бу инде бер дә «читләшү» түгел, әлбәттә.

А.Кәримов «читләшү»дән куркуын нәрсә белән нигезли соң? Ленин, «милләтләрнең ясалма чикләр белән аерылуына, милли йомыклыкка һәм үз-үзләрен изоляцияләвенә кискен каршы чыкты»,

ди. Карагыз әле, чыннан да, татар иҗтимагый үзәге эшлеклеләре балаларны туган телдә укытуның «милләтләрне ясалма чикләр белән аеру» булуын, туган телдәге китапларның «милли йомыклык һәм үз-үзеңне изоляцияләү»гә хезмәт итүен белмиләр, уйлап карамыйлар икән!

Мәгълүм булганча, марксизм-ленинизм классиклары «марксизм җансыз догма түгел, нинди дә булса тәмамланган, әзер, үзгәрешсез тәгълимат түгел, бәлки эш итү өчен җанлы кулланма» дип саныйлар. (В.И.Ленин, Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 17 том, 25 бит). Менә шул сүзләрнең мәгънәсен аңлау, аларның асылына төшенү бүген социализмны гына түгел, бөтен дөньяны да глобаль һәлакәттән коткарып калырга сәләтле яңача фикерләүнең нигезен тәшкил итә түгелме соң!

В.И.Ленин әле Октябрь революциясенә чаклы ук үзенең оппонентларын власть өчен, мөстәкыйль милли-территориаль төзелмәләр өчен көрәш урынына «милли-культура автономиясе» генә тәкъдим итүләре өчен тәнкыйтьли. Башында эшчеләр сыйныфы торган чын демократия, ди ул, милләтләрнең тигез хокуклыгы һәм сыйнфый көрәшләрендә барлык милләтләрнең берләшүе байрагын күтәрә. Бу күзлектән караганда, ди ул, без «милли-культура автономиясе» дигән нәрсәне инкарь итәбез.

Димәк, Октябрь революциясенә чаклы Ленинның милли культура автономиясенә мөнәсәбәтенең төп асылы — төрле милләт эшчеләренең игътибарын, милли культура белән генә мавыгып, сыйнфый көрәш хакына берләшүдән читкә тартмау иде.

Шәхес культы елларында милли культура автономиясенә марксистик диалектик караш бар идеме? Юк, булмады. Сталинның социалистик дәүләт үсү белән сыйнфый көрәш көчәячәк, дигән теориясенә таянып, ул чордагы барлык авторлар да диярлек милли культура автономиясе төшенчәсенә тискәре мөнәсәбәттә торалар. Бу

урында Ленинның революциягә чаклы күп элек милли культура автономиясе турындагы мәсьәләгә диалектик якын килүен искәртергә тиешбез. Сыйнфый көрәш өчен берләшергә кирәк булган изелгән эшчеләргә, ди ул, «мәктәп эшен милләтләр буенча аеру» зарарлы булса, «шул ук вакытта балалары бай хосусый мәктәпләр... белән бик яхшы тәэмин ителгән капиталистларга бернинди «милли культура автономиясе» һичбер хәлдә дә бернинди бүлгәләү, бернинди көчсезләндерү куркынычын салмый». (Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 19 том, 498 бит).

Димәк, бер үк «милли-культура автономиясе»нең төрле сыйныфларга йогынтысы төрлечә.

Тагын шуны да искәртик: Ленин милли-культура автономиясе турында гасыр башында, Европада бары Австриядә генә телгә бәйле социаль конфликтлар туган шартларда язган. Тагын илле елдан соң андый конфликтлар Бельгия, Швейцария, Канада кебек нык үскән илләрдә дә килеп чыкты. Аларда төрле телдә укытыла торган мәктәпләрнең автономиясенә китергән вакыйгалар булды, андый мәдәни мөстәкыйльлек бер илдә төрле телдә сөйләшә торган халыкларның социаль тигезлеген бетерү шарты итеп каралды.

Социалистик дәүләт туган телләрнең азатлыгын һәм барлык халыклар өчен демократик совет мәктәбен тәэмин итте. Бу — халыклар дуслыгын, аларның бердәм демократик дәүләткә туплануының нигезләреннән берсе. В.И.Ленин язганча, демократик дәүләт туган телләрнең тулы азатлыгын һичсүзсез танырга һәм берәр телнең һәртөрле өстенлеген кире кагарга тиеш.

Үзгәртеп коруга чаклы булган чорларда ленинчыл милли политиканы бозу нәтиҗәсендә нинди тайпылышлар килеп чыкты соң? Иң зурысы — милләтләрнең иҗтимагый-мәдәни мәнфәгатьләренә карата битарафлык. Шул исәптән, мәктәп эшендә рус теленә өстенлек бирү, аңа яхшырак шартлар булдыру. Рус

булмаган кешеләрнең аны мәҗбүри өйрәнүе һәркайда танылды, ул укытучылар, финанс (ягъни, мәктәпнең уку планнарында вакыт бирү) белән, уку әдәбияты, китаплар, ярдәмлекләр белән күп тапкыр яхшырак тәэмин ителде. Аны куллану өлкәләре киңрәк, дәүләт аны үстерү һәм җәелдерү турында ныграк кайгырта.

Болар барысы да башка халыкларның рус телен өйрәнү сыйфатын яхшыртты һәм аларның гомум-культура, иҗтимагый аң дәрәҗәсе күтәрелүдә уңай роль уйнады. Әмма шул ук вакытта бу — туган телләрнең мәнфәгатьләре кысылуга, куллану өлкәләре тараюга, милли мәктәптә аларны өйрәнү вакытының кимүенә китерде. Бигрәк тә миллитерриториаль берәмлекләрдән (автономияле республикалардан) читтә урнашкан милли мәктәпләрдә 60–70 нче елларда укытуны беренче класстан башлап рус теленә күчерү киң колач алды, язгы ташкын кебек җәелде.

Бүген татар җәмәгатьчелеге (татар гына да түгел) телнең шундый хәлдә калуына нык борчыла. Татарстанның үзендә партия һәм совет органнары, фәнни учреждениеләр төп халыкның культурасын тергезү өчен күп нәрсә эшлиләр. Шушы көннәрдә генә республикабыз хөкүмәте, 20 еллардан соң беренче мәртәбә татар телен өйрәнү мәсьәләсен тикшереп, карар кабул итте. Анда туган телгә игътибарны көчәйтү, татар мәктәпләре, балалар бакчалары санын арттыру, укытучылар хәзерләү бурычлары куелган.

Ләкин җәмәгатьчелек дәүләтнең рус теленнән тыш башка телләр язмышына да игътибарны көчәйтүе, конкрет алганда, автономияле республикадан читтә яшәүче татарларның милли культурасын үстерү өчен, татарларның үзләре катнашында җирле совет органнары тарафыннан шартлар тудыру турындагы мәсьәләне куя.

Үз тарихыбызга яңача карау ирек, социализм һәм социаль гаделлек турындагы элекке теоретик күзаллауларның тормышта

барлыкка килгән халәткә бөтенләй капма-каршы икәнлеген күрсәтте. Бу милли культура автономиясе төшенчәсенә дә кагыла. Элекке фикерләвебезнең схоластик характеры һәр адымда диярлек расланып тора.

Реаль тормышта, нәкъ менә практикада, безнең дәүләт шартларында милли культура автономиясе күптән урын алган иде һәм һәркайда гамәлгә ашырылды. Моның мисаллары күп. Үзәк матбугатта алар тулып ята. Әмма ләкин, 1937–38 еллардагы канлы репрессияләр татар интеллигенциясен кырып салды, милли культураның тамырына чапты, сугыш алдыннан ябылган мәктәпләрнең, театрлар һәм газеталарның хәзер дә ачылганы юк.

Төрле өлкәләрдә авылы-авылы белән яшәп килгән совет немецларының сугышка чаклы мәдәни автономияләре булган. Шул вакытта бетерелгән хокуклары кире кайтарылмагач, күп кенә немецлар Федератив Германиягә күчеп китә һәм туган иленнән чын-чынлап читләшергә мәҗбүр була...

Бу хәзер безнең илдә милли-культура автономиясе дигән төшенчә һәм күренешнең булмавын күрсәтәме соң? Юк, әлбәттә. Мәсәлән, Россиядән башка һәр союздаш республикада мөстәкыйль рус-милли культура төзелеше тормышка ашырыла. Хәтта руслар азрак булган урыннарда да эш кагәзьләре, кагыйдә буларак рус телендә алып барыла, рус театрлары, төрле клублар бар. Рус телендә мәктәпләр, түгәрәкләр, фольклор ансамбльләре эшли, журналлар һәм газеталар чыга, фильмнар күрсәтелә, җирле телевидение һәм радиодан русча тапшырулар алып барыла, рус православие чиркәве эшли һ.б. Боларның һәммәсе (чиркәүдән башкалары) дәүләт бюджетыннан финанслана, партия һәм совет эшлеклеләре, Советларның мәгариф һәм культура бүлекләре тарафыннан оештырыла һәм күзәтелеп тора.

Әйтик, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Эстония, Әрмәнстан һәм башка республикалар территориясендә бу күренеш рус халкы өчен милли-культура автономиясе булмыйча нәрсә булсын? Һәм мондый милли-культура автономиясе халык һәм социалистик дәүләт мәнфәгатьләренә һич каршы килми.

Әмма татар халкының милли культурасы өчен шундый шартлар тудыру турында сүз кузгала икән, кемнәрдер аны бәхәсле мәсьәләләр рәтенә кертә, милли-культура автономиясенең «реакционлыгы» турында сүз куерта башлый.

Үзенең мәкаләсендә А.Кәримов җәмәгатьчелек исеменнән Татарстанда татар телен дәүләт теле дип игълан итүне таләп иткән татар иҗтимагый үзәге белән бәхәс алып бара. Ни өчен бу нәрсә А.Кәримовта борчылу уята? Чөнки «Дәүләт органнары шул телдә генә эшли башлаячак... Теге яки бу кешенең гражданлыгы турындагы мәсьәлә телне белүенә карап хәл ителәчәк һ.б.».

Безнең уебызча, хокукларын Конституция гарантияләгән, милләтара аралашу телен бик яхшы белгән ватандашларының язмышы өчен юкка гына борчыла автор. Бу — беренчедән. Ә икенчедән татар теле дәүләт теле дип игълан ителгәндә бөтен эш кагәзьләре татарча гына язылачак, вузларда укыту татарча гына булачак дип кем әйтә әле? Вузларда да, дәүләт аппаратында да татарча эшли алырлык кешеләр бетә язганын А.Кәримов белә микән? Рус теле республикада күптән инде дәүләт теле (һәм милләтара аралашу чарасы) булып торганда, татар телен егерменче еллардагы шикелле дәүләт теле дип игълан итү ничек итеп тискәре нәтиҗәләргә китерә алсын икән? Һәм инде Ф.Кәримовның дәүләт телен дәүләт дине кертү белән, «аны тотмаучы кешеләр дәүләт хезмәтенә кабул ителергә мөмкин булмау» белән тәңгәлләштереп каравы бөтенләй аңлашылмый. Җитмәсә тагын мисал итеп, автор хәзерге Иранны (!?) китерә.

Монысы тагын нинди арттыру? Нигә кирәк бу уйдырма? Җавап гади: А.Кәримов татар теленең Татарстан территориясендә рус теле белән бертигез хокуклы тел булуын теләми. Шунлыктан ул, йомшак кына итеп әйткәндә, логикасыз аналогияләр һәм чагыштырулар китереп, укучыны өркетә.

Барыбызга да мәгълүм булганча, Ленин рус телен һәркем өчен мәҗбүри дәүләт теле итүгә каршы булган. Ул рус теленә көчләп өйрәтүгә каршы чыккан, чөнки экономик тормыш ихтыяҗлары кечкенә милләт вәкилләрен болай да күпчелек халыкның телен өйрәнергә мәҗбүр итә дип саный. Аның «Безгә мәҗбүри дәүләт теле кирәкме?» дигән мәкаләсенең асылы шунда. Шул мәкаләнең асылына түгел, хәрефенә таянып, безнең элекке идеологларыбыз тәва кошы политикасы алып бардылар. Юридик яктан рус теле дәүләт теле дип теркәлмәгән, әмма барлык халыкларның тормыш эшчәнлеге рус телендә генә барган илдә аның чынлыкта дәүләт теле булмый хәле юк.

Мәктәпнең, балалар укытуның туган телдә булуы аларның сөйләме, фикер йөртү сәләте, хәтере, бөтен шәхесе үсү өчен иң беренче шарт булу беркемгә дә сер түгел; бу — милли культура үсүнең дә шарты. Моны кешенең фикер йөртү дәрәҗәсен, эрудициясен чагылдыра торган телнең үзендә дә күрсәтеп була.

Милли мәктәпне уңышлы үзгәртеп кору нәрсә өчен кирәк? Иң элек теләсә кайсы совет мәктәбенә кирәкле нәрсәләр: оештыруның яңа принциплары, анык максат, яңартылган эчтәлек (нәрсәгә өйрәтергә?) һәм методлар (ничек укытырга һәм тәрбияләргә?) һәм шуның белән бергә туган тел проблемалары принципиаль хәл итү, аның статусын билгеләү зарур. Тел ситуациясе барлык республикаларда да диярлек бертөрле: рус теле һәркайда, шул исәптән теләсә кайсы милли мәктәптә дә мәҗбүри укытыла, ә туган телне өйрәнү мәҗбүри түгел, ирекле итеп куелган.

Моннан башка союздаш һәм автономияле республикаларда туган телнең халәте төрлечәрәк. Мәсәлән, Балтик буе республикаларында мәктәптә уку срогы башка республикалар белән чагыштырганда бер елга артыграк. Димәк, аларның уку планнарында туган тел һәм әдәбият өйрәнү өчен вакыт күбрәк (димәк, акчасы да артыграк). Башка союздаш республикалар мәктәпләрендә туган телне өйрәнүгә вакыт, автономияле республикалар белән чагыштырганда шулай ук күбрәк бирелә. Ә автономияле республикаларда рус телен өйрәнүгә максимум, туган телне өйрәнүгә минимум вакыт бирелү инде традиция булып әверелде, ягъни уку планнарында, экономикадагы кебек, калдык принцибы өстенлек итә.

РСФСРдагы автономияле республикаларда тел проблемасын хәл итү союздаш республикалар чагыштырганда кыенрак булыр, чөнки аларда традицияләр башка, психологик ситуация, туган телгә мөнәсәбәт бүтәнрәк.

Тулаем алганда, безнең илдә тел проблемасын демократик хәл итү буенча практик тәҗрибә юк дәрәҗәсендә аз әле. Чит илләрдә бармы соң ул? Әйе, бар.

Төрле илләрдәге күптеллелекнең асылын аңлау табигый, тарихи, социаль һәм политик факторларга бәйле, дип яза профессор Биердмюр. («За рубежом», № 50, 1988). Лингвистик проблемаларны хәл итүгә һәр ил үзенчә якын килә, һәркайсының үз үзенчәлеге бар. Ни өчен соң бу проблемалар әлеге илләрдә сизелми диярлек, ә икенчеләрендә даими низаг, социаль конфликтлар чыганагы булып тора?

Биердмюр болай дип раслый: лингвистик киеренкелек килеп чыккан урында күп теллелек проблемасы һәрвакыт зуррак нәрсәне, атап әйткәндә, социаль һәм политик тигезсезлекне чагылдыра.

Автор бу фикерне безгә лингвистик проблемалар юк кебек тоелган илләр мисалында аңлата.

Швейцария үз халкы сөйләшә торган француз, немец һәм итальян телләрен дәүләт теле, дип таный. Ул барлык телләрне дә тигез дип игълан итә, федераль суд составында рәсми телләрнең өчесен дә белүчеләр булуны таләп итә. Кантоннардагы мәктәпләрдә укыту, кагыйдә буларак, мәгълүм бер телдә алып барыла, әмма икенче телне мөстәкыйль өйрәнү дә хуплана.

Канадада Квебек провинциясенең тиз индустрияләшүе нәтиҗәсендә тел җирлегендә политик киеренкелек кискенләшеп киткән иде. Андагы нигездә французча сөйләшүче халык үзенең тел ягыннан кысылуын аңлый башлады. 1977 елда француз телен провинциядә бердәнбер, рәсми тел дип игълан иткән закон чыгарылды. Административ органнар да, мәгариф системасы да француз теленә күчтеләр. Тел турындагы законның тайпылышсыз саклануын күзәтеп тору өчен махсус комиссия дә бар.

Белгиядә өч рәсми культура бердәмлеге — фламанд, француз һәм немец общиналары бар. Һәркайсының мәктәбендә ике тел укытыла. Үзәк хөкүмәткә француз һәм фламанд общиналарыннан тигез сандагы министрлар керә.

Финляндиядә халыкның алты проценты гына шведча сөйләшә. Шулай да фин теле дә, швед теле дә дәүләт теле итеп саналалар, мәктәптә аларны өйрәнү мәҗбүри, ә университетта теләгәнен сайларга була.

Шулай итеп, социаль һәм политик киеренкелек чыганагы буларак, лингвистик проблема төрле илләрдә төрлечә хәл ителә. Классик буржуаз демократия илләре тәҗрибәсен безнең чынбарлыкка механик рәвештә күчереп буламы? Табигый, алай эшләргә ярамый, чөнки һәр илнең тәҗрибәсе уникаль, кабатланмас нәрсә. Әмма һәркайсыннан нәрсәдер алырга, өйрәнергә була.

Европалалылар һәм канадалылар әле күптән түгел генә шөгыльләнә башлаган тел проблемаларының күбесе Советлар Союзында Октябрь революциясе булу белән хәл ителгән иде. Әмма кайбер проблемалар хәл ителмичә калды, кайберләре кабат килеп чыкты, бөтенләй яңалар да хасил булды.

Хәзер мәсьәләне хәл итү юлын илдә ике теллелек булдыруда күрәләр. Бу нәрсәне аңлата? Иң элек шуны: милли республикада яшәүчеләр җирле халык телен һәм рус телен белергә тиеш. Ләкин бит төп халык вәкилләре генә ике телле, руслар, әйтик, татар теленә мохтаҗ түгел. Аннары. Вакыт үтү белән татар мәктәпләре кими бара һәм татарлар да бертөрле генә (рус телле!) булып кала. Проблемамы бу? Әйе, проблема.

Татарстанда һәм бөтен Россиядә тел проблемасын практикада хәл итүне ничек күз алдына китереп була? Мисал өчен шул ук татар телен алыйк, чөнки анда лингвистик проблемаларның бөтен йомгагы диярлек ачык чагыла. Татарстанның үзендә 1 миллион 800 мең чамасы татар яши (халыкның 48 проценты), ә СССРда татарлар халык саны буенча алтынчы урында тора. Бездә авылда яшәүчеләр татар, рус, чуваш, мари, удмурд, мордва телләрендә сөйләшә. Барлык телләрне тигез хокуклар һәм куллану шартлары белән ничек тәэмин итәргә?

Үз автономияле республикаларыннан тыш, татарлар тагын (районнар һәм төбәкләр булып) Башкортстанда (бер миллионнан артык), Молдавиядә, Мари АССРда, Пермь, Свердловск, Ульяновск, Саратов, Горький, Астрахань өлкәләрендә һәм илебезнең тагын егерме өлкәсендә тупланып яши. Шундый хәлдә татарларның балаларын туган телдә укыту хокукын ничек тәэмин итәргә соң? Урынлы гына түгел бу сорау, катлаулы да ул.

Беренчедән, ул татар теленең хокуклары Татарстанда егерменче еллардагы кебек рус теле белән бертигез дәрәҗәдә дип саналганда

тәэмин ителергә мөмкин. Бу производствода да, хезмәт күрсәтү, мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәсендә һәм дәүләт документлары тутырганда бөтен нәрсә ике телдә алып барылырга тиеш, дигән сүз. Татар телен өйрәнү — татарлар өчен мәҗбүри, башкаларга — ирекле.

Тормышта тамыр җәйгән традицияләрне исәпкә алып, милли мәктәптә укыту дүрт модель буенча алып барылырга мөмкин: а) I класстан алып X класска чаклы туган телдә генә белем бирү, б) VIII класстан соң барлык предметларны рус телендә укытуга күчә торган мәктәпләр; в) IV класстан соң, хәтта I класстан соң русча укытуга күчә торган мәктәпләр. Мондый очракта туган тел предмет итеп укытыла (телгә һәм әдәбиятка ике генә дәрес түгел — җитәрлек санда сәгатьләр бирелә); г) русча һәм татарча укытулы класслар параллель эшли торган катнаш мәктәпләр дә була.

Аннары, милли-территориаль билге буенча барлык телләр рәсми статус алырга тиеш: Татарстандагы татар, чуваш, удмурт һ.б. авылларында барлык эшләр һәм укыту анда яшәүчеләрнең туган телендә алып барыла. Кирәк булган очракта документлар (мәсәлән, җыелышлар беркетмәсе һ.б.) татар, мари, чуваш һ.б. телләрдән милләтара аралашу теленә тәрҗемә ителә.

РСФСРда барлык телләрнең дә хокуклары шундый ук схема буенча тәэмин ителергә мөмкин. Татарстаннан тыш татар теле дәүләт теле була алмый, ләкин татарлар җыелып урнашкан урыннарда рәсми тел дип танылырга һәм экстерриториальлек хокукы алырга тиеш (җыелышлар, киңәшмәләр алып бару, юл күрсәткечләре, вывескалар, белдерүләр һ.б. рус һәм татар телләрендә).

Мәсәлән, чынбарлыктагы шартларны искә алып Башкортстанның берничә районыннан бөтен бер өлкәсе, Пермь, Ульяновск, Горький һ.б. өлкәләрдә бөтен-бөтен районнар тел

ягыннан аерылып тора. Ниһаять, илнең төрле өлешендәге барлык татар авылларында татар теле рәсми тел булырга тиеш (мари, мордва яки чуваш телләре дә үз республикаларыннан читтәге авылларда шулай була). Татар теле рәсми дип игълан ителгән урыннарда шул республиканың (мәсәлән, Мордовиянең) дәүләт телен өйрәнү һәм куллану татар мәктәбендә укучылар өчен мәҗбүри була алмый. Туган тел һәм милләтара аралашу теле буларак рус теле мәҗбүри булып кала. Безнең тәкъдим татар халкының балаларын туган телләрендә укыту һәм милли культурадан файдалану хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле. Бу — лингвистик проблемаларны хәл итүнең ныграк мөмкин булган бер варианты гына. Ихтимал, башка вариантлар да булыр.

Авылда яшәүчеләр бер төрлерәк булса, шәһәрләрдә хәл катлаулырак. Төрле телле микрорайоннарда нишләргә? Әйтик, 220 меңләп татар кешесе яши торган Мәскәүдә тел проблемасын ничек хәл кылырга? Анда, бәлки, балаларындагы татар группаларында (андыйлар хәзер барлыкка килә башлады) формаль булмаган берләшмәләрдә, клубларда, милли җәмәгать оешмаларында (мәсәлән, татар фольклорын сөючеләр җәмгыятендә һ.б.) татар телен рәсми дип игълан итәргә кирәктер.

Рәсми тел статусы кирәкме? Әйе, бу җирле власть вәкилләренең игътибарын милли культура ихтыяҗларына җәлеп итәчәк, аның үсешен финансларга милли культура үзәге булган Татарстаннан кирәкле программалар, дәреслекләр һ.б. алу чараларын табарга мөмкинлекләр бирәчәк. Бу үз туган телеңне өйрәнергә, татар милли җыелышларында татарча сөйләшергә генә түгел, ял итү урыннарында үзешчән чыгышлары үткәрергә, китаплар, газеталар бастырырга, белдерүләр, бюллетеньнәр чыгарырга, телевидениенең җирле каналы һәм җирле радиочелтәр буенча сөйләргә хокук бирә. Моннан тыш, кешегә башка телдә сөйләшүчеләр арасында үз

телендә сөйләшергә комачаулый торган «кыенсыну», психологик барьер бетә. Бу да шәхеснең ирекле, тигез хокуклы кеше икәнен раслый түгелмени?

...Берәүләр икенчеләр исәбенә файда алырга маташкан урыннарда, милли эгоизм уянып, бер милләт кешеләре үзләрен генә ихтирам иткәндә һәм башка милләт вәкилләренә өстән караганда, берәүләр башкаларның дәрәҗәсен кысу исәбенә үз абруйларын күтәрергә омтылган җирдә хәтта яхшы ук тупланган күпмилләтле коллективларда да кайчак мыж-мыж килә башлыйлар. Татулык социаль гаделлек, тигезлек хаким иткән хәлдә генә була ала. Андый хезмәт коллективлары өчен «читләшү» ят нәрсә ул, мәдәни автономия аларның рухи дөньялары өчен шарт булып тора.

2.8. Милли үзенчәлек: кичәгесе һәм иртәгәсе

(“Соц.Татарстан”, 1989, 26 октябрь)

...Канлы утызынчы елларның караңгы төннәрендә Казан өстендә куе кара төтен баганалары күтәрелеп, яшерен яндырылган китапханәләр көле җил белән шәһәрдән читкә, ераккә тарала иде. Казанның зыялыларын мондый вәхшилеккә нәрсә мәҗбүр итте соң? Югыйсә, татарлар һәрвакыт китапка табынып яшәде һәм кинәт... нинди көч ата-бабадан килгән культура мирасын утка ташларга җөрьәт иттерде? Бу көч кешеләрнең үзләренең һәм балаларының тормышы өчен курку иде: шушы дәхшәтнең янавы астында китапханәләрдә сакланган гарәп шрифты белән татарча яисә гарәпчә, фарсыча, төрекчә язылган йөзләрчә мең китап — бизәкләп эшләнгән яраткан китапларыбыз, шамаиллар, догалыклар исламга йөз тотуда гаепләнүдән курыккан кешеләр кулы белән көлгә әйләндерелде. Шул елларның активистлары, үзләрен горур рәвештә

«сугышчан алласызлар» дип йөрткән, ә чынлыкта әлифне таяк дип тә белмәгән кешеләр иде.

Егерменче еллар ахырында татарлар мең ел кулланган гарәп алфавиты латинчага алмаштырылды. Шуның аркасында барлык яңа буыннар иске язма культураны файдаланудан мәхрүм ителде. Тиздән латин хәрефләре рус хәрефләре белән алмаштырылып, татарча белем алганнарның барчасы ул язуны танымас булып, наданга әйләнде.

Утызынчы еллар ахырында яндырылган китаплар көле татар халкын социаль сукырайтып кына калмады, туган телгә, милли традицияләргә һәм әхлакый байлыкларга битарафлык күпмилләтле илебез халыкларының уртак бәласенә әйләнде. Менә шулай культура чыганакларыбызны «ура кычкырып» юк иттек тә, хәзер мәдәни-әхлакый кытлык кичерәбез. Без хезмәт һәм җитештерү культурасы, аралашу, милли мөнәсәбәтләр тәртибе, җитәкче, укытучы, тәрбияче — ата-ана культурасы түбән дигән сүзләрне көн саен ишетеп торабыз... Һәм без барыбыз да теге яки бу халыкның фикер юнәлешен, холык үзенчәлекләрен тудыручы гомуми һәм милли мәдәниятне күтәрү ысулларын эзләп борчылабыз.

Бу теманы тикшергәндә әледән-әле сорау туа: ә элек ничек булган соң? Революциягә чаклы татар халкы үзенең һәр патриоты горурлана алырлык мәдәният дәрәҗәсенә ия идеме? Әйе, мондый дәрәҗәгә ия социаль һәм интеллектуаль зыялылары булган. Крестьяннар һәм эшчеләр сыйныфы политик һәм социаль-экономик шартлар аркасында югары эстетик байлыклардан мәхрүм иделәр.

Дөрес, татарлар яшәгән җирләрдә мәктәпләрнең шактый киң челтәре булуы мәгълүм. (Һәр мәчет каршында мәктәп-мәдрәсә бар иде). Бу исә көнкүреш һәм үзара мөнәсәбәтләр әдәп-тәртибенең чагыштырмача югары дәрәҗәсен күрсәтә. Татарларның үз дини һәм сәнгать интеллигенциясе бар иде: 1913 ел мәгълүматларына

караганда, китап басу һәм китапларның тиражы буенча татарлар рус булмаган халыклар арасында илдә беренче урынны алып торганнар.

Ә бүген без нәрсә дибез? Егерменче еллардагы социаль һәм культура революциясе дулкынында тиз күтәрелгән халык аннан соңгы ярты гасыр дәвамында үзенең байлыкларының, традицияләренең гаять зур өлешен, шулай ук аларны тудыручыларны да — Октябрь революциясеннән соң эшчеләр һәм крестьяннар арасыннан чыккан талантларны, интеллектуаль элитаны — югалтып бетерә язды.

«Милли үзенчәлеккә битараф карау, — диелә КПСС платформасында, — күп кенә социаль проблемаларның хәл ителмәгән булуы милли аңда тискәре чагылыш таптылар, үпкә хисе уяттылар».

Милли үзенчәлекләрне без ничек аңлыйбыз һәм ул кешенең милли үзаңы белән ничек бәйләнгән? Милли үзенчәлек, милли аерымлык кешенең милли горурлыгын чагылдырмыймы соң? Ә бу тойгы исә башка халыклар арасында үз халкының ролен һәм урынын аңлауда туа. Әгәр кеше хокукларда, мөнәсәбәтләрдә, җәмгыятьтәге урынында тигезлек сизә икән, бу еш кына күңелдә тирән кимсенү тойгысы тууга сәбәп була. Халыкларның бер ишесе — беренче сорт сыман, союз статуслы, башкалары исә — икенче сортлы, гамәлдә бөтенләй хокуксыз автономиягә генә ия. КПСС платформасында бу бүленеш хәтта аклана да шикелле. Дәлил итеп төрле халыкларның социаль-экономик үсешендәге төрле дәрәҗә, халык санындагы аермалык, культура дәрәҗәсе, элек дәүләтчелеге булмау һ.б. лар китерелә.

Әмма әлеге искәрмәләр татар халкына карата, мәсәлән, хакыйкатьне чагылдырмыйлар. Татар халкының элек тә дәүләтчелеге юк идемени? Бу халык сан ягыннан РСФСРда икенче, СССРда алтынчы урында тормыймыни?

Хәтта 7 миллионлы татар халкының бары тик бер ярым миллионының гына автономиягә ия булып яшәве дә бу халыкның үзенчәлеге булып торамы соң? Калганнары гасырлар буенча Россиянең 30 өлкәсендә һәм күп кенә союздаш республикаларда тупланып яшиләр. Мәсәлән, Башкортстанда татарлар миллионнан артык, хәтта башкортлардан да күбрәк. Әмма кем дә булса аны Кабарда-Балкар, Чечен-Ингушетия республикалары үрнәгендә татар-башкорт республикасы дип үзгәртү турында авыз ача икән, аңа шунда ук милләтче ярлыгы тагыла. Боларның барысы да кимсетелү һәм ярсу тойгысы тудырмыймыни? Болар милли аңга йогынты ясамыймыни? Ни өчен күп санлы башка халыклар белән беррәттән, татар халкы мөстәкыйльлектә югарырак статуска хокуклы түгел?

Илдә демократияләштерү башлангач та, милли үзаң кабынып китте, хәтта аны идарә итү дә кыенлашты. Бу исә куркыныч. Милли үзаң үзенчәлекле нәрсә. Әйтик, татарча, яһүдчә сөйләшмәсә дә, үзләрен татар, еврей итеп танучылар күп. Әмма бу табигый тойгы да акрынлап югала бара. Мәсәлән, илдә татарлар күп булса да, халык санын алу мәгълүматларыннан аларның саны үсү сизелми: күпләр Баланы рус, һич югында, Башкортстанда — башкорт, Үзбәкстанда — үзбәк, Казахстанда — казакъ булып саналуы яхшырак, уңайлырак, хәвефсезрәк дип саныйлар. Бу күренеш тә ирекле ассимиляция дип санала микән?

Милли үзаңда милли тойгылар җитди роль уйный. Үз милләттәшләреңнең уңышларын яисә уңышсызлыкларын башка халыкларныкы белән чагыштырганда кемнең генә милли хисләре кузгалмас һәм кем генә борчылмас яки шатланмас икән? Мәсәлән, Идел буе һәм Урал татарларының тарихын мәктәп дәреслекләрендә бозып күрсәтү хәтер калдырырлык түгелме? Аларда язылганнар илебез халкында татарлар, янәсе, монгол-татар басып алучылары

белән килеп, рус җирендә төпләнеп калучылар дигән ялган күзаллау тудыра. Бу исә еш кына рус халкында татарларга карата аларның милли тойгысын кимсетә торган «аерым» мөнәсәбәт формалаштыра. Фән әһелләренә хәзерге татарларның монгол-татарлар килүенә чаклы 600 ел элек үк мөстәкыйль һәм чорына күрә көчле дәүләт булып яшәгән Идел болгарлары нәселеннән булуы мәгълүм. Кораллы килмешәкләр, инде Н.Г.Чернышевский үк язганча, русларны буйсындырган кебек үк, болгарларны да басып алып буйсындырганнар.

Ә халыкның исеме? Ул кайчан үзгәртелгән? Тарихта исем үзгәрү шикелле күренешләр һич тә сирәк түгел. VII гасырда, мәсәлән, болгарлар (телләре буенча төркиләр) Балкандагы славян кабиләләрен буйсындырып, алар белән кушылалар, әмма аларга үзләренең исемнәрен калдыралар. Берничә гасырдан соң басып алучы татар-монголлар Идел һәм Камада яшәүче болгарларга татар исемен калдыралар...

Милли культура — ул, беренче нәүбәттә, мәдәни байлыкларны яңа буыннарга тапшыруның иҗтимагый формасы булган мәктәп. Татар мәктәбенең күтәрелеше Россиянең азсанлы халыкларын рухи изүне бераз йомшарткан беренче рус революциясе чорында башлаган иде. Мәктәпнең чәчәк атуы исә 1917 елдан соң башланды, егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында европача белем бирү учагы буларак формалашты.

Ә хәзер? Хәзер илдә татар балаларының нибары йөздән җидесе генә ана телендә укый. Милли мәктәп югалды диярлек. Аның бетүе халыкның яртысы чамасы өчен милли телне югалтуга китерде һәм, шуның белән бергә, халык тарихының онытылуына, милли культура үсешенең тукталуына да сәбәп булды. Милли сәнгать әһелләре, зыялылар санын арттыру чыганагы нык тарайды. Элек татар культурасы өчен кадрларны илдәге барлык татар мәктәпләре бирең

килгән булса, хәзер бу вазифаны Татарстандагы кайбер мәктәпләр генә башкара ала. Шуңа күрә хәзер музыка һәм шигырь яки китап язарлык, сәхнәдә уйнарлык, ана телендә җырлар җырларлык кешеләрне табуы кыен.

Октябрь татарларга музыкаль культура, опера, балет алып килсә дә, торгынлык чорында опера театры нигездә рус музыкасына, рус сөйләменә күчте. Татарча дәреслекләр тиражы елдан-ел кими. Боларның барысы да милли хисләрнең кискенләшүенә китерми калмады. Ризасызлык туплана килде, ә халык депутатларын сайлаулар чорына бу хисләр матбугат битләренә, шәһәр урамнарына һәм мәйданнарына ташып чыкты.

Нигә соң без меңнәрчә еллар буена халкыбызның рухи тормышының әлифе булып торган бабаларыбызның рухи, мәдәни мирасыннан, мөселман, шәркый халыклар мәдәниятеннән (дини тәгълиматтан түгел, ә гомумкешелек әхлагы кагыйдәләреннән) шулай катгый һәм мәгънәсез рәвештә кинәт баш тарттык? Халыкның рухи тормышындагы кискенәйгән проблемаларны чишү ысуллары кайда соң? Боларны милли культура экологиясенең бозылу сәбәпләрен дөрес билгеләү аша гына табып була. Чөнки репрессияләр һәм торгынлык чорында татар милли мәдәнияты гына түгел, ә бөтен җәмгыятьнең, барлык милләтләр культурасының, шул исәптән рус культурасының да дәрәҗәсе төште.

Беренче сәбәп итеп культураның үтә идеологияләштерелүен, ягъни политика һәм философияне, политика һәм сынлы сәнгатьне, политика һәм музыканы гарипләндереп бергә кушуны, гомумкешелек байлыкларын тар сыйнфый кысаларга кертүне, динне, генетиканы, кибернетиканы эзәрлекләүне, әхлакый таләпләрне идеологик категорияләр белән алмаштыруны санарга кирәк. **Икенче сәбәп** — культураны идарә итүнең үзәкләштерелгән катгый системасы: культурада монополизм иллюзиясе, барлык

мәктәпләр өчен бердәм программалар аша стандарт фикерләү тудыру. Үзләре бу эшне тирәнтен белмәгән җитәкчеләрнең ялган социалистик культураны урнаштыруы халыкның рухи ихтыяҗларының тараюына, мәдәни-тарихи тамырларыннан аерылган, милли культураларның үзенчәлекләре бетеп, стандарт бер культурага әверелүенә китерде.

Табигый ки, милли культура өчен көрәш бер чиктән икенче чиккә талпынуны, әйтик, гомумкешелек рухи байлыкларыннан, Европа цивилизациясеннән, рус классикасыннан читкә тайпылуны таләп итми.

Гомуми культура дәрәҗәсенең түбәнәюен һәм әхлаксызлыкка бирелүнең **өченче сәбәбен** галимнәр хаклы рәвештә кешеләрнең мәдәнияттән, әдәп-әхлактан тулаем читләштерелүендә күрәләр. Экономикада тигезләүчелекнең хөкем сөрүе рухи тормышта да тигезләүчелеккә китерде. Халык массаларының югары эстетик байлыклар җитештерүдә катнашуы да, эстетик культура элементларының акрынлап югалуына китерде. Кешеләр хәзер үзләре тырышып көч куймыйча гына (радио, телевидение, магнитофон һәм видеотехника ярдәме белән) мәдәни байлыктан файдаланучыларга гына әйләнеп калдылар. Моңа фән-техника революциясе һәм көчле үсеш алган информация чаралары да объектив булышлык итәләр.

Җәмгыятьнең әхлакый тәррәкыяте, прогрессы, шәхеснең һәрьяклы үсеше — чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәттә йөзләрчә буыннар туплаган тәҗрибәне үзләштерү нәтиҗәсе, культура үсеше дәвамчанлыгы ул. Рухи тормышыбызда элек булганнарның күбесе җимерелде һәм дәвамчанлык җепләре өзелде, әмма аркасында без әлегә яңа нигездә әхлакый прогресска ирешә алмадык. Бу хәлдән ничек чыгарбыз икән?

Моннан чыгу өчен милли культура өлкәсендә дә үзгәртеп кору мөһим: аның төп таянычы — яңача фикерләү булырга тиеш. Татар милли мәдәниятенең яңаруы процессы бик киң колачлы. Бу өлкәдә яңача фикерләүгә, культура һәм тарих факторы буларак, ислам диненә яңача мөнәсәбәт тә керә. Кешене әхлакый тәрбияләүдә диннең уңай йогынтысы турында әйткәндә, дини догмаларның кешене иҗади активлыкка өндәмәвен инкарь итәргә ярамый. Шәхеснең бүгенге социаль үсеше өчен дин әллә ни бирмәс. Әмма аны милли культура үсеше тарихы яктылыгында өйрәнү кешенең тарихи фикерләвен формалаштыруга, һичшиксез ярдәм итәр. Чөнки дин тарихы — халыкларның акыл һәм рух, интеллектуаль үсеш тарихының бер өлеше ул. Тарихи-иҗтимагый күренеш булган дин аша кешенең танып-белү эшчәнлеге үсеше ачыла. Борынгы бабаларыбызның ислам динен кабул итүләренә һиҗри белән 1100 ел тулу юбилеен бәйрәм итү борынгы мәдәниятебезне барлауга, терелтүгә хезмәт итә. Бу исә шәхеснең әхлакый-эстетик үсеше чыганакларына игътибарны көчәйтте, хәтта яшь буынның да иҗтимагый активлык ният-теләкләрен үстерергә этәргеч булды.

Политикада яңача фикерләү — ул бәхәсле мәсьәләләрне ирексезләү юлы белән хәл итүнең мөмкин түгеллеге. Ул властьны халыкка бирү, иҗтимагый тормышны демократияләштерү, экономикада яңача фикерләү, «милек» төшенчәсен яңача бәяләү, аның күп төрләре өчен юл яру, җитештерүчеләрнең хуҗалык итү мөстәкыйльлеге, үзфинанслау, хезмәткә аның күләменнән чыгып түләү һ.б.

Мәдәниятта яңача фикерләү — ул культура белән үзәктән идарә итүдән баш тарту, иҗат иреге, милләтнең үз-үзен күрсәтүнең яңа формалар һәм ысуллар эзләве, барлык милли культураларның тигез хокуклылыгы һәм аларның тигез материаль тәэмин ителеше.

Әлбәттә, теләсә кайсы милләт кешесенең шәхесен үстерү, аның милли культурасын үстерү өчен һәм политик, һәм экономик шартлар булуы зарур. Союздаш һәм автономияле республикаларны региональ хуҗалык исәбенә күчерү юлы белән аларның экономик хокукларын киңәйтеп, һәм үз республикасыннан читтә яшәүче милләтләргә, аерым алганда татарларга культура автономиясе өчен киң юл ачу — КПСС платформасы менә шундый шартларны тудыруны күздә тота.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, арабызда манкортлар ишәймәсен өчен, халыкка, әйтик, татар милләтенә үзенең үзенчәлеген, үз халәтен аңлату, әһәмиятле булыр дип уйлыйм. Бу — аңа үз тарихына карата ныграк кызыксыну уятыр, үз аңын үстерүгә ярдәм итәр. Бер төрле социаль-экономик шартларда бергә яшәгән милләтләр үзара якыная барсалар да, һәр милләтнең үз үзенчәлекләрен саклавы һәм үстерүе — объектив тенденция, закончалык. КПССның милли платформасы нәкъ менә милли культуралар үзенчәлегенең уникаль кыйммәтләрен саклап калуны хуплый һәм аларны киләчәктә дә үстерә бару юлларын билгели.

Кыскасы, тарихта күп җитди ялгышлар ясалды. Утызынчы еллардагы кебек, беткә үч итеп тун яндыручылар кабат булмас, дигән өмет белән яши хәзер халкыбыз. Шул өмет белән ул илебездә киң җәелгән үзгәртеп коруларда актив катнаша.

2.9. Татарлар Америкада

(“Татарлар Америкада”, “ Мирас”, №4, 1993)

— Сез саф татарча шундый әйбәт сөйләшәсез ки, әйтерсең лә шәһри Казанда яшәгәнсез, — дидем мин туган телемдә «Форд» автомобиле рулендә утырган әңгәмәдәшемә.

— Юк,— дип жавап кайтарды ул шул ук телдә.—Мин Төркиядә тудым, анда егерме яшемә чаклы яшәдем, төрек мәктәбендә белем алдым. Ләкин гаиләдә туганнарым барысы да татар телендә сөйләштеләр. Алар кагыйдәне бик төгәл үтәделәр. АКШка без моннан егерме ел элек күчеп килдек. Биредә күптән яшибез,—дип ул сүзен тәмамлады һәм миңа дустанә елмаю белән карап алды. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

... Америкага бару белән хәзер инде Казанда берәүне дә шаккатырып булмый. Элек анда безнең кебек үзәктән читтә урнашкан шәһәрләрдә яшәүчеләр бик сирәк була торганнар иде. Әгәр берәрсе форсат чыгып шундый мөмкинлеккә ия була икән, ул анда бару хакында тәфсилләп сөйли, үзенең ничек самолетка утыруы һәм аның биеклеккә күтәрелгәндә пассажирларның нинди халәткә дучар булуын да онытмый. Соңрак самолет һәм пассажирның эчке кичерешләре хакында язмый башладылар. Хәер чит илгә бару хакында да аз язалар. Чит ил гражданнары үзләре безгә киләләр һәм үзебезнең республика телевидениесендә иркенләп сөйләшәләр. Гомумән, чит илләр турында хәзер мәгълүмат зур. Әмма илебез эчендә бара торган вакыйгалар хәтта ерак Америка белән очрашуга караганда да күбрәк дулкынландыралар, көчлерәк тәэсирләр тудыралар.

Гәрчә шулай булса да, безнең укучыларыбызны кызыксындыра торган сораулар бар әле. Мәсәлән, татар укучысын чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы бик кызыксындыра. Чөнки, элекке заманнарда, бигрәк тә торгынлык елларында, бу хакта бернинди дә мәгълүмат бирелмәде. Бары безнең көннәрдә генә хәбәрдарлык хасил булу сәбәпле ул хакта яза башладылар. Ләкин бу бик аз әле. Ышануымча, бу язмада Америкада чакта очрашырга туры килгән милләттәшләребез хакында беркадәр мәгълүмат бирә алырмын дип уйлыйм.

... Шәхси йортның зур аш өстәле янына Американың иң зур шәһәре Нью-Йоркта яшәүче дистәдән артык татар кешесе җыелды. Һәрвакыттагыча, таныш булмаган кешеләр белән беренче тапкыр очрашу бераз каушата төшә. Дустанә елмаюлар, татарча әйтелгән «исәнмесез», гомум мөселманга эндәшелгән «әссәламәгаләйкем» сүзләре уңайсызлану хисен баса төшә. Һәм без салмак кына сүзгә-сүз ялгап, кызыксынып әңгәмә куертып җибәрәбез.

Минем өчен, әлбәттә, барысы да яңа, кешеләрнең кыяфәте дә, аларның теле дә, тавышларындагы интонация дә, хәтта татарча сүзләре арасында катнашып киткән сирәк инглиз сүзләре дә сәер яңгырый. Сәер, чөнки безнең «татарча»бызда рус сүзләре ешрак кулланыла. Яңа танышларым белән сөйләшү генә түгел, хәтта аларны күзәтеп тору да бик кызык иде.

Бу зур һәм бай илдә яшәүче татарлар тормышы турындагы минем күзаллауларым аларның кайберләре белән булган кыска вакытлы очрашулардан соң гына түгел, бәлки Американың үзе, аның көнкүреше белән танышу, төрле милләттән чыккан һәм төрле төстәге америкалылар белән очрашу аша да барлыкка килде. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: бу илдә яшәүче кешеләр милли билгеләре буенча аерылмыйлар һәм төрле документларда, паспортларда да бу хакта бернинди дә искәрмә юк. Бу турыда сүз чыкканда сезгә: болар «төсле тәнлеләр», ә болары исә — испан телендә сөйләшүче америкалылар дип кенә әйтергә мөмкиннәр.

Беренче тапкыр АКШта мин 1989 елның сентябрь аенда Сент-Луис, Жәксонвиль һәм Уокеша шәһәрләренең профессиональ белем бирүче коммуналь колледж директорлары (америкача— президентлары) чакыруы буенча барган идем. Майк Кроуфорд, Чарльз Спенс һәм Дик Андерсон үзләре дә шул ук елның августында Казанга килеп киткәннәр иде, без тәмам дуслашып, телевидениедә инглизчә-татарча әңгәмәдә мәгариф өлкәсендә

хезмәттәшлек итә башладык, дип сөйләгән идек. Америкада ун көн эчендә алар миңа бик күп нәрсә күрсәттеләр. Без аларның гаиләләрендә дә булдык, заводларга да бардык, зур шәһәрләрнең мэрлары белән дә сөйләштек.

Американы мин икенче тапкыр 1990 елның апрель-май айларында күрдем. Коммуналь колледжларының Америка ассоциациясе Президенты Дейл Парнейл мине Вашингтон штаты (Америка башкаласы Вашингтон шәһәре илнең Көнчыгышка урнашкан Колумбия округына карый) башкаласы булган ике миллионлы Сиэтл шәһәрендә оештырылган ике зур конференциядә катнашырга чакырды.

Апрель уртасында Сиэтл шәһәрендә салкынча һава: тирә-юньдә түбәләрен ап-ак кар каплаган таулар күренә, Тын океан култыгында куе зәңгәр төсле салкын дулкыннар тәгәри... Дүрт мең кешелек зур залда мәгариф әһелләре алдында миңа доклад сөйләргә кирәк иде. Гәрчә мин бик күп тапкыр трибуналарга менеп сөйләгән булсам да, шундый зур аудитория алдында инглиз телендә чыгыш ясау психологик яктан җиңел булмады. Бары тик чыгышымның әллә бишенче, әллә алтынчы минутында гына мин бераз тынычлана төштем, профессиональ белем өлкәсендә эшләүче америка белгечләренең мине зур игътибар белән тынлауларын күргәч кенә калтыраулы тавышым ныгыды.

Өченче конференция май аенда, АКШның космик кораблъләре очыртыла торган атаклы Канаверал борыныннан ерак түгел җирдә урнашкан көньяк шәһәре Жәксонвиллдә (Флорида штаты) булды. Биредә инде без өчәү идек: безнең фәнни-тикшеренү институты галимнәре Диләрә Шакирова белән Морат Чоншанов та актив катнаштылар. Диләрә ханым да матур итеп инглиз телендә Казан мәктәпләрендә компьютерлардан файдалану турында чыгыш ясады. Бу конференциядә бер нәрсәне тирән аңладым: мондагы халык

гомуми белем түгел, яшенә-картына югары квалификацияле профессия бирү кайгысы белән яши. Ә без әле һаман башлангыч мәктәп хәлләрен тикшерәбез. Бу хакта Америкага ни өчен бардыгыз дигән сорауга җавап төсендә язам.

... Мәгълүм булганча, 1990 елның март аенда шәһри Казанда чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән хезмәттәшлек итүне җайга салу өчен «Ватан» җәмгыяте төзелгән иде. Әгәр беренче сәяхәтем вакытында бу хакта уйламаган булсам, хәзер инде мин Сиэтл шәһәре кунакханәсендә утырып телефон аша милләттәшләремне эзли башладым. Дөресен әйткәндә, үземдә нибары бер телефон номеры гына бар иде. Әле анысын да миңа үзе Америкада булган чакта андагы милләттәшләребез белән очрашкан әдип Әбрар Кәримуллин биргән иде. Төгәл әйткәндә, Сан-Франциско шәһәрендә яшәүче Халидә Деушның телефон номеры иде ул. Минем шалтыратуыма хуҗасы җавап бирде.

— Исәнмесез, Халидә ханым,—дип татарча башладым мин сүземне. Сезнең белән профессор Мирза Мәхмутов сөйләшә. Мин Казаннан очып килдем. Сезгә Сиэтлдан шылтыратам.

— Исәнмесез, - дип йомшак кына тавыш белән җавап кайтарды Деуш. — Сезнең тавышны ишетүгә бик шатмын. Рәхим итеп безгә килегез, килә аласызмы?

— Кызганычка каршы, вакытым юк, бара алмыйм. Ләкин сезгә сәлам тапшырасым килә...

Сөйләшү, кем әйтмешли, булды. Мин башка ватандашларымның да телефон номерларын сорадым, һәм ул миңа бик теләп шул ук шәһәрдә яшәүче берничә кешенең исемен атады. Шулай итеп мин телефон аша Сан-Францискода яшәүче Равил Селехметка чыктым. Ул миңа Нью-Йорк шәһәрендә яшәүче татарларның бер-ике телефон номерын бирде...

Америка профессорлары Кәмал Карпат белән Юлай Шамил углы эшләгән Висконсин университетына да шалтыратып карадым. Юлай Шамил углы белән мине профессор Мирфатыйх Зәкиев таныштырды. Ул чакта Юлай Шамил углы Казанга килеп киткән иде. Бу чибәр яшь кеше миңа шунда ук ошады. Һәм мин аның белән очрашырга теләдем. Ләкин аларның берсе белән дә күрешә алмадым, анда кешеләр безгә караганда күбрәк эш белән мәшгуль һәм өйләрендә сирәк утыралар икән.

Акрынлап кына булса да минем башта төп эшемә зыян китермичә милләттәшләрем белән очрашу планы өлгерде. Америкада булу программасы эчендә мин якын-тирәдәге шәһәрләрдә яшәүче татарлар белән очрашырга уйладым. Моның өчен вакыт табарга кирәк иде. Ләкин татарларның күпчелеге Нью-Йорк шәһәрендә яши диделәр.

Беренче булып мин телефон аша Надыйр Дәүләтне эзләп таптым. Соңыннан ачыкланганча, ул татар халкы тарихына караган материаллар туплау максатында АКШ китапханәләрендә эшләү өчен бирегә килгән Төркия гражданины булып чыкты. Минем шалтыратуыма профессор Дәүләт бик куанды һәм без мөмкинлек чыгу белән очрашырга сүз куештык.

Командировкам тәмамлану алдыннан минем бер-ике көн буш вакытым калды һәм мин Вашингтонда танышым фатирында яшәдем. Аннан мин телефон буенча Татар җәмгыяте президенты Илдар Агишны табып алдым да, без очрашу турында сөйләштек. Мин икенче көнне кичен поезд белән Нью-Йоркка барырга булдым, ә ул исә мине вокзалда каршылармын диде. Беренче булып башыма билет кайгысы төште. Дустым агентлыкка шалтыратып поездның кузгалып китү вакытын ачыклады һәм билет бәясе белән дә кызыксынды.

Үзегез дә яхшы беләсез, гәрчә ул академик булса да, чит илгә командировкага киткән совет гражданинының акчасы санаулы гына түгел, бөтенләй булмаган чаклар еш була. Юл вакыты өч сәгать. Күңелдән генә хисаплап алдым — бездә поезд белән өч сәгать барсаң, билетың өч сумга якын тора. Шулай булгач, барып кайту бәясе якынча алты-сигез долларга төшәчәк дип уйладым. Бераздан мин үземнең беркатлы булуымны бик тиз аңладым. Вашингтоннан Нью-Йоркка бару бәясе 60 доллар тора икән. Димәк, анда барып кайту өчен мина кимендә 120 доллар кирәк! Бу зур сумма ич! Ләкин бару турында алдан ук сөйләшеп куйгач миндә доллар юк дип кенә аклану килешеп бетмәс. Безнең хакта мондагы татарлар ни уйлар? «Яхшы көннәр килгәч» түләү шарты белән дустымнан әҗәткә акча алып торырга туры килде.

Утырып кына бара торган вагонның уңайлы кәнәфиендә вакытның узганы сизелми. Җитмәсә, мин тәрәзәдән күзләремне аера алмый күзәтеп барам. Америка буйлап поездда һәр көнне йөреп булмый ич. Әле һаман Америка шәһәрләрендәге урамнарның чисталыгына гаҗәпләнәм, андагы йортлар тирәсендәге җир тәрбияләнгән — тигез итеп киселгән чәчәк түтәлләре һәм яшел үләннән келәм белән йортлар әйләндереп алынган, беркайда да кыйшайган капкалар, такта сарайлар, бәләкәй корылмалар һәм чүп-чар өемнәре юк... Шундый манзарадан соң, кем әйтмешли, бөек дәүләтебез өчен оят булып китә.

Һәм менә мин Вашингтон — Нью-Йорк поезды тәрәзәсеннән тимер юл тасмасыннан арырак җирдә агач сыныклары, иске кәгазь, буш шешәләр кебек чүп-чар аунап ятуын күреп алдым. Әһә, дим, эчемнән генә сөенеп, бездә генә түгел, биредә дә чүп-чар бар икән...

Вокзалда мине каршы алучы кеше күренмәде. Урамга чыктым. Карыйм, берәү кемнедер эзли кебек. Янына барам—«Сез мистер Агиш түгелме?»— дип инглизчә сорыйм моңардан. Елмая, — «Мин

Агиш, — ди ул, ә Сез, минем аңлавымча, Мәхмүтов әфәнде»,— дип кайтарып сорый ул саф татар телендә. Без аның белән шулай таныштык. Ул, мине автомобиленә утырырга чакырды.

Машина эчендә аның дуслары — бер яшь ир белән яшь хатын утыра иде. Алар икесе да татар кешесе булып чыкты, Агиш аларны минем белән очрашу өчен өенә чакырган икән. Америкалылар төрле йортларда яшиләр: фәкыйрьрәкләре — күп катлы биналарда, аерым фатирларында торалар, хәленнән килгәннәре исә аерым йорт сатып ала яки яшәү өчен алып тора. Аерым йорт булдыру һәм аерым яшәү һәр америкалының хыялы. Бер-бер артлы тезелеп җиткән бер-ике катлы, бер-берсенә охшамаган матур йортларны һәр Америка шәһәрендә күрергә мөмкин. Бер төрле "типовой" биналар да очрый — хезмәт хакы әзрәк булган эшчеләр өчен мондый арзанлы йортларны фирмалар үзләре төзиләр һәм кредитка саталар.

Йортның яки фатирның зурлыгын бездә гадәттә бүлмәләр яки квадрат метрлар саны белән үлчиләр: ничә бүлмә бар? дип сораргa яратабыз без. Йортта (фатирда) ничә йокы бүлмәсе бар?— дип сорый америкалы. Йортта гадәттә ике-дүрт йокы бүлмәсе була. Димәк, анда шул ук санда ванналар һәм туалетлар да бар. Һәркем иртән-кичен чиратсыз душ керә ала, ягъни.

Нью-Йоркның галәмәт зур һәм матур күперләре аша чыгып, гигант шәһәрнең Лонг-Айленд исемле абруйлы районына килеп җиткәндә кич булды. Шәхси коттеджлар төзелеп киткән озын урамны үткәч, без кызыл кирпечтән салынган өч катлы тар гына бинаның алгы ягына килеп туктадык. Челтәрләп эшләнгән тимер ишек ачылып китте — һәм безне мөлаем йөзле яшь хатын каршы алды.

Моңарчы миңа америка йортларында булырга туры килгәләде. Гадәттә, аларда ашханә булып та хезмәт иткән зур гына

«сәламәтлек» бүлмәсе дә була. Хуҗалар еш кына кухняда яки аның белән янәшә бүлмәдә ашыйлар.

Бу йортта әллә ни зур булмаган бүлмә өйалды белән тоташа, уң якта тәбәнәк өстәл һәм аның әйләнәсендәге диванда берничә кеше утырган, каршы якта икенче катка алып бара торган баскыч, ә алда исә 15 квадрат метр чамасы янә бер бүлмә, анда аш өстәле һәм урындыклар тора.

Икенче катта өлкәннәр өчен ике йокы бүлмәсе һәм балалар өчен бүлмә бар. Алар Агишта өчәү. Өченче катта янә бер бүлмә. Анда мин кунып чыктым. «Мунча» икенче катта иде. Агишның үз йорты менә шулай.

Гомумән әйткәндә, уртача яшәүче америкалыларның торак мәйданы әллә ни зур түгел. Миңа башка дусларымда дүртәр-бишәр көн яшәргә туры килде. Мәсәлән, Уоксимада врач Питер Конерт өендә. Аның йорты бер генә катлы, ләкин зур бүлмәләр бар, бик җайлы, ишегалдында бассейн бар.

Кичләрнең берсендә хуҗа мине университет колледжының бер укытучысы һәм унлап студентлары белән бергә Милуоки шәһәренә театрга чакырды. Нибары ике артист антифашистик спектакльне менә дигән итеп куйды (фашист Эйхманны Израильдә ничек итеп хөкем итү турында).

Питер белән автомобильдә барганда сөйләшү хәтергә кереп калды.

— Сез сәясәт белән кызыксынасызмы?— дип сорадым.

— Ай хейт Рейган (мин Рейганны күралмыйм),— ди Питер.

— Ни өчен,— дип сорыйм мин аңардан, — ә үзем эчтән генә салпы якка салам кыстырмакчы була дип уйлыйм.

— Ул бик күп никарагуалыларны үтерде, — дип җавап кайтара Манагуа госпитальләрендә үлемне күп күргән хирург.

— Соңрак "озын" Питер, мин аны үзалдыма шулай дип атадым, Казанда минем өемдә кунакта булды, хәтта бакчамдагы мунча белән дә «сыйланды». Шулардан башка америкалыны тагын ни белән сыйлап була соң?

Агиш йортында нигездә олы яшьтәге кешеләр җыелган иде. Ни турында гына сөйләшмәделәр алар.

— Татарлар Россиядә ничек яшиләр? Мәктәпләрдә балаларын татар телендә укытып буламы икән? — дип сорый өстәл артында утырган олы яшьтәге ханым. Билгеле, мин ислах (реформа) башлангач бездә нинди үзгәрешләр булуы, мәктәпләр, театрлар җәмәгать оешмалары һәм туган телебездә басыла торган гәзитләр турында сөйләдем. Ислах, социализм, тормыш шартлары барысын да кызыксындыра.

Кунаклар социализм һәм капитализм турында гәпләшә башладылар. Мине ике күршемнең бәхәсе аеруча кызыксындырды. Зәйтүнә капитализмның социалистик фикерләр һәм социал-демократлар йогынтысы астында үзгәрүе турында сөйли. Чамадан тыш табышка прогрессив налог салу, капитал өстеннән дәүләт контроле һ.б. шундый чаралар капиталистик мөнәсәбәтләр белән идарә итәргә мөмкинлек бирә, ди ул.

Ирфан исә социализмның бөтен Европада тар-мар килүен сурәтләргә маташа. Мисал рәвешендә ул производство артка китә һәм анда эшләүчеләрнең тормыш дәрәҗәсе түбәнәя башлаган Швецияне китерде. Гәрчә шведлар капиталистик җитештерү ысулын кооператив хәрәкәт белән кушуның гаҗәеп формасын уйлап тапсалар да, алар хәзерге конкуренциядә оттыралар, күп нәрсә югалталар. Хосусый милек идеяләре җитештергән товарларның сыйфаты дәүләт предприятиесендә эшләнгән әйберләр сыйфатыннан күп тапкыр югары.

— Ни өчен шулай килеп чыга,—дип кызыксынам мин.

— Чөнки социалистлар күп законнар кабул иттеләр, эшчеләргә эш урыны гарантияләнә, профсоюзлар ялкау, булдыксыз кешене эштән куарга ирек бирмиләр. Кешеләр андый шартларда тыныч яши башладылар һәм ялкауландылар...

— Ләкин биредә дә, социалистик идеяләрдән ерак җирдә дә әйбәт яшиләр ич?

— Биредә бөтен милек хосусый, хуҗа ялкауны шунда ук эштән куып чыгара һәм аны берәү дә якламый. Чөнки барысы да тырышып эшлиләр. Шуңа күрә халыкның 80 проценты әйбәт эшли (бездә киресенчә, дип уйладым мин).

— Бик мактамагыз аларны, Ирфан әфәнде. Капиталистлар ярлы кешеләрне эксплуатацияләп байыйлар, — диде катгый рәвештә Зәйтүнә.

Эш башында торучылар сәләтле кешеләр алар, үзләре намус белән эшләгәч, алар ничек баемасыннар инде, — ди аңа күршесе.

— Бик гади байыйлар. Биредә, Америкада, эшчегә күп түләргә кирәк. Ә ул исә отышлы түгел. Шуңа күрә эшмәкәрләр акчаларын чит илләргә күчерәләр, анда заводлар төзиләр. Мексикада, мәсәлән, эшчегә американыга караганда тугыз тапкыр кимрәк түлиләр. Бөтен табышны хуҗалар үз кесәләренә салалар, — дип җавап бирде Зәйтүнә.

Бездә бу турыда экономистлар гына сөйләшә, дип уйладым мин. Бәхәс дәвам итте.

— Сезнең бабаларыгыз кайсы яктарак яшәгәннәр, — дип сорадым күршемнән. Әтием белән әнием Идел буе татарлары булсалар да, без Симферопольдә, Кырымда яшәдек, — дип җавап бирде Ирфан Таби.

— Немецлар безгә тимәделәр. Әмма партизаннарга ярдәм итмәгәннәрне КГБ Себергә җибәрә, дип куркыттылар. Әткәй курыкты һәм без немецлар артыннан Германиягә киттек.

Белмим, ни дәрәҗәдә дөресен сөйләгәндер Ирфан. Бәлки, атасы немецлар белән хезмәттәшлек иткәндер. Ә бәлки карт татар сугышка барудан үзенең биш улын шулай саклап калгандыр. Без янәшә утырдык, Ирфан сүзен дәвам итте.

Гаиләдә җиде бала идек, бишесе ир балалар. Без Германиядә начар яшәмәдек. Бер танылган кеше, хәтерем ялгышмаса, аның фамилиясе Исхаков иде бугай, аны әти бик ихтирам итә иде, аңа Төркиягә китәргә киңәш бирә. Без күченеп киттек, ләкин анда яшәү бик авыр булды һәм әткәй әлеге киңәшчесенә каты үпкәләде. Соңрак без кабат Германиягә күчеп килдек. Теге кеше белән очрашу вакытында әткәй аңа үпкәсен белдерә. Ә ул исә әтигә әйтә:

— Син нигә миңа үпкәлисең. Улларың немец кызларына өйләнсә, син кем булыр идең? Мин гаиләңне каферлектән коткардым. Хәзер син бөтен улларыңны татар кызларына өйләндердең. Кайда теләсәң, шунда яши аласың.

Чыннан да, без барыбыз да татарлар бик күп яшәгән Төркиядә өйләндек. Бер туганым төрек кызын алды. Алар барысы да татар-төрек телендә әйбәт сөйләшәләр.

Безнең белән утырган бер татар хатыны чыннан да шулай сөйләшә иде. Аның бабасы 20 нче елларда Йәмәндә беренче совет илчесе булган икән...

Ирфан профсоюзларны да, социализмны да яратмый. Алар, аның фикеренчә, бары кешене генә аздыралар.

— Әгәр кешене бөтен мәшәкатьләрдән азат итсәң, ул мәче кебек бозыла; хуҗа кулыннан гына тукланырга гадәтләнә, тычканнар тотмый башлый, — дип үз фикерен кабатлый Ирфан. Андый кешене инде яхшы эшләргә мәҗбүр итеп тә булмый, ди Ирфан. Хәтта аңа акча бик кирәксә дә, ул ялкаулыгыннан арына алмый. Социализм Европада үзен акламады, шуңа күрә ул тарихи факт буларак кына калды.

— Социализм үзен акламады, дисез, кемгә соң ул капиталистик Евроада зыян китерде?

— Швеция үз эшчеләренә яхшы тормыш шартлары тудырды, иң югары социаль тәэминатны бирде, компанияләр хәтта авырып эшкә чыкмаган көннәр өчен дә эшче-хезмәткәрләргә акча түлиләр. Хәзер Швеция авыр хәлдә, күбесе көчәнеп эшләргә теләмиләр, хезмәт җитештерүчәнлеге төшә бара. Ә бик югары хезмәт хакы исә производствоның файдасын киметә.

— Ә Америкада ничек соң, бит бөтен кибетләр югары сыйфатлы товарлар белән тулган ич?— дип сорыйм мин.

— Монда табыш, файда китермәгән предприятиеләр бөлгенлеккә төшәләр, ябылалар. Эшсез кемнең каласы килә? Берәүнең дә килми, шуңа күрә барысы да тырышып эшлиләр, укыйлар, квалификацияләрен күтәрәләр. АКШта эшмәкәрләр зур табыш артыннан куып капиталны башка илләргә дә чыгаралар. Америкада, мәсәлән, теләсә нинди эш өчен кимендә сәгатенә 4,5 доллар түләргә кирәк, ә Мексикада исә ул нибары 1,5 доллар гына тора. Ә товарларны бирегә кайтаралар да шул ук бәяләр белән саталар.

Ирфан гасабилана башлады: чүп җыючы, урам себерүче елына 44000 доллар ала, үз йортында яши, өч-дүрт машинасы бар һәм ... эш хакын күтәрүне таләп итә?!

— Башбаштаклык!— диде өстәл артында утыручы берәү. Укытучы елына 22000 доллар ала һәм тир түгеп, нервлары бозылганчы эшли.

Ирфан: гомумән эшчеләрнең профессорларга караганда эш хакын күбрәк алуы ул үзе мәгънәсезлек. Ярым белемле эшчегә караганда, университет дипломлы кеше бездә начаррак яши.

— Сездә, Советлар илендә бу мәсьәлә ничек тора?— дип кызыксындылар миннән.

— Әйе, бездә дә андый күренеш күзәтелә. Минем гыйльми хезмәткәрләрем институтта айга 140—200 сум акча алалар, ә ил буенча уртача эш хакы 240 сумга җитә. Автобуслар йөртүче шоферлар исә Мәскәүдә 600—700 сум алалар.

Илдар Агиш Америка университетын тәмамлаган. Аңа 40 яшь, ул үсеп килүче түрә: Нью-Йорк шәһәренең автобус хәрәкәте һәм метрополитен идарәсе бүлеге начальнигы. Мин анда булган көннәрдә ул идарәнең киләсе елдагы бюджеты өчен кайгыра иде. Бик күп эшли, барысына да өлгерергә кирәк, юкса компания сиңа алмашны тиз таба... Мин аңардан хезмәте өчен күпме алуы хакында сорадым. Америкада бу турыда сөйләшү гадәткә кермәгән: кем күпме эшли, шул чаклы ала.

Илдарның җәмәгате Нәркис тә университет тәмамлаган, ул эшмәкәрлек белән шөгыльләнү эшен өйрәнгән. Ләкин хәзер башка белгечлек буенча «Панамерикан» авиакомпаниясе агентлыгында эшли, үз һөнәре буенча эш таба алмаган. Әмма бу урынның да ул кадерен белә: эшкә иртәнге дүрттән чыгып китә, соң гына кайта. Балаларны әнисе карый.

Иртән барысы да эшкә киттеләр. Илдар бераз соңрак кайтып мине вокзалга озатып куярга вәгъдә итте. Без аның әнисе Фатыйма ханым белән икәү генә сөйләшеп утырдык. Ул миңа улы һәм киленең һәр көнне эштән арып-талчыгып кайтулары хакында зарланды.

Илдарның әнисе Фатыйма ханым үз тормышы турында бик теләп сөйләде. Ул универмагта 20 ел сатучы булып эшләгән. Хәзер аңа компания ай саен 1000 доллор пенсия түли.

— Бу акчалар җитәме соң?— дип сорыйм мин. АКШтагы тормыш дәрәҗәсен якынча чамалап.

Әгәр үз йортын булса, пенсия җитә. Ә ике-өч бүлмәле уртача фатир тоту өчен Нью-Йоркта айга 600 дән алып мең долларга кадәр

акча түләргә кирәк.

«Иртә торган тешен казый, соң торган башын кашый». Шуңа күрә америкалылар иртә торып эшкә чабалар, һәм табигый, яхшы яшиләр. Нәкъ менә безнең дәүләт хезмәт ияләренә хөкүмәт сезне тәэмин итәр, дәүләт сезгә анысын бирер, монысын бирер дип (һәм бирде дә!), булдыксыз, ялкау халыкка да чиксез хокуклар биреп, аларда читтән килгән ярдәмгә исәп тоту психологиясе тәрбияләде. Эшләгән эше булмаса да «хакым бар» дигән сүзләр гел ишетелеп торды. Ә бу «хак» аңа матди яктан кем тәэмин итәр, анысын үзе генә белә. Хәзер икътисад базар шартларына күчерелә башлады. Базар тәртипләре кергәч кайберәүләр муллык безгә күктән явар дип өметләнәләр. Ә базар мөнәсәбәте үзе генә беркемне дә туйдырмаячак: базар — яхшы сыйфатлы товар дигән сүз, товарларны кешеләр ясый. Безнең кешеләрнең квалификация дәрәҗәсе шундый түбән, ә күктән бәхет төшүенә бары сабыйлар гына ышанырга мөмкин.

Уртача алганда илебездә эшче-белгечләрнең квалификация дәрәҗәсе хезмәт катлаулыгы таләпләре югарылыгыннан бер баскычка түбәнрәк. Бу ни дигән сүз? Экономикада бөтенләй надан булган кешеләр өчен — бу буш сүзләр. Ә Көнбатышта, әгәр эшчеләрнең квалификация дәрәҗәсе хезмәт катлаулыгы белән чагыштырганда 0,4 процентка ким була икән, андый предприятие табышка эшләми, бөлә һәм ахыр чиктә эшче-хезмәткәр халкы эшсез кала. Кибет киштәләре товарлардан сыгылып торсын өчен кирәк булган көч-куәтне без кайдан алырбыз соң? АКШтагы кешеләрнең производстводагы эше һәм хезмәт хакы, теге яки бу системаның өстенлеге хакындагы сүзләрне тыңлаганда минем башта шундый фикерләр бөтерелде.

Американың байлыгы, куәте — аның гражданнары кулында, квалификация дәрәҗәсенең югарылыгында. Фәндә, идарәдә,

производствода, хезмәт күрсәтү өлкәсендә — һәркайда да югары квалификацияле, үз профессияләрен яратып сайлап алган компетентлы кешеләр эшли. Белем дәрәҗәсе илдә бик югары: халыкның 43 проценты югары белемгә ия! Безнең хәлебез мөшкел: Татарстанда мең кешегә югары белемле 76 рус һәм нибары 42 татар бар!

Америкада эшче белгеч һәм хезмәткәрләрне кайда һәм ничек әзерлиләр соң? Әлбәттә, күпсанлы университетларда һәм коммуналь колледжларда. Колледж нәрсә соң ул? Ул профессиональ уку йорты. Анда хезмәткәрләрне, эшчеләрне, эшмәкәрләрне өйрәтәләр, анда ихтыяҗга карап теләсә нинди белем бирәләр. Әгәр сез кытай телен өйрәнергә, яки кулинария сәнгатен үзләштерергә, автобус, автомобиль, мотоцикл йөртү хокукын алырга телисез икән, рәхим итегез. Шулай итеп, АКШның коммуналь (община) колледжлары токарьлар белән слесарьларны гына әзерләми. Ул теге яки бу завод, район, шәһәрнең зур ихтыяҗларын канәгатьләндерә алган күп профильле уку йорты.

Мәсәлән, Сент-Луис шәһәрендәге колледжда 80 меңнән артык олы һәм кече яшьтәге кеше белем ала, шул җөмләдән, 22 мең студент көндез укый, ә 60 мең кеше исә ике көннән алып ике елга чаклы вакытка исәпләнелгән төрле формадагы белем алуга омтыла. Аларның күбесе — 12 еллы гомуми урта белемле халык. Америкада шулай, кем яхшы эшли, шул әйбәт яши. Андагы фәнни-техник прогресс, товарларның һәм тормышның сыйфаты — болар барысы да эшләүчеләрнең югары квалификациясе нәтиҗәсе. Шуңа күрә анда һәм урта, һәм югары профессиональ белем алуга зур әһәмият бирәләр.

Миңа колледж халыкка профессиональ белем бирүнең зур мөмкинлегенә ия булуы, яхшы әзерлекле зыялы укытучылары белән бик ошады. Укытучыларның кайберләре фән докторы дәрәҗәсенә

ия. Андый колледжлар Казанда, Татарстанда ачылса да начар булмас иде. Андый тәкъдим белән хөкүмәтебезгә кергән идем. Безне базар үзе түгел, ә хезмәт ияләренең профессиональ осталыгы ашатыр, эшкә өйрәтер. Безгә базар түгел, бәлки сатып алучының холык-табигатен, психологиясен яхшы белгән итагатьле, әдәпле-тәрбияле кешеләр тормыш-көнкүрештә хезмәт күрсәтер.

Нәкъ менә океан артында яшәүче кешеләрнең характеры, гадәтләре аларның үзара мөнәсәбәтләре хакында бер-ике сүз әйтәсе килә. Сез безнең урамнарда, трамвайда, чиратларда, хәтта өйдә булган сөйләшүләргә колак салганыгыз бармы? Кешеләрнең күбесе сөйләшмиләр ич, бәлки кычкырышалар, әйтерсең лә тирә-юньдә саңгырау кешеләр яши. Бу акыру-бакыруларда шул хәтле явызлык, тупаслык ки, хәтта тыныч табигатьле кеше дә борчыла, нервлана, ачулана башлый. Гүя кырыс халык, салкын караш чиратларда, трамвайларда, автобусларда, базарда үзең кебекләр белән гел көрәшеп, тарткалашып яшәү өчен махсус рәвештә тәрбияләнгән.

Боларның барысын да мин америкалыларның бер-берсе белән аралашулары вакытында күрмәдем, сизмәдем. Гаҗәеп йомшак, салмак тавыш. Хәтта начальник үз кул астында эшләүчене берәр гөнаһы өчен орышса да, һич тавышын күтәрмәс. Әңгәмәдәшенә мөрәҗәгать итүгә аның йөзендә дустанә елмаю чагыла. Әгәр син аңа ун тапкыр мөрәҗәгать итсәң, сиңа ул ун мәртәбә елмаячак һәм сабыр тавыш белән җавап бирәчәк. Ясалма түгел, ихлас рәвештә елмаячак. Күрәсең, аларны шуңа балачактан үк өйрәткәннәрдер, тәрбияләгәннәрдер. Елмаю шунда ук дустанә мөнәсәбәткә чакыра, беренче мәртәбә очрашу вакытында була торган уңайсызлану хисен бетерә. Аралашкан кешенең сине күптән яхшы яктан белә һәм ул сиңа ярдәм күрсәтергә әзер дигән фикер тудыра. Яхшылык теләү, нинди дә булса игелек эшләргә әзер тору сыйфаты америкалыны совет кешесеннән аерып тора, гомумән, америкалыларны бездән,

кечкенә генә сәбәп өчен дә низаг куптарырга әзер торган кешеләрдән, әдәп, тәүфикъ нык аера.

Шушы игелеклелек сыйфаты биредә яшәүче татарларга да хас. Аларның күбесе бездән, планнар, йөкләмәләр, бүлекләр, чиратлар өчен канга батышып көрәшкән татарлардан, шундый ук күркәм яклары белән дә нык аерылалар инде. Тормышыбызны уннарча ел көйли алмау безнең психикага тәэсир итте, безнең яшәү рәвешебез дөньяга карашларыбызга нигез салды, гадәтләребезне, характерларыбызны, зәвыкларыбызны формалаштырды. Халкыбызның шактый өлеше диярлек, «ташучы»лар дип оялып исемләнгән каракларга һәм вак каракларга әйләнде. Дәүләткә һәм аның куәтле атрибутларына каршы чыгарга берәү дә кыймады, хәтта каршы сүз әйтергә дә җөрьәт итмәде.

Америкада ачулы кешеләр юк дип әйтү бик үк дөрес булмас булуын. Анда яман итеп сүгенә дә беләләр. Ләкин сез боларның берсен дә урманда, җәмәгать урыннарында ишетмәссез. Бары сирәк очрый торган хулиганнар гына кылырга мөмкин ямьсез гамәлләрне. Бездә исә — хәтта университетлар коридорларында да "зыялы", интеллигент адәмнәр сүзләрен тәмсезлиләр, кайчакта ачусыз, болай гына, «пар чыгару» өчен генә әшәке сүгенеп алалар...

... Әле «Ватан» җәмгыятеннән Америкага барганчы ук күп кенә татарларга Казанга сабантуйга килергә чакыру хатлары җибәрелгән иде. Телефон аша сөйләшкәндә мин чакыруның килеп җитүе белән кызыксындым. Чакырылган кешеләрнең күбесе килүдән баш тарттылар, ерак, вакыт юк, чакыруны соң алдык, диделәр. Чыннан да, Америкадан шул елның июнь аенда сабан туе бәйрәменә Казанга бары Надыйр Дәүләт белән Равил Сәлихмәт кенә килделәр.

— Татарлар арасында бай эшмәкәрләр күпме соң? — дип сорадым мин Агиш әфәнде өендә өстәлдәш күршемнән.

— Гомумән, Америкада яшәүче татарлар бик бай түгел.

Аларның күпчелеге бәләкәй бизнеста — сәүдә, контораларда хезмәткәрләр булып эшлиләр. Биредәге үлчәү буенча байлар безнең арада юк. Ләкин безнең халык тырыш, галимнәр һәм эшмәкәрләр үз икмәкләрен туйганчы ашыйлар. Татарлар арасында эшсезләр юк бугай, — дип аңлатты миңа Ирфан.

— Ә рухи тормыш мәсьәләсендә ничек соң, — дип сорадым мин өй хуҗаларыннан. — Чит илләрдә яшәүчеләр Ватаннарын бик сагыналар дип ишеттем.

— Ватанны сагыну хисе бар-барын, ләкин ул шулай ук чагыштырмача төшенчә, Америкада яшәүче татарлар арасында Россиядә туып-үскән кеше бик аз. Өлкән буын нигездә Кытайда, Харбин шәһәрендә туган. Анда алар татар башлангыч мәктәпләрендә укыганнар. Ата-аналары, ыру-кардәшләре аларга ерак Ватаннары — авыл-шәһәрләре хакында сөйләгәннәр. Урта буын нигездә Төркиядә һәм Америкада туган, Россияне, Татарстанны алар риваять рәвешендә ишетелгән сөйләүләр аша гына беләләр.

— Шулай булса да туган телгә тартылу көчле, менә сез дә әйбәт кенә сөйләшәсез, бер дә онытмагансыз, — дидем.

2.10. Мөстәкыйльлеккә юл

(Соц. Татарстан, 1990, 22 август)

Хезмәт ияләренең борчылуы урынлы. Милли аң нык уянды. Барлык милләтләр иреккә һәм азатлыкка омтыла. Автономияле республикалар, Грузия ССРдан чыгу өчен көрәшәләр. Балтик буенда өч республика ССР Союзыннан читкә омтыла.

Дөрес, КПСС Үзәк Комитеты узган ел үзенең сентябрь пленумында милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсен тикшереп, аны берникадәр йомшартырга омтылды, яшәп килгән гаделсезлекләрне

танып, конфликтларны хәл итү юлларын билгеләде, милләтара мөнәсәбәтләр буенча үзенең платформасын эшләде. Бу документта: «Милләтләрнең үзбилгеләнү формаларының төрле булуы тормыш чынбарлыгын чагылдыра, чөнки Союз төзелгән вакытта халыклар социаль-экономик үсешенең төрле дәрәҗәсендә торганнар, кайсылары әле милли консолидация этапларын да үтмәгән яки үз дәүләтчелеген булдырырга әзер дә түгел иде (ассызыклау минеке М.М.)».

Мине шушы дүрт принцип уйландыра. Биредә фәнни яктан объектив булмау һәм теоретик сайлык күзгә ташлана. Дөнья картасына күз салсак, бу принципларны кире кагу кыен булмас. Мәсәлән, үсешнең төрле дәрәҗәдә булуына тукталыйк. Африкадагы колониаль халыкларның бәйсезлеккә ирешүенә аларның төрле үсеш дәрәҗәсе һич тә комачауламады. Халык саны турында әйтәсе дә юк: 1 миллион кешеле Лесото да, 80 миллионлы күпмилләтле Нигерия дә бертигез азатлык алды. 20–50 мең генә халкы булган яңа илләр дә бар. Милли туплану, консолидация процессы нәкъ менә бәйсезлек алганнан соң көчәя түгелме? Дәүләтчелек мәсьәләсенә килгәндә РСФСР территориясендә яшәүче кайсы гына халыкның заманында үз дәүләте булмады икән? Татар башкорт халыклары 1917 –1920 елларда бәйсезлек, үз дәүләтчелеген булдыру өчен кабат җитди көрәшләр алып бардылар. Ул чорда берәүләргә союздаш, икенчеләренә автономияле республика статусы бирү һич тә халыкның экономик яки политик үсеш дәрәҗәсенә бәйләнмәгән булуын да мисаллар ачык күрсәтә. Әйтик, кыргызлар егерменче еллар башында феодаль үсеш стадиясендә була (алар капитализмны читләтеп үтеп социализмга керделәр), халкы да күп санлы түгел иде. Әмма бу халык союздаш республика статусы алды. Ә аннан югарырак үсеш дәрәҗәсендәгеләр автономия статусы белән чикләнде.

Россиядәге иң күп санлы халыклардан татарлар узган гасыр азагында ук капиталистик үсеш юлына бастылар, ә халык саны ягыннан 1920 елда илдә дүртенче урында иделәр. Кыскасы, милләт булып бик күптән, электән формалашкан идек. Ул чорда дәүләтне идарә итәрлек зыялыларыбыз булуы да мәгълүм. Шулай да татарларга автономия статусы гына бирелде. Ни өчен? Бәлки, монда буйсынмас татар халкына элекке рус колонизаторлары урнаштырган караш роль уйнагандыр. Совет власте елларында ул караш үзгәртелмәде генә түгел, көчәйтелде дә түгелме соң? Россия халыклары аңына тарих дәреслекләре аша уннарча еллар буена коточкыч «татар изүе» дигән төшенчә сеңдерелде. Чынлыкта, күренекле тарихчы Л.Н.Гумилев исбатлаганча, бернинди изү булмаган. Монгол-татар урдасы рус князьләренә керемнәрнең 10 процентыннан да артмаган күләмдә салым түләткән. Моның кадәрне безнең һәркайсыбыз бүген дә дәүләткә бирә.

Хәтта шушы түләтүдә дә безнең Идел буенда яшәүче татарларның бернинди өлеше юк. Аларның бабалары идел буе болгарлары үзләре монгол-татарларның беренче һөҗүмнәрен кайтаручылар, ә XIII гасырда (1236 елда) Алтын Урда Болгар ханлыгын тармар итеп, җирен һәм халкын үзенә куша. XV гасырда безнең бабалар, Алтын Урдадан котылып, үзләренең Казан ханлыгын төзегәннәр. Бу ханлык Мәскәү патшалыгы белән тату яши. Ләкин рус патшалары Иделгә, Уралга, Себергә кызыга, үзләренә анда юл ачу өчен Казан ханлыгына һөҗүмнәрен башлый. 1552 елда, Казан ханлыгын тар-мар итеп, үз максатына ирешә. Бу хәл татар халкына күп мәхрүмлекләр китерде. Шулай да безнең бабалар, үзенең тарихына, язмышына буйсынып, руслар белән күп гасырлар буена тату, дус яшәделәр. Тик еш кына рус шовинистларының татарга явыз көч итеп каравын тоеп килделәр. Бу карашның әле дә бетеп җитмәвен әйтергә кирәк. Татар халкының

моңа күңеле рәнҗи. Аның руслар белән тигез хокуклы буласы килә. Алар белән тиңнәр рәвешендә эш итәсе килә.

Ләкин моннан 70 ел элек төзелгән Татарстан Совет Автономияле Республикасы татарларның хокукларын русларныкы һәм кайбер башка халыкларныкы белән тигезләмәде, татар халкына мөстәкыйльлек тәэмин итмәде, аны өченче сортлы халык дәрәҗәсендә калдырды. Автономия шартларында республиканың «экономикасы һәм мәдәнияты чәчәк ата» дисәләр дә, без моның киресенчә булуын күрдек. Кимсетелү рухында яшәп, балигъ булган яшь буынның демократияләштерү чорында ирек даулап баш күтәрүе бер дә гаҗәп түгел.

Ризасызлык өчен сәбәпләр күп. Менә 1917 елгы революцияләр алдыннан татар телендә китаплар «социалистик чәчәк атуның» 70 елындагыдан күбрәк чыгарылган. Россиядә татарлар, руслардан тыш, үз телендә китап чыгаручы халыклар арасында беренче урында торганнар. Хәзер исә балаларыбызга ана телендә тәкъдим итәрлек рәтле китапларыбыз юк. Өстәвенә татарча укучылар да бетеп бара, чөнки илдә татар балаларының нибары 7 проценты үз ана телендә белем ала. Хәзерге үзгәртеп корулар чорында да Казанда бөтен мәгариф мәсьәләләрен шәһәр мәгариф бүлеге мөдире Ю.Прохоров җитәкчелегендә руслар хәл итә. Ул исә: «Татар мәктәпләрен һәм бакчаларын руслар түгел, татарлар үзләре яптылар», дип, үзен акламакчы булып, безгә үк яла ягып маташа. Минем татар милли мәдәниятен үстерүгә күпме акча тотылуы хакында беркайчан да ишеткәнем юк. Биш миллион халкы булган Финляндия моңа 6 миллиард доллар тота. Советлар Союзы исә 300 миллионга якын кешесе булуга карамастан, мәдәнияткә барлыгы 6 миллиард сум гына акча тота да, шуның белән вәссәлам. Аның күп өлешен исә Мәскәү, Ленинград, Киев кебек мәдәни үзәкләре «йота», җиде миллионлы халкы мәдәниятенә моннан нинди генә өлеш кала икән?

Тиеннәр генә! Анысы бер хәл. Өстәвенә татар театрында нинди әсәрләр куярга кирәклеген дә Мәскәү билгели. Татар драма театры репертуарының Мәскәү түрәләре тарафыннан раслануы шуның бер чагылышы. Аларның милли мәдәнияткә һәм сәнгатькә битараф карашы нәтиҗәсендә татар опера һәм балет театрында татарча спектакльләр юк дәрәҗәдә аз куела. Ул инде рус театрына әйләнеп бара.

Татар халкы, мондый хәл тагын дәвам итмәсен өчен, тигез хокуклыкка, суверенитетка омтыла. Татарларның үзбилгеләнү, үзидарә хокукына табигый, тарихи хакы бар. Татар халкының күптән күп өлешен читтә калдырып төзелгән шушы Татарстан чикләрендә булса да, республикага тулы мөстәкыйльлек бирүне таләп итә. Үз җиребезгә үзебез хуҗа булып, халкыбызның тормыш хәлен дә, мәдәниятен да үзебезгә үстерү мөмкинлеге алу өчен көрәш һич тә гаеп эш түгел. Бу Татарстанны Россиядән аеруга һәм бергә яшәп килгән русларны кимсетүгә һич тә китермәячәк. Ул тиешле килешү нигезендә сәяси өлкәдә дә, экономик һәм мәдәни өлкәдә дә Россия белән даими хезмәттәшлек итәчәк. Башкача мөмкин дә түгел. Без күптән инде, Г.Тукай әйтмешли, Россия белән бер җепкә теркәлгән.

Ниһаять, ничә гасырлардан килгән өметне гамәлгә ашыру минутлары килеп җитте. Б.Н.Ельцин Татарстанда булганда Татарстанның союздаш республика статусы алуы хакында сүз чыккач: «Татарстан үзе нинди форманы сайласа, шундыйны расларбыз», диде.

Әгәр дә Литва яки Эстония үзен мөстәкыйль җөмһүрият дип игълан итә икән, нигә әле Татарстан Югары Советы бу мөмкинлектән файдаланмаска тиеш? 27 августта безнең парламентарийлар да бу хокуктан файдаланырлар дип ышанабыз, без моны таләп итәбез.

Тик кайберәүләр һаман да, Н.И.Травкин кебек, «бүленмәс Россия» ягында. Россия составында, аңа буйсынып яшәүнең нәтиҗәләре хакында төптән уйламыйлар. Үзебез тапкан малны Мәскәү бюрократлары бүлеп утыра: үзләренә бер сум, безгә 5 тиен. Инде бернәрсәсез хәерче булып калдык бит. Үзебездә нефть чишмәсе ачуга карамастан, хәтта керосиныбыз да юк. Безнең нефтьне эшкәртүче предприятиеләрне метрополиядә Рязаньда һәм Горькийда төзеделәр. Без хәзер самолетларыбызга керосинны әнә шуннан ташырга мәҗбүрбез. Урамнарыбыз машина йөрерлек түгел, чокыр-чакыр, ямаулык өстенә ямаулык, аларны асфальтларга битум юк, имеш. Битум заводлары да читтә. Балаларыбызга талон белән дә җиткерә алмаган хәлдә, республикадан читкә 40 мең тонна ит озатабыз. Мондый мисаллар санап бетергесез.

Минемчә, безнең күпмилләтле илебез дә Европа халыклары үткән тарихи этапларны үтәр, ахрысы. Барлык милләтләр дә, башта мөстәкыйльлек алып, аннары яңа шартларда, яңа нигездә берләшә алалар.

Европадагы хәлләрне искә төшерик. Европа халыклары «милли квартираларына» таралып урнашканчы күп гасырлар буенча милли һәм дини сугышлар кичерделәр (бездә генә була күрмәсен!) Хәзер тынычландылар кебек. Франция, Испания, Италия кебек зур дәүләтләр генә түгел, Ирландия (территориясе һәм халкы Татарстанныкы кадәр), Швейцария, Австрия, Венгрия һәм нибары 350 мең кешеле Люксембург кебек кечкенә илләр дә тулы суверенитетка ия булды. Алар күптән мөстәкыйль булып, бер-берсеннән аерым яшиләр, матди, рухи һәм иҗтимагый яктан үсәләр.

Ләкин экономик мөнәсәбәтләр һәм социаль үсеш закончалыклары аларны яңа тип дәүләткә берләштерергә мәҗбүр итте. Бу берләшү элек Европа экономик советы дәрәҗәсендә булса, хәзер бердәм Европарламентка әверелде. Экономик һәм социаль

үсешнең закончалыгы бу. Бүген көчләү, кан кою юлы белән түгел, экономик үсеш һәм мәдәни прогресс нәтиҗәсендә европалылар социаль өлкәдә шундый югары ноктага күтәрелделәр.

Мондый прогресс булмаганда хәтта тугандаш халыклар да, язмыш бүлгәләгән бер үк милләт халыклары да берләшә алмый. Гарәпләр моңа ачык мисал. Касабланкадан Багдадка чаклы территориядә яшәүчеләрнең телләре, диннәре бер, мәдәниятләре, гореф-гадәтләре уртак. Әмма Мисыр, Сүрия, Тунис, Алжир, Ливияләрнең берләшергә омтылышы барып чыкмады. Хәзер Төньяк һәм Көньяк Ямән берләшергә маташа, нәтиҗәсен киләчәк күрсәтер.

Сүз уңаеннан депутат Морат Сираҗинга да җавап бирү кирәк дип саныйм. Ул «Вечерняя Казань», «Советская Татария» газеталарында Татарстанның Россиядән чыгуына каршы килә. Янәсе, республикада он да, балык консервлары да читтән керә. Шул исәптән безгә ирек кирәк түгел?! Имеш, кирпеч һәм керамика читтән килә, шуңа күрә Россия бюрократларыннан аерылып калмыйк! Минем карашка, ул тарихи әһәмиятле шушы проблемага сәяси яктан тар, экономик күзлектән берьяклы гына якын килә. Дәлилләре дә ышандырырлык түгел. Шул ук газетада депутатлардан Р.Зарифуллин, З.Сафиуллин, Н.Мансуровлар, Татарстанның экономикасына тирән анализ ясап, эшнең кая барганын күрсәттеләр.

Әйе, Россия безнең зур Ватаныбыз. Без, татарлар, үзебезне һәрвакыт россиялеләр итеп хис иттек. Рус патшалары Төркиягә каршы сугышлар алып барганда, Россия кешеләре буларак, без дин һәм кан кардәшләре булган төрекләр белән дә сугыштык.

Ләкин һәркемнең кечкенә Ватаны да булуын әйтергә кирәк. Безнең өчен ул туган Татарстаныбыз. Без аның уллары һәм кызлары. Без аны яратырга, төзергә, үстерергә тиешбез. Безне элек дөньякүләм революция рухында тәрбияләделәр, үзебезнең кечкенә Ватаныбыздан читләшергә чакырдылар, «урынчылык», имеш. Безне

Алласыз, йортсыз, имансыз, җирсез күчмә халык хәленә калдырдылар. Инде ул заманнар үтте шикелле.

М.Сираҗин тагын бер мәсьәлә - референдум мәсьәләсен күтәрә. Монысы да безне гажәпләндерә. Милләтнең үзбилгеләнү, үзидарә хокукын кем якларга тиеш? Шушы милләт вәкилләреннән кала тагын кемнең эше бар анда? Суверенлы Татарстан башка милләт кешеләренең мәнфәгатьләренә кагылмагач, нигә минем язмышымны алар хәл итәргә тиеш? Бусы бер. Икенчесе, Татарстанда үткән референдум ничек итеп башка төбәкләрдә яшәүче 75 процент татар халкының фикерен чагылдырыр икән? Моны шуның өчен әйтәм: илнең төрле төбәкләрендә, хәтта чит илләрдә яшәүче татарлар да Татарстанны үзләренең Ватаны дип хис итәләр, мәдәни, рухи кыйблалары нәкъ менә аңа юнәлгән.

2.11. Мәгълүмати көрәштә мәдәнилек

(Казан утлары)

XIII—XVI гасырларда татарлар.

Тарихи экскурслар безгә һич тә ата-бабаларыбызның мәдәниятен бөек итеп күрсәтү өчен кирәкми, алар безгә татарлар «кыргый» булган, ул чор рус мәдәниятенә алар бернәрсә дә бирмәгән, дигән тезисларны кире кагу өчен кирәк.

Алтын Урда дәүләте төрле сәяси һәм икътисади сәбәпләр аркасында таркалып, берничә мөстәкыйль (суверен) дәүләтләргә — Казан ханлыгы, Кырым, Әстерхан, Нугай, Себер һәм башка ханлыклар булып калган.

Казан ханлыгы нинди булган соң? Ул шәрекъ тибындагы күпмилләтле феодаль дәүләт булган, икътисады алга киткән, сугышчан кораллы көчләре дә булган. Атаклы тарихчы академик И. Р. Таһиров Казан ханлыгы җитәрлек өйрәнелмәгән, бозып күрсәтелә

дип саный. Ул, янәсе, артта калган кыргый, комсыз һәм мәрхәмәтсез баскынчылар дәүләте булган. Ә ул чынлыкта Урта гасырлар дәүләтләре арасында алга киткән дәүләт булып, үзен-үзе тәэмин итеп торган. «Атаклы Казан патшалыгы, - дип яза революциягә кадәр Иван Михайлов, — русларга гына билгеле булып калмаган, ул дөньяның башка кыйтгаларында да танылган булган, чит ил тарихчылары дөньяда булып үткән башка хәлләр турында язганда әлеге патшалыктагы вакыйгаларны да искә ала торган булганнар».

Поляк тарихчысы Александр Гвагнин болай дип язып калдырган: «Казан татарлары башка татарлардан әдәплелекләре, йортлар төзү осталыгы һәм игенчелек белән дә аерылып торган. Алар бик яхшы төзелгән йортларда яшиләр, россияннар, фарсилар һәм башка халыклар белән товарлар алмашып сәүдә итәләр, аларның үз патшалары булган, алар В. К. Иоанн Васильевич һәм аның улы Василий Иоаннович патшалык иткән чорларга кадәр беркемгә дә кол булмаганнар» (И. Таһиров). А. Курбский Казан ханлыгында төрле милләт халыклары тигез хокуклы булганнар, ул «болгар теленнән башка патшалыкта тагын биш телдә — мордва, чуваш, чирмеш, вотяк, башкорт телендә сөйләшкәннәр» дип билгеләп үтә. Бу хәл ханлыкта төрле халыкларның үзара дус-тату яшәүләре турында сөйли.

Ул чордагы Болгар-Казан ханлыгының сәнгать, мәдәниятенең көнбатыш Европа һәм шулай ук шәрекъ илләре белән бер дәрәҗәдә үскәнлеге күренә. Казан һәм болгар-татар культурасы шул мәдәниятләр чигендә булуы аркасында ул заманнарда Европа мәдәниятенә дә шактый зур йогынты ясаган. Шуңа күрә дә А. Курбский үзенең «Казанны яулап алу турында бәян»ендә Казан болгарларының бөек һәм көчле измаил токымы булуларын, шуның белән халыкның борынгылыгын да искәртә, «кайчандыр бөтен дөнья кан калтырап торган алар алдында» дип яза ул. (Ф. Салихова).

1882 елны басылып чыккан В. Рогозинның «Волга» дигән китабында Идел буе халыклары этнографиясенә фәнни анализ бирелә. Халыкларның уңай сыйфатлары аерып күрсәтелә һәм, кушылган очракта, рус халкына да уңай йогынты ясарлар иде, диелә. «Казан татарлары яхшы тән төзелешле, алар матурлар. Үзләренең тән төзелеше һәм акыл сәләте буенча аларны затлы, зәвекъле халыклар исәбенә кертәләр. Тарихчылар татарларның ягымлы сөйләшүчән-килешүчән холыклы, матур мөгамәләләре һәм гаҗәп киң күңелле булулары турында язалар. Шул ук вакытта абруй-дәрәҗәләрен дә саклый беләләр. Алар горур кыяфәтле, якты карашлылар. Һәрвакыт горур-бәйсезлекләрен иркен-ирекле елмаюлары белән күрсәтәләр. Бу аңлашыла да, чөнки алар эчми, Мөхәммәт өммәте кануннары белән яшиләр» (Ф. Салихова).

Димәк, Казан ханлыгында, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен хәзер язылган дәреслек авторлары «кыргый татарлар» дип күрә торып ялганлыйлар, алар россияле татарларны мыскыллыйлар, татарларның милли горурлыгын мәсхәрәлиләр. Көнбатышта мәдәниятләрнең үзара багланышларын әллә шулай аңлыйлармы?

Рус дәүләтенең мәдәнияте хакында

Киев Русенең мәдәнияте турында күп язылган. Рус халкының үз этник мәдәниятен үстерү өчен тырышуы бик табигый, ул аны башка халыклар мәдәниятеннән ала-ала да үстергән. Бүген бу бөек халыкның бөек мәдәнияте бар. Ләкин күп кенә тарихчылар Русьның үткәненә Кремльнең алтынланган сарайлары һәм бүгенге рус мәдәнияте аша карыйлар. Ул мәдәният көнбатыш Европа мәдәниятен «куып җитәргә» бик тырыша, әмма һич кенә куып җитә алмый. Шуңа күрә гаепле итеп әлеге дә баягы «татар-монгол иго»сын саныйлар...

Россия нинди булган? Төрле чорда төрлечә. Ул һәрвакыт зур һәм ярлы, шуның өстенә бик сугышучан дәүләт булган. Тарихчы К.

Д. Кавелин язганча: «Россия империясенең барлыкка килүен, аякка басуын идеаллаштырып кararга ярамый. Урта Азияне яулап алу, Ермакның Себер ханлыгына походы, Амур буйларындагы тыныч халыкны талап йөргән Хабаров, камчадалларга карата бик күп явызлыклар кылганы өчен үз казаклары тарафыннан үтерелгән Атласов...» (К. Д. Кавелин. Наш умственный строй.—М. Правда, 1989, стр. 69).

Күренекле галимнәр Карамзин, Костомаров, Платоновлар Россиянең бөек үткәне, аның мәдәнияте турында гына язып калмыйлар, алар ул заманнардагы кешеләрнең гореф-гадәтләре турында, патшалар, боярлар, воеводаларның рәхим-шәфкатьсез эш-гамәлләре турында да сөйлиләр. Иван IV (XVI гасыр) чорындагы опричникларның явызлыгы, яулап алу сугышлары турында, үз улын үтергән патша турында укыганда чәчләр үрә тора. Ил үзе ниндирәк булган? Иван IV чорында Россиянең мәйданы 2800 мең кв. км., халкы 7-8 миллион булган. Күпчелек халык чиркәүле авылларда (село) һәм чиркәүсез (мәктәпсез) авылларда (деревни) яшәгәннәр. «Әй, син, деревня!»—дигән мыскыллы гыйбарә шул заманнардан калган. Шәһәр халкының саны 2% тан артмаган (һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр). Ел саен төбенә кадәр диярлек янып торган агач Мәскәүдә — 100 мең чамасы, Новгородта — 30 мең, Можайск, Серпухов, Коломна ише вак шәһәрләрдә 3 меңнән 8 меңгә хәтле кеше яшәгән (Казанцев).

Хәзерге тарихчылар әле күптән түгел генә (XX гасырның утызынчы елларына кадәр диярлек) Россия халкының төп өлеше авылларда салам түбәле агач өйләрдә яшәгәнлеген, агач савытлардан агач кашыклар белән ашаганлыкларын, өйдә сугылган күлмәк-ыштаннан, чабатадан йөргәнлекләрен бөтенләй онытканнар... Авыл халкы шуңа күрә дә «лаптем щи хлебали» (чабата белән кәбестә шулпасы чөмерә идек) дип шаяртканнар.

Совет чорында шәһәрләшү авыл халкының 80%ын шәһәр кешесе иткән...

Ә шәһәрләргә килеп тулган бу халык ничегрәк яшәгән соң? Әдәбиятта астыртын хәйлә-мәкер белән тулган боярлар, кенәзләр, дини руханиларның «татлы» тормышы күбрәк сурәтләнә. Шәһәр ярлы, шыгрым тулы кысанлык, караклык һәм даими янгыннар эчендә яшәгән. «Комсызлык, акчага хирыслык, ач күзлелек, эчкечелек, бозыклык һәм наданлык—руханиларның төп сыйфатлары әнә шундый. Болар барысы да чиркәүгә йөрүче халыкта ризасызлык тудырган. Руханиларны тәнкыйтьләү, гомумән, чиркәүләр кирәкмәс, дигән фикергә китергән» (Казанцев). Шул заманнардан Россиядә чиркәү кагыйдәләренә каршы хәрәкәт, динсезлек башланып киткән.

Шулай булгач, Россиялеләр арасында бүгенге әхлаксызлык кайдан килеп чыккан соң? Тарих дәреслекләре язучы авторларның кайберләре турыдан-туры моны татарлар йогынтысы дип тамгалыйлар. Шулаймы икән? Буыннардан-буыннарга күчеп килә торган генетик милли гореф-гадәтләр түгелме икән ул? Күренекле тарихчылар нәкъ шуны раслыйлар да бит. Н.К. Карамзинның бик үткен әйткән сүзләре бар: «XVII гасыр Россия өчен тәмуг уенына тиң хакимлек ярату, коточкыч ачлык, һәркайда талаулар, йөрәкләрнең таш булып катуы, халыкның бозыклыгы белән ачыла. Болар барысы бергә дәүләтне ватып бетерүгә илтәчәк киләчәктер».

Игомы, әллә хезмәттәшлекме?

«Татар-монгол игосы» дигән гыйбарә йөз еллар буена тарих дәреслекләре битләреннән төшми йөри. Яшьләрнең аңына гасырлар дәвамында «дошман татар» образы сеңдерелә. Бу бигрәк тә татар дәүләтләрен — Казанны, Әстерханны, Себерне, Кырымны яулап алу чорларында ачык чагыла. Россия дәүләтенең барлыкка килү тарихы

һәм христиан чиркәвенең татарларны «дошман» итеп күрсәтүе Россиянең Төркия белән сугышларын идеологик яктан да дәлилләү өчен кирәк була (8 сугышның барысын да Россия башлап җибәрә). Россия сәяхәтчеләре бу төшенчәне үзләренең мәнфәгатьләре өчен һаман да файдалана торалар. Мәсьәлән, Г. Н. Селезнев, Европарламентта чыгыш ясап, Европаны татар-монгол игосыннан Русь кына коткарып калган, дип ялагайланып сөйләгән. Ләкин бит беренче һөҗүм вакытында ук татар-монголлар рус җирләре аша Польшага, Чехиягә бәреп кергәннәр, хәзер инде бу илләр, Батый хан гаскәрләренең көнбатышка баруын без генә туктатып калдык, дип раслыйлар.

Ике күрше халыкның хезмәттәшлеге дә булганмы, әллә алар «иго» йогынтысы белән даими дошманлашып торганмы? Менә тарихи тикшеренүләрдән берничә өзек: «Әле 1917 елга кадәр үк кайбер галимнәр Мәскәү дәүләтенең үсешенә монгол дәүләте зур йогынты ясаган. Икенчеләре исә монгол-татар игосы рус дәүләте тормышына тирән социаль үзгәрешләр китермәгән дип саныйлар.»

Тарихчылар сугыш хәрәкәтләре тукталгач ике арада хезмәттәшлек башланганын инкяр итә алмыйлар. «Урда белән Русь мөнәсәбәтләренә килгәндә, инде 1243 елда ук ике як өчен дә файдалы килешү төзелгән. Алтын Урдага рус кенәзләре еш барып йөргән, алар татарлардан өйләнеп хатыннар алып кайткан...» (Платонов). Менә сезгә «иго»! «Л.Н. Гумилев иго булганлыгын кире кага һәм руслар белән монгол-татарлар арасында һәр ике як өчен дә файдалы союз булган дип раслый...» (Казанцев). Тарихи фактлар да Л.Н. Гумилевның хаклы булганлыгын күрсәтә. Рус кенәзләре Алтын Урда оешкач та ханнар һәм морзалар белән дуслашкан. Мәсәлән, Александр Невский Батыйның улы Сартак белән җан дуслар—борәдар булган (монголларның бер өлеше христиан динен тоткан). Невскийның оныгы Юрий Данилович «озак еллар Урдада хан

сараенда яшәгән, Үзбәк ханның сеңлесенә өйләнгән. Юрийдан башлап рус кенәзләре Урдага йөз тоткан, ханнар һәм татар аксөякләре белән тыгыз элемтә булдырганнар, бу Русьта үз позицияләрен көчәйтү һәм кенәзлекләрен нығыту өчен эшләнгән» (Казанцев).

Европа белән элемтәләр турында

Тарихчылар татарларны, игодан тыш, Русьның Европадан артта калуына сәбәпче итеп тә гаеплиләр. Дәреслекләрдә шундый сорау да очрый: «Алтын Урда Россиянең Көнбатыш Европа белән мәдәни багланышларына һәм рус мәдәнитенең алдагы язмышына йогынты ясаганмы?» Сорау очраклы гына куелмаган, авторлар шуңа таянып татарларны гаеплиләр.

“Монголларның басып алуы һәм Алтын Урда игосы рус җирләренең Көнбатыш Европадагы алга киткән илләрдән артка калуына сәбәпләрнең берсе булган. Русьның икътисади, сәяси һәм мәдәни үсешенә гаять зур зыян китергән... Рус җирләренең мәдәни үсеш темплары бик акрынайган...» (Казанцев). Әлбәттә, монголлар һөҗүме зур зыян салган (дөрес, ул немец фашистларының хәзер сөйләнми торган һөҗүме белән чагыштырырлык та түгел). Ләкин бит татар-монголлар барып җитә алмаган гомер-гомердән рус җирләре дә булган, мәсәлән, Новгородтан башланган төньяк төбәкләре. Аларына үсеш алырга кем комачаулаган?

Ә татарлар Русьның Көнбатыштагы агрессив көчләргә каршы көрәшендә кем ягында булганнар? «Әгәр дә Литва һәм башка дошманнар белән сугышларда татар сугышчылары да катнашкан булса, XIV—XV гасырларда ул Урда ханы ярдәме түгел, ә татар патшаларының һәм башка феодалларның русларга хезмәткә кергән һәм Русь дошманнары белән шул исәптән үз кабиләләре белән дә сугышкан уллары булган» (Казанцев). Рус кенәзләренең литвалылар, поляклар, немецлар, шведлар белән һәм үзара да

туктаусыз булып торган сугышларында татарлар һәрвакыт кенәзләр яклы булган, аларга җиңү яулашкан (кара — Н. Карамзин). Урдалылар Русьның Европа белән багланышларына берничек тә кире йогынты ясый алмаган, рус кенәзләре үзләре таркау һәм көчсез булган. Икенче закончалык бар: Русьның Европадан артка калуына татарлар гаепле түгел, ә рус халкы үзе европалылардан 500 елга яшьрәк булган (Казанцев редакциясендә чыккан дәреслекнең 72 битен кара).

Россиядә колбиләүчелек булганы билгеле — ул крепостное право, феодализмның үзенчәлекле бер төре, ягъни алпавытның крепостной крестьяннарны эксплуатацияләүгә һәм җәзаларга хокуклы булуы... «Феодализмның мондый үзенә бер аерым төре буллу — татар-монгол игосы аркасында Русьның 240 ел буе Европадан чикләнгән хәлдә үсеш нәтиҗәсе» (Казанцев). Болай дип раслау дөресме? Фактлар алай сөйләми. Беренчедән, Алтын Урдада турыдан-туры колбиләүчелек булмаган (бары тик йорт коллары гына булган). Икенчедән, Россиянең көнбатыш чикләре Урда тарафыннан тикшереп торылмаган, төньяк җирләре, гомумән, ирекле булган, (шулай булгач, Урда Русьны чикләп тә тора алмаган). Әллә поляклар, шведлар, литвалылар аркылы рус кенәзләре немец шәһәрләре белән сәүдә алып бармаганмы? Шул «изоляция»-чикләүләрсез алга китү булыр идеме? Шикләнәм, чөнки Русь тормыш логикасының башка законнары белән үсеш алган, ул үз гореф-гадәтләре, үз үзенчәлекләренә таянган.

Бер халыкның икенче халыкка йогынтысы күбесенчә үз зыялылары, сәүдәдә аралашулары, товар, тел-лөгать һәм мәдәни байлыкларын, белемнәрен, осталыкларын алмашу юлы белән тормышка ашырылган. Казанцевларның 250 ел буена руслар Европа белән багланышта булмаган дип ah орулары бик тә беркатлылык. «XV гасырда,—дип язалар дәреслек авторлары, — Европада 30

университет булган, ә Россиядә шул ук вакытта белемлелек кискен түбән тәгәри, хәтта кенәзләр дә һәр очракта да белемле булмаган». Йә, татарларның моңа ни катнашы бар? Мөселманнар дөньясында университетлар Европага караганда күпкә алданрак барлыкка килгән, Европа исә X гасырда халкының белемлелек дәрәҗәсе буенча Кытайдан ун мәртәбә артта калган.

Ә тарих дәреслекләре язганча, рус кенәзләренең поляклар, литвалылар, шведлар белән туктаусыз сугышып торганлыкларын, тегеләренең рус җирләрен татарлардан да күбрәк басып алуларын һәм талауларын кая куясың? Александр Невский кебек кенәзләр Көнбатышны Урда белән ныклы союзы булганга гына, татарларның хәрби һәм сәяси ярдәме белән генә җиңә алганын тарихчылар раслый, фактлар раслый.

Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынтысы булмаганмыни?

Югарыда «башка» халыкларны түбәнсетергә теләгәндә, аның мәдәнияте юклыгы турында сөйлиләр, дип язылган иде инде. Моның бер мисалы — Алтын Урда чорындагы татар халкы мәдәниятенең рус мәдәнияте үсешенә ясаган йогынтысын инкяр итү. Ләкин бу мәсьәләдә әдәбиятта ике төрле караш яши. Беренчесе — ул йогынты булмаган. Икенчесе — булган, әмма аз булган.

Алтын Урда Русь мәдәнияте үсешенә уңай йогынтысы булганмы-юкмы? Үз-үзенә каршы килеп, культурология дәреслеге авторы Драч болай яза: «Безгә әле хәзергә андый йогынтыны эзләп табарга туры килмәде», — ди.

Россия тарихы бары тик кенәзләр һәм патшалар эшчәнлеге турында гына язылган, аннары, сугышлар, революциягә бәйләп, халык турында да яза башлаганнар, ләкин хәзергәчә бу тарих рус халкы тарихы гына, анда башка халыкларга урын юк.

Шуның өчен дә кемгәдер «эзләп табарга туры килмәгән...» Ә бәлки, Россия халыкларының тарихын белергә кирәктер, бигрәк тә аның хәзерге биләмәләрендә кайчандыр зур һәм кечкенә дәүләтләре булган, рус дәүләтенең аякка басуына йогынты ясаган һәм рус тарихының бер өлеше булган халыкларның тарихын. Дәреслекләр авторы Россиядәге рус булмаган халыклар—татарлар, чувашлар, якутлар, кареллар һәм башкаларның тарихларын белмиләр дигән тәэсир кала. XI гасыр төрки телле шагыйре Йосыф Баласагуни бик акыллы әйткән:

Табиблар дәваламас авыруын наданның,

Дәвала белем белән наданлыгын аның.

Татар мәдәниятенең үзенчәлекләре нәрсәдә?

Күрше булып яшәгән халыклар мәдәниятләренең үзара йогынтылары турында фикер йөрткәндә, без һәрвакыт бер сорауга килеп төртеләбез: татар мәдәнияте нинди булган соң? Югарыда татарларның борынгы халык булганлыгы, Бөек Болгар дәүләте мәдәнияте, аның мирасчысы Алтын Урда һәм Казан ханлыклары турында сөйләнелде. Тарихи фактлар шуны раслый: Алтын Урданың (Жучи Олусының) бик кыска башлангыч чорыннан тыш, монгол мәдәниятеннән бигрәк, анда төрки-татар мәдәнияте өстенлек иткән, ул исә һуннар, борынгы татарлар, Төрки каганат, Идел Болгары һәм дала кыпчаклары мәдәниятләрен үзенә сеңдергән. Алтын Урдада дәүләт теле төрки-татар теле булган, шул телдә рәсми эшләр, дипломатик язышулар алып барылган, әдәбият үскән.

Татар-монголлар, — Кытай мәдәнияте белән таныш халыклар, — корал йөртүне, сугышуны гына белгән кыргыйлар булганмы? Юк, әлбәттә.Тарихның һәр чоры үз дәрәҗәсендә мәдәниятле булган. Татар монгол аксөякләре, түрәләр Алтын Урданың беренче дистә елларында да, дәреслекләр авторлары язганча, кыргый булмаганнар. Шул чорның шаһиты монах Плано Карпини болай яза: «Монголлар

рәссамнарны яратканнар… Людовикның илчесе (француз короленең — М.М.) хан сараенда (ул вакытта Мәнгү хан хакимлек иткән — М.М.) венгрларны, инглизләрне һәм Париж алтын остасы Гильйомны очраткан... «Әлеге Француз татар морзаларына сарайлар салганда скульптор да, архитектор да булган. Бу мәдәниятнең аерым йогынтысын рус кенәзләре дә кичергән.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, Алтын Урда чорында Русьта беренче мәртәбә халык санын алу үткәрелгән, ям (почта) хезмәте оештырылган, төзелеш эшләре алып барылган, игенчелек үсеш алган, хәрбиләр көчәйгән һ.б. Урда һөнәрчеләренең шактый оста булулары турында күп тарихчылар яза.

Рус аксөякләре, бигрәк тә хатын-кызлары татар киемнәрен иң яхшы модалы дип санаганнар. Рус кенәзләренең кием-салымында, аяк киемнәрендә дә татар киемнәре йогынтысын күрергә мөмкин. Мәсәлән, Иван Грозный турындагы «Иван Васильевич сердится» исемле кинофильмда ул яхшы чагылдырылган.

Әхлакый мәдәнилек турында

Хәзерге россияннәргә әхлаксезлек кайдан килә? Дәреслекләр авторлары янә дә татарларны мәсхәрә итеп әхлаксезлектә, рәхимсезлектә һәм башка гөнаһларда гаеплиләр. Шулаймы соң? «... Рус кенәзләренең һич бетмәслек үзара дошманлык-низаглары халыкның барлык катламнарында, бигрәк тә югары катламнарда әхлак дәрәҗәсенең түбәнәюе нәтиҗәсе ул. Череп таркалу, бозыклык чиркәүләргә дә үтеп керә, татарлар хакимлек иткән шартларда анда исә, чиркәүнең өстенлекләренә кызыгып, күп кенә аксөякләр һәм түрәләр дә агыла. Үз мәнфәгатьләрен кайгырту, шәфкатьсезлек, икейөзлелек, хыянәт-мәкер, татарларга тәлинкә тоту һәм алардан курку, эчкечелек һәм башка гөнаһлар гади кешеләр белән чиркәү руханилары арасында киң тарала...» (Казанцев). Әгәр дә инде эчкечелек һәм бозыклык хәтта христиан руханилары арасында да

шулай таралган икән, монда татарларның ни гаебе бар, алар бит исерткеч эчемлекләр эчми, ә зина кылу үлем җәзасы белән тәмамлана. Ә үз мәнфәгатеңне кайгырту, тәлинкә тоту - ялагайлану һәм икейөзлелек рус түрәләренә XXI гасырда да хас түгелмени?

Күп авторлар ни өчендер сүгенү татарлардан кергән дип уйлыйлар. Хәтта бу хакта еш кына рус руханилары да газеталарга язып чыгалар. Ләкин бу бит чи ялган. Сүгенү сүзләре татарларда һәм башка төрки телләрдә рус телендәгедән күпкә азрак. Хәтерлим әле, Үзбәкстанда руслар үзбәкләр турында ярым шаярып: «Кара, үз телендә мыгырдый, ә русча сүгенә, үз сүзләре җитмидер,ахрысы», — диләр иде.

Сүз уңаеннан, күпләр сүгенү сүзләре рус телендә нык таралган, дип уйлыйлар һәм ялгышалар — иң күп сүгенүчеләр венгрлар. Әмма алар бер дә күршеләренә ымламыйлар: һәр халык үз телен үзе үстерә.

Татарларның эчке мәдәнилеге бик түбән дәрәҗәдә, дип расламакчы булалар. Әмма тарих башкача сөйли. Н.М.Карамзин хезмәтләрендә кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, ул монах Карпининың сүзләрен китерә. Карпини әйтә: татарлар «әшәке сүз әйтүне күрәлмиләр» (димәк, сүгенү аларга хас түгел—М.М.), «хатын-кызлар белән мөгамәләдә тыйнаклар», «уйнаш-зина гына түгел, хәтта караклык та үлем белән җәзалана»,—ди. Күргәнебезчә, татарларның төп әхлак дәрәҗәләре бүгенге русларныкыннан да югарырак булган». «... татарлар, -дип яза Карамзин,—түземлелек белән данлыклы вә үз диннәрен башкаларга такмыйлар...» (Д.М.Карамзин).

Культурология дәреслекләре авторларыннан аермалы, башка абруйлы галимнәр татарларның рус мәдәниятенә уңай йогынтысы шулай да булган, дип язалар. Мәсәлән, академик Френ: «Алтын Урданың хакимлеге азмы-күпме дәрәҗәдә безнең ватанның

язмышына, төзелешенә, карарларына, мәгарифенә, гореф-гадәтләренә һәм теленә йогынты ясарга тиештер...», — дип яза.

Тарихчы Платонов: «XIV гасырдан башлап руслар «яман» татарларның шәрекъ йолаларын, гореф-гадәтләрен күчереп ала, хәтта никахлашып туганлашалар да», — дип яза. Әйе, руслар, татарлардан гореф-гадәтләрен, йолаларын алган шикелле үк, бераз соңрак — XIX йөз башларында французлар белән дә шулай эшләгәннәр: гореф-гадәтләрен, хәтта кием-салым ишеләрен дә алганнар, никахлашканнар да. Никахлашуны, әлбәттә, беренче чиратта аксөякләр, боярлар һәм кенәз балалары башкарган. Шунысын да искә алырга кирәк, ул заманнарда, гыйшык-мәхәббәткә бик игътибар итеп тормыйча, нигездә сәяси һәм матди мәнфәгатьләр алда булган. Сәясие —ханнан кенәзлеккә ярлык-указ алу яки башка берәр кенәзгә һәм чит кешеләренә каршы көрәштә аның ярдәмен көтү. Матди мәнфәгать исә, теге йә бу җирләргә ярлык алып, үз кенәзлегендә ясакны үзе жыю хокукына ирешү һ.б. Татар морзалары һәм гаскәр башлыклары да, үз чиратларында, рус кызларына өйләнгәннәр.

Димәк, мәдәни дәрәҗәләре дә чама белән бер тирәдәрәк булганмы?! Әле җитмәсә, «бернәрсәгә дә өйрәнмәгәннәр» дип сөйләнәләр һәм язалар бит. Туганлашканнар икән, дуслашканнар да дигән сүз ич! Димәк, тарихчы Л.Н.Гумилевның «иго» булмаган, ә хезмәттәшлек булган» дигән сүзләре дөрескә чыга. Бөек Габдулла Тукаебыз да:

Рус белән гомер кичердек сайрашып,

Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып,—

дип юкка гына язмагандыр, шәт.

Соңгы елларда ярым ялган белән бер рәттән үткәннәргә азмы-күпме дөрес бәя дә бирелә башлады. «Русиядә Урда игосы, - дип, элекке гадәт буенча язалар Сахаров белән Буганов, — һичшиксез,

тискәре йогынты ясаган... Шулай да, элек тә һәм хәзерге йөзьеллыкларда да чит ил хакимлеге Русиянең үсешенә уңай тәэсир иткән, дигән фикерләр әйтелә килгән: дәүләт тәртибен ныгыту, кенәзләр арасындагы ызгыш-талаш-тарткалашны йомшарту... урдалыларның хакимлеге, барыннан да тыш, ике яклап та хуҗалык эшләрендә, тормыш-көнкүрештә, телдә һом башкаларда үзара алмашып яшәүгә китергән». (Сахаров А.Н., Буганов В.И. 1995 елны басылып чыккан дәреслектә.)

Димәк, ул хакта беркайда да диярлек сөйләнмәсә дә, «уңай йогынты булган, 250 ел хезмәттәшлек» (Л.Н.Гумилев) дәверендә Кытай, Һиндстан һәм, гомумән, Шәрекь мәдәнияте өлгеләрен кием-салымда, йорт кирәк-яракларында гына түгел, фикерләүдә дә алып килгән татарлардан руслар күп нәрсәләргә өйрәнеп калганнар…

Казан ханлыгы һәм мәдәниятләрнең үзара йогынтысы турында

Тарихи фактларны рус һәм татар мәдәниятләренең үзара йогынтысы турында дөрес мәгълүматларны без М.Г.Худяков китабыннан таба алабыз (Очерки по истории Казанского ханства, Казань, Фонд ТЯК, 1990). Алар Казан ханлыгы тарихына караса да, бераз Алтын Урдага да кагылып үтә: «Җиңелгән илгә яулап алучылар (монголлар — М.М.) тарафыннан кертелгән дәүләт төзелеше татарларга кадәр Русиядә яшәгән патриархаль тәртипләргә караганда бик нык уйланылган һәм нык тәртипле булган. Дәүләт белән идарә итү нигезләре белән руслар татарлар аша танышкан: беренче мәртәбә халык санын исәпкә алу үткәрелгән, мәҗбүри ясак, салым һәм пошлина түләтүләр башкарылулары буенча шуннан да яхшырак була алмаган.

... Болар бик күп яхшы белемле һәм тәҗрибәле түрәләр булуын таләп иткән, — биредә кытайлыларның традицияләре сизелә, — татарларга кадәр белемлелек бары тик руханилар, сәүдәгәрләр һәм

бөек кенәзләр арасында гына төсмерләнгән иске Русия моны күз алдына да китерә алмаган».

Алтын Урда таркалганнан соң, рус һәм татар мәдәниятләренең үзара йогынтысы турында бер-ике сүз белән генә Мәскәү кенәзлекләренең Казан ханлыгы арасындагы тыгыз багланышларын әйтеп үтү кирәктер. Күпмилләтле Казан ханлыгы 1432-1552 еллар дәвамында (Иван Грозный Казанны яулап алганга кадәрле) яшәп килгән. Ул да шул чордагы Мәскәү кенәзлеге кадәр мәйданны биләп торган. Рус тарихчысы М.Худяков Казан ханлыгының чәчәк ату чоры дип аның Мәскәү белән әле бәрелешеп, әле килешеп, файдалы сәүдә, дуслык һәм үзара йогынтылар белән яшәгән озак вакытлы тыныч елларын атый.

Ул чорда ханлыкта чама белән 2,5 млн. кеше яшәгән, шуларның I миллионы татарлар булган. Мәскәү кенәзлеге исә, Тверь һәм Новгород кушылганнан соң Казан ханлыгын җирләре белән дә, халык саны буенча да (5-6 млн.чамасы) шактый узып киткән.

Халыкның тарихи хәтерендә яхшы заманнар да, начарлары да сакланып каладыр. Шундый начар заманнар Мәскәү белән Казанның 1439-1445 елларда Мәскәүдә кенәз Василий III (Темный) хакимлек иткән чорына туры килә. Казан ханы Олуг Мөхәммәт Суздаль янындагы сугышта Мәскәү кенәзенең гаскәрләрен тар-мар итә, энесе белән үзен әсирлеккә алып, зур салым сала. Салым җыяр өчен рус җирләренә татар түрәләре җибәрелә. Моны халык кына түгел, боярлар һәм кенәзләр дә өнәми. Алар Василий III не тәхеттән бәреп төшереп, күзләрен сукырайталар. Әмма Олуг Мөхәммәт гаскәр җибәрә һәм Василий III не яңадан тәхеткә менгезә. 1439-1445 еллардагы вәзгыять шундый була. Ләкин нәкъ шул чорда татарлар белән руслар арасында сәүдә һәм дәүләт элемтәләре көчәеп китә, товарлар алмашып кына калмыйлар, гореф-гадәтләр, дәүләт белән идарә итү һ.б. багланышлар да ныгый.

М.Худяков үз китабының «Татарларның Россиягә мәдәни йогынтысы» дигән бүлегендә татарлар белән руслар арасындагы мәдәни багланышлар турында тәфсилләп яза: «... казанлыларның тормышын мәдәниятсез кыргыйлык дип күзалларга ярамый. Мәдрәсәләрдә укырга-язарга өйрәткәннәр, суфыйлык серләренә төшендергәннәр. Татарлар арасында укый-яза белү шактый киң таралган булган, чөнки мәчетле һәр авылда мәдрәсәләр дә эшләгән. Төбәкнең үз әдәбияты булган, шуннан байтак китаплар хәзерге заманга кадәр килеп җиткән...»

«...Татар халкы башка халыклардан үзенең байлык-муллыгы, рәхәт тормышы белән аерылып торган... Болгарларның электән килгән игенчелеге язгы милли бәйрәмнәре - сабантуйда чагылыш тапкан. Бу бәйрәмдә яшьләр спорт ярышлары үткәргән... Матди мәдәният өлкәсендә аларның чүкеп төшерелгән бизәкле савытлары, зәвекьле үрелгән ювелир бизәнү әйберләре, мәчет манараларының матур гөмбәзләре, аллы-гөлле тукымалары, матур каллиграфик кулъязмалары, катлаулы миниатюралы китаплары булган...»

Татарларның русларга ясаган уңай йогынтысы турында М.Худяков: «Татарларның рус дәүләтендәге вечены (ягъни дәүләт һәм җәмәгать эшләрен тикшерү өчен шәһәр халкының җыелышын) бетерү, Мәскәүнең бербөтен дәүләтчелеген булдыру һәм аны ныгыту кебек йогынтылары булган, руслар көнчыгыш күршеләреннән мәдәни казанышларны да күчереп алганнар. Рус хакимнәре падишаһ титулын Византия китаплары йогынтысында гына алмаган, татар ханнарына да охшарга тырышканнар, аларны Россиядә «падишаһлар» дип атаганнар бит.

Хәзер инде халык санын исәпкә алуны руслар татарлардан өйрәнгән, дигән фикер тулысынча раслана. Канцелярия эшләрен язмача башкару шәрекь-Кытай, фарсы һ.б. илләрнең мәдәниятендә гомумән үзенчәлекле сыйфат булган, ул урта гасыр көнбатышына

капма-каршы буларак, Русьта киң кулланылыш тапкан. Язма эш кәгазьләре, барлык халык санын гаять зур күләмдә исәпкә ала — болар барысы да татарлар турындагы «кыргый күчмә халыклар» дигән гадәти күзаллауларны кискен юкка чыгара... Нугай биләмәләрендә кәгазьне бик күп кулланганнар — димәк, бу да эш башкару һәм язу-сызуның яхшы үсеш алганлыгын искәртә. Татарларның русларга тагын бер мәдәни өлкәдәге йогынтысын билгеләп үтү кирәктер —дипломатиядә... (Худяков).

Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынты ясау юллары

Димәк, татарлар рус мәдәниятенә бернәрсә дә кертмәгәннәр, дибезме? Мондый фикер йөртүләрне хата санап, без бу йогынтының шул заманнардагы ике генә юлын күрсәтергә телибез.

Беренче юл — татарларның һәм татарлардан чыккан күренекле кешеләрнең рус кенәзлекләренә һәм рус мәдәнияте тормышына турыдан-туры катнашулары. Өстәрәк татар түрәләренең рус җирләрендә булулары турында әйтелгән иде. Үзләренең белемнәре, хәрби һәм җитәкчелек итү осталыклары, тәрбияле һәм гыйлемлекләре булган ничәмә-ничә ханзадә, морза һәм бәкләр рус кенәзләренә һәм патшаларына хезмәткә күчкән бит! Алар әллә үзләре бернәрәсә дә алып килмәгәнме? Алар тәҗрибәләрен, белемнәрен алып килгәннәр, алдагы буыннарда Россиянең ватанпәрвәрләре булып әверелгәннәр. Бу очракта гадәти үк булмаган вакыйгаларны искә төшерү дә зыян булмастыр. Распутинны үтергән кенәз Йосыпов Россияне сәяси шарлатаннан коткармаганмы әллә? Татар кенәзләре бертуган Урусовлар Серпухов тирәләрендәге урманда икенче Ялган Дмитрийны тураклап, поляклары җиңүне тәэмин итмәгәнме? Болар рус дөньясына өлеш түгелмени?

Милләтнең менталитеты, ягъни фикер йөртү үзенчәлеге гасырлар дәвамында барлыкка килгәнлектән, бу милләткә саркып кергән чит тел вәкилләренең белемнәрен дә инкяр итәргә ярамый.

Татарларның русларга йогынтысы нәтиҗәләрен әдәбиятта, дәүләт төзелешендә, хәрби эшләрдә, архитектурада күрергә мөмкин. Әллә Мәскәү тирәләрендәге (Архангельскоедагы) һәм Петербургтагы кенәз Йосыпов, Шереметьев, Измайловларның атаклы сарайлары рус мәдәниятенә саллы өлеш түгелме?

1311 елны, Үзбәк хан ислам динен Алтын Урдада дәүләт дине дип игълан иткәннән соң, аның белән килешмәгән татарларның бер өлеше рус кенәзлекләренә китеп барган. Кемдер үзенең өч йөз кешесе, кемдер хәтта биш меңлек гаскәре белән дә киткән. Алар рус кенәзлекләренең ышанычлы сакчылары булып әверелгәннәр. Хәтта Касыйм ханлыгы кебек аерым дәүләтләр дә барлыкка килгән.

«Ислам диненә каршы татарларга табардай бердәнбер ышык һәм дустанә урын рус кенәзлекләрендә генә булган. Шул рәвешле, Русьта Урдадан чыккан ник холыклы, тәвәккәл кешеләр барлыкка килгән, алар менә дигән сугышчылар булганнар һәм рус кенәзләренең дружиналарын, ә соңрак Мәскәү кенәзенең дә гаскәрен тулыландырып, аларның сугышчанлыкларын сизелерлек дәрәҗәдә күтәргәннәр»...,—дип яза тарихчы Платонов. Алтын Урданың Мәскәү кенәзлекләрен поляклар, литвалылар һәм шведлардан саклап торулары турында язылган иде инде.

Кем син Русич?

Күп телле җәмгыятьтә халыкның үзара аралашып кушылуы һәрвакытта да аксөякләр арасында гына бармаган. Рязань өлкәсендә, мәсәлән, Алтын Урдадан килгән татарлар токымыннан торган тулы районнар бар. «Һәр өченче русны чокып кара һәм син аңарда татарны табарсың» — К.Марксның бу сүзләре рус әдәбиятында аңа кадәр дә яхшы билгеле булган. Күпмегә дөрестер бу сүзләр, әйтүе

кыен. Әмма шунысы хак, руслашкан миллионлаган татарлар рус халкының аерылгысыз өлешенә әйләнгән. Үзләрен «рус» дип яздыручы һәм рус исем-фамилияләрен йөртүче татарлар бер генә миллион түгелдер. Күпме, рус фамилияләренең тамырында татар чыгышы ята бит: Муратовлар, Сабуровлар, Батышевлар, Калгановлар, Балабановлар, Измайловлар һ.б. шәһәрләрдә генә түгел, рус авылларында да яшиләр, үзләренең борынгы бабаларының кайдан килеп чыгышын, белсә дә, бик азлары гына беләдер.

Тарих дәреслекләреннән укып, мәктәп балалары Афанасий Никитинның Һиндстанга сәяхәте турында беләләр. Үзенең «Хождение за три моря» (“Өч диңгез артына сәяхәт”) дигән китабында ул үзе күргән шәһәрләрне сурәтләп китә.

«Казан биек тау башында тора, — дип яза ул, — елгадан бик яхшы күренә, шәһәр өстенә биек-биек мәчет манаралары һәм хан сарае күтәрелгән». Афанасий Никитинның бу китабын татар телендә язганлыгын белә идегезме? Гажәпкә калдыгызмы? Тикшеренүче галимнәр бу хәлне аның «урман болгары», ягъни мишәрлеге белән аңлаталар. «Димәк, Тверь кенәзлегендә XY гасырларда татарча язган һәм сөйләшкән «урман болгарлары» да яшәгән», —дип нәтиҗә ясый тарихчы Ф.Салихова.

Русларның аксөяк, затлы катламы ничек барлыкка килгән? Тарих моның өч юлын күрсәтә: мирас булып атадан балага күчә килүе; кенәз һәм граф, сирәгрәк бояр исемен Россиядә дәүләткә яки патшага шәхсән зур хезмәтләр күрсәткәне өчен патшаларның гади кешеләргә дә бирүе (классик мисалы—кенәз Меньшиков) һәм өченче юл: рус дворяннары сафларының татар морзалары һәм бәкләре,соңрак немец, швед һәм башка чит-ят кешеләр белән тутырылуы—тулыландыруыннан барлыкка килгән.

Әдәбиятта Россиядә дворяннар катлавының барлыкка килүе турында материаллар шактый. Бик күп татар кенәзләре, морзалары

һәм бәкләре рус дворяннары сафына кереп кушылган, алар үз белемнәрен: дәүләт белән идарә итүләрен, дипломатия тәжрибәләрен, шәркый телләрне белүләрен, хәрби гыйлемнәрен, билгеле бер дәрәҗәдәге әхлаклы булуларын һ.б. шунда салган. Алар йөзәр еллар дәвамында Польша һәм Литва аша Идел Болгарыннан, Алтын Урдадан, Казан һәм башка ханлыклардан рус хезмәтенә күчә барганнар.

А.Х.Халиковның «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (Казань, 1992) дигән китабыннан кайбер мисаллар китерик. Руслар өчен бүген дә бик таныш берничә исемне атап үтәбез. Иң күп төркемне әдәбият-сәнгать әһелләре тәшкил итә. Әдәбиятчылар атаклы рус язучысы Аксаков, шулай ук танылган Мусин-Пушкин, Радищев, Чадаев; бояр дәрәҗәсе һәм Мәскәү тирәләрендә авыллар биләгән Булгаковлар, Иван Бунин, Иван III заманында Урдадан чыккан Гардиннар... Кем генә соң Г.Р.Державинның, И.А.Тургеневның (морза Турген Арслан нәселе), Купринның һәм инде безнең заманда М.Львовның, әнисе татар булган Чыңгыз Айтматовның рус әдәбиятына керткән бер өлеше дә юк дип әйтер икән? Күп кенә әсәрләр халык авыз иҗаты дип йөртелә. Театр сәхнәләрендә без әтиле-уллы Абдуловларны күрәбез. Рус әдәби әкиятләрендәге Салтан патша (Солтан-хаким), Руслан (Арслан) һ.б.

Ә музыка өлкәсендәге Алябьев, Рахманинов, Скрябиннар (Урданың Сокур бәй нәселеннән). Рус халык җыры «Во поле березонка стояла»ның авторы Казан университеты укытучысы Нигъмәт Ибраһимов икәнен дә бик азлар гына беләдер. Рәссамнар Шишкин, Китаевлар…

Хәрбиләр... Рус кенәзләре татар морзаларын, бик тәжрибәле булганнары өчен аларга утарлар һәм авыллар бүләк иткәннәр, татарлар исә ул җирләрне көнчыгыштан да, көнбатыштан да һөҗүм

итүчеләрдән саклап торганнар. Чыгышлары белән Дмитрий Пожарский, Михаил Кутузов, Александр Суворов, кенәз Василий Кочубей—Петр I нең көрәштәше һ.б. татарлар булган.

Рус һәм совет армиясендә һәрвакытта да татарлар күп булган. Атаклы маршал Тухачевский (тухач-тукач—байрак йөртүче). Инде безнең заманда да татар хәрбиләре шактый, мисалга армия генералы М.Гәрәев. Совет армиясенең Генштаб башлыгы урынбасары һәм Әфганстанда, Мисырда хәрби киңәшче иде. Фашистлар әсирлегендә инженер-генерал Карбышев батырларча һәлак була. Үзенең автобиографиясендә ул бабасының Себер татары икәнен язып калдыра. Ватан сугышында керәшен татарлары генерал Яковлев белән Брест крепосте герое майор Гаврилов та тиңсез батырлыклар күрсәтәләр. Советлар Союзы герое исемен алучылар буенча татарлар дүртенче урында тора.

Галимнәр, татарлар һәм аларның буыннары Россия фәненә дә зур өлеш керткән. Россия фәннәр академиясенең беренче президенты Екатерина Дашкова булган (ул Урданың 1400 елгы морзасы Дашек нәселеннән). Гавриил Романович Державин морза Ибраһим нәселеннән, морза үз вакытында Зур Урдадан бөек кенәз Василий Васильевичка хезмәткә килгән. Ул шагыйрь генә түгел, дәүләт эшлеклесе дә булган. Россия дәүләтенең беренче тарихын Н.Карамзин язган,ул чыгышы белән татар дворяны Кара Морза тамырыннан. Инде безнең заманнарда СССР Фәннәр Академиясенең җитәкчесе академик Мстислав Кельдыш поляклашкан татар дворяннарыннан. Безнең замандашыбыз Тимирязев Урдадан 1408 елны бөек кенәз Василий Дмитриевичка хезмәткә кергән Ибраһим Тимеряз нәселеннән булган.

Дәүләт эшлеклеләре: Россия тәхетенә Борис Годунов утырганына кадәр Иван Грозный Бикбулатовичны премьер-министр итеп куйган. Аракчеев та бик зур эшчәнлек күрсәткән. Аның

турында А.С.Пушкин: «нинди бөек һәм атаклы булган Кочубей, аның җирләренең дә иге-чиге булмаган...»—дип язып калдырган. Ә күпме зыялы татарлар Мәскәүгә «шәрекъ» җирләрен үзләштерергә ярдәм иткәннәр! Мәсәлән, XIV гасырда Россиянең Һиндстандагы беренче илчесе Әстерхан татары Касыймов булган. Совет заманнарында илчеләр Йәмандә, Төркиядә, Әфганстанда һ.б. илләрдә шулай ук татарлар булган.

Рус тарихында татарларның эзе-буразнасы шактый тирән, культурология дәреслекләрендә моны чагылдырырга кирәк иде, болар бит Россиянең һәр патриоты горурланырлык фактлар, һаман да татарларны рус халкы өчен «дошман» итеп сурәтләүдән туктарга бик вакыт.

Шул ук культурология дәреслекләрендә: «Монгол гореф-гадәтләре рус аксөякләре тарафыннан күчереп алынган, мәсәлән, патшага хәләл җефетен дә аларның иң чибәр кызларыннан сайлаганнар, сарай хезмәтенең дә киң тармакларына... лачын белән ауга йөрү, бурзайлар белән ауга чыгу да алардан күчкән. Рус казаклары алардан бик күп сугыш һөнәрләренә өйрәнгән, яшеренеп засада полклары, «лава», «куренной» формаларын армиягә һәм тыныч тормышка да кертү һ.б. шактый булган.

Әмма ул дәреслекләрдә төрки-татарларның руслар белән мәдәни һ.б. багланышларын сөйләү урынына, «христианлыкның ислам динен җиңүе белән горурлану», Иван Грозныйның җиңүеннән соң йөз еллар үткәч тә аның канлы эшләрен хуплау гына бар.

Ярар, шулай да булсын, ди: революциягә кадәрге тарихчы хәзерге кебек тирән тарихи белемнәргә ия булмаган, аннары ул бит патшага хезмәт иткән. Ләкин бит бүгенге «рус тарихчылары да шул ук «бер җырны җырлыйлар», патша империясенең идеологиясен алга сөреп, хакимият һәм чиркәүнең агрессив асылын аңлатмакчы булалар. Әле хәзер дә рус зыялылары арасында, халыкка хезмәт итү

урынына, хакимияткә хезмәт итеп, хакыйкатькә түгел, ә ялганга, тәлинкә тотарга тырышалар (А.Х .Борһанов).

Телем — дустым минем

Мәктәп дәреслекләренең авторлары рус мәдәниятенә татарлардан кергән алынма сүз-гыйбарәләрне кире кага алмыйлар. Татар мәдәниятенең рус мәдәниятенә йогынтысы рус теленә кергән татар сүзләре—алынмалары аша да булган; сүзләр исә әйбер белән бергә алына; яңа сүзләр, гыйбарә-терминнар, аңлашулар дусларның үзенчәлегенә һәм фикер йөртүләренә дә тәэсир итми калмаган, әлбәттә. (Бу хакта, ягьни россияннарга Евразия үзенчәлеге төп элемент булып керү турында күп язылган (Трубецкой һ.б. китапларында).

Бер халыктан икенчесенә күчереп алу, әгәр дә ул бигрәк тә күрше халыкларныкы да булса, объектив законча лыклы күренеш. Хәзер, әйтик, хәтта америка гамбургерларын, бигмакларын ашыйбыз, кока-кола эчәбез, джинс чалбар-юбкалар футболка-кроссовкалар киябез икән—болар бит рус аш-суына кайчандыр татар шашлыклары, токмач, пилмән, бәлеш һ.б. да кергәнгә дәлил генә. Ә киемнәр: толып, ыштан, халат, шәл, башмак, башлык—һәммәсе татарлардан кергән ич, һәр чорның үз теле-үз йөзе һәм үзенчә күчереп алуы да бар.

Сүз һәрвакыт фикерләүне, уйлауны чагылдыра. Уй-фикерләүдән соң кешенең эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы, тәртибе килеп туа. Димәк, сүз, кайбер авторлар уйлаганча, аралашу чарасы гына түгел. Әйтик, «тынычлык» сүзе «сугыш юк» дигән сүз генә түгел бит әле, ул дәүләтләрнең дистә еллар буе алып барган сәясәте дә, мәдәниятенең үсеше дә һәм халыкның мул-иркен тормышын күтәрү-тәэмин итү дә... Сүз теге яки бу әйберне (өстәл, урындык, тәрәзә һ.б.) шулай ук теге яки бу эш-гамәлне (уку, язу, эзләү, аралашу һ.б.), аннары тормыш-көнкүрештәге, фәндәге, фәлсәфәдәге

хәл-әхвәлләрне дә аңлата. «Сүз белән кешеләрнең йөрәкләрен яндыр...» А.С.Пушкин бу гыйбарәне Коръәннән алып Мөхәммәт галәһисәламны шуңа чакырган. Сүз ул үзенең бер лексик мәгънәсен генә эченә алмый. Ул үзе аңлаткан бик күп мәгънәләрне, аларның фәнни дәрәҗәләрен һәм аларның тышкы бәйләнешләрен, аларның (прагматик) бәяләрен дә ачып бирә торган лексик берәмлек.

Читтән алынган сүзләр нәрсә аңлата?

Культурология дәреслегендә рус теленә «татар теленнән бик аз сүзләр кергән: чердак, магазин...» дип кенә аңлаталар. Әлбәттә, рус теле соңгы йөз еллар эчендә, бигрәк тә Көнбатыш Европа телләре аша бик үскәндер. Ләкин татар сүз-гыйбарәләре элегрәк анда шактый күп булган. Бүгенге сүзлекләр күбесенчә архаизм , (иске) сүзләрне генә искә ала, ул сүзләр исә хәзер инде әһәмиятләрен дә югалтканнар. Мисалга, арчак—ыңгырчак, аргамак—ат, чаптар ат; аршин, арык, атаман, караул, есаул, атлас, аул, бадана -кулчак, ягьни кулга кия торган тимердән үрелгән бияләй (шуннан Колчак исеме), бадья, байбак, байгуш, балакир—сөт савыты (шуннан Балакиревлар), амбар, алтын (алты тәңкәгә яки өч тиенгә тиң—шуннан биш алтынлык), алпавыт һ.б. бик күп сүзләр, инде социаль әһәмиятен югалтып, төшеп калганнар.

Әмма әле бүген дә кулланылышта булган татар сүзләре дә шактый күп. Рус телендә хәзер «чердак»—чарлак, «дорога—«даруга», «лошадь»—алаша, «корзина»—кәрзин; кием-салымнан «шаровар», «ыштан», «халат», башлык», «башмак», кәвеш—«калош»; азык-төлектән—«пилмән», «бәлеш» һ.б.—кабатлансак та, әйтеп китик әле... Хәтта «кәрзин», «кинжал», «булат», «түбәтәй», «аркан», «буран» һ.б. бездән - татарлардан барып кергән бит.

Тарихи белемнәр чыганагы буларак сүзләр

Бер телдән икенче телгә күчерелеп алынган сүзләр нәрсә турында сөйлиләр соң? Әлбәттә, әйткәнебезчә, йөз еллар дәвамында рус теленнән татар сүзләре кысырыклап чыгарылган. Ләкин әле бүген дә сүз тамырларына карап (этимологиягә) татарларның рус тарихында нинди урын тотканнарын әйтергә була. Бик күп кенә икътисад һәм мәдәният өлкәсендәге сүзләр татарчадан килә бит әле. Әйтик, «кремль» (кирмән), кирпеч, сандык, тара, тариф, чапрак, урман, арба, батрак, бурлак, бояр, «богатырь»—батыр-баһадир, базар, кәҗә, баран, сабантуй, чәй һ.б. һ.б. Мисалга, дәреслекләрдә еш кына «боярин», «бояре» сүзләре кулланыла. Ә төбендә бит татарның «бай ир»е ята! Кайбер сүзләр хәзер инде беренчел мәгънәләрен яшерә дә төшкән. Мәсәлән, һәркем белгән «товарищ» сүзе ике татар сүзеннән «товар» «иш», Руслар инде шул сүз белән ничә гасырлар буе яши, диген! Әле бит А.С.Пушкин да: «Товарищ, верь, взойдет она, Звезда пленительного счастья...»—дип язган. Әмма... бәхет кенә һаман ераста әле.

М.Худяков үз хезмәтләрендә «балалайка» сүзенең дә татардан булганлыгын исбат итә.

Һәр сүз аркылы үзара мөнәсәбәтләрне ачыкларга була. Мисалы—татар сүзе «казак»—атлы казак мәгънәсен белдергән.Алар Алтын Урданың атлы сугышчылары булган һәм дәүләтнең ил чикләрен саклап торганнар, тора-бара аларга рус алпавытларыннан качып киткән рус крестьяннары да килеп кушыла барган. Әкренләп аларның саны үсә барган һәм Россия чикләрендә рус казаклары үскән-көчәйгән. Хәзер инде «казак» сүзенең татарныкы икәнен бик азлар гына беләдер. Менә шулай безнең сүзебез саф рус сүзе булып киткән һәм әле кайбер тарихчылар аны Россия чикләрен саклаучылар итеп тә күрсәтергә тырышалар.

Әгәр дә без хәзер рус телендәге «базар» сүзләрен (лексика терминнарын) Алтын Урда чорында ук барлыкка килгән, дисәк, күпләр

ышанмыйча, елмаер гына иделәр. Ә бит шулай дип дәлилләргә бөтен нигезләр бар. Кешеләр бит һәрвакыт үзләре яшәр өчен төп нигез шартларны булдырганнар: азык-төлек, кием-салым, йорт кирәк-яраклары, хезмәт кораллары, сәүдәгәрлек һ.б,—болар сөйләп бетермәслек күп. Алар бер халыкның икенче халык белән аралашуында да нык чагылган. Шуннан ул сүз—гыйбарәләр аерым төшенчәләр белән билгеләнгән. Алар билгеле бер социаль-икътисади шартларда башка телләргә дә үтеп кергән.

Рус теленә кергән татар сүзләре «товар» (»туар-тывар») нәрсә аңлаткан? Русларның икътисади фикерләүләрен үстергән дигән сүз. Русларга «деньги» («тәңкә») сүзе килеп керү дә шул ук «товар» сүзе аша түгелме соң? Ә аңа кадәр, бик борынгы заманнарда, әле акча «тәңкә» сүзе юк чакта, төркиләр-татарлар бит тиешле бер урынга, уз «товарын»—малын куйган да, «биш тиен», «ун тиен» дип бәя биргән. Теләгән кеше «биш тиен» (тиен тиресе) яки «ун тиен» түләп алган. Руста безнең бу «тиен» сүзе кереп китмәгән, алар үз вак акчаларына, ук тоткан сугышчы сукканнар да, «копейка»—«копья» сүзен алганнар.

Казына башласаң, менә бит ул Тарих нинди!

Аннары, «базар» сүзе үзе дә төрки-татарлардан килеп кергән ич. Татарлар тәңкәләр сукканнар. Хәтта руслар үзләре тәнкәләр суга башлагач та элгәре аларга гарәп хәрефләре белән татар сүзләрен яза торган булганнар.

Башта Россиядә акчалар агачтан, күннән булган. XIV гасырда рус кенәзе Иван III тимер—бакыр-көмеш акчалар суга башлаган. Димәк, Алтын Урданың бу мәсьәләдә дә зур йогынтысы булган. Әйткәнебезчә, аларда башта гарәп хәрефләре белән татар сүзләре генә язылган. Менә шул рәвешле, рус җирләрендә товар—акча («товар—деньги») мөнәсәбәтләре барлыкка килгән. Әллә бу хәлләр

рус икътисади фикеренә һәм финансына йогынты ясамаганнардыр дип уйлыйсызмы?

... Йөз еллар үткән. Күп кенә татар сәүдәгәрләре, зыялылары йотылып руслашкан, әмма аларда барыбер татар рухы, үз ата-бабаларының эш-гамәлләренә хозурлыгы сакланып калган, күпләр, диннәрен һәм исемнәрен алыштырып, христиан диненә күчкән, үзләрен «рус» дип йөртә башлаган.

Ә дәреслек авторлары әле һаман да «татар-монгол иго»сы дип, ясак түләтергә теләгән татарларга һаман да нәфрәт уятырга теләп язуларын дәвам итәләр... Әллә болар татар халкының горурлыгына, үз дәрәҗәләренә китереп сукмыймы? Һәм шушы шартларда әлеге дәреслек авторлары ике мәдәният өчен уңай йогынты ясый, дип әйтеп буламы? Татарларны «дошман» итеп күрү шундый ук иртәрәк язылган дәреслекләрдә дә бар. Бу мөнәсәбәт хәзер гади рус кешесенең аңында йөз елларча яши һәм ул аның дөреслегенә һич кенә дә шикләнми. Бу тискәре уй-фикерләр нигездә революциягә кадәрле авторларның китапларыннан алына.

«Татар тәртипләре,—дип яза С.Ф.Платонов,—Рәсәй өчен бик авыр булган. Баскаклар һәм кораллы гаскәрләре булган татар түрәләре халыкны бик нык җәберләгән, татарларның ясагы бик авыр һәм мәсхәрәле булган (бу ул вакыттагыча «десятина», ягъни табышыңның 10%ын ясакка түлә (М.М.) дигән сүз). Әмма ләкин халыкны «баскаклар түгел», ә үз ясак җыючылары җәберләгән икән ләбаса (ә кайчан һәм кайда ясак җыючыларны кочак җәеп каршы алганнар?—М.М.). Рус кенәзләренең үзләре ясак җыючылар»,—дип яза С.Ф.Платонов —халыкны татарлар белән турыдан-туры багланышка кертүдән, димәк, алар ягыннан еш кына булырлык көчләү-җәберләүләрдән дә коткарып калган» (С.Ф.Платонов).

Рус тарихчылары Россия дәүләтенең сугышчан булуын, басып алучанлыгын акламакчылар. Мәсәлән, шул ук С.Ф.Платонов,

Казанны яулап алуны сурәтләп, болай яза: «Шәһәр тулысынча яндырылган, татар сугышчылары якын-тирәдәге урманнарда кырып бетерелгән. Казан патшасы Едигәй (Ядигар) әсирлеккә алынып, чукындырылган, шулай итеп, Казан ханлыгы тулысынча юкка чыккан... Казан татарлары һәм аларга буйсындырылган халыклар Мәскәү тирәләренә һаман да тынгылык бирмәгәннәр, һәм русларның шәрекькә таба яулап алу юлын бикләп торганнар...»

Ничек»бикләп торганнар» икән? Димәк, алар алга табан да чит җирләрне басып алуга комачаулаганнар. Бик ачыктан-ачык һәм әхлаксыз рәвештә шулай язылган. Татарлар үз җирләрендә, беркемгә дә комачауламыйча, гомер сөргәннәр. Димәк, болай фикерләгәндә, Польша да, Прибалтика белән Румыния дә Көнбатышка табан юлны ябып тора, ә Төркия диңгез бугазларын бирми—димәк, боларның барысын да тар-мар итәргә кирәктер? Әмма... Россиянең моңа көче җитми, әлбәттә.

Платонов менә мондый нәтиҗәләр ясый: «Татар патшалыгын буйсындыру—ул халыкның бөек эше иде... Ниһаять, христианлыкның ислам динен җиңүе Европаның Азияне дә җиңүе тантанасы булды. Үз җиңүенең барлык бөеклеген аңлаган рус халкы аның хакында җырлар җырлады, шуның өчен Иван IV не Грозный (Явыз патша) дип, эпик (тарихи) дәрәҗәгә күтәрде.» (С.Ф.Платонов).

Шушы сүзләрдә Мәскәү патшаларының басып алу сәясәтенә тарихчылары да тулысынча дан җырлаганлыклары ачык чагыла. Һәм иң төп фикер—«христианлыкның ислам динен җиңүе». Нәкъ шушы фикерне бүгенге авторлар да күтәреп алды, алар христианлыкның ислам дине өстеннән җиңү яулавын, руссианнар арасында руслар гына түгел, ә күпмилләтле рус булмаган халыклар да яшәвен оныталар. Әле күптән түгел генә Россия президенты В.В.Путин: «Россиядә 20 миллион мөселман яши»,—дип игълан

иткән иде. Без—катнаш халык. «Мин рус түгел, әмма россиянмын»,—дип татар шагыйре Әхмәт Ерикәй язса: «Мин татармын, ләкин каннар катыш татар...»—дип рус шагыйре Корнилов та язган иде.

Аннары бит тарихи белемнәр дә артты, хәзер инде тарихчылар күбесенчә тарихи фактларга таяна, ә элекке әкиятләргә ышанмый, яки кулъязмаларның, язучыларның һ.б. язмаларына көлеп кенә карый.

Дәреслек авторлары исә һаман да чеп-чи уйдырма язалар, рус балаларында татар—«дошман» дигән сурәтне тудыралар (»История отечества. Учеб.пособие для 8 кл. с.ш. Коллектив).

Хәзерге татарлар турында берничә сүз

Әлбәттә, бүгенге рус теле татарлардан сүзләр алуга мохтаҗ түгел. Заманнар үзгәрә. Россия белән дүрт йөз ел яшәү дәвамында, татар теле дә руслардан күп сүзләр алды; рус теленең фонетикасы, морфологиясе һәм синтаксисы йогынтысы аркасында үз грамматикасы да үзгәрешләр кичерде. Рус телен бик яхшы белгән татарлар хәзер үз телен яхшы белгәннәреннән күпкә артыграктыр.

Шулай булуга карамастан, халык рухы яши, халыкның тарихи хәтере бар, шуның нигезендә татар җәмгыятенең милли үз аерымлыгын яшәү тәррәкый итә. Халыкның милли үзаңы, рус түрәләренең рухи кысымнарыннан азат булырга теләп, егерменче гасырның туксанынчы елларында бик активлашып киткән иде. Фәндә, хөкүмәттә, идарә итүдә, әдәбиятта, сәнгатьтә, музыкада, рәсем сәнгатендә, сәясәттә, дипломатиядә татарлар һәм аларның токымнары милли аерымлык сыйфатлары белән генә аерылып тормый; рус зыялылары арасында бүген Россия фәннәр академиясенең танылган академиклары физик Роальд Сәгъдиев, Камил Вәлиев, А.Сюнәев, философ Булат Галиев, кардиолог Ринат

Акчурин һ.б. бар. Татар халкының талантлы уллары һәм кызлары Европа мәдәниятенә дә үз өлешләрен һаман кертәләр.

Ә спортта күпме данлыклы милләттәшләребез?! Футболчылар Г.Хөсәенов. Р.Дасаев, Р.Нигъмәтуллин һ.б. Бүгенге Россия данын яклаучы теннисчыларыбыз Ш.Тарпищев (тренер), Марат Сафин. Шахмат буенча дөнья чемпионы булган Алисә Галләмова... Әмма беркем дә аларны ассызыклап татарлар дип әйтми. Һәм шунысы яхшы да, без үзебезне күптән инде шушы дәүләтнең гражданнары, россияннәр итеп хис итәбез, без бу дәүләтне төзүчеләр һәм дошманнардан яклаучылар арасында.

Татарстан тарихчылары Урта гасырлар чорына ничегрәк карый соң?

Г. Ковальская «Татарстан тарихы» дәреслегендә руслар белән татарларның һәрвакыт бердәм, иңгә-иң куеп яшәүләре турында яза. Татарстанда хәзер татарлар руслардан әз генә күбрәк, аларның мул-тыныч яшәве — ике милләтнең дә тыныч, килешеп яшәве дигән сүз ул. Бездә мәктәпләрдә татар укучылары да, рус укучылары да Казанны кайчандыр руслар яулап алганлыгы турында тузынып сөйләнми.

Мәдәниятләрнең үзара килешү-сөйләшүе

Мәгълүмати көрәш бай капиталистик илләрнең идеаллары, аларның кыйммәтләре белән җир шарындагы күпчелек ярлылар арасындагы көрәш ул. Мөселман дөньясы, гаять күп нефть байлыклары булса да, үз халкын туйдыра алмый, чөнки аның байлыкларын капиталистик илләр талап бетерә.

Мәдәниятләрнең үзара килешү-сөйләшүләре, цивилизацияләрнең килешүе күршеләреңнең Урта гасырда яшәгәнлекләрен аңлау-төшенү өчен кирәк түгелмени? Тынычлык һәм кешелекне төрле һәлакәтләрдән йолып калу хакына гаделлек-дөреслек өчен көрәшү кирәкмимени? Цивилизацияләрнең үзара

килешүе халыкларның мәдәни психологиясе дәрәҗәсенә, аларның бер-берләрен аңлау дәрәҗәсенә дә бәйле. Һәр халыкның зыялы акыллыларын халыкларны якынайту юлына юнәлдерергә кирәк. Белмәү, Фицжеральд ишеләрнең наданлыклары һәркайда нәфрәтләнү һәм сугышлар гына тудыра. Моны халыклар күптән белгәннәр.

Наданнарны дәваламас табиблар,

Наданлыкны гыйлемең белән дәвала.

Акыл-гыйлем—кайсыдыр шул бер баудыр –

Упкыннан безне һәрчак тотып торыр.

Й.Баласагуни.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы да рим-католик чиркәүләре белән мөселман диннәре арасында сөйләшү-килешүләр алып барырга чакыра... Әмма бу сөйләшүләрнең дәүләт-хөкүмәтләр арасында, сәяси рәвештә алып барылырга тиешлеге хакында бер сүз дә юк. Башка мәдәниятләрне, башка халыкларның гореф-гадәтләрен белү мондый сөйләшүләрдә иң кирәклеседер.

Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында бу сөйләшүләр халыклар мәдәниятендә ничек чагыла соң? Халыкларның төп өлеше бу гамәлдән читтә кала. Моны Россия халкының мәдәни мәнфәгатьләре никадәр «европалашкан» мисалында да күрергә була. А.А. Андреевның тикшеренүләре Европа мәдәниятенең Россия мәдәниятенә бик аз үтеп керүе турында сөйли. Гамәлдә россиялеләрнең дүрттән бер өлеше читтә кала бирә. А.Андреев халыкны өч өлешкә бүлеп карый: «мәгълүматлылар» (нигездә эшмәкәрләр, студентлар һәм зыялылар), «кызыксынучылар» (хәрбиләр, хезмәткәрләр, инженер-техник вәкилләр), сәүдә һәм хезмәт өлкәсе кешеләре), «читкә тибәрелгәннәр» (җәмгыятьнең иң түбән катламы—эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре һәм пенсионерлар).

Халыкның өчтән бере—Европа мәдәнияте белән кинофильмнар һәм әдәбият аша гына таныш.

Америка халкының күпме өлеше генә мөселман илләре мәдәнияте белән кызыксына икән? Бик аз өлешедер, мөгаен. Шулай булгач, ике мәдәният арасында нинди эшлекле сөйләшү булырга мөмкин.

Мисыр кинофильмнар эшләп чыгару буенча Һиндстаннан кала икенче урында тора. Америка халкы ул фильмнарны карыймы? Юк, әлбәттә. Алар ислам дөньясы турында бары тик телевизион тапшырулар аша гына беләләр. 2001 елның 11 сентябрендә булган фажигадән соң исламга каршы мәгълүмат күпкә артты. Көнбатыш белән Көнчыгыш мәдәниятләре арасында нинди сөйләшү-килешүләр булырга мөмкин?

Йомгак

Россиядә мәдәниятләр сөйләшүен уңышлы башкарырлык социаль-сәяси шартлар бармы? Дини тәрбия бирү, милләтләрнең килешеп яшәвен ничек хәл итеп булыр? Беренче чиратта, тарих дәреслекләреннән татарларга карата кире мөнәсәбәтне алып ташларга кирәк. Мәктәпләрдә укучыларның әхлакый хокукларын кысу булмаска тиеш, психик басым да ясалмаска тиеш.

Бары мәсьәләне шулай хәл иткәндә генә кеше хокукларын кысу бетерелер. Һәм бу сәяси дә, тарихи да, этик яктан да дөрес булыр иде.

Яшь буынны тәрбияләүнең төрле формалары—якшәмбе мәктәпләре, дин тарихы буенча факультатив курслар, христиан дине белән ислам динен дөрес тәрбияләү һ.б. Яңа тип дәреслекләр кирәк. Бары тик шул шартларда гына яшь буында Россия патриотизмы хисен һәм аңын тәрбияләргә мөмкин.

III. ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

3.1. Әхлакый аң тәрбияләү

Россиялеләрнең әхлакый сыйфатлары кими баруы турында күп языла һәм сөйләнелә. Билгеле, бу күренешнең күптөрле сәбәпләре бар. Алар нидән гыйбарәт соң?

Монда тирә-юньнең, гаилә, мәктәп һәм диннең гаебе бармы? Бу сорауга әйе дип тә, һәм юк дип тә җавап бирергә мөмкин. Моның төп сәбәбен без XX гасырдагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрнең үсеш ягыннан алга киткән халыклар тормышында чагылуында күрәбез. Моны раслау өчен бер генә мисал китерү дә җитә: әгәр дә XIX гасыр ахырында хезмәтнең 99% хайван һәм кешеләрнең мускул көче белән башкарылган булса, ә инде XX гасыр ахырында хезмәтнең шундый ук өлеше техника, машина һәм аппаратлар ярдәмендә эшләнә. Тупланган белемнәр нигезендә кешелек интеллекты үзенең иң югары үсешенә иреште шикелле: кеше атом-төш энергиясенең иң зур серләрен ачты һәм галәмгә, җир орбитасыннан читкә дә чыкты. Әмма техника һәм технология өлкәсендәге үсеш бер үк вакытта кешенең рухи үсешен тизләтмәде. Рухи халәт артта калып барды. Алай гына да түгел, алга киткән илләрдә яшәүчеләр әкренләп әхлакый сыйфатларын югалта башладылар. Кеше үзе, аның дөньяны танып белүе, иҗтимагый аңы, әхлакый юнәлеше ничек үзгәрде соң? Кешеләрдә әхлак, әдәптәртип тәрбияләү үсешендәге үзгәрешләр турында сөйләргә мөмкинме соң? Диннең әхлакый-этик өйрәтүләре һәм XX гасырда әдәплелекне алга куйган галимнәр тәгълиматы педагогикада нинди урын тоткаННар? Бу сорауларга җавап бирү өчен Европа илләрендә дә, Россиядә дә тәрбия процессы

үсеше тарихын җентекләп өйрәнергә кирәк. Без бу мәкаләдә шушы процессның төп юнәлешләренә генә тукталабыз.

XX гасыр башында

Элекке гасырларда яшәгән пәйгамбәрләр һәм бөек моралистлар (әдәп-әхлак таратучылар) (Конфуций, Будда, Муса, Гайсә, Мөхәммәт, Л.Толстой, А.Швейцер һ.б.) тәгълиматларында дини-әхлакый тәрбиянең һәм яшь буында әдәплелек сыйфатлары булдыруның зур әһәмияткә ия булуы турында әйтелә. Әмма кешенең үз-үзен тотышы әхлакый вәгазь укулар белән генә көйләнми, ә бәлки аны тормыштагы шартлар, вакыйга, хәлләр дә җайлый.

Социум (тирә-юнь)

Россиядә Беренче бөтендөнья сугышына кадәр әдәплелек нәрсәгә нигезләнгән соң? Рус халкының күбесендә Православиегә, Аллага, патшага һәм туган илгә, гадәти әхлакый кыйммәтләргә ышануга, гореф-гадәткә нигезләнгән. Аз санлы «аксөякләрнең», интеллектуаль элитаның әхлагы сәнгать, әдәбият, мәгарифкә нигезләнгән һәм әдәплелек, кешеләр арасындагы әхлакый кыйммәтләр балаларга ана сөте белән кергән.

Татар халкын әхлакый тәрбияләүдә нинди тенденцияләр күзәтелә? Элек алар тулысынча Корьәннең изге сүзенә әхлакыят тәгълиматына, халык гореф-гадәтләренә нигезләнгән булган. Оят, намус, бурычлылык, шәфкатьлелек, юмартлык, киң күңеллелек, ярдәмгә мохтаҗларга булышу кебек әхлакый төшенчәләр һ.б. халыкта, гаиләдә, мәдрәсә, мәчеттә балаларга һәм яшьләргә тәрбия бирү нигезен тәшкил иткәннәр.

Мулла җитәкчелегендә аксакаллар идарә итә торган җәмәгать авыл, ул вакытта дини белем һәм тәрбия бирүне беренче максат итеп куйган мәдрәсә, гаилә зур әһәмияткә ия булган. Шәхестә әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә физик хезмәт иң мөһим нәрсә саналган. Гомумән, хезмәттә чыныгу Россия халкының күпчелеге өчен хас бул-

ган. Моны раслау өчен саннар китерергә кирәк түгел. 1920 елда Россиядә яшәүче барлык халыкның 80 проценты авылларда яшәгән, олысы-кечесе эшләп, тир түгеп тамагын туйдырган.

Хезмәт процессы һәм аның нәтиҗәләре яшь буында намуслы хезмәт итү гадәте, эшкә уңай караш, үзара һәм туганнарча ярдәмләшү, яхшылык тели белү күнекмәсе булдырырга ярдәм иткән. Хезмәттә кешенең холкы, ихтыяр көче, максатка ирешергә, башкалардан начаррак булмаска омтылу хисе тәрбияләнгән. Табигый ки, шәхестәге тискәре сыйфатлар да (көнләшү, саранлык, икейөзлелек һ.б.) шул ук шартларда барлыкка килгән, алар җәмәгатьчелек тарафыннан кискен тәнкыйтьләнгәннәр.

Авылларда һәр кеше бер-берсен яхшы белгән, өлкәннәр балаларның һәм яшьләрнең тәртибен күзәтеп, тикшереп торган. Теләсә нинди баланың тәртип бозуын, гомум кабул ителгән тәртип кагыйдәләрен үтәмәвен мәктәптә бик тиз белгәннәр һәм аңа кисәтү ясаганнар, ә инде мулла мәчеттә вәгазь сөйләгәндә тәртипсез баланың әтисен Коръәндә язылганнарны боза дип халык алдында хур иткән. Башкача әйткәндә, җәмәгатьчелек фикере тәрбия эшенең барышын тикшереп торуда мөһим чара булып торган.

Мәдрәсә (мәктәп)

Россиядәге татар халкының XIX гасыр урталарына кадәр халык өчен дини мәктәп һәм мәдрәсәләре генә булган. Аларда, нигездә, дин сабагы укытылган. Әмма XIX гасырның икенче яртысында табигать-математика фәннәре укытыла торган «җәдиди» мәктәп-мәдрәсәләр күпләп ачыла башлый. Аларда югары мәдрәсәләрне тәмамлаган мулла һәм мөгаллимнәр укыта. Төп дәреслек итеп Коръән файдаланылган. Аны балалар даими укыганнар, аңа аңлатма биргәннәр, барлык укучылар да сүрәләрне, Коръәннең аерым өлешләрен (мәсәлән «Әфтияк»не) яттан өйрәнгәннәр. Дәреслекләрдә милли авторларның һәм көнчыгыш илләре язучыларының мәсәл, гыйбрәтле

хикәя, поэма һәм шигырьләре урын алган. Иң мөһиме, дәреслекләрдә көнчыгыш шагыйрьләренең Корьәндәге әхлакый-этик темаларны тагын да үстерә барган шигъри әсәрләре күп булган. Шәригать кануннары нигезендә һәр мөселманның белемле булуы һәм Коръәнне белүе мәҗбүр итеп куелган. Шуңа күрә XX гасыр башында татар балаларының күбесе үз вакытында иң гади башлангыч мәктәптә булса да белем алган. Бу турыда В.И.Ленин укый, яза белә торган татар крестьяннары башкалар белән чагыштырганда, күбрәк проценты тәшкил иткән, дип яза.

Гаилә

Мөселман гаиләләренең күбесе дини белем алганда үзләштергән әхлакый кагыйдәләр нигезендә яшәргә тырышканнар. Өлкәннәр көн саен биш мәртәбә намаз укыган. Балалар яшьтән үк гарәп догалары белән беррәттән, мөселманның тормыш тәртибе нормаларын үзләштергән. Халык сүзнең көчен чамалый белгән. «Кылыч ярасы китәр, сүз ярасы китмәс», дигән. Тәрбиянең төп коралы сүз булган (чыбык та читтә калмаган). Оят белән намус, шәфкатьлелек, башкаларның кайгысын уртаклашу кебек төшенчәләр балаларга һәм яшьләргә әхлакый йогынты ясый торган төп чара булган. Саранлык, явызлык, сүгенү, комсызлык, Коръән кануннарын бозу (аракы эчү, сүгенү һ.б.), әхлаксызлык сыйфаты буларак, кискен тәнкыйтьләнгән. Тырышып уку, намуслы хезмәт итү, эшне җиренә җиткереп эшләү, түземле, тыңлаучан, итагатьле, кешеләргә яхшы мөнәсәбәттә булу, бигрәк тә өлкәннәрне, ата-аналарны хөрмәт итү һ.б. хупланылган. Мәсәлән, гаиләдәге кечкенә эне һәм сеңелләр өлкән туганнарына «абый», «апа» (ягъни «кадерле») дип мөрәҗәгатъ иткәннәр. Билгеле бер канунга буйсыну яшь кешенең һәрберсенә дип әйтерлек тәртип нормасы булып саналган. Хәтта аз-маз укый-яза белгән крестьян халкы арасында да Коръәнне генә түгел, ә бәлки мәхәббәткә, дуслыкка, тугрылыкка, тыйнаклыкка, гафу итә, кешеләрнең кайгысын

уртаклаша белүгә, юмартлыкка, гомумән, кешедәге уңай сыйфатларга дан җырлаган «Йосыф һәм Зөләйха», «Бакырган», «Таһир һәм Зөһрә» поэмаларын да яттан белүчеләр аз булмаган. Бәетләрне һәм күп кенә поэмалардан өзекләрне халык алдында җырлаганнар һәм сөйләгәннәр. Бәйрәм көннәрендә, мәҗлесләрдә, очрашуларда мөнәҗәтләр көйләү кешеләрне рухи яктан берләштергән. Әхлакый-этик эчтәлекле шигъри әсәрләр белән тулыландырылган очрашулар, дини вәгазьләр кешеләр хисенә көчле тәэсир иткән. Гасыр башында дөньяви белем белән бергә халык аңына социаль проблемалар да сеңә башлый. Мәсәлән, мөселман дин әһелләрендә булган кимчелекләрне ачып салган Габдулла Тукайның социаль юнәлешле шигырьләре бик популяр булган. Әхлакый тәрбия бирүче гореф-гадәтләр гасырлар дәвамында ныгый барган, тотрыклы булган, мөэмин-мөселманнар арасында әхлакый принциплар булдырганнар, шәхестә әхлакый тәртип тәрбияләгәннәр, халыкның ярлы катлавына күп кенә матди һәм әдәп мәсьәләләрен күмәк рәвештә хәл итәргә булышканнар.

Татар мәгарифе үсешенең шул чорында укытучыга тәрбияви мәсьләләрне хәл итү җиңелрәк булган. Беренчедән, мәктәпкә укучылар әдәп-тәртип кагыйдәләрен һәм әхлакый күнекмәләрен җитди үзләштереп килгәннәр. Менә шулар ярдәмендә яшь буында гражданлык сыйфатлары формалашкан. Татар җәмгыятендә рус дәүләтенә ышанмасалар да, «шикләнеп» карасалар да (чөнки халык төрле салымнар түләп, буйсынып яшәп, рекрутчылыктан һ.б. газап чиккән), халык аңында «кече туган ил», «ватан» төшенчәләре мөһим урын алып торган һәм алар кешеләрне күмәк эшләр эшләргә берләштерелгән. Икенчедән, халык Европа илләрендәге кебек үк, кешеләрнең матди һәм рухи тормышын бары тик белем генә үзгәртә алуына, аның иң мөһим булуына инанган. Шуңа күрә балаларны укытуга бик җитди караганнар. Бары тик соңыннан гына алар кешенең барлык тормыш мәсьәләләрен белем генә хәл итмәвен аңлаганнар. Дө-

нья күләм әһәмияткә ия булган вакыйгалар, тормыш шартлары тәэсирендә яшь буынның кыйммәт юнәлеше даими үзгәрә бара...

Беренче Бөтендөнья сугышыннан соңгы чор

Сугышның афәт икәнлеген һәркем аңлый. Сугышлар халыкларга һәрвакыт матди зыян гына китереп калмый, ә бәлки бик зур әхлакый зарар да сала. Яуда, сугышта кеше үтерү күпләргә «хәләл» кебек күренә һәм барлык диннәрнең «үтерү катгый тыела» дигән беренче фаразы белән каршылыкка керә. Сугышта кешелек дөньясы тарафыннан меңнәрчә ел дәвамында тыныч тормышта тупланган әхлакый тыюларның мәгънәсе бетә. Тыныч тормыштагы «ярамый» сүзе дә сугыш вакытында үзенең мәгънәсен югалта, чөнки ул вакытта барысын да эшләргә «камил рөхсәт». Бу каршылык шуның белән дә кискенләшә: җәмгыятьтә синең кешене (дошманны) үтерергә тырышуың хуплана, батырлык мактала торган төшенчәләр рәтенә кертелә, уңай гамәл дип исәпләнә. Шәхеснең күңелендәге каршылык кискенләшә, ул кешенең кыйммәти юнәлешен үзгәртүгә, аның аңын, дөньяны танып белүен, аңлавын бүлгәләүгә китерә. Кеше үзе эшли торган эше белән идарә итә алмый.

Беренче Бөтендөнья сугышында барлык кануннарны, килешүләрне, кагыйдәләрне бозып, христиан һәм мөселман әхлагын санга сукмыйча, кешеләрне ерткычларча күпләп юк итү әдәплелеккә, әхлакка зур зыян китерде. Шуның белән бәйле рәвештә, җәмгыять тормышы, «әхлакый хәл» кискен үзгәрде. Сугыш афәтләре кешенең яшәеш мәгънәсе турындагы гадәти күзаллауларын үзгәртә. Бу шуның белән аңлатыла: беренчедән, шәһәр халкында атеистик аң үсә, Аллага да, шайтанга да ышанмаучылар саны кинәт кенә артып китә. Кешеләрнең күбесенең төп әхлакый принципларны үтәмәве Алла васыятьләренең көченә һәм бу принципларның чын булуына ышанмаучылык тудыра. Кешеләр Ходай васыятьләрен бозуга һәм әхлаксызлыкка җәза бирелмәвен белделәр, ә дәһшәтле сугышның коточ-

кыч һәлакәте аларга тәмуг утыннан да куркынычрак булып тоела. Авыл җирендә урысы-татары тормышында иман әкренләп «сүнә» бара.

Россиядә 1917 елгы революция һәм аннан соңгы гражданнар сугышы тагын да дәһшәтлерәк булды, халыкларның әхлакый аңына, рухи тормышына яңа көчле һөҗүм ясады. Бу сугыш элеккеге тәртип-кагыйдәләрне, гореф-гадәтләрне, кыйммәтләрне юкка чыгарды, чөнки ул һәр гаиләгә, һәр авылга, һәр кешенең аңына үтеп керде. Социаль гаделлек урнаштыру өчен ярлыларның байларга каршы көрәше нәтиҗәсендә бөтендөнья революциясе шигаре (лозунгысы) белән милек тартып алына, «изүчеләр» ерткычларча җәзалана. Берәүләргә булган гаделлек икенчеләргә гаделсезлек булып кире кайта. Җинаятьчелек нык үсә: шәһәрләрдә һәм губерналарда атаманнар һәм «законлы» караклар хуҗа булып тора. 1919 елда кораллы бандитлар хәтта Ленинның үзен дә талыйлар. Идарәче даирәләрнең Мәскәүдә җинаятьчелеккә чик куярга теләгәннәре өчен, шәһәрнең төнге «хуҗасы» әмере белән бер төндә генә дә 22 милиционер атып үтерелә.

Алга таба дини йолаларны һәм гореф-гадәтләрне тыю, дин әһелләрен эзәрлекләү, муллаларны репрессияләү, дингә каршы пропагандаңы киң җәелдерү әдәп-әхлак принципларына төзәтә алмаслык зыян китерде. Эшче-крестьян ир-егетләренә гаҗәп күренә: элек бераүне мәсхәрәләгән өчен, дворяннар, дуэльгә чакырып бер-берсенә аткан булсалар, революциядән соң, сука һәм станоктан килгән «офицерлар» бер-берсен элек йөк ташучылар да кулланмаган әшәке сүзләр белән сүгәләр.

Кешеләрнең киләчәккә ышанычы да үзгәргәнме соң? Аларның тормышны үзгәртүгә керткән өлеше нәрсәгә нигезләнгән? Аллага ышану һәм теге дөньядагы тормыш урынына, сыйнфый көрәш теориясе нигезендә, барлык кеше бертигез яши торган һәм социаль га-

деллек хөкем сөргән яңа җәмгыять барлыкка килү ышанычы, социализмга һәм коммунизмга — барлык кеше әйбәт яши торган җәмгыятькә өмет белән карау туа.

Халыкның күпчелеге җирдә «якты тормышка ышана, совет хакимиятен хуплый һәм күтәренке рух белән басуларда, завод-фабрикаларда, төзелешләрдә эшли. Социаль тигезсезлекне бетерү, милли азатлыкны гарантияләү мисалларында Россия (Советлар Союзы) халыкларында яңа ышаныч һәм бердәмлек ныгый. Совет җәмгыяте халык аңында әкренләп яңа кеше идеалы тудыра башлый. Ләкин 30 нчы елларда кулакларны юк итү һәм репрессияләр, якын кешеләреңә яла ягуны хуплау мичкәдәге балга дегет салуга тиң булды.

Икенче Бөтендөнья сугышы

Киләчәккә өмет баглап халык тынычрак яши башлаган гына иде, яңадан үтереш башланды. Беренче Бөтендөнья һәм гражданнар сугышлары белән чагыштырганда, совет халкының Бөек Ватан сугышында үлүчеләр, яраланучылар, ятим калучылар, тол хатыннар саны күбрәк булды. Фронттагы коточкыч бәрелешләр, тылдагы кыенлыклар, хәерчелек һәм юк ителүләр кешеләрдә кан коюга, үлемгә, явызлыкка һәм югалту, кайгыларга күнегү (хисе) барлыкка китерде. Кешеләрнең үз-үзләрен әхлаксыз тотуы сугыш белән акланылды («война все спишет»), акрынлап ул көнкүреш, тормыш рәвеше нормасына әверелде. Кешене үтерергә өндәү гадәти күренеш дип кабул ителде. Мәсәлән, һәр җирдә дә «Әти, немецны үтер!» дигән плакатлар эленеп торды. Билгеле, алар милләтнең рухи көчен фашизмга каршы туплау өчен кирәк иде. Ләкин шул ук вакытта кеше аңына алар үтерү рухын сеңдерделәр. Тормыш фәкыйрьлеге, хәерчелек хәлне тагын да кискенләштерде. Югарыда аңлатылган рухи җимереклек, күңел яралары тагын да хәтәррәк булып китте.

Совет халкының кайбер катламнарының әхлак дәрәҗәсенең түбән төшүенә бәя бирү бик читен. Беренчедән, җинаятьчелек киң ко-

лач ала, аңа балигъ булмаганнар да тартыла. Икенчедән, көнкүрештәге хулиганлыкка (тупас сүгенү, оятсыз сүзләр әйтү, җәнҗаллар, сугышу, үтереш һ.б.) чик куелмый. Һәр гаиләгә милиционер куеп булмый, ә элек дин һәм халыкның уңай гореф-гадәтләре белән күнеллəргə сеңдерелгән әхлакый тыюлар эшче, крестьян, интеллигенциянең көндәлек тормышыннан юкка чыга барды.

Мисал аз түгел. Җинаятьчелекнең барлык төрләре арасында халыкның күпчелегенең хәерчелеге, матди хәлен яхшырта алмавы тудыра торган караклык, урлашу киң җәелә. Элек авыл җирендә аерым кешеләр генә урлашса, бу чорда байлыкның теге яки бу төрен (икмәк, сөт, йомырка, мал-туар өчен азык һ.б.) алырга мөмкинлеге булган һәркем караклана. Бер кешенең дә намусы борчымый, берәү дә вөҗдан газабы кичерми, урлаганда «үзебезнекен алабыз», ди. «Тирәякта колхоз малы, барысы да минеке...», дип җырлаганнар.

Моны кешеләрнең яшәү өчен табигый көрәше дип тә аңларга була. Күмәк хуҗалык шартларында бушлай хезмәт җитештерү мөнәсәбәтләрендә бу гадәти хәлгә әверелә һәм урлашуны тормыш рәвеше итә, ул гадәткә әйләнә. Һәм моны крестьяннар, күпләп шәһәрләргә күчеп китеп, төзелеш, завод, фабрикалар тормышына да кертәләр. Илдә ирләр һәм хатын-кызлар саны бертигез булмау (хатын-кызлар 23 миллионга күбрәк була!) да зиначылыкның киң җәелүенә уңай тәэсир итә.

Социум (тирә-юнь), хезмәт коллективы, мәктәп һәм гаилә — җәмгыятьнең барлык тәрбияви институтлары матди яктан бертигез дәрәҗәдә ярлы хәлдә, әмма сәяси, идеологик яктан тупланган була. Халыкка сугыш китергән әхлакый зыянга бәя бирү турында әллә ни уйлаучы булмый: ул вакытта партия барлык иҗтимагый мәсьәләләр хакында фикер йөртү хокукын үз кулында тота; мәгариф һәм пропаганда системасы аша халыкны сыйнфый көрәшне мөһим мәсьәлә

дип карауга, сәнгатьтә патриотизмга һәм партиягә тугрылыклы булуга дан җырлау — әхлаклылык ул, дип инандыралар.

Идеологияләштерелгән мәктәп яшь буынны Ленин һәм Сталин эше өчен көрәштә идея ягыннан нык булырга өнди, балаларда батырлык мисалында нык һәм яңа көрәшләргә әзер булу сыйфаты тәрбияли. Шагыйрь һәм язучылар сугыш фажигасе, кешеләрнең әхлакый ныклыгы, фидакарьлеге турында күп язалар, алар җиңү-җиңелүне, кем кемне күбрәк үтерү, куу, юк итү, дошманның җирен-малын тартып алуны күңелләргә сеңдерерлек итеп тасвирлыйлар. Боларның барысы да дөрес, билгеле. Ә аннары безнең балалар сугышны уйнап күрсәтә, уенчык автомат һәм туплардан «дошман»ны «үтерә» башлыйлар. Кеше үтерүнең ярамаганын, кешенең аны кимсетү, мәсхәрәләүнең зур гөнаһ булуын аларга кем төшендерер, ярамаган эш эшләгән өчен кешеләр алдында оят булуын кешенең иң кыйммәтле сыйфаты икәнлеген кем аңлатыр?

Матур әдәбиятта, миллионнар катнашкан зур сугыштан соң, кешенең ни дәрәҗәдә бөек, батыр, инсафлы булуы белән беррәттән, әхлакый яктан түбән төшүе, хайванилыкның киң таралуы ап-ачык күрсәтелгән. Әмма элекке хакимият илдәге чынбарлыкны күз алдына китерә алмый, аның кулында булган рәсми пропаганда уңышлар турында күбрәк сөйли. Шәһәрләрдә яшәү өчен иң гади шартлар булмау сәбәпле, күп кешенең көнкүреш культурасы түбән дәрәҗәгә төшә (мәсәлән, фатир юклык фажигасе); яшьләр арасында дуслыкка, хатын-кызга тискәре мөнәсәбәт киң тарала.

Сәхнә, кино сәнгате, әдәбият, социалистик реализм принцибын кулланып, чынбарлыкка туры килмәгән тормышны кешенең әхлакый югалуын түгел, ә бәлки аның хезмәт тәртибен, партия тормышы нормаларын һ.б. бозуын чагылдыралар. Эре-эре түрәләр һәм вак партократлар бер төрле уйлап, икенче төрле сөйләп, өченче төрле

эшлиләр, яманны – яхшы, караны ак дип атыйлар. Шулай итеп, яшь буынга монафикъ, икейөзле булырга үрнәк күрсәтәләр.

Мондый хәл нәрсә белән аңлатыла соң? Бер яктан, компартиянең сәясәте халык мәнфәгатен яклый, җәмгыятьне игътисадны үстерергә чакыра һәм халык күңелендә бөек төзелешләр энтузиазмы тудыра. Икенче яктан, сугышта һаләк булучылар санына сугыш нәтиҗәләре, матди югалтулар дип кенә бәя бирелә, ул яу кырында югалту нәтиҗәләренең берсе итеп кенә китерелә. Әхлакый, рухи югалтуларга бәя бирелми, чөнки коммунистик идеология тарафыннан бернинди рухилык («духовность») танылмый: «рухи» сүзе үзе генә дә «дини» сүз дип кенә исәпләнә һәм ул «культура» сүзе белән алмаштырыла. Бу исә әхлаксызлык идеологиясенә киңрәк юл ача.

Хәерчелектән хәерчелеккә юлыгып, бер буын артыннан икенчесе «теге дөньяга» китә тора, партия тарафыннан вәгъдә ителгән хокук һәм ирекләр, матди байлык, мул тормыш сүздә генә кала. «Теге дөньяда» «оҗмахта» яшәрсез дип, дин әһелләре вәгъдә иткән кебек, коммунистларның «якты киләчәк»кә ышандырырга тырышуы буш куык булып кына кала. Тормыштан эшче һәм крестьяннарның да, «халык интеллигенциясенең» дә гайрәте чигә... Барлык халыкның дип әйтерлек фәкыйрьлеге (хәзер моны «ярлылыкта тигезлек» дип йөртәләр), рәсми пропаганданың тырышуына карамастан, аның рухи дөньясы үсешенә ярдәм итми.

Кануннар һәркайда да үтәлми диярлек. «Закон – тәртә кебек, кая борсаң, ул шунда карый». Югары чиновниклар үзләре үк: «Законны бозарга ярамый, әмма аны читләтеп үтәргә мөмкин», — диләр. Билгеле булганча, әгәр дә идарәче даирәләр, кеше психологиясен, ихтыяҗын һәм мәнфәгатен үзгәртү белән беррәттән, дәүләтнең социаль–сәяси һәм икътисадый хәлен үзгәртергә өлгерә алмасалар, кешеләр дәүләткә, законнарга, кагыйдәләргә ышанычын югалталар һәм үзләре яши торган дәүләтне һәм аның хөкүмәтен тәнкыйтьли-

ләр. Коммунистлар партиясе догматик (катып калган) идеология һәм фәлсәфәгә нигезләнеп эш иткәнлектән, ул халык алдында үзенең авторитетын югалта.

Партиянең алдан күрүчән аерым лидерлары догматизм һәм консерватизм турында белмәгәннәр, партиядәге, икътисадтагы, идеологиядәге торгынлыкны күрмәгәннәр дип әйтеп булмый. Мәсәлән, Н.С.Хрущев һәм Н.А.Косыгинның партия эшчәнлегендә, икътисадта реформалар үткәрергә омтылыш ясаулары билгеле, әмма алар партократия тарафыннан хупланмый, аларга үзләренең менталитеты да, Суслов кебек идеологик догматиклар да комачаулый.

Шуңа да карамастан, илдә тәртип була. Эшли торган һәр кеше үз вакытында хезмәт хакы ала, халыкка бушлай медицина хезмәте күрсәтелә, ул бушлай белем ала, ел саен 5 миллионга якын кешегә санаторий һәм ял йортларында ял итү өчен юлламалар бирелә, халык җәмәгать транспортында да бушлай дип әйтерлек йөри. Балалар өстенлекле сыйныф итеп санала. Сабыйларның 80 процентка якыны яслеләргә һәм балалар бакчаларына йөри, мәктәп яшендәгеләрнең барысы да белем ала. Кешеләр якты киләчәк булуына өметләнеп яшиләр. Мәгариф системасында укучыларны әдәп-тәртипкә өйрәтәләр, дәүләт җинаятьчелеккә юл куймый, картларны карый, аларның минималь ихтыяҗларын канәгатьләндерә...

XX гасыр ахырына

Шулай да консерватив сәясәт, товар җитештерүнең кимүе әкренләп икътисадны, җәмгыятьне торгынлыкка китерә. Ашкынып коралланууга, Африка хәерчеләрен туендыруга зур чыгымнар тотыла. Икътисадны җимерүдән, җәмгыять торгынлыгыннан дәүләтне саклап калу өчен, җитәкчеләр илне демократияләштерергә дигән карарга килделәр.

Әмма ул рациональ (акыл) дәрәҗәдә түгел, ә бәлки эмоциональ (хисси) дәрәҗәдә генә кабул ителә, партиянең, җәмгыятьнең яңа төр-

рен төзү өчен бернинди фәнни нигезе булмый. СССРны үсеш ягыннан алга киткән бер үзенчәлекле тарихи дәүләт, озак вакыт үсеш һәм демократик институтлары, базар икътисады тәҗрибәсе тупланган, халкы да үзенчәлекле булган Америка Кушма Штатлары тәҗрибәсе нигезендә үзгәртеп кararга уйлыйлар. Бу нәрсәгә китерә соң? Менә шул чорда ярым-йорты белемле, дан-шөһрәт яратучы кешеләрнең идарә башында утыруы дәүләтнең таралуына, икътисадның җимерелүенә һәм халыкның төп массасының тормыш хәле начараюга китерде. Илгә яңадан Россиянең «кыргый капитализмы» урнашты. Һәм бер төркемнең түзем һәм тыңлаучан халыкның 99% ын «кеше кешегә бүре» дигән принцип белән талавы башланды.

Шулай итеп, соңгы дистә елларда мәктәпләрдә әдәп-тәртип, шәфкать-фәлән белмәгән балаларның күбрәк булуы илнең катлаулы тарихы белән дә аңлатыла, XX гасыр ахырында кешеләрдә әхлакый сыйфатларның кими баруы элеккеге объектив сәбәпләр белән үк аңлатыла; әмма алар җәмгыятьтәге яңа буталчык сәяси һәм җимерек иктисадый халәттә тагын да кискенләшә бара. Бу сәбәпләрдә нәрсә үзгәрде соң?

Кешеләрдә әхлаксызлык сыйфатлары арта баруның беренче сәбәбе — идеологиянең алышынуы һәм дәүләтнең таркалуы. Соңгы ун елда социум, балаларны һәм яшьләрне чолгап алган мохит танып була алмаслык үзгәрде. Ирек һәм демократияне беркайчан да күрмәгән россиялеләр нәрсә эшләргә яравын һәм ярамавын белмәделәр. Партиянең генеральный секретаре М.Горбачев, Закон тарафыннан тыелмаган һәрнәрсәне эшләргә ярый, дип сөйләп йөрде. Ә әхлакый нормалар исә бернинди законда да язылмаган, алар кешеләр акылында һәм хисендә, йола һәм гореф-гадәтләрендә сакланып килә. Үзгәртеп кору һәм реформалар башында ялгыш аңлашылган демократия россиялеләрнең күбесен социаль һәм рухи тормышта ярый һәм ярамый торган эшләрне эшләргә этәрде, ул барлык яшьләрне генә түгел, ә

бәлки өлкән буынның берникадәр өлешен әхлаксызлык мохитенә тартып алып керде. Законсызлык, хокук тәртибен бозулар, икейөзлелек (зур сәясәт нәтиҗәсендә дә!), караклык, фәхишәлек һ.б. әхлаксызлык сыйфатлары киң җәелде. Балалар җинаятьчелеге һәм наркомания җәмгыятьнең рухи нигезен җимерә.

Совет чорында хезмәт коллективында, радио, телевидениедә, мәктәптә һ.б. уку йортларында, производствода кеше тәрбияләүдә «көрәш», «класс», «коллектив», «план», «партиягә бирелгәнлек» һ.б. төп термин төшенчәләр булып торды. Ул пионерларга: «Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә әзер булыгыз!» дигән мөрәҗәгать белән башланды. Пионерлар бу чакыруга: «Һәрвакыт әзер!» — дип җавап бирделәр. Өлкәннәр зур җитдилек белән бөтендөнья революциясе өчен көрәш, халыкара империализмга каршы көрәштә пролетар теләктәшлек мәсьәләләре һ.б. турында бик җитди фикер алыштылар. Африка һәм Азия илләрендәге кабиләләрнең һәм халыкларның «суверенитет» өчен көрәшенә ярдәмгә миллионнарча доллорлар җибәрелде. Совет кешеләре аңында көрәш шулкадәр тирән тамыр җәйде ки, тормышта һәрнәрсә көрәшкә кайтып калды. Мәсәлән, хезмәт дисциплинасы өчен көрәш, үткән заман калдыкларына каршы көрәш, партия членнары арасында сафлык өчен көрәш (чүп-чарны себерү түгел — көрәш!) һ.б. яшьләрне зур сәяси максатлар өчен көрәшчеләр итеп әзерләделәр.

XX гасыр башында киң файдаланылган әхлакый төшенчәләрнең күбесе гасыр ахырында тәрбия системасы төшенчәсеннән төшеп калды. Кешенең шәхси сыйфатларын, рухи тормыш эчтәлеген чагылдыручы бу төшенчәләр совет кешесе тормышында бернинди әһәмияткә ия булмаган дини, буржуаз, мистик, мифик төшенчәләр дип саналды. «Бәхет», «җан», «рух», «эчкерсезлек», «шәфкатьлелек», «мәрхәмәтлелек», «кеше кайгысын уртаклаша белү» һ.б. да шундый төшенчәләргә кертелә. Компартия лидерлары 60 нчы еллар-

да «Коммунизм төзүченең мораль кодексы»н раслагач кына үзләренең пропагандистларының ахмаклык эшләүләрен аңладылар шикелле.

Совет чорыннан соң «демократияләштерү» вакытында, «кеше хокукы» дигән төшенчәләр белән беррәттән «рекитер», «карак», «бандит», «башкисәр», «мафиозник», «коррупционер», «бай булу», «малга ия булу», «милекне приватизацияләү», «вазифаны приватизацияләү», «түбә («крыша») булдыру», «тәэсир итүче көчләр» һәм «акча» төшенчәләре һ.б. киң кулланыла башлады. Россиялеләр телендә «булдыру» төп сүз һәм төшенчәгә әйләнде. Әмма Америка фәлсәфәчесе Э.Фромм дәлилләгәнчә, кешенең бәхете бары тик кеше «булуда». Безнеңчә әйткәндә — иманлы булуда.

Элек җәмгыятьтә дини, ныклы әхлакый нигез булмаганлыктан (алар «Коммунизм төзүченең мораль кодексы» нигезендә генә булдыра алмый), **барлык халык та нәрсә тели, шуны эшли башлый**. Карт-карчыклар сексуаль мөнәсәбәтләр «могҗизаларын» телевизордан күзләрен дә алмыйча карыйлар, ә бит АКШта тәртипле гаиләләрнең берсе дә мондый фильмнарны карамый. Хәзер бездә сатыла торган китапларны карагыз: аларда үтереш, суеш, фәхишәлек турында сөйләнә. Балаларның күбесе телевизордан шундый пычрак күренешләрне карап, шундый китаплар укып, анда сөйләгәннәрне, күрсәтелгәннәрне үрнәк дип, әхлак нормасы, дөрес әхлакый тәртип дип кабул итә.

Икенче сәбәп — икейөзлелекне, ялган мәгълүматны киң тарату. Хәзер массакүләм матбугат чараларының төп төре булып телевидение санала. Ул иҗтимагый аңны ничек формалаштыра соң? Ул экраннарда антикоммунизмны котырынып пропагандалап кына калмый, ә бәлки үтерү, талау, көчләүнең иң пычрак, иң куркыныч күренешләрен, шулай ук аерым кешеләрнең һәм криминал төркемнәрнең әхлаксызлыгын, үрнәк алу өчен диптер инде, бик тәфсилләп күрсәтә.

Халык гореф-гадәтендә төпләнгән элекке идеалларның күбесе юкка чыкты; аларны ничек кенә сүкмәделәр һәм сүкмиләр, яңалары исә бөтенләй әхлаксызлыкка корылган.

Массакүләм матбугат чаралары (ММЧ), барлык әйбәт эшләрне пычратып, кешеләрнең идеалларыннан көлеп, россиялеләрнең элекке тормышы турында кеше ышанмаслык ялган хәбәр тараттылар, әокеан артының пычрак тормышын пропагандалау, исәннәргә һәм үлгәннәргә яла ягу — яшь буын аңында җәмгыятьтәге кыйммәтләр турында дөрес күзаллауларын юкка чыгарды. Балаларны аталарына каршы котырттылар. Моңа мисалны күпләп китерергә мөмкин. (Мәсәлән, «Советская Россия» газетасында шушы елның 16 гыйнварында басылган «Оклеветаны живые и павшие» дигән мәкаләне укыгач чәчең үрә тора.)

Җәмгыятьтә әхлаксызлыкның көчәюенең өченче сәбәбе — гаиләнең һаман таркала баруы. Дөнья күләмендә алганда аның таркалуы техноген цивилизациясенең үсеше, халыкларның әхлакый үсеше техник-технологик прогресстан һәм тормыш шартларын «техникалаштырудан» артта калу белән аңлатыла. Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләр, киеренкеләшү (туганнар арасында мөнәсәбәтләр начарлану да) Россиядә 20 елларда ук башлана. Бу авыл халкының күпләп шәһәрләргә күчеп китүе, моның исә соңгы чиктә крестьян авылын тәмам таркатуы белән бәйле. Мондый хәл тагын ике мәсьәләгә йогынты ясый: яшьләр өлкән буыннан аерыла һәм бүгенге көндә хатын-кыз беренче булып эшсез кала. Шәһәрдә фатир алып аерым яшәп, яшьләр үзенең эти-әниләреннән аерылдылар, балалары исә әби-бабаларының әкият сөйләвеннән, китаплар укуыннан мәхрүм калды.

Хатын-кызларыбыз авыр физик хезмәттә генә түгел, ә үзләрен тотышында да ирләр белән бертигез хокуклы булдылар; аракыны аналары гына түгел, балалар да эчә башлады. Гасыр башында иҗтимагый аңда әхлаксызлык дип исәпләнгән нәрсәләр гасыр ахырында

яшьләр аларны гомум кабул ителгән әдәп-тәртип нормасы дип аңладылар.

Шуны билгеләп үтү урынлы: боларның күбесе — алга киткән илләр өчен хас сыйфат. Мәгълүм булганча, техник прогресс дәрәҗәсе югары булган саен, илдә әхлаклылык дәрәҗәсе шулкадәр түбән була икән. Бу Россия өчен генә законлы күренеш түгел. Мәсәлән, Америка — иң демократик, иң хокукый, иң бай ил... Әмма анда җинаятьчелек, наркоманлык, көчләү, талау-урлау, гаиләләрнең таркалуы ифрат күп таралган. Шәригать буенча яшәгән илләрдә генә әдәп-тәртип күбрәк саклана.

Һәрнәрсәнең дә уңай һәм тискәре яклары була. Совет чорында балалар вакытның күп өлешен гаиләдән читтә — балалар яслеләрендә, бакчаларында, мәктәптә, пионерлар лагерьларында үткәрделәр. Узган тормыш белән чагыштырганда гаилә тәрбиясенә караганда җәмәгатьчелек тәрбиясе әһәмиятлерәк була барды. Гаиләдә һәркемне яраталар, һәркемгә игътибар була иде. Балаларга әкиятләр укыйлар иде.

Бүгенге көндә әхлакый тәртип дәвамчанлыгы югалып бетә язды, ул җимерелә барды. Ә советлардан соңгы чорда балалар гаилә тәрбиясеннән дә җәмәгатьчелек күзәтчелегеннән дә мәхрүм калдылар. Хәзер алар «урамда», нигездә, үз язмышлары үзләре кулында, аларның аңы криминал социум тәэсирендә формалаша.

Хәзерге гаиләгә барыннан да бигрәк нинди сыйфатлар хас соң? Гасыр ахырында техноген цивилизациясенең бер казанышы булып хатын-кыз эмансипациясе (аңа һәртөрле ирек, хокук бирү) тора. Европада һәм Төньяк Америкада барлык гаиләләрнең — 50%ы, Россиядә исә тагын да күбрәге таркала. Статистика мәгълүматларына караганда, 1998 елда Мәскәүдә ялгыз яшәүче хатын-кызлар — 22, Парижда — 36, Лондонда — 20% тәшкил итә. 1998 ел ахырына Россиядә ике миллионнан артык сукбай бала һәм әниләре ташлап калдыр-

ган ярты миллион бала исәпләнә. Бу гражданнар сугышы чоры белән чагыштырганда күпкә артыграк.

Әхлаксызлык сыйфатлары арта баруның дүртенче сәбәбе — алкоголизм. Россиядә аракы, исерткеч эчемлекләрне элек-электән эчкәннәр. Әмма бүгенге кебек эчү тарихта беркайчан да булмаган шикелле. Алкоголизм акылның җимерелү процессын туктата алмаслык итте. Шул сәбәпле, акылга зәгыйфь, гарип балалар туа. Россиядә яшәүче һәр гаилә дип әйтерлек алкоголизм фаҗигасе кичерә. Хәзер безнең илдә һәр елны алкоголизмнан 30 меңгә якын кеше үлә, барлык җинаятьчеләрнең, шул исәптән, үтерү, көчләүләрнең 80%ы исерек килеш эшләнә.

Моңа бер мисал гына китереп узыйк: миллионнарча ир-ат төрмәләрдә утырып кайтты. (Россия, һәр мең кешегә күчереп исәпләгәндә төрмәдә утыручылар саны буенча дөньяда беренче урында тора.) Аларның «иреккә», шул исәптә армиягә дә нинди гадәтләр, нинди тәртип алып кайтулары һәркемгә аңлашыла. Шуңа өстәмә рәвештә офицерларның эчкечелек белән шөгыльләнүе төзәтә алмаслык «дедовщинаны» барлыкка китерде, рус армиясен хурлыкка калдырды. Балаларның күбесенә исерек ата-аналарыннан башка үрнәк алырлык беркем дә булмаган вакытта нинди әхлаклелек турында сүз алып барырга мөмкин соң?

Әхлаксезлекнең бишенче сәбәбе — халыкның һаман хәерчеләнә баруы, көнкүреш һәм гомуми культурасы дәрәҗәсе түбән төшүе. Ул элек тә әллә ни югары түгел иде, дәүләт җимерелгәннән соң, кешеләр матур әдәбиятны укымый башлады, кинотеатрларда әдәпсез фильмнар, телевизорда әдәпсез кыланышлар күбрәк күрсәтелә. Өйләрнең беренче, икенче катларының тәрәзәләре тимер рәшәткә белән әйләндереп алынды, подъездлар һәм фатирларга тимер ишекләр куелды, алар серле йозаклар белән бикләнә башлады.

Мондый чакта мәктәп авыр матди хәлдә калдырылды, аңа акча бик аз гына бирелде һәм бирелә. Җәмгыятьнең иң карусыз кешеләре — укытучылар. Әмма «демократик» дәүләт аларны хезмәт хакыннан, икмәктән мәхрүм итте. Ач укытучы әхлаклелек үрнәге була аламы, җәмгыять гөнаһка һәм коррупциягә кереп чумган чакта ул шәфкатьлелек орлыклары чәчә аламы? Бердәм идеологияне юк итү иҗтимагый аңда идеологик вакуум барлыкка китерде. Укытучы моны, беренчеләрдән булып, үз җилкәсендә татыды, ул «җилкәнсез» калды кебек.

Укытучыларның яшь буыны «демократик» пропагандага ышанды, чөнки көн саен колак итен чәйнәп тордылар… Россия мәгариф министрының элекке урынбасары Асмолов кебек кешеләр мәктәп һәм югары уку йортлары программаларына, ил тарихы курсына махсус рәвештә тормышыбызны, вакыйгаларны бозып күрсәтә торган темалар керттерделәр, акны кара дип атадылар. Боларның барысы да өлкән һәм яшь буынның тормыштагы күренешләргә төрле кыйммәти күзлектән каравына, аралары бозылуга китерде, аларны бер-берсе белән дошманлаштырды, гаиләдә, коллективта, җәмгыятьтә кешелек мөнәсәбәтләрен пычратты, мәктәпне таратуга китерде. Хәзер гаилә дә, укытучы да яшәү өчен көрәшә.

Сугышлар (Бөек Ватан сугышы, әфган, чечен сугышлары), 1993 елда Россия парламентын утка тоту һәм «демократияләштерү» күпчелек халыкта кыйммәти юнәлешнең алышуына китерде. Социаль гаделлек, намус, җаваплы булу, оялу, үз-үзеңне лаеклы тоту кебек төшенчәләргә игътибар ителми башлады, яшьләрнең дөньяны аңлавы, дөньяга карашы алышынып бара. «Син кем булырга телисең?» дигән сорауга балалар: «Киллер, рекитер, фахишә буласым килә», — дип җавап бирә башлады.

Элегрәк мәктәп намуслы хезмәткә, туган ил азатлыгы өчен көрәшкә өндәсә, хәзер исә массакүләм матбугат чаралары битләрен-

нән, дәреслекләрдән, рәсми пропагандадан «хезмәт» дигән сүз юкка чыкты. Ә бит хезмәт һәрвакытта да яшьләрне тәрбияләү өчен беренче шарт булып торды. Бүген исә бала намусын һәм шәхес сыйфатларын мәсхәрәләгән өчен, кеше үзен мәсхәрәләүчесен (элекке заманда) дуэльгә чакырып, үлемгә баруын күз алдына да китерә алмый: Лаураның ялан (перчаткасыз) кулын гына күреп кенә дә шагыйрь Петрарканың таңга калуы бүгенге яшүсмергә көлке булып тоела. Без шундый нык үзгәрдекмени? Нәрсәдәдер үзгәрдек, нәрсәдәдер үзгәрмәдек. Кешенең балачакта алган сыйфатлары гомергә кала, диләр психологлар. Ләкин тормыш рәвеше кыргыйларча булса — адәм баласы изгелеген саклый алмый шул. Ләкин без иң әһәмиятле нәрсәдә, менталитетта (ата-бабадан, нәселдән килгән хис-акыл нигезләре), мөнәсәбәтләр әдәбендә Петр I заманына кадәрге вакыт дәрәҗәсендә томана булып калдык шикелле. Чөнки шәфкатьлелекне явызлыктан аерырга өйрәнмәгәнбез, күп кешене адәм баласын талау, үтерү турындагы картиналар, кешелек мөнәсәбәтләрендә кан төсе һәм пычраклык кына кызыксындыра кебек. Россиянең күпчелек халкына бирелгән бич микәнни бу? Россиянең бөек язучысы: «Прощай, немытая Россия, Страна рабов, страна господ, И вы, мундиры голубые, И вы, послушный им народ», — дип безнең хакта әйтмәдеме икән?

Кызганычка каршы, Совет власте чорында халыкның төп массасының югары белем дәрәҗәсе халык менталитетында, аның әхлакый тәртибенә зур йогынты ясый алмады. Дин белән бергә әхлакыят тә каядыр югалды кебек. Россиялеләрнең күбесенең канында колларча буйсыну, холыксызлык, мәрхәмәтсезлек сыйфаты сакланып калды. Ил башында торучы идарәчеләр шулай ук халык арасыннан чыккан кешеләр. «Һәр халыкның идарәчеләре халыкның үзенә лаек була», ягъни “халык нинди булса – идарәчеләр шундый” дигән сүзләр нәкъ безнең хакта әйтелгән шикелле.

Аларның нинди кеше булуын бөтен дөнья ачыктан-ачык күрде... Элек чикмән һәм чабата киеп йөргәннәр хәерчелек, укый-яза белмәүчелек, крестьяннарның тыңлаучан булуы турында сөйлиләр иде. Хәзер шул ук рухи коллар, әмма алар галстук тагып, модалы джинсы һәм чит ил чүпрәк-чапракларыннан тегелгән киемнәр, зиннәтле мех киемнәр киеп йөриләр. Боларның барысы да, кешенең байлык тупларга омтылуы, «кара фикерле» көнләшүе, саранлыгы, комсызлыгы, һәрнәрсәдән файда алырга тырышуы һәм, гомумән, «телле хайван», зат икәнлеге хакында сөйли. Һәм җитәкчеләрне берсүзсез тыңлау, аларның көченә буйсыну, модалы киенергә, акча тупларга омтылу хисе генә калды. Муса пәйгамбәрнең ун васыяте, Коръәннең әхлакый тәгълиматы, бабаларыбызның рухи васыяте — барысы да онытылды кебек...

Әмма барысы да шулай ук начармыни? Юк, әлбәттә, ләкин кешене кеше иткән мөгаллим, укытучыга битарафлыкны ничек яхшы дисең? Шулай ук, үсешнең уңай мисаллары юкмыни? Билгеле бар, әмма алар, караңгы төндәге төтен баганасы күренмәгән кебек, күренми. Бүген кеше идеалы нинди соң? Яшьләр нинди идеалга омтыла соң? Тормышның мәгънәсе нәрсәдә? Болар, үзенең вазифасы таләп иткәнчә, укытучы һәркөнне җавап бирергә тиешле иң читен сораулар. Ләкин ул аларга нәрсә дип җавап бирергә дә белми. Белә дә алмый. Һәм барлык яманлыкны я элекке советлардан, я бүгенге «демократлардан» күрә. Әхлаксызлык проблемасы исә XX гасыр башыннан ук туа, һәм имансызлык чәчәк ата.

Без югарыдагы сорауларга җавапларны мәгарифкә реформа үткәрү нәтиҗәсендә күрәбез. Татарстанда, мәсәлән, милли мәдәниятне яңадан кайтару хәрәкәтендә башлап йөрүчеләр һәм укытучылар гомуми белем мәктәпләрендә һәм гимназияләрендә диннең тәрбияви әһәмияте турында сөйлиләр, түгәрәкләрдә Коръәнне, Библияне өйрәнүне оештыралар, балалар бакчаларында кечкенәләргә кешеләр-

нең үзара мөнәсәтләрендәге мәңгелек кагыйдәләр хакында бәян итәләр, тыйнак, гадел, игелекле булырга өйрәтәләр. Саранлыкның, үз-үзеңне әллә кем итеп тотуның начар сыйфатлар икәнлегенә төшендерәләр. Хәзер дини әхлакый тәрбия бирү турында язылган бик күп китап сатыла, өлкән буын мәчетләрдә гыйбадәт кылуларда катнаша... Дини-әхлакый тәгълимат белән тәрбияләнгән балалар үсеп җитеп, алар өлкәннәр коллективында укый-эшли башлагач кына бу үзенең беренче җимешләрен бирәчәк. Әмма хәзергә җәмгыятьтә бер төркем байлар һәм сан янгыннан бик күп булган хәерчеләр яши. Бүген Россиядә 8 миллионлап эшсез бар, бу актив халыкның 12%ын тәшкил итә. Дөньяда башка мондый ил юк, диләр. Гуманизмны кысрыклап, икейөзлелек һәм ялган хакимлек иткән җәмгыятьтә кешеләр игелекле һәм гадел була алмый. Бу хәл бездә генә түгел. Әнә Гыйрактан соң инде Сербияне дә тупка тоттылар. «Хәзерге вакытта «тәртип» иман һәм гаделлектән өстен булырга тиеш», — ди мәгълүм Киссенджер әфәнде.

Мәгариф нинди булырга тиеш соң? Галим-педагоглар бу сорауга бертөрле генә җавап бирә алмыйлар. Берәүләр — мәгариф элеккеге социаль кыйммәтләргә, икенчеләре — шәхси, өченчеләре — милли-патриотик, дүртенчеләре гадәти гуманистик кыйммәтләргә юнәлгән булырга тиеш диләр. Ә хакыйкать кайда соң? Аны эзләүгә күп вакыт кирәк әле. Шунысы ачык: социаль гаделлектән һәм гуманлы социумнан (җәмгыятьчелектән), гаиләдә әхлакый принциплардан, максатчан белем бирүдән һәм яшь буынга гадәти, әхлакый тәрбия бирүдән башка ил яши алмый. Бусы инде аерым фикер алышуны таләп итә торган тема.

Россия тарихында төрле авырлыклар булган. Эшчән, түземле, киләчәккә өмете өзелмәс халык барысын да кичергән, тырышып-тырмашып үз иманына таянып төрле афәтләрне җиңеп чыккан... Бу

юлы да чыгачак, ләкин дөрес юлны табасы бар, киртәләрне бәреп егасы да яшь буынны хезмәткә һәм әдәп-тәртипкә өйрәтәсе бар.

3.2. Милли тәгълим-тәрбия мәсьәләләре

(Мәгариф №1, 1998)

Матбугатта милли мәсьәләләрнең күбесенә шактый игътибар ителде. Ләкин милли үзаң, яшь буынга тәгълим-тәрбия бирү дә бик мөһим. Туган илгә һәм туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, әдәп-әхлакка өйрәтү, иман нуры тарату, адәм баласын кеше итү бигрәк тә читен, чөнки яшьләрнең бик күбесенең бүгенге кыенлыклардан зиһене тарала, алар дөньяда яшәү мәгънәсенә төшенми башлый. Тукай әйтмешли, «...бөек максат безем» күренми. Һәрбер кеше уртак бәладан ялгыз гына, үзе генә котылырга тырыша. Яшьләрнең күбесе ак белән караны аера алмый, күңеле белән акчага, шул исәптән, хәрам малга алданып яши... Бу хәлне нәкъ Шәехзадә Бабич әйткән сүзләр белән аңлатып була:

Күктә Алла, җирдә иблис, мин малай,

Берсе «син», берсе «мин», дип тарткалый.

Белмимен,

Әллә Алла, әллә иблис алдалый.

Милли хәрәкәтнең һәм җәмгыятьне демократияләштерүнең төп максаты нәрсәдән гыйбарәт? Милләтне бетүдән, үлемнән саклап калу, аның культурасы үсешенә юл ачу — иң олы максатыбыз. Аңа ирешү өчен нинди шартлар тудырасы бар? Бер төркем милләтпәрвәр (яхшы мәгънәдә «милләтчеләр») «Милли әләмгә өч шарт язылырга тиеш, диләр: — латин графикасы; — милли университет; — дәүләт теле».

Бу фикергә киңрәк караш белән анализ ясаганыгыз бармы икән? Халыкның иң зур мәнфәгатьләре һәм бүгенге кайгысы нидән

гыйбарәт? Әлбәттә, рухи азык кына түгел. Халыкның күпчелеге бүген исән калу, ашау-эчү; сәламәтлек, балаларны тәрбияләү, аларга тиешле белем бирү турында кайгыртып яши; аннары сәнгатьтән, нәфис сүздән, музыкадан ләззәт табу нияте уяна.

Латин (яки рус, гарәп) хәрефләре, милли университет, дәүләт теле халыкның бу мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә аламы? Күп илләр һәм халыкларның тарихы һәм бүгенге халәте мондый сорауга нинди җавап бирә? Мисал өчен Латин Америкасы халыкларын алыйк: Алар латин хәрефләре белән генә язалар, телләре дә (испан, португал) — дәүләт теле. Милли университетлары да бар. Алар нигә соң начар яши? Нигә аларда хәерчелек хөкем сөрә? Төркия 70 ел латин графикасын куллана, университетлары да бар, төрек теле — дәүләт теле. Нигә соң халык 6 еллык мәҗбүри укытудан 8 еллыкка күчә башларга кирәк дигән фикергә шунда ук каршы чыкты!? Ник дисәгез — 13–15 яшьлек балалар «тир түгеп таба ашарын». Алар әти-әниләренә булышалар. Бүген татарларның 90%ы тулы урта белемгә ия, 25%ы югары белемле, 10 млн. кешегә күчереп исәпләгәндә, галим, инженер, врач һәм башка интеллигенция вәкилләре саны төрекләрнекеннән 5–10 тапкыр артык!

Димәк, халыкның көнкүреше, рәхәт тормышы хәрефтән тормый, белем, хезмәт, эш эшли белүдән тора! Моны безнең яшь буынның аңына сеңдерәсе бар бит!

Мәгариф. Милләтнең сакланып калу мәсьәләсендә без ике якны күрәбез: тереклек иясе буларак та, милләт буларак та бетүдән сакланып калу өчен, татар халкы аңында яшәү, тереклек көче уянырга тиеш. Милләтне саклап калудан милли мәгариф системасының әһәмияте гаять зур, хәлиткеч дип әйтеп була. Соңгы елларда тәгълим-тәрбия өлкәсендәге шактый нәтиҗәле эш эшләнде. Милли хәрәкәт, җәмәгатьчелекнең милли үзаңы, хакимият башлыклары, президент һәм хөкүмәтнең тырышлыгы мәгарифне

җанландырып җибәрде. Хакимият вәкилләре законнар кабул итеп, татар телен дәүләт теле иттеләр, аңа сәяси игътибарны көчәйтеп, телебезнең абруен күтәрделәр. Ана теле сабый чактан ук өйрәнелсә, ул хәтергә уелып кала, гомергә саклана, дигән фикер бик дөрес. Татар теле ата–ана, укытучылар кулында, әлбәттә, телне саклап калуда журналистлар, гомумән, каләм әһелләренең дә тырышлыклары бик мөһим.

Мөгаллим халкы, мәктәп җитәкчеләре, без халыкка да, дәүләткә дә кирәк әле, дип хәленнән килгәнчә тырышып эшли башлады. Нәтиҗәдә татар мәктәпләре саны артты. Русиянең татар диаспорасы яшәүче 30 лап өлкә, республикасында да ана телендә укыту җанланып китте, мәктәп укучылары саны гына түгел, балалар бакчасында да ана телендә тәрбия алучы сабыйлар саны да нык артты. Милли тәгълим–тәрбиянең беренче нәтиҗәләрен без татар телендә эшләүче мәктәпләр, балалар бакчаларының эшендә күрәбез. Татар мәктәпләрен тәмамлаучыларның югары уку йортларына күпләп укырга керүе дә куанычлы хәл.

Әмма татарларны халык милли мәктәп кенә саклап кала алмый, бу гаять катлаулы һәм авыр бурычны башкару өчен мәгариф халкының гына көче җитми шул. Мәгариф әһелләре милләтне саклап калу юлында педагогик ысуллар белән генә хәл ителмәслек проблемаларга, аларның нигезендә яткан кыенлыкларга, каршылыкларга дучар була.

Тарихка тирән кермичә, аларның берничәсе турында әйтмичә булмый. Мәгариф әһелләренә җәмәгатьчелекнең игътибары, галимнәр, журналистлар, әдипләрнең һәм, һичшиксез, хакимият башлыкларының матди һәм рухи ярдәме зарури. Безнең юлыбызда киртә булып торган каршылыкларның серенә төшенмәсәк, аларны хәл итү юлларын аңламасак, татарча тәгълим–тәрбия, милли аң һәм дөрес идентификация, ана телен саклау, милли мәдәниятне үстерү

максатларына ирешү функцияләрен мәгариф системасы үзе генә башкара алмаячак. Бусы бигрәк тә диаспорага карый.

Татар мәгариф системасына, мөгалимнәргә балаларны чын милли рухта тәрбияләргә нинди кыенлыклар комачаулый? Фәлсәфи анализ шактый күп объектив каршылыклар, тискәре тенденцияләр, гасырлар буе үсеп килгән уңышсыз традицияләр барлыгын күрсәтә. Мәсәлән, татарлар инде күптәннән («тел, лөгать вә әхлак алмашып...»), рус-европа цивилизациясенә тартылганнар, күңелдән үзләрен шәркый халык дип исәпләсәләр дә, Көнчыгыш, гарәп–иран мәдәниятыннан аерылганнар дисәк тә була. Милли үзаңны үстерү өчен татарларның этник, культурологик базалары җитешми, ул йомшак.

Яшәп килгән милли традицияләрдә тәгълим–тәрбия төшенчәсе яңа аңлатма, яңа мәгънә таләп итә, чөнки хәзерге фикерләүгә, тормышны аңлауга, кызыксынуларга яшьләрнең мөнәсәбәте Европа тәэсирендә формалашкан (шәкелләнгән).

Бу каршылыклар тудырган мәсьәләләрне мәгариф халкы үзе генә хәл итә аламы соң? Юк, әлбәттә. Югарыда күрсәтелгән объектив каршылыклардан башка төрле киртәләр дә юк түгел. Мәсәлән, заманасына күрә кеше үзе дә үзгәреп тора, аның психологиясе, дөньяга карашы алмашына, әхлакый сиземләү һәм кешеара мөнәсәбәт, хәят кыйммәтләре, идеологик хаос халәтендә үсмерләр һәм яшьләрнең фикерләве, дөньяви юнәлеше, мәнфәгате, нияте үзгәрә...

Бәлки без милләтне үлемнән саклап калу проблемасын күпертә торганбыз? Юк, чөнки бөтен Русия хәтәр хәлдә. Монда яшәгән халык күптөрле сәбәптән кырыла, үлә, кими башлады. Мәсәлән:

а) үлүчеләр саны туучылар санынннан артты, ел саен Русиядә халык бер миллионга кими һәм бу процесс тизләнә; Татарстанда былтыр үлүчеләр саны туучылардан 4 меңгә артык иде;

б) Русия халкының сәламәтлеге начарлана бара. Элек беткән авырулар (туберкулез, сифилис шикеллеләр) тагын күбәеп китте, яңалары (СПИД, наркомания) зур тизлек белән тарала башлады;

в) элегрәк эчүчелек белән, нигездә, ирләр генә шөгыльләнсә, хәзер хатын-кызлар да, хәтта 10–12 яшьлек балалар да эчкечегә әверелә бара. Бүгенге көндә татар милләте дә күптөрле куркыныч астында яши: сәламәтлек һәм хәерчелектән башка, алкоголизм, наркомания, фәхишәлек соңгы дәрәҗәгә үсеп җитте.

Алкоголизм. Татар халкын физик яктан да, акыл ягыннан да бетерә, имгәтә, юк итә (психик авырулар, исерек килеш шактый кеше үзен–үзе үтерә һ.б.ш.) бу чир. Эчүчелек белән шөгыльләнмәгән гаилә калмады шикелле. Җан башына исәпләгәндә, аракы эчүдә без мөселман халыкларыннан гына түгел, христиан һәм мәҗүсиләрне дә узып киткәнбездер дип уйлыйм. «Юкмы берәр яртың?» исемле шигырендә Роберт Миңнуллин җан әрнүен болай белдерә:

Башкалар да эчә диеп,
Ник эчәсең, татар!?
Алкашларың бер ягыңа
Анасын да сатар.
Эчә синең хатын–кызың,
Эчә яше–картың.
төрле яктан кул сузалар:
«Юкмы берәр яртың?»...
Алла да юк, мулла да юк
Бу татарга бүген.
Хет акырып елап утыр,
Хет кычкырып сүген!..

Бу фаҗигане без аңларга тиеш түгелмени? Алкоголизмга каршы ныклап көрәшергә кирәк. 80 нче елларда бик дөрес башланган кампанияне, яңадан торгызып, дәвам иттерергә кирәк Бюджетка

зыян китерер, дип тормастан, үзебезнең Татарстан Законы кабул ителергә тиеш; җәмәгатьчелекнең фикерен уятып, халыкны эчүчелеккә каршы күтәрмичә, яшь буынны ахмаклыктан, маргиналлыктан, манкортлыктан, үлемнән хәреф алмаштырып кына коткарып булмаячак.

Наркомания өстебезгә шакшы сулар дулкыны кебек килеп төште. Русия яшьләренең 80%ы теге яки бу наркотикны инде татып караган. Аларның күбесе наркоман булмаса да, шактые шуңа ияләшеп китә, кемдер тәмәке кебек «травка» тарта, кемдер химик матдә иснәп исереп йөри, кемдер кулына инә кадый (укол ясый). Бу афәткә каршы тору өчен, шулай ук җирле Закон кабул ителергә тиеш.

Фәхишәлек (проституция) Русиядә тормыш рәвешенә әверелде инде, фәхишәлек һәм җенси авырулар афәте татарларда да — тагын бер милли фаҗига. 12–14 яшьлек рус һәм татар кыз балалары бүген социаль ярдәмгә мохтаҗ. Аларны мәктәп укытучылары гына яман чирдән коткара алмый, әлбәттә. Татарстанда сифилис белән алты йөзгә якын яшь кеше авырый, алар арасында 15–14 яшьлекләре дә бар. Бу — мөселман халкы әхлагына хилаф, коточкыч бәла–каза килгәнен күрсәтүче мисал. Әгәр фәхишәлек һәм җенси авырулар таратучыларга каршы Закон кабул ителмәсә, милли генофондны югалтачакбыз, һәм киләчәк буыннар безне гафу итмәячәге көн кебек ачык!

Гаилә. Адәм баласының күңелендә булган изгелек тә, яманлык та гаиләдә тамыр җәйгән. Тәрбия эше бала бишектә вакытта ук башлана, һәм мәктәпкә кергәнче үк, аның холкы, гадәтләре, күнекмәләре, мөнәсәбәтләре формалашкан була инде. Мәктәп, мөгаллим, тәрбиячеләр укучының шәхси сыйфатларын камилләштерәләр, үстерәләр генә: фәнни белем бирәләр, дөрес

фикерләү ысулларына өйрәтәләр, фикерләү һәм хәтер сәләтләрен үстерәләр, фәнни нигездә дөньяга караш тәрбиялиләр.

Ләкин татар гаиләсенең XX гасыр башында булган тәрбияви функцияләре гасыр азагына чаклы җитмәде, хәзер ул юк дәрәҗәсендә. Мондый хәл бездә генә түгел, әлбәттә. Ул — гомуми тенденция. Гаиләнең тәрбия функцияләре акрынлап дәүләт, мәктәп, мәгърифәт, пропаганда һәм мәгълүмат бирү чаралары кулына күчте.

Халыкта «ана сөте белән кермәсә — тана сөте белән кермәс» дигән сүз бар. Балага милли тәрбия, милли үзаң һәм идентификация мәктәпкәчә яшендә бирелә башлый. Ата-ана тырышлыгы, әби–бабайның йомшак сүзе, гаиләдәге халәт сабыйның холкын тәрбияләргә, дөньяга карашын үстерергә ярдәм итә.

Ләкин татар гаиләсе бүген авыр хәлдә, никахларның яртысы таркала, алкоголик аталар гына түгел, аракыга күнегә барган аналар да акылга зәгыйфь бала таба, тәрбияви бурычларын үтәмиләр, чөнки үти алмыйлар, ялгызак аналар «яшәрә» бара, 15 яшьлекләр тапкан балаларын ташлап китәләр, ятим итәләр, бала табу кими бара, үлем–җитем хәтәр рәвештә арта. Күптән ишетелмәгән туберкулез балаларны аяктан ега башлады, нерв авырулары ишәя, элек юк ителгән сифилистан да хәтәррәк СПИД зур тизлек белән тарала, хатын–кыз хисапсыз аборт ясап, милләтнең тамырына балта чаба... Катнаш никахларны да исәпләсәң, татар халкы физик яктан бетүгә йөз тота, дип фән әһелләре әйтмәсә, кемнәр генә әйтер икән? Минемчә, Германиядә «Гаилә, бала һәм ана» министрлыгы юкка гына оештырылмаган.

Татар халкы, тулаем алганда, үрчеми, кими, кырыла башлады, дип чаң сугарга вакыт түгелмени, милләттәшләр? Мәгълүм булганча, татарларның дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Аның диаспорасын тоталь рәвештә ассимиляциядән саклап кала алмасак, 25–30 ел эчендә зур татар милләте кечкенә бер кабилә

булып кына калачак. Бусы безнең рус белән уртак язмышыбыз, ахры...

Европада «Рим клубы» исемле абруйлы галимнәр һәм сәясәтчеләр берләшмәсе бар. Ул дөньяда булган глобаль тенденцияләрне күзәтеп килә һәм ара–тирә дөньякүләм фаразлар ясый. Мәсәлән, Көнбатыш (ягъни «Запад») Россиянең киләчәген постиндустриаль илләр өчен чимал чыганагы итеп күрә, дигән фикер тарала. Бу планнар нигезендә Русиядә 2020 елларга халык 40–50 миллионнан артмаска тиеш, имеш. Болай булса, татарның саны өч–дүрт тапкыр кимиячәк. Руслашу тизлеген исәпкә алсак, нәкъ шул бер кабилә чамасында гына калачакбыз икән...

Глобаль үзгәрешләр килеп җиткәнче, интеграция процессы көчәя барган хәлдә, Русиянең 30 лап төбәгендә яшәүче татар диаспорасы тел-лөгатен саклап калдыру чараларының берсе буларак, татар телен Русиянең икенче дәүләт теле итәсе иде (Санкт-Петербургта милли–мәдәни автономия барлыкка килү бу фикернең чынга ашарлык икәнлеген раслый). Төп халыктан тыш, сан ягыннан азрак халык яшәгән илләрдә дәүләт теле булып ике тел исәпләнә. Мәсәлән, Финляндиядә 5% швед халкы яши; биредә швед теле фин теле белән бер үк хокукта. Ул да дәүләт теле булып исәпләнә.

Татар телен шундый шартларга куеп, милләтебезне мәдәни асссимиляцияләгән, кызу темпта барган руслашудан берникадәр коткарып булыр иде, бусы диаспорага күбрәк тә карый. Тар функция дигәнем — дәүләт идарәсе, югары белем, армия, индустриаль җитештерү өлкәләрендә татар теле Русиядә мәҗбүри булмас иде. Мондый хәлдә татар теленең абруе үсәр, әлбәттә. Татарлар күпләп яшәгән җирдә милли мәгариф һәм мәдәни тормыш яшь буында кызыксыну, ихтыяҗ уятыр.

Мәктәп–мәдрәсәләрдә тәгълим тәрбия эше кыенлаша бара, чөнки балаларның һәм яшьләрнең психологиясе, дөньяга карашы үзгәреп тора. Мисал өчен аларның кайбер приоритетларын карыйк.

Базар мөнәсәбәтләре шартларында милләтебезнең матди һәм рухи тормышын күтәрерлек көчле чара булып нәрсә хезмәт итә ала? Һичшиксез, милләтнең белем һәм интеллектуаль дәрәҗәсе. Белем — җәмгыятьнең иң югары социаль кыйммәте. Без бүген Көрьәннең зирәк сүзләрен укыйбыз. Шушы бөек цивилизация мирасында бик күп тапкырлар — бары тик уку, гыйлем алу ярдәмендә генә мөэмин–мөселман булып була, диелә анда. Надан һәм тәкәббер коммунистларны шелтәләп, Ленин: «Кешелек дөньясы барлыкка китергән барлык белемне үзләштергәндә генә чын коммунист була алырсыз», — дигән.

Бу файдалы киңәшләр хәзерге яшь буынның аңында ничек чагыла соң? Галимнәр тикшеренүләре күрсәткәнчә, буген укучы һәм студентларның биштән берсе генә (20%ы), белемне югары бәяли. Дәүләт предприятияләрендә эшләүчеләрнең 15%ы, колхоздагыларның 6%ы белем алырга кирәклеген әйтә. Белемгә бәя бирүдә татарның да, русның да фикере бер (милли аерымлыклар юк). Мондый хәлдә мәктәп ничек милли аң тәрбияли ала?

«Җәмгыятьтә тырыш хезмәт белән лаеклы урын алып буламы?» дигән сорауга җавап бирүчеләрнең 7%ы «әйе» дигән, 75%ы катгый рәвештә «юк» дип җавап биргән.

Бу хәлне милләтнең үсеш перспективасы белән ничек бәйләргә? Без, татарлар, гадәттәгечә, гел «мәктәп балалары», дип сөйләшәбез. Бүгенге яшьләрнең гомуми белемгә бер дә исе китми. Һөнәри (профессиональ) белем алуны күбрәк кеше хуплый. Ләкин һөнәри белем бирүнең татар телендә булганы да юк, лабаса! Бу проблема түгелмени? Милли университет кирәк. Әлбәттә. Ләкин меңләгән квалификацияле эшчеләрне, техник хезмәткәрләрне ПТУ һәм

техникумнарда татарча укытмасак, без татар теленең тормышта кирәклеген җәмгыять аңына сеңдерә алмаячакбыз! Телебезнең функциональ көчсезлеге дә шуннан килә, ләбаса!

Нәкъ шул сәбәптән, «Кешенең милләте шәхси карьерасына, тормыш перспективасына тәэсир итәме?» дигән сорауга, рус һәм татар яшьләренең 70 проценты тискәре җавап бирде. Өчтән берсе генә (26%ы. Аларның 11% ын — руслар, 15% ын татарлар тәшкил итә) милләт кешенең киләчәге өчен бик мөһим дип уйлый. Яшьләрнең дәүләт мәсьәләсенә дә карашы шулайрак. Аларның күбесе (Казан яшьләренең — 49, башка шәһәрләрдә яшәүчеләрнең — 64, авылларда торучыларның — 39, русларның — 54, татарларның — 44, чувашларның 33 проценты) Татарстанда тормыш яхшыру перспективасы күренмәсә, читкә китәргә кирәк, дип саный.

Яшьләрнең яртысыннан күбесе Татарстанны эш хакы югарырак булган илгә алмаштырырга әзер торганда нинди милли патриотизм булсын. Алай гына да түгел. «Кешенең җәмгыятьтә абруй–дәрәҗәсе булсын өчен нәрсә кирәк?» дигән сорауга яшьләрнең 66%ы агай–энелек кирәк, дип җавап бирә (шуларның 54%ы — руслар, 52%ы — татарлар, 60%ы — чувашлар).

Әгәр яшьләр бу факторга өстенлек бирсә, киләчәктә кешенең шәхси сәләте, аның язмышы кемгәдер бәйле рәвештә хәл ителәчәк. Кешеләр, иң беренче чиратта, үзләре алдына табыш алуны, ришвәтчелекне куйсалар, тырыш хезмәтнең, хәләл малның кадере бетәчәк, кеше үзе дә сизмичә, коллык дәрәҗәсенә төшәчәк. Бүгенге көндә Русия 176 ил арасында коррупция буенча дүртенче урында тора.

Шулай итеп, яшьләр туган илгә, җәмәгатьчелек әхлагына битараф, үз язмышын хәл иткәндә милләткә игътибарсыз булса, алфавитта хәреф алмаштыру нәрсә бирер икән?

Әдәп–әхлак мәсьәләсе. Без аны дин нигезендә хәл итмәкче булабыз, мөселмән дине традицияләренә өмет баглыйбыз. Һичшиксез, бу — дөрес юлларның берсе. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, яшьләрнең күпчелеге (90%ка якыны) дингә уңай карашта. Дингә гомуми бәя югары булса да, яшьләрнең 12%ы гына, дини тәэсиргә бирелеп, үзендә тормышка яңа караш тудырмакчы, тик 5%ы гына киләчәктә гыйлем алуда, укуда, сәнгатьтә, мәдәнияткә караган эшләрендә дини тәжрибәсеннән файдаланмакчы.

Яшьләрнең дин турында тирән белеме юк, булган хәтлесе тәртипкә салынмаган; аларның 50% диндә булган этик кагыйдәләр белән таныш түгел. Балаларның 10%ы гына Коръәннән аерым аятьләр укый. Яшьләр мәчетләргә йөрми, дип әйтеп була. Татарстандагы 700 имам арасында укымышлы кешеләр күп, дип әйтеп булмый, ләкин татарча ватып–сындырып сөйләүчеләр бар. ??Яшьләр дини мәктәптә укытылырга тиеш, дип саный.??

Кол Шәриф мәчетен төзү — изге эш, моның өчен хакимият башында торган кешеләргә халык мең рәхмәтле булачак. Ләкин әхлакый тәрбиянең әһәмиятен исәпкә алсак, дин мәсьәләләрен хәл итүдә дә хөкүмәттән берникадәр ярдәм кирәк.

Ассимиляция. XX гасыр башында татарларның 80%ы авылларда яшәгән, алар руслар белән бик аз аралашкан; татар балалары гаиләдә һәм авыл халкы күз алдындагы мохиттә үскән, тәрбияләнгән. Мәктәп-мәдрәсәләргә татар телле, милли җанлы, мөселманнарча итагатьле, күндәм балалар килгән. Аларга милли тәрбия бирү мәсьәләсе булмаган дип әйтергә дә мөмкин. Ләкин, тора–бара ярлы-ябагай яшьләр шахталарга, тимер юл төзелешләренә авыр хезмәткә китә башлый. Урбанизация процессы көчәя, рус шәһәрләрендә татарлар ишәя... XX гасыр башында Габдулла Тукай рус белән бергә яшәдек, «... тел, лөгать, вә әхлак алмашып», дип яза.

XX гасыр ахырында татар шагыйре Назар Нәҗми «Ачыну» шигырендә ассимиляцияне болай дип күрсәтә:

Алла да юк хәзер, мулла да юк —
Милләт һәм тел, җыр, моң буталды.
Үз арбаңда башка җырны җырлау
Тыелмады, хәтта хупланды.

Рус телен үзләштерү, рус культурасы белән таныша барган саен, милли аң кими бара, чөнки башка культура тәэсире аны кысрыклап чыгара. Хәзер татар шәһәр баласы, мәктәпкә кергәнче үк, үзендә рус культурасы рухын сеңдереп килә, рус телендә ана теленнән шәбрәк сөйләшә, рус әкиятләре персонажларын яхшы ук белеп килә. Андый балага милли рух, милли аң сеңдереп кара әле син!

Бүген бар өметебез авылда, авыл халкында. Ләкин урбанизация процессы авыл җирендә барлык халыкның 22%ын гына калдырды. Анда да Мәскәү телетапшырулары Казанныкыннан эчтәлеклерәк, матуррак, сыйфатлырак. Шуңа күрә дә һәм югарыда әйтелгән башка сәбәпләр аркасында да, авыл халкы, «балаларыбызны русча укытыгыз» дип, мәктәп директорларына еш мөрәҗәгать итә. Ассимиляциянең тәэсире бик көчле.

Милли хәрәкәт әләменә нәрсә язылырга тиеш соң? Хәзерге хәлгә һәръяклап анализ ясасак, әлеге олы максатка ирешү шартларының иң әһәмиятлеләре, милли хәрәкәт байрагына язылырга тиешлеләре: латин графикасы, милли университет, дәүләт теле дип кенә әйтү беръяклы һәм тар булыр иде. Минемчә, байрагыбызга (әләмгә) языласы милли шигарь (лозунг), халыкның дөньяви ихтыяҗларын исәпкә алып, җитдирәк булырга тиеш:

1) тулы хокуклы милли демократик мөстәкыйль дәүләт (дәүләтнең мөстәкыйльлеген, Конституциябездә әйтелгәнчә, әкренләп киңәйтергә, Мәскәү чиновникларының Татарстан

инициативаларына аяк чалуларыннан котылырга кирәк; демократияне киңәйтү, ягъни хакимиятнең бөтен эшен халык күзәтчелегенә кую (җәмәгатьчелек тәртибендә төзелгән комиссияләргә тапшыру); дәүләт бюджетында һәм бюджеттан тыш булган фондлар акчаларын халык контроленә буйсындырырга);

2) камил язуы булган киң функцияле дәүләт теле (Татарстанда, таррак функциядә — Русиядә) һәм шул телдә дин нигезендә әхлакый тәрбия бирү. Хәреф белән мавыгып, телебездән колак какмагаек; татар китапларын даими укучылар саны зур тизлек белән кими бара, монысы вакытлы матбугат мисалында ачык күренә;

3) татар телендә башлангыч, урта, югары, өзлексез һөнәри (профессиональ) белем бирү һәм базар бәйгесендә (конкуренциядә) җиңеп чыгарлык сыйфатлы товар җитештерү. Финанс, сәүдә, банк, менеджмент һәм икътисад белеме таратылмыйча матди хәлебез үзгәрмәячәк.

Тәгълим–тәрбия эшенең сыйфатын күтәрергә кирәклеге моңа чаклы да билгеле иде. Яңа чорда бу таләп бик табигый. Көн саен диярлек үзгәреп торган баланың психологиясен даими өйрәнмәгән мәктәп үзенең эшен дөрес, нәтиҗәле итеп оештыра алмый һәм алмаячак. Ләкин, ни аяныч, 5–6 ел элек ашыгыч рәвештә әзерләнгән психологлар бүген мәктәпләрдән куыла (акча юклыктан, штатлар кыскартыла, имеш). Демократиянең әле «Д» хәрефе белән генә танышып өлгергән мәктәпләр яңадан, йодрык белән өстәлгә сугып, бугаз көче белән идарә ителүгә дучар булачак, ахрысы...

Латин шрифты буламы, камилләштерелгән кириллица каламы, төзелгән орфография кертеләме - дәүләт теленең функцияләре социаль өлкәгә генә түгел, җитештерү һәм дәүләт белән идарә итү сфераларына да кертелергә тиеш. Халыкның матди ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм телнең функцияләрен киңәйтү хезмәттән, җитештерү өлкәсеннән башка мөмкин түгел.

3.3. Коръән Сүзе татар телендә

"Күктә Аллаһ, җирдә Иблис, мин - малай,
Берсе "дин" дип, берсе "мин!" дип тарткалай..."

Шәйхзадә Бабич

1917 елгы революциянең салкын җилләрендә халыкның "Кемгә ышанырга?", "Кемгә иман китерергә?" дип зиһене таркала башлаган, иман нигезләре ишелеп төшәргә торган заманда Шәехзадә Бабичның бу сүзләре илебездәге рухи афәтне бүгенге чор көзгесендә күрсәтә шикелле. "Кемгә ышанырга?" соравы бүген дә һәр гаиләдә яңгырый.

Коръән - мөселманнарның, шул исәптән татарларның да күңеленә изге Сүз булып сеңгән һәм аларның рухи дөньясын тутырган китап. Укыгач, пакъ сөлгегә төреп, киштәге куеп сакланган язмаларның иң кадерлесе. Элек-электән Коръәнне гарәпчә укый белә торган кешегә астан өскә карый торган булганнар... Моңарчы татар әдәби телендә Коръән булмаган, халык сүрә-аятьләрне гарәпчә яттан бикләп намазларда укыган. Дини белем чыганагы булып ана телендә бер Ногмани хәзрәт Коръән-тәфсире хезмәт иткән. Аерым сүрәләр, аерым аятьләр, хәдисләр, вәгазьләр, аңлатмалар мәдрәсәләрдә дә, гаиләдә дә кулланылган. Әлбәттә, соңгы 10-15 ел эчендә татарча да, урысча да ислам турында бик күп уку әсбаплары китап киштәләрендә урын алды. Сиксән милләт телендә укыла торган Коръән тик татар телендә генә юк иде. Ниһаять, 2000 елның башында татар телендә бер юлы ике Коръән басылып чыкты.

Әйе, бүген ана телебездә басылып чыккан Коръән-Кәрим китабы кулыбызда. Аның турында бик кыска гына мәгълүмат

биреп, тәрҗемәсе тирәсендә фикер йөртәсе килә. Коръәннең беренче нөсхәсен атаклы язучыбыз Рабит әфәнде Батулла тәрҗемә

иткән, икенчесен - Фәрит хәзрәт Сәлман. Яңа басмалар шатландыра: тәрҗемәнең икесендә дә текст бер үк биттә гарәпчә һәм татарча янәшә бирелгән. Татар дөньясы өчен яңалыкмы бу?

Әйе, яңалык!

Коръәннең татар мәдәнияте өчен әһәмияте нәрсәдә?

Кеше күңелен үзенә җәлеп итәр өчен, аның аңына нинди генә белем салмаганнар. Бер-берсенә хилаф дини мәсләк бар, бар фәнни идеология, аларны сугыштырудан кешеләр рухиян зыян гына күрә. Кеше фәнгә таянамы, дингә таянамы - барыбер; аның иманы (ул ышану, инану дигәнне аңлата) - рухи таянычы, өмет баганасы, мәсләге булып тора. Халыкның бер өлеше фәнне түгел, динне иман итеп кабул иткән икән, бик мәгъкуль ("... ләком динуком, вә лийә дин..." (109:6)* - "сезгә үз динегез, миңа үземнеке"). Ирекле илдә адәм баласы йә бусын, йә тегесен сайлап ала икән, моның бер дә зыяны юк, тик кеше имансыз гына калмасын. Ирекнең, хөрриятнең мәгънәсе дә сайлап алырга мөмкинлек булуда. Һәрхәлдә, зыялылар, кешенең психологиясен аңлап, халык белән бергә булырга, аның акылын, фикерләү сәләтен үстерергә, рухи дөньясын киңәйтергә тиеш түгелме соң? Тиеш, әлбәттә. Мондый вазифа галимнәргә, зыялыларга гына түгел, имамнарга да йөкләтелгән. *Сүрә һәм аятьләрнең тәртип саны (2:20 - әйтик, икенче сүрә, егерменче аять, 6:8 - алтынчы сүрә, сигезенче аять).

Коръән - гарәпчә язылган Аллаһ сүзе, һәр мөэмингә турыдан-туры Аның мөрәҗәгате диелә. Ләкин ул Сүзне теләсә кайсы татар ишетми, чөнки тел белми, имамнар гына арадашлык кылып, ул Сүзне кешеләргә җиткерергә тырышалар. Әмма аларның фәнни дә, дини дә әзерлеге хәзерге татар кешесенең интеллектуаль дәрәҗәсенә муафикъмы? Мәдрәсә шәкертләре белән бергә җәмәгатьчелек тә бер ише имамнарның аң-белем дәрәҗәсе белән канәгать түгел, дип матбугатта еш яза башладылар. Галимнәр фәнни белем бирергә

тырышалар, имамнарның бер ишесе, ана телен ватып-сындырып булса да, дини белем тарата. Нәтиҗәдә, халыкка тәгълим-тәрбия ике юлдан бара шикелле. Соңгы йөз ел эчендә киң мәгърифәт, фәнни белем алган халкыбыз кемнең сүзенә ныграк колак салыр икән? Бергәлек юк. Тотрыклы иман да юк.

Бу проблеманы хәл итүдә телнең әһәмияте гаять зур: тел аралашу коралы гына түгел, ул - фикерләү коралы да, кешенең хис-тойгысын белдерү ысулы да, аларны берләштерү шарты да. Фәнни уй-белемне кешеләргә дөрес аңлаткан шикелле, дини белемне дә шулай ук дөрес аңлатырга тиешбез. Халыкның тел культурасын, фикерләү культурасын үстерү өчен, шик юк - мөгаллимнәр һәм имамнарның ана теле остасы, нотык-вәгазь остасы, мантыйк-логика остасы булуы төп шартларның берсе. Алай гына да түгел, укымышлы, киң карашлы, тирән белемле, глобаль фикер йөртә белүче галимнең чын зыялы булуы зарури! Төрле телләргә Изге китаплар тәрҗемә итүчеләрнең күбесе нәкъ шундый зыялылар, югары культура ияләре.

Мәгълүм тәртиптә тәсбих төймәләре тезелеп киткән шикелле телдә дә аерым сүзләр логика кагыйдәләренә буйсынып килгән хәлдә генә чынбарлыкны ачык һәм дөрес чагылдыралар, теге яки бу фикернең эчтәлеген кеше аңына дөрес җиткерәләр. Бусы чит телдән ана теленә тәрҗемәгә күбрәк карый, чөнки төрле телләр бердәм логика кануннарына буйсыну белән бергә, һәрберсе үз грамматикасына да буйсындырылган. Чит телдә булган фикерне ана телен бозып, аны чит тел грамматикасына буйсындырып тәрҗемә иткән чакта тел тәртибе генә түгел, шул телдә фикерләү тәртибе дә бозылуы мөмкин. Бу инде хакыйкатьне дөрес күрсәтмәү дигән сүз.

Коръән аятьләрен тәрҗемә итүгә дә шул ук сүзләрне әйтеп була. Яңа басмалар хәзерге татар әдәби телендә язылган, димәк, ана телендә укый белә торган һәр кеше Коръәннең эчтәлегенә керә,

аның тирән мәгънәсенә төшенә ала дигән сүз. Димәк, тәрҗемәчеләрнең эше мактауга лаек һәм халык аларны үзенең рәхмәтеннән мәһрүм итмәс, дип ышанам.

Коръәннең эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Бик кыска итеп әйткәндә, Коръән күпходалыкка, мәҗүсилеккә, пот-санәмнәргә табынучыларга каршы көрәш коралы ул. Аның иҗтимагый-икътисади, сәяси һәм рухи нигезләре бар. Димәк, "Алла бер" дигән идея белән "күпходалык" идеясе бер-берсенә хилаф, алар туры килмиләр, алар арасында булган идеологик көрәш, ягъни ике мәсләк (мировоззрение, идеология) каршылыкларын бетерү һәм адәм баласына чын хакыйкатьне ачу - Коръәннең төп вазифасы булып чыга. Коръән-Кәрим - изге китапларның иң соңгысы*. *Инглизчәгә тәрҗемәсендә Ришад Халифә (USA, 1992) аны "The Final Testament", "дип атый, ягъни, Коръән - "соңгы васыять" ("Последний завет", т.е. после Ветхого завета - иудейского, Нового - христианского завета).

Коръәннең асылында тирән фикер ята: яһүдиләр, мәсихиләр (христианнар) һәм мөселманнар өчен Хода, Тәңре бер, аның исеме - Аллаһ. Мусага ул Тәүрат китабын иңдергән, Даудка - Зәбурны, Гайсәгә - Инҗилне, Мөхәммәд пәйгамбәргә (салла Аллаһу галәйһи вә сәлләм) - Коръәнне. Мөхәммәд - актык пәйгамбәр. Китаптан китапка Алла үзенең берлеге турында кабат-кабат әйтеп килгән ("тәүхид"). Кешеләргә үз фикерләрен Хак Сүз белән җиткерер өчен ул халыкларга пәйгамбәрләр (рәсүл, нәби) җибәргән. Ләкин кешеләр рәсүлләргә (Адәм, Нух, Мусаларга) ышанмаганнар һәм элеккечә кыргыйлыкта яши биргәннәр - иске заманнарда кан катнаштыру йоласы киң таралган була, күтләклек (гомосексуализм), нәҗеслек чәчәк аткан, кешене корбан итеп чалганнар, кеше үтерү, алдашу, урлашу гадәти хәл булган, сугышып кан коеп яшәгәннәр. Коръән боларны харам (ярамас) кылган, тыйган (6:137; 7:84), ул кешеләргә

гаделлектә, инсафлыкта яшәү өчен хокук нигезләре, кагыйдәләр системасы (шәригать) биргән.

Изге китап - әдәп-әхлак кагыйдәләре бирә, гаиләдә, сүздә, сугышта, үч алуда h. б. эшләрдә ризалык (консенсус), үзара килешү булырга тиешлегенә басым ясый (4:128, 135), намуслы сәүдә турында бик күп төгәл киңәш-нәсихәтләр бирә (2:282), күңел сафлыгы, инсафлык, гаделлек турында сөйли (5:8). Исламга чаклы, җаһилият дәверендә, хатыннарны күп итеп алу, аларны рәнҗетү, малларын талау h.б. хөкем сөргән. Коръән хатын алуны дүрт белән чикләгән, хатын аерып җибәрүне катлауландырган; ятимнәрнең хакын ашаучыларга карата тәртип керткән, бу гадәт тыелган (5:90). Коръәннең асылында шулар ята.

Аллаһның сүзен Мөхәммәд пәйгамбәр (салла Аллаһу галәйһи вә сәлләм) гарәп халкына җиткерә. Ул кабиләдәшләрен, Мәккә гарәпләре булган көрәешләр кабиләсен мәҗүсилектән ваз кичәргә, баш тартырга чакыра, 300ләп пот-санәмнәрне ташлап, Алланың берлегенә ышанырга, итагатьле булырга өнди. Чөнки хакыйкать - яңа дин - Исламда. Ул диннең үз тәгълиматы һәм кешенең тормыш рәвешен үзгәртерлек үз кагыйдәләре бар. Яшәү рәвешенең асылында гаделлек, мәрхәмәтлек, шәфкатьлелек, инсафлык, юмартлык, сафлык, риясызлык ята, дип тәсдикълана.

Мөселман булыр өчен Аллаһның хак сүзенә инанырга, аңа табынырга, итагать кылырга, ахирәт барлыгына ышанырга һәм тиешле фарызларын үтәргә, башкарырга кирәк. Коръәндә әйтелгәннәргә ышанмаган кешеләрне пәйгамбәр табигый афәтләр һәм хәтәр тәмуг уты белән кисәтә, Алланың каргышы белән, төрле җәза белән куркыта да белә.

Кыямәт көнендә һәр кеше тереләчәк һәм Алланың хозурына, хөкеменә киләчәк, кемнең күпме савап, күпме гөнаһ кылганы шунда хисапланачак, үлчәнәчәк. Тәмугъның төрле катламы, төрле төсле

җәзасы барлыгын аңлата, шуның белән куркыта. Мәсәлән, Нух пәйгамбәрнең язмышы турында сөйли, аның пәйгамбәрлеген танымаган кабиләсе туфанда һәлакәткә дучар була (11:89; 32:23). Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә ышанмаган кеше-халык Аллаһның ачы каргышына, табигать афәтенә дучар булачак, ди. Җаһилияттән чыга башлаган халык боларның барысына да ихластан ышанган, әлбәттә.

Бүгенге кеше өчен Коръәннең файдасы нәрсәдә соң? Изге китап кешене бүгенге язмышы турында уйланырга мәҗбүр итә. Тагын басым ясап әйтик, Коръән элек булган кыргыйлыкка каршы чыга: мирас бүлү тирәсендә канлы көрәшне бетерә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала, кагыйдәләр кертә, ришвәт бирү-алуны, риба (процент)ны, аракы эчүне харам кыла. Бүгенгечә әйткәндә, Коръән гуманизм идеяләрен тарата (2:123-185), мин-минлеккә, мөнафикълыкка (икейөзлелеккә) каршы чыга (2:206). Уйлап карыйк әле, элек булган кыргыйлык бүген дә илебездә хөкем сөрә түгелме соң? Вәхшилек, мөнафикълык, көпә-көндез картларны талау, сабыйларны көчләү, мал бүлешеп кеше үтерү - бүгенге халәт түгелмени?

Коръәндәге гуманизм идеяләре кешеләрнең аңына ничек җиткерелә соң? Куркыту белән беррәттән, пәйгамбәр Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә төрле-төрле бүләкләр, нигъмәтләр, рәхәт, бәхетле тормыш вәгъдә итә. Пәйгамбәр сүзен тыңлаучыларга, Аллаһның берлеген танучы кешеләргә, Аллаһы Тәгаләга иман китерүчеләргә, аның кодрәтенә ышанучыларга бүләк булыр, ул бүләкләрнең беренчесе һәм иң зурысы Аллаһның нигъмәтедер, ягъни җәннәттер. Моңа ирешү өчен һәр кеше туры юлдан барырга, Аллаһның берлеген танырга, игелек кылырга тиеш. "Игелек кылуда ярышыгыз" диелә 2 сүрәнең 147 аятендә. Димәк, үтерү дә, кире терелтү дә - барысы да кешене куркытып та, өметләндереп тә бу

дөньяда игелекләр кылуга чакыру, шуңа мәҗбүр итү, мотивация бирү (32:12). Ахыр чиктә - куркытулар, янаулар, өндәүләрнең дә максаты бер - алар инсаниятkә, гуманизмга, кешелекле булырга чакыра.

Коръәннең кешелек дөньясы өчен әһәмияте

Коръән мөселманнар өчен генә, дин әһелләре өчен генә түгел, ул дин, фәлсәфә, тарих белән кызыксынучы барлык кешеләр өчен дә кирәкле китап. "Коръәннең әһәмияте нәрсәдә? Коръән нигә кирәк?" - дигән сорауларга кыска гына бер җавап бар: ул кешеләрне һәлакәттән кисәтә (17:9). Планетабызга атом-төш һәм экология катастрофалары яный, адәм баласы үлем коралларын камилләштереп дөньяны һәлакәткә алып бара... Бу хәлдән котылу юлы бар микән?

Шуңа охшашлы сорауларга борынгылар да җавап эзләгән икән. Коръән кешеләрне тел һәм милләте ягыннан аермый, аларның барысын да бертигез мөселманнар итеп карый. Шул нигездә Коръән төрле телдә сөйләшүче халыкларны берләштерә, халыкара тынычлыкны сакларга, милләтара ыгы-зыгыны бетерергә өнди һәм шуңа ирешер өчен туры юл күрсәтә.

Җыеп әйткәндә, Изге Китапның әһәмияте чиксез зур. Ул - кешелек дөньясының узганы, фикер йөртүе, дөньяга карашы, мәсләкләрнең үзгәреп тору тарихы. Коръәннең әһәмияте - һәр кешенең, кабиләнең, халыкларның тормышын мәгълүм идея нигезендә тәртипкә салуда. Ул - белем чыганагы, хак, хокук, шәригать нигезе. Кеше үзенең хис-тойгыларын аңлап гамәл кылырга тиеш, ди. Ягъни, Коръәндәге әдәп-тәртип, әхлакый нормалар, борынгы халыкка бирелгән киңәш-нәсихәтләр, кагыйдәләр хәзер дә зарур, чөнки бүген дә кеше кешене рәнҗетү, мыскыллау, җәзалау, күпләп үтерү һ. б. шуның кебек хәтәр җинаятьләр бер дә бетми, арта гына бара. Коръән хайвани гадәтләрдән ваз кичү, нәҗеслектән чыгу,

хатын-кызның хокукларын яклау, ятимнәрнең хакын саклау, кешеләрнең яшәү рәвешен гаделлеккә, инсафлыкка корып үзгәртү юлын күрсәтә.

Коръән - дөнья әдәбиятының борынгы үрнәге, шул ук вакытта ул фәлсәфә китабы да. Монда кешелек дөньясының язмышы, Җир йөзендә кешенең тоткан урыны турында фикер йөртүләр, Кешегә, аның яшәү рәвешенә, фигыл-гамәленә карап бәя бирүләр зур урын алып тора (2:282). Шуңа күрә Коръәнгә дин күзлегеннән генә карау җитми, аңа фән күзлегеннән дә карарга кирәк.

Коръән һәм милли идеология

Бу сорауга алда җавап бирә башлаган идем, дәвам итәсе бар. А. Пушкин Коръәнне укып чыккач: "... да притечем и мы ко свету, И да сойдет с очей туман", - дип язган. Күзебезне ачып карыйк әле, яктылыкка чыгыйк, дигән, ягъни дәһи шагыйрь Коръәнне белем, хакыйкать чыганагы итеп кабул иткән, андагы хикмәтләрне үзләштерергә чакырган.

Диннең идеология, мәсләк икәнен беркем дә инкарь итә алмый. Рухи дөньябыз нәрсәгә корылган? Белемгә, иманга. Тик шунсы бар - кемгә иман китерергә соң? Элек Аллаһы Тәгаләгә һәм патшага иман китергәннәр. Аннары сыйнфый көрәш мәсләгенә, коммунистлар идеясенә. Гасыр ахырында яңадан дингә йөз тоттык, урыслар Православиегә, татарлар - Исламга. "Артыңа кара да шөкер кыл, алдыңа кара да фикер кыл". Тирән тарихлы мәдәниятебез нәрсәгә корылган иде? Элек-электән үк - халык иҗатына һәм исламга, аның тәгълиматына, фәлсәфи хикмәт - фикерләренә.

Бүген галимнәр физика, химия динне инкарь итми, дип тә әйтәләр. Рухи бушлыкта калган чорда фәнни белемгә дини белем өстәлсә, кемгә зыян китерер икән? Әлбәттә, элекке идеяләр сөременнән чыкмаган кешенең башында бүген бу хәл төрле сораулар тудыра. Мәсәлән, рухиятның эчтәлеге - дин, иман гынамы,

әллә рухият динсез дә була аламы? Кешенең рухын баеткан, аңа илһам биргән, рухи дөньясын барлыкка китергән илаһи сүз белән янәшә әдәби сүз, моң да бар ич. Музыка, рәсем, образ, сурәтләр, гомумән, сәнгать исламның әхлакый тәгълиматы белән ничек тоташалар, кебек сорауларга да галимнәр күптән җавап эзлиләр, философлар арасында да бәхәсләр сүнеп тормый. Эзләнү тукталмаска тиеш...

Үткән гасырда ике бөтендөнья сугышы кешенең кыргыйлыктан әле һаман чыга алалмаганын дәлилли түгелме соң? Кешенең рухи пакълеге, гаделлеге, инсафлыгы, шәфкатьлелеге турында фикерләр сүрәдән сүрәгә күчә. Мәсәлән, (5:8,90) аятьләрендә Коръән элекке кыргый гадәтләрнең күбесен харам кылган мал-мөлкәтне, мирасны гаделлек белән бүлү тәртибен керткән; ятимнәрне рәнҗеткәннәр икән, Коръән аларның үзләрен дә, хакларын да яклаган. Мәсәлән, (6:137) кешене корбан итү тыелган һ.б.ш. Без барыбыз да шуларны сабый чактан ук белергә тиеш түгелме соң?

Әдәп-әхлак турында

Адәм баласының үзен ничек тотуы Аллаһы Тәгалә теләгәнчә була аламы икән? Коръән бу хакта нәрсә ди соң? Кеше иң элек бик мәрхәмәтле булырга тиеш, башка кешеләрнең, бигрәк тә ятимнәрнең өлешенә кермәскә, киресенчә, аларга булышырга, ярдәм кулы сузарга тиеш, ди. Шул чакта гына кеше чын мөэмин мөселман була ала. Адәм баласы комсыз, зәһәр булмасын иде, диелгән Коръәндә; ул башка кешеләргә йомшак күңелле булырга, аларны рәнҗетмәскә, күрешкәндә ачык чырай күрсәтергә тиеш. Һәр кеше олыларга ихтирам белдерергә, ата-анасын хөрмәт итәргә, үзенең намусын сакларга, харам эштән сакланырга, оялырга, хурланырга тиеш, ярамаган эш эшләргә тиеш түгел, харам гамәл кылмаска, тыелган нәрсәләрне башкарудан баш тартырга тиеш һ.б.ш. Менә шушы фикерләр Коръәннең беренче битеннән башлап азагына хәтле дәвам

итә. Болар барысы да аять артыннан аять, сүрә артыннан сүрәләрнең мәгънәсен ача торган Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле, күңелләргә кереп урнашырлык тәэсирле Сүзе белән аңлатыла.

"Коръән вәгазь һәм нәсыйхәтләрдән тора..." (80:11) диелгән; ләкин башка диннәрдән аермалы буларак, Коръән үгет-нәсыйхәт, куркыту белән генә чикләнми - тәртип бозган өчен җәзасын ахирәттә, теге дөньяда гына түгел, бу дөньяда, көндәлек тормышта ба бирә. Мәсәлән, зина кылган өчен 100 таяк суктыралар (24:2), нахак сүз, гайбәт тарату, нахакка гаепләү өчен - җәза бирелә (24:29,33). Үгет-нәсыйхәт бирә һәм Кыямәт көне турында кисәтә (80:11). Коръән һәм исламның көчле ягы - иҗтимагый, социаль проблемаларны хәл итү юлларын күрсәтү, беренче нәүбәттә - ярлыларны, юксылларны яклау. Ислам гарәп булмаган башка халыкларны да шул ягы белән үзенә җәлеп иткән һәм хәзер дә җәлеп итә (башка диннән Исламга күчү тенденциясенең күп илләрдә көчәя баруы шуны күрсәтә).

Коръәнне ничек өйрәнгәннәр?

Халыкларның бер өлеше Коръәнне исламга керер, иманлы булыр өчен өйрәнгәннәр, икенчеләре - исламга каршы торыр өчен. Европалылар Коръәнне урта гасырларда ук укый башлаган. Христиан дин әһелләре аны "ересь" диләр, буш бер уйдырма дип, ничек кенә хурламыйлар; галимнәр исә бу мәсләк нигезле, дип уйланалар. XII гасырдан башлап, Изге китап башта латин теленә, аннары хәзерге французь, алман, инглиз телләренә тәрҗемә ителә һәм 1716 елны урыс теленә дә килеп керә (француз теленнән тәрҗемә ителгән). XIX йөздә, мәсәлән, Саблуков, христиан дине хасиятеннән чыгып, XX гасырда Крачковский - фәнни максат белән Коръәнне урыс теленә гарәпчәдән тәрҗемә иткәннәр.

Татарлар Коръәнне элек ничек өйрәнгәннәр? Нинди китаплар укып дин турында белем алганнар? Мәдрәсәләрдә Изге китапны,

"иман шарты", "һәфтияк" шикелле уку китапларын һәр көнне укып ятлый торган булганнар. Өйдә дә Коръән укылган, мәчеттә - мулла сүзе алдан йөргән. Биш вакыт намаз кылганда вак сүрәләр яки озын сүрәләрнең аятьләре бик күп мәртәбә кабатланып ятланган. Коръәнне гарәп телендә ятлаганнар. Гасырлар буе күңелдән бикләү, ятлау ысулы булган. Коръән сүзен халык зиһененә сеңдергән. Әле хәзер дә гарәпләрдә, әйтик, 6-8 яшьлек сабыйларның бер ишесе 500 битлек китапны яттан белә.

Совет чоры, аның сәясәте, совет мәгариф системасы исә халыкны диннән читләштерде, яшьләрне дәһри (атеист) итте. Хәзер бу дәһриләргә иман кирәк, дибез, чөнки ул физика, химия белеме белән генә күңелгә керми икән. Бүген бик аз санлы мәдрәсә шәкертләре генә Коръән сүрәләренең мәгънәсен аңларга өйрәнәләр. Ләкин авыр да инде бу гарәп теле! Алар өчен дә ана телендә басылган Коръән кирәк!

Гаҗәп хәл! Изге дип саналган, Кешенең бөтен күңел-тойгыларын сыйдырган Коръәнне татарлар урыс телендә укыйлар, өйрәнәләр, шул нигездә дин турында фикер йөртәләр иде. Ник дисәгез, беренчедән, татар телендә Коръән юк иде; икенчедән, татарларның күбесе ана телен белми, бернинди китап-фәлән укымый! Ә инде латин хәрефенә күчкәч, татарча укучылар саны, һичшиксез, тагын да кимиячәк, әлбәттә.

Коръән теленең үзенчәлекләре турында

Коръәнне татарчага тәрҗемә итү бик кыен икәнен аңлар өчен аның теле турында бераз әйтәсе бар. XX гасыр башында урыс крестьяннарының күбесе сөйләм телендә 800 сүз белән чикләнгәннәр, диелә. Укымаган татарлар да шул ук чамада булганнардыр. Фәнни белемгә ия булу, кешенең сүз байлыгын арттыра, тел культурасын, фикерләү культурасы үстерә.

Хәзерге укымышлы урыс кешесе сөйләгәндә кимендә 4-5 мең сүз куллана (актив сүзлек). Укымышлы татар да шулай уктыр, дип уйлыйм, гәрчә әдәбиятта булган 35 - 40 мең сүз күпләргә таныш булса да (пассив сүзлек). Борынгы төрки-татар телендә сүз күп булмаган, әлбәттә. Унөч-ундүрт йөз ел элек булган рун язмаларын бүгенге татар укый алмый, чөнки тел үзгәргән, сүзләрнең мәгънәләре бүтән. Мәсәлән:

... Иллек будун эртем, -

Илем амти каны?..

Каганлык будун эртем, -

Каганым каны?

Тәрҗемәсез аңлашыламы? Юк, әлбәттә:

... Дәүләтле халык идем, -

Илем инде кайда?

Патшалы халык идем, -

Каганым кайда?

Әле XX гасыр башында гарәп-фарсы һәм төрек сүзләре тулган татар язма телен гади халык ачык аңлый алмаган. Тукайлардан башланып китеп, йөз ел өчендә телебез үзгәрә - сүзлеге арта, грамматикасы камилләшә. Башка халыкларның теле 200 - 300 ел эчендә төрле шивәләрдән бүгенге милли әдәби телгә әверелә*.

*XYI гасырда Мартин Лютер - Рим католиклар чиркәвенә каршы чыгып дингә реформа ясый: Инҗилне (Библияне) латин теленнән немец теленә тәрҗемә иттерә. Еллар үтү белән шул тел халык арасында тарала. Немецләр төрле шивәләрдә генә түгел, бердәм әдәби телдә дә сөйләшергә гадәтләнәләр. Шулай итеп, хәзерге немец әдәби теле барлыкка килә һәм саклана, дип санала.

Нәкъ шундый ук рәвештә гарәп әдәби теле дә барлыкка килә, тик бу хәл күп гасырлар элегрәк һәм көчлерәк дәрәҗәдә була; Коръән сүзләрен бозып әйтергә ярамый, үзгәртү гөнаһ санала,

гарәпләр Коръәнне гасырлар буена көн саен укып яшиләр. Шул рәвешчә гарәп телендә гаять бай сүзлек сакланып, үсеп килә. Кайбер төшенчәләргә бер түгел, уннарча, хәтта йөзләрчә сүз табыла, ягъни синонимнар ишәя. Мисал өчен, "дөя" ("тәвә") төшенчәсен белдерер өчен гарәп телендә 400 сүз бар диләр, арслан төшенчәсен 200 ләп сүз аңлата. Аллаһы Тәгаләнең дә 99 исеме бар. Гарәп теле синонимнарга бик бай тел, шуңа күрә бу телдә тирән фәлсәфи фикерләр дә, гыйльми төшенчәләр дә ансат аңлатыла, рифмалар тиз табылып, шигъри юллар да бик табигый рәткә салына.

Гарәп теленең озын тарихы бар: гарәпләрнең шивәләре милли әдәби телгә әверелүе 1400 ел элек башланган, дип әйтеп була, чөнки Коръән теле халык арасында тарала башлау белән, гарәпләрнең мәдәнияты үсә башлау белән бердәм телгә әверелә.

Хәзерге гарәп әдәби теле белән Коръән теленең аермасы юк түгел, азмы-күпме бар, әлбәттә. Бу ни дигән сүз? Бу - гарәп кешесе Коръән телен укып (ишетеп) яхшы ук аңлый дигән сүз. Ләкин башка телгә тәрҗемә итүче, кагыйдә буларак, әдәби телне дә, Коръән телен дә укымышлы гарәп кешесе кебек үк белә алмый, әлбәттә. Шуңа күрә тәрҗемә итүнең кыенлыклары күп була.

Коръән теленең үзенчәлекләре бар, дидек, алар нәрсәдән гыйбарәт? Беренчедән, ул борынгы тел. Шулай булгач, хәзерге гарәп әдәби телен өйрәнеп алган кеше әлеге үзгәрешләргә сөртенә. Бусы - сүзләрнең мәгънәви үзгәрешләре дә, грамматиканың үзенчәлекләре дә. Икенчедән, Коръән - Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән бербөтен язуга тупланган Аллаһ сүзе, диелә, уй-фикерләр, кагыйдә-күрсәтмәләр китабы. Инҗил (Библия) ул - төрле чорда төрле кеше тарафыннан язылган 74 кечкенә-кечкенә китаплар мәҗмугасы.

Бүген миллиардтан артык мөселманнарның күңелен яулаган, аларның рухи таянычы булган, тәрҗемәчеләрне кыен хәлдә

калдырган Коръән теленең тагын берничә үзенчәлеге турында әйтми булмый.

Сүз көче. Кешене берәр нәрсәгә ышандыру, берәр фикер-идеягә инандыру өчен төрле аһәң тавыш, интонация белән һавада яңгырап, йөрәктән-йөрәккә күчкән Сүздән дә көчле корал юк, диләр. Коръәндәге һәр сүзнең мәгънәсе шул сүрәдәге темага, аятьтәге фикергә бәйләнгән. Борынгы чүл гарәпләренең акылына сыймаслык вазгыятьләрне тасвирлаган сүзләрнең мәгънәләре тирән, җитмәсә алар кабат-кабат аңлатыла һәм шул рәвешчә кешенең күңеленә кереп утыра. Коръәндәге Сүзнең куәтенә хәйран калып, даһи шагыйрь А. С Пушкин болай дигән: "... Не я ль язык твой одарил могучей властью над умами?"

Мөхәммәд пәйгамбәр Алланың сүзләрен еш кабатлый һәм һәрберсенең мәгънәсен тарихи мисаллар китереп ача. Мәсәлән, Нух пәйгамбәрнең халкы ник туфанда һәлак булган? дип риторик сорау бирә дә үзе үк аны болай дип аңлата: чөнки кешеләр Нухның пәйгамбәрлегенә ышанмаганнар, ул китергән хакыйкатьне кабул итмәгәннәр. Муса пәйгамбәрнең халкын фиргавен нигә эзәрлекли? Чөнки фиргавен Ходайның берлеген аңлый алмаган һ.б.ш.

Сүз байлыгы. Коръән теленең беренче үзенчәлеге шунда ки, андагы лексика синонимнарга бай; теләсә нинди мәгънәне яки мәгънә төсмерен чагылдыра торган Алла, дин, фикер, җан, рух, нигъмәт, гаделлек һ. б. шуның шикелле кешенең фикерләү сәләтен югары күтәрә торган абстракт төшенчәләр һәм терминнар күп. Бусы да гарәп теленең көчен, инандыру мөмкинлеген күрсәтә. Икенчедән, китапларның тексты язма телдә, ягъни грамматик кагыйдәләргә буйсындырылган телдә була. Ул шигъри яки прозада (чәчмә) аңлатыла. Коръән ниндирәк телдә язылган соң?

Сөйләм теле. Коръән теле әдәби язма тел түгел, ә бәлки Мәккә мәҗүсиләренең көраеш халкына җиткерергә тырышкан Алла сүзе,

вәгазь сүзләре; ягъни Коръән тексты - Мөхәммәд пәйгамбәрнең вәгазьләрен язып алган сөйләм теле. Алай гына да түгел, Инҗил теленнән аермалы буларак, Коръән телендә сюжетлар бер буйдан, бер-беренә бәйләнеп түгел, өзек-өзек төзелә, факт һәм вакыйгалар бер-берсенә бәйләнмичә, эзлексез рәвештә бирелә, хәтта вакыт-вакыт мәгънә берлеге дә югалып кала. Сөйләм теле - грамматик кагыйдәләргә буйсынмый торган халыкның җанлы теле ул*. *Аермалык язма тел белән сөйләм теле арасында гына түгел, грамматика белән логика арасында да бар, диелә логика фәнендә. "Грамматический строй не является полным торжеством логического строя. Грамматический строй - это структура слова и формы связи и сочетания слов в предложении. Логический строй - это структура мыслей, формы сочетания и связи мыслей в рассуждении. (Н. И. Кондаков. Логический словарь, М, 1971, с. 321.).

Сөйләм теленең үзенчәлеге сүз өзеп әйтүләр, сюжеттан читләшүләрдә, синтаксис нормаларын бозып сөйләүләрдә чагыла. Җөмләдә логик басым ясау, төрле-төрле интонация белән әйтү дә сөйләү телендә үзенчәлекле була. Өченчедән, Коръән текстлары күбесенчә диалог, сорау-җавап формасында бирелә. Дүртенчедән, текстта бик күп тарихи аналогияләр очрый, чөнки Мөхәммәд теге яки бу тезисны тыңлаучыларын ышандырырлык итеп әйтер өчен, аларга мәгълүм булган фактларны күрсәтә, дәлил итеп тарихи аналогияләр китерә, төрле вакыйгаларны тасвирлый, аларга аңлатма бирә, аларны чагыштырып күрсәтә.

Шуңа күрә Коръән теленә ассоциатив фикерләү хас: сүз теге яки бу җирле вакыйгага, шул халыкта гына булган яшәү рәвешенә, гореф-гадәтенә бәйле булган төшенчәне белдерә; мәсәлән, безгә мәгълүм булмаган кабиләләр, шәһәрләр, елгалар, таулар исемнәре, дөяләр, ком сәхрәсе күренешләре турында булган подтекстлар бар.

Бер яки берничә аятьтәге фикер вакыт-вакыт әйтелер-әйтелмәс шикелле беленер-беленмәс формада бирелә. Тәрҗемәче подтекстны укучыга аңлаешлы итәр өчен, андый җөмләләрнең "серен" ачарга өйрәнмичә булдыра алмас. Моның өчен төшенчәне логик яктан үстерү, төзәтү зарур, ягъни интерпретация ысулын кулланырга кирәктер.

Бишенчедән, берничә җирдә җәннәт һәм җәһәннәмнең сыйфаты сурәтләнә (Данте шул сурәтләрне "Божественная комедия"сендә күрсәтә, диләр). Алтынчыдан, кешенең хакын яклап хокук нормалары бирелә, шәригать нигезләре аңлатыла (мирас бүлү кагыйдәләре, хатын-кыз һәм ятимнәр хакын яклау һ. б.). Җиденчедән, харам булган эш-гамәл, азык-төлек, эчемлекләр турында язулар белән рәттән мөселман кешесенең яшәү рәвеше аңлатыла.

Боларның һәммәсе дә кешенең зиһененә сеңдереп аңлатырлык сүз һәм терминнар белән бирелә һәм болар барысы бергә Коръән теленең үзенчәлекләрен тәшкил итә.

Коръән - пәйгамбәрнең күз алдында тыңлап торучы конкрет кешеләргә мөрәҗәгать сүзе. Алар, әлбәттә, Мөхәммәд белән элек очрашканда сөйләнгән вакыйгалар, персонажларны, сөйләгән сүзләрне азмы-күпме хәтерләп белеп торучылар, алар "ярым сүздән" аны аңлаучылар. шуңа күрә дә текстта әйтелер-әйтелмәс сүзләр дә бар, киная һәм элек әйтелгәннәрне искә төшерүләр дә байтак... Хикмәт Коръәндәге теге яки бу вакыйганың әһәмияте булуында түгел, аның мәҗүсилеккә каршы дәлил булып торуында, Аллаһы Тәгаләнең берлеген тәсъдиклавында. Тыңлап торучыларны яки әңгәмәдәшләрне инандыру көче - Сүз, Аллаһ Сүзе (Каләму Аллаһы).

Нәхү кирәкме соң?

Чит телдән тәрҗемә иткәндә без сүзләрнең мәгънәсен белеп кенә дөрес тәрҗемә итә алмыйбыз. Грамматиканы, морфология (сарыф), синтаксисны (нәхү) белү кирәк. Сүзләрнең генә мәгънәсен белеп тәрҗемә итүдән "чыктым аркылы күпер"ләр хасыйл була. Сүзнең төрләнүе, җөмләдәге урыны, башка сүзләр белән бәйләнеш ысулы, хәтта логик басым да сүзнең дә, җөмләнең дә мәгънәсен үзгәртә, һич булмаса, яңа мәгънә төсмере кертә.

Нәкъ менә шундый хәлләрдә сөйләм теленең үзенчәлекләре ачыла, шуның белән ул язма телдән аерылып тора һәм тәрҗемә итәр өчен кыенлыклар тудыра. Коръән текстын тәрҗемә итүче гарәп теле грамматикасын да, татар теле грамматикасын да тигез, яхшы белергә тиеш, шулай булмаса тәрҗемәче атлаган саен диярлек йә гарәп җөмләсенең мәгънәсен, йә татар теле синтаксисын һәм стилистикасын вата. Тәрҗемәчегә нишләргә?

Мондый хәлдә тәрҗемәче вакыт-вакыт теге яки бу фигыльнең грамматик формасын яки алмашлыкның кемгә караганын белә алмыйча аптырый. Элек заманда тыңлап торучыларга ап-ачык булган нәрсәләр бүгенге укучыларда сораулар тудыра. Җитмәсә, Коръән текстында, сөйләм теле булгач, тыныш билгеләре юк, тәрҗемәче җөмләнең башы кайда да, ахыры кайда икәнен аера алмыйча интегә. Изге китаплар тәрҗемәсенә хас кыенлыкларның бер ишесе сүзләрдә дә, әйтемнәрдә дә аллегория, метафора, символизм, куппланлык, полисемия күренешләре булуда. Терминология, үзенчәлекле изгелек лексикасы тирән игътибар итүне таләп итә.

Диалог. Коръән тексты фикерне тоташ бәян итүче сөйләм теле генә түгел, ул - диалог. Пәйгамбәр алдында тыңлап торган кешеләргә Коръән сүрәләренең эчтәлеген аңлата. Аларның сорауларына җавап бирә, үзе риторик сораулар куя да, үзе үк аларга

җавап та бирә... Сорау-җавап формасында бәян ителгән текстта пәйгамбәр төрле образлар тудыра, шулай итеп тыңлаучыларның дикъкатен җәлеп итә генә түгел, метафора, чагыштырулар кулланып, аларның күз алдына рәсем-сурәтләр китереп күрсәткән кебек була; ә рифмалап төзелгән аятьләрне көйләп сөйләү исә кешене күбрәк дулкынландыра, күңелгә аеруча нык тәэсир итә. Берничә мисал китерик. "Аллаһ яманлык эшләргә кушмас. Белмәгән көенчә Аллаһка каршы сөйләргә ничек җөрьәт итәсез?" - ди Мөхәммәд (7:28). Коръәндә: "Аллаһ турында ялган сөйләгән, Аның аятьләрен ялганга чыгарырга маташучы кешедән дә кәбахәтрәк берәү бармы икән?" (7:37). "Аллаһка тиң күреп табынган ялган тәңреләребез кайда?" шикелле риторик сораулар күп. Сез Салихның Раббы тарафыннан күндерелгәнлеген беләсезме (ышанасызмы)? (7:75) - дип сорадылар. Тегеләр исә: "Шик юк ки, без аңа ни иңдерелсә дә ышанабыз" - диделәр. "Алар могҗизаларны инкарь иттеләр. Бак, фетнәчеләрнең ахыры ни белән бетте?" (7:103). Шундый сораулар аятьтән аятькә күчә бара. Мәсәлән, "Мин аларга юри михнәт (сынау вакыты) бирәм, әмма минем җәзам бик тә хәтәр булачак. (Мөхәммәд) тик (алда куркыныч җәза барлыгы турында) кисәтүче генә. Күкләр һәм Җирдәге төзек тәртип (белән идарә итүче Аллаһ икәнлеге) турында уйлап бакмадылармы? Аллаһ яраткан һәр нәрсәгә игътибар итеп, әҗәлнең киләчәгенә ышанып карамыйлармы? Шулай булгач, алар (Коръәннән башка) тагын нинди китапка ышанырлар икән иде?" (7:183,184). Коръәндә Мөхәммәд кем беләндер әңгәмә корган булып сөйләшә, сораулар куя, аларга җавап итеп дәлилләр китерә. Мәсәлән, (10:15) (Аллаһы Мөхәммәдкә әйтә): "Аятьләребезне дәлилләр белән ап-ачык итеп укыгач, (Ахирәттә) Безнең белән кавышырга теләмәгәннәр (мөшрикләр) сиңа": "Юк! Безнең өчен син башка бер Коръән китер яки монысын (безнең файдага) үзгәрт" - дисәләр, син әйт: "Аны

алыштыру яки үзгәртү минем көчемнән килә торган нәрсә түгел. Мин вәхи булып (иңдерелеп) килгәннән башкасына табынмам. Әгәр дә Раббыма каршы баш күтәрсәм, шик юк ки, Хәтәр көннең газабыннан куркам" - диген (26:91). - Алардан: "Күкләрне һәм Җирне кем яраткан? Кояшны, Айны буйсындырып йөртүче кем?" - дип сорасаң, алар мотлак: "Аллаһ, - дип җавап бирер. Шулай булгач, нигә соң алар (иманнан) йөз чөерәләр? (29:61)

Образлы шигъри юллар. Өченче үзенчәлеге - шигъри тел, рифмаланган проза, гарәпчә аны "сәҗгъ" диләр. Борынгы гарәп шигырь законнары безнең поэтик нормаларыбыздан ерак тора. Шуңа күрә, ул тәрҗемәдә генә түгел, гарәпчә укыганда да гарәп булмаган кешегә сизелми. Мәсәлән, "Фатиха"ны белмичә, мәчеткә йөргән кешеләр юк. Ләкин кем аның рифмасын шигъри дип әйтер? "Әл-хәмду-лилләһи раббуль-галәмин, әр-рахмәнир-рахим, мәлик йаумид-дин, иййәәкә нагбуду вә иййәәкә нәстәгыйн, иһдина-сыйрата-ль мөстәкыйм. Шулайрак язганда, "иин" иҗекләре кабатлану күренеп тора. Ләкин гарәп колагы өчен генә. Әмма рифма, кагыйдә буларак, сүзгә, җөмләгә мәгънә төсмере кертә, теге яки бу аятькә логик басым ясый. Ә инде көйләп укылса, эчке ритмикасы да барлыкка килә һәм тыңлаучының хиссиятен уята, күңелен дулкынландыра, үзенә җәлеп итә. Табигатьнең гаять матур күренешләрен сурәтләп, эчке ритмикалы бай җөмләләр белән фикерне җиткерү Коръән сүрәләрендә аз түгел. Мәсәлән, (81:1-14) аятьләрендә болай диелгән: "Кояш бөрешеп сүнгән заманда, йолдызлар сүнеп, егылган чакта, таулар кубарылып хәрәкәткә килгәндә; буаз дөяләр караучысыз калгач, кыргый хайваннар бер урынга тупланган чакта, диңгезләр дөрләп яна-яна бер урынга коя башласа, җаннар үз тәннәре белән кушылган заманда; тереләй җиргә күмелгән сабый кыз баладан, ни сәбәпле сине шулай кылдылар, дип сорар вакыт җиткәч; (гамәл) дәфтәре ачылып, (җинаятьләр) фаш

ителгәндә; Күк урыныннан купкан мәлдә, хәтәр ялкынлы җәһәннәм артыгы белән кызганда; җәннәт мөэминнәргә якынайганда, менә шул чакта һәрбер кеше үзенең кылмышлары белән үзенә ни хәзерләгәнен бик яхшы аңлар". Шулай ук күтәренке рух белән әйтелгән сүзләр бүгенге укучыга да көчле тәэсир итә. Мәсәлән, (89:1-4) аятьләрендә: "Атып килгән таң белән ант итәм; Ун кичәнең изге исме белән ант итәм; Җөп саннар белән так саннар изге булсын; алмашынып торучы көн вә төн белән ант итәм. Башында акылы булган кешеләр өчен ант итәрлек дәлилләр түгелмени болар?". Сөйләм теленең бу формалары тыңлап торучыларга, әлбәттә, тәэсир итми калмаганына без ышанабыз. Шулай итеп, Коръән тексты сөйләүче белән тыңлаучыларның әңгәмәсе булып чыга, уртак фикерләү юлы белән хакыйкатьне дәлилләүгә әверелә. Андый чакта сүзләр белән белдерелгән мәгънә ансат аңлашыла, кешене үзенә җәлеп итә, ышандыра, аның аңына сеңдерелә.

Тәрҗемәләр нинди була?* *Тәрҗемәләр турында бай әдәбият бар: мәсәлән, Крупнов В. П. Лексические аспекты перевода. "Высшая школа", М., 1984; Миньяр-Белоручев Р. К. Общая теория перевода и устный перевод. М., 1980; Чужакин А., Палажченко П. Мир первода или вечный поиск взаимопонимания. "Валент", М., 1997. Халыклар тормышында үзара мөнәсәбәт, бер-береннән өйрәнү-тәрәккыятьнең, үсешнең бик зур чыганагы булып санала. Ул багланышның төп ысулы - Габдулла Тукайчарак итеп әйтсәк - "тел, лөгать вә әхлак илә алмашу". Фикер, белем алмашуда телдән-телгә тәрҗемә итүнең әһәмияте гаять зур. Кешелек тарихында галимнәр тәрҗемә мәсьәләсенә күптәннән игътибар иткәннәр һәм ничек итеп дөрес тәрҗемә итү турында төпле фикерләр әйткәннәр. Безнең эрага чаклы I гасырда Борынгы Римның атаклы галиме Цицерон борынгы грек теленнән латин теленә тәрҗемә итү турында болай дигән: "Чит телдә әйтелгәнне тәрҗемә иткәндә формасы да, эчтәлеге дә, сүз

тәртибе дә сакланып, барлык фикерләре бөтен тирәнлеге белән бирелергә тиеш, сүзләр исә үз теленең тәртибенә туры китереп алынырга тиеш..." (С. С. Толстой. "Как переводить с английского языка", М., 1960, 12б.) Татарлар күп гасырлар буена чит телләрдән, башлыча, гарәп, фарсы, төрки һәм урыс телләреннән әдәби, дини, фәнни эчтәлекле китапларны бик күпләп тәрҗемә иткәннәр һәм бу өлкәдә зур тәҗрибә туплаганнар. Алай да, тәрҗемә турында бер-ике сүз әйтеп китмичә булмас. Тәрҗемә кагыйдәләре арасында бер бик әһәмиятлесен искә төшерик: "Тәрҗемә хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз булмаска тиеш, ди С.С. Толстой, оригиналдан калька тыела. Ягъни тәрҗемәче аерым сүзләрне түгел, ...аерым җөмләләрне түгел, авторның фикерен бөтен нечкәлекләре белән бирергә тиеш" (С.С. Толстой, 12б.). Тәрҗемә теориясендә булган төп кагыйдәләр түбәндәгедән гыйбарәт. Эквивалент юлы - төп нөсхәдәге сүз яки гыйбарә тәрҗемә ителә торган туган тел сүзе яки гыйбарәсенә туры килү: мәсәлән, гарәпчә "китап" сүзе татарча да "китап", гарәпчә "мәдинә", "ражул" татарча "шәһәр", "ир" һ.б.ш. Аналог юлы - төп нөсхәгә бик якын булган сүз яки гыйбарә табу: мәсәлән, гарәпчә "җәмил" татарча "чибәр" ("матур", "гүзәл" дип тә әйтеп була); гарәпчә "салих" татарча "яраклы" ("туры килә", "файдалы" дип тә әйтеп була). Эквивалент һәм аналог нигезендә тәрҗемә итү кыен түгел, дип санала. Иң зур кыенлыклар мәгънә ягыннан чит сүзләргә туган телдә сүз табылмаганда (аның гомумән булмавы да мөмкин) килеп чыга. Мондый хәлдә тәрҗемәчеләр адекват юлы белән тәрҗемә итәләр. Адекватның өч ысулы бар: төшенчәнең логик үсеше (аңлатмалы тәрҗемә, ягъни интерпретация); формасы белән кире яктан килү, ягъни антонимнар тәрҗемәсе; өченчесе - компенсация юлы, ягъни төп нөсхәдәге фикерне башка чаралар белән, бүтән сүзләр белән бирү. Компенсация юлы белән чит телдән тәрҗемә иткәндә текстның нечкәлекләре югала торган очракларда

әйтемнәр, мәкальләр, идиомалар һәм башка махсус гыйбарәләр тәрҗемәсе кулланыла (С.С. Толстой, 14 - 16 б). Сүзлекләрдә, әлбәттә, хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз дип аталган тәрҗемә ысулы кулланыла, ягъни һәр сүзгә икенче телдә шундый ук мәгънәле сүз табыла. Сүзгә-сүз һәм җөмләгә-җөмлә ысулын юлга-юл (подстрочный) дип тә атыйлар. Бу алым шигырьләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә күбрәк кулланыла; чөнки, гадәттә, икенче телле шагыйрь беренче телне белмәве дә мөмкин, ул сүзгә-сүз тәрҗемәдән беренче телдә әйтелгәннең мәгънәсен отып алып, шигырьне үз телендә калыплаштыра. Мондый тәрҗемәне ирекле тәрҗемә дип тә атыйлар. Иң кыйммәтле тәрҗемә, әлбәттә, эквивалент, аналог һәм адекват кагыйдәләре нигезендә мәгънәви тәрҗемә, ягъни бер телдә әйтелгәннең икенче телдә төгәл мәгънәсен бирергә тырышу. Боларның барысы да әдәби текст, фәнни текст, сөйләм телдә булганнарны тәрҗемә итү юллары. Әмма бу урында бер сорау туа: Коръән шикелле "Изге китаплар"ның тәрҗемәсе нинди булырга тиеш соң? XX гасырның уртасына чаклы мөселманнар, кагыйдә буларак, Коръәнне тәрҗемә итәргә алынмаганнар, чөнки тәрҗемә иткәндә изге сүзнең мәгънәсен ялгыш бирү ихтималыннан шикләнгәннәр. Шуңа күрә мөселманнар Коръәннең тәфсирен (аңлатмалы тәрҗемәсен) генә кулланырга тырышканнар. Мәсәлән, гасыр башында татарлар арасында киң таралган Ногмани тәрҗемәсе шундыйлардан санала. Аны гасыр ахырында кириллица хәрефләре белән тагын бер басмасын чыгардылар ("Әль-Коръәну-ль-кәрим", Коръән тәфсире, Казан, 1996, 684 б). Тәрҗемәнең нинди үзенчәлекләре бар? Алдарак Коръән теленең үзенчәлекләре турында сүз барганда тәрҗемәнең кыенлыклары турында әйтелгән иде. Лексика һәм грамматикадан башка сәбәпләр дә юк түгел. Мәгълүм ки, гарәп халкы сәяси һәм икътисади яктан бердәм халык түгел: гарәпләр 22 илдә яши. Сөйләм

теле ягыннан караганда да бердәмлек юк: һәрбер гарәп илендә үз шивәләрендә сөйләшәләр, һәр илдә радио-телевидение тапшырулары җирле телдә башкарыла, әкият, шигырь һәм җыр турында әйтәсе дә юк. Мисырлылар үз шивәләрен яраталар, Сүрия, Ливия кешеләре әдәби телгә якынрак телдә сөйләшәләр, Мәррәкәштә, Алжирда үзгә сөйләм. Ләкин гарәпләрне берләштергән нәрсә - күп гасырлар буе шомарып килгән әдәби тел. Аны саклап калучы - Коръәннән башка бик бай матур әдәбият та бар. Борын-борын заманнардан ук бер үк телдә язма укып килгән гарәпләр төрле илләрендә бүген сүзгә бай әдәби телдә бер үк төсле укырлык китаплар, гәзитә-журналлар чыгаралар. Алай да, хәзерге гарәп әдәби телендәге кайбер сүзләрнең мәгънәләре Коръәндә булган сүзләрдән аерылып тора, чөнки күп гасырлар дәвамында сүзләр дә азмы-күпме алмашынган яки аларның мәгънәләре, һич булмаса мәгънә төсмерләре үзгәргән. Мәгълүм булганча, һәр халыкның үз тарихы, үз тормыш шартлары, яшәү рәвеше, үзенчәлекле үзаңы, үзенә генә хас гореф-гадәтләре, үзенең ассоциатив фикерләү ысуллары була. Ул гореф-гадәтләргә бәйле мәгънәләр, элек булып та хәзер булмаган нәрсәләр белән ассоциатив фикер йөртү һәм сүзгә салынган мәгънә үзгә нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Мисал өчен "фәкыйрь" сүзе хәзерге гарәп телендә "ярлы", "юксыл" мәгънәсен белдерә. Коръәндә исә бу сүз башка мәгънәдә кулланыла: галим-голямә, белем эстәүчеләр, Алла сүзен таратучылар мәгънәсендә килә (текст буенча - аларның көндәлек икмәк эзләп табарга вакытлары юк, шуңа күрә байлар аларга ярдәм итәргә тиеш. Хәзергечә әйткәндә - "спонсорлык" идеясе). Икенче мисал: "ниҗмә" сүзе әдәби телдә "йолдыз"ны белдерә, ә Коръәндә ул "үләннең" бер төрен дә аңлата. В. Порохова нөсхәсендә очраган ялгыш тәрҗемәләрнең берсе әнә шул. Ләкин лексик "караңгылык" моның белән генә чикләнми. Коръән Сүзен тәрҗемә итү җиңел эш

түгеллеген күрсәтер өчен берничә үрнәк китереләчәк. Мәсәлән, икенче сүрәнең 138 нче аятендә болай диелгән: "Сыбгатә Аллаһы вә мән ахсән минәә Аллаһы сыбгатан вә нәхну ләһү гаабидүна". Бу җөмләне ничек тәрҗемә иткәннәр? "Аллаһның күркәмлеге. Кем Аллаһтан күркәмлерәк белән гүзәлрәк икән? Һәм без аңа гыйбадәт кылучылар!" (Ф. Сәлман). "Аллаһның нурына урандык. Аллаһның нурыннан да гүзәлрәк нурны кем бирә ала? Без (бары тик) Аңа гына (гыйбадәт кылабыз) буйсынабыз, диген" (Р. Батулла). Бер үк аятьнең ике вариант тәрҗемәсе килеп чыкты. Кайсысы дөрес? Берсе дә төгәл тәрҗемә түгел шул (соңрак моны күрсәтәчәкбез). Һәр милләтнең аңында дөнья чынбарлыгы үзенчә чагылыш таба, һәм ул чагылыш телне дә үзенчәлекле итә. Мәсәлән, урысча "дождь идет" диләр. Ләкин татар кешесе яңгыр "бара" яки "йөри" дип әйтми, бу табигый күренешкә татар телендә аерым фигыль бар: "яңгыр ява". Шулай ук "птица поет" дигән төшенчәгә дә татар телендә аерым караш: татарның аңында кеше генә "җырлый" ала, кошлар җырламый, "сайрый", ягъни бу күренеш тә аерым фигыль белән аңлатыла. Шундый ук мисаллар башка телләрдә дә бар, шул исәптән гарәп телендә дә. Шуңа күрә ике телне дә бер үк дәрәҗәдә яхшы белгән кеше генә төгәл тәрҗемә итә ала, дип әйтәләр. Ә инде 1400 ел элек Коръәндә әйтелгән сүзләрнең үзенчәлеген белеп бетереп буламы икән? Фикер йөртү үзенчәлегенә мисал: Коръәндә (17:29) "Кулыңны үз муеныңа бәйләмә" диелгән. Аның мәгънәсе - "саран булма". 11 сүрәнең 40 аятендә борын заманнарда "мич кайный" гыйбарәсенең мәгънәсе су ташкыны башланды, "туфан башланды" мәгънәсендә йөргән.

Коръәннең тәрҗемәләре хакында. Без урысча чыккан Коръәннең кайсы тәрҗемәләреннән файдаланабыз? 80 еллар азагында Коръәнгә ихтыяҗ тугач ук, халык урысча И. Ю. Крачковскийның тәрҗемәсеннән файдалана башлады. Аның

тәрҗемәсе фәнни максат белән башкарылган6 автор тарафыннан тәмамланмаган, алай да бик күп санда тарала, бигрәк тә соңгы ун ел эчендә, дингә игътибар артып киткәч. И. Крачковскийның тәрҗемәсе юлга-юл "подстрочная форма" дип санала. Аны хәтта хәрефкә-хәреф тәрҗемә дип тә атарга мөмкиндер (отличается "нарочитым буквализмом" - В.Д. Ушаков). Тәрҗемә аңлашылмауга, ялгышка, мәгънәнең югалуына, хәтта текстның "караңгылыгына" китерә, диләр. Шуңа күрә И. Крачковский тәрҗемәсен укыганда, кеше күп кенә аятьләрнең мәгънәсен аңламый, ярым-йорты гына аңлашылган текст аркасында Коръән изге китап, дини истәлек булып хәтердә калмый. Мәгънәви тәрҗемәләрнең бер үрнәге итеп галимнәр Валерия Порохова нөсхәсен күрсәтәләр. Бу автор Коръәннең эчтәлеген урыс телендә халыкка җиткерүчеләрнең иң зурысы булды. Монда ирекле тәрҗемә ысулы белән шигырь формасында бирелгән аятьләр җиңел укыла, ләкин аларның бер ишесе мәгънәсенә бер дә туры килми, "Алла кәлимәсе" урыны-урыны белән бозыла. Мәсәлән, В.Д. Ушаков күрсәткән хаталар турында гына әйтик. Порохова тәрҗемәсендә Муса пәйгамбәр "хайваннар өчен агач башларыннан җим кагып төшерә" (20:112). Гомумән, галимнәр В. Порохованы урыс теле стилистикасына да зыян китергән, дип тә язалар, рецензиясез, фәнни редакциясез чыккан, дип тә әйтәләр. Гарәп галимнәре дә борчылып сөйлиләр, "Коръәнне шигырь иткән", диләр. Тәрҗемәченең максаты укучыларга Коръәннең тулы мәгънәсен җиткерү, аны аңлаешлы итү, әлбәттә. Ләкин В. Порохова тәрҗемәнең тышкы ягына гына түгел, аның эчке әдәби-нәфислегенә җитәрлек игътибар итмәгән. Мәсәлән, Коръәндә булган антропоморфизмнар (кешегә хас сыйфатларны хайваннарга, әйберләргә күчерү) төшеп калган, "Хода йөзе", "Хода кулы" шикелле тәрҗемә ителми торган сүз тезмәләре бирелмәгән, тәрҗемәнең образлылыгы киметелгән, ди профессор В. Д. Ушаков.

Инглизчәдән урысчага тәрҗемә. Коръәннең төрле телләргә тәрҗемәсе бар, дип әйтелде инде. Инглиз теленә Коръән соңгы мәртәбә гарәп теленнән Әхмәдия мәзһәбе тарафдары Маулана Мөхәммәд Али тарафыннан да тәрҗемә ителә, 1917 елда ул Китап Англиядә бастырыла һәм Гарби (Көнбатыш) илләрендә киң тарала. Шуннан соң аның инглиз телендә генә дә 15 ләп басмасы чыга. Бу тәрҗемәнең төп аермасы - киң фәнни шәрехләүгә, тарихи аңлатмаларга бай булуында. 1997 елны бу Китап инглизчәдән урысчага доктор А. Садецкий тарафыннан тәрҗемә ителеп, АКШта басылып чыга.

Урысча соңгы тәрҗемә. Белгеч буларак, доктор Ушаков өр-яңа тәрҗемәләр арасында дагстанлы профессор Мөхәммәт-Нури Османов китабына югары бәя бирә. Ләкин бу хезмәттә дә кимчелекләр барлыгын әйтә. Мәсәлән, аңлатмалар күбрәк тәфсирләргә, мөселман факиһлары (дин белгечләре), галим-голямәләре (ислам белгечләре) күрсәткән фактларга, дөньяви хәлләргә таянып эшләгән, И.Ю. Крачковскийның комментарийларыннан артыгы белән алынган, диелә. Шулай да М. Османов күп кенә фактлар, терминнар, төшенчәләргә аңлатмалар бирмәгән, дип яза В. Д. Ушаков. Мәсәлән, икенче сүрәнең 255 аятендә: "аның тәхете җир һәм күкләрне ала" дигәнне "җир һәм күкләр аңа буйсына" дип ялгыш тәрҗемә ителгәне күрсәтелә. Дөньяви төшенчәләр Коръән телендә "изгелек", илаһият төсмерләре ала. Мәсәлән, "тәхет" сүзе Коръәндә бөтен дөньяны үз эченә ала һәм изгелек (эзотерик) функциясен үти торган төшенчә безнең аңыбызда берәр патшаның утыра торган урындыгы булып кузаллана. Шуңа күрә аны мәгънәгә зыян китермичә генә тәрҗемә итеп тә булмый шикелле. Изге китапларның эзотерик (иррациональ) ягын читтә калдырырга ярамый, чөнки аларда яшерен, ягъни гайрегыйльми

(бүгенге фәнгә мәгълүм булмаган) мәгълүматның булуы бар. Бусы да Коръән тәрҗемәләренең бер үзенчәлеге.

Коръәннең татарчага тәрҗемәсе. Коръәнне бер үк телгә ничә тапкыр күчереп була? Изге китапны тәрҗемә итү тарихы - үзе генә дә бу Китапның тирән эчтәлегенә, аның мәгънәви рухына, әдәби нечкәлекләренә үтеп керү тарихы ул. Һәр тәрҗемә камил тәрҗемәгә ирешү максатының бер баскычы диләр, ләкин тулы, мөкәммәл тәрҗемәнең булуы шикле, чөнки һәр тәрҗемәнең үз кимчелекләре бар. Шуңа күрә тәрҗемәченең бурычы 100 процентка үтәлергә мөмкин дә түгел шикелле... Тәрҗемә Коръәннең серләренә төшенү, стилистик, әдәби-нәфислегенең үзенчәлекләрен күрсәтү юлының берсе булып кына кала. Коръәннең татарча беренче тексты XX гасыр башында басылып чыккан дип санала. Фән күзлегеннән караганда, Ногмани тәрҗемәсе - ул Коръән-тәфсир тәрҗемәсе, ягъни аңлатмалы тәрҗемә. Тәфсирдә, аңлатмада һәрвакыт авторның субъектив карашы тәкъдим ителә. Кәръән-тәфсир - укучының үзенә фикер йөртергә урын калдырмый торган дини аңлатма. Шуңа күрә, галимнәр Коръәннең төгәл тәрҗемәсе кирәклеген исбатлыйлар. Яңа, чын мәгънәсендә тәрҗемә танылган татар язучысы Рабит Батулла тарафыннан башкарылган. Шул сәбәпле аның теле дә хәзерге, халыкның күпчелегенә мәгълүм, татар әдәби теле. Тулаем алганда, Батулла Кәръән тәрҗемәсен, кыенлыкларны җиңеп, уңышлы башкарып чыккан. Язучы аны асылда төрекчәдән алып эшләде, әмма Ногмани варианты да исәпкә алынмады түгел, алынды. Аннары Коръәннең төрле телләрдә тәрҗемәләре булуы да ярдәм итте. Урыс телендәге текстларга да игътибар булмады түгел, булды. Аннары редактор Коръәннең татарчага тәрҗемәсен гарәпчәсе белән чагыштырып, тикшереп, тиешле җирләрдә төзәтеп чыкты. Коръәнне татарчага тәрҗемә итү телебезгә йогынты ясамый калмас, аның дини генә түгел, фәлсәфи, сәяси, иҗтимагый терминнары да

активлашачак, артачак һәм татар теленең үз элекке (урыс теленнән азат) стиленә кайту юлларына тәэсир итми калмас, дип уйлыйм. Коръәннең элек-электән үк телебезгә, фикер йөртү рәвешебезгә йогынтысы зур булган, әлбәттә. Мисал өчен генә әйтик, татарныкы икәненә шик тудырмаган "Күңел күзе белән күрмәсәң, маңгай күзе - ботак тишеге" дигән мәкаль бар, ул Коръән теленнән кереп калган икән (22:46). Телебездә бик күп гарәп алынмалары бар, Коръән текстын ана телендә укыгач, аларның мәгънә төсмерләре ачыкланачак, әлбәттә. Шулар арасында иман, хөррият, хак, хакыйкать, харам, хәләл, инсаният, канун, вөҗдан, фикер, зыялы, дөнья, рух, рухият, намус шикелле абстракт төшенчәләр фикер йөртүдә кешенең гомумиләштерү мөмкинлеген киңәйтәләр. Мондый сүзләрнең күбесе күптән татарлашып беткән, читтән кергәнлеге хәтта сизелми дә, ләкин сөйләм телебездә аларның күбесе актив кулланыла, дип әйтеп булмый.

Тәрҗемәнең кыенлыклары. Соңгы дистә ел эчендә татар телендә шактый күп илаһият әдәбияты мәйданга чыкты дигән идем. Алар арасында Коръәннең аерым сүрәләр, аятьләр, хәдисләр, догалары тәрҗемә ителгән. Бу мәкаләдә дүрт китаптан мисаллар алынды: Ногмани хәзрәтнең тәфсир тәрҗемәсе, (Казан, 1996), Җәлил хәзрәт вәгазьләре (Казан, Мәдәни җомга, 1998), Батулла (Казан, 2000), Сәлманның (Казан, 2000) Коръән тәрҗемәләре. Шуннан алган кайбер мисалларны тел белеме җәһәтеннән карап, чагыштырып күрсәтмәкчебез. Коръән кебек бөтендөнья мәдәниятенең хәзинәсен теләсә кем "ирекле рәвештә" тәрҗемә итәм, дип, мәгънәләрен бозып күрсәтү телебезгә дә, фикер йөртүебезгә дә, һичшиксез, зыян китерә. Шуңа күрә дин әһелләре генә түгел, фән әһелләре дә моңа игътибар итми калмас, дип ышанам.

Буяумы, мәсләкме, чукындырумы? Алдарак икенче сүрәнең 138 аятен ике төрле тәрҗемәсен күрсәткән идек. Бу мисал бик

гыйбрәтле, чөнки Коръәндә күпмәгънәле сүз, кагыйдә буларак, бер генә мәгънәсендә кулланыла, әйтик, әлеге "Сыйбгат" сүзенең берничә мәгънәсе бар. Тәрҗемәчеләрнең бер ишесе аны төрлечә аңлап, төрлечә тәрҗемә итәләр. Мәсәлән, урыс теленә ничек күчерелгән? XX гасыр башында Г. С. Саблуков: "Мы по крещению Божию; и кто лучше того, кто по крещению от Бога? И ему мы поклоняемся" (Г. С. Саблуков. Коран, перевод с арабского, третье издание, Казан, 1907). Нигә Саблуков мөселманнарның Изге Китабының сүзләрен болай тәрҗемә иткән? Чөнки ул, православие миссионеры, гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә христиан (мәсихләр) дини терминнар кулланган һәм башкача аны бирә дә алмаган! "Без" сүзенә юкка гына басым ясамаган, ягъни без христианнар "кто по крещению от Бога, тому и поклоняемся". Димәк, "сыйбгат" сүзенең мәгънәсе - "чукындыру" ("крещение"). В. Порохова да шул ук юлдан барган: Вот таково крещение Господне, а может кто-нибудь помимо Бога - лучше окрестить? И лишь ему мы предаемся! (Коран. Перевод Пороховой. - Дамаск, 1998). "Сыйбгат" сүзен еш кына "буяу" ("краска") мәгънәсендә язалар. Америкада басылып чыккан "Священный Коран" китабында болай диелгән: "(Мы берем) цвет Аллаһа, и кто лучше Аллаха в расцвечивании, и мы Ему поклоняющиеся*"). *Тәрҗемәче А. Саденцкий коментарий: да "сыйбг" сүзендә "буяудан" башка "суга төшерү" мәгънәсе дә бар дигән. Шуннан мөселман булмаган кайбер тәрҗемәчеләр "сыйб" сүзеннән "чукындыру" мәгънәсен чыгаралар, чөнки чукындыру суга төшереп башкарыла. Ләкин шул ук автор "сыйбгат" сүзенең "дин" мәгънәсе дә бар ди, дин кешенең рухи дөньясына яңа төс кертә, аның мәсләген үзгәртә. Шул ук "сыйбгат" сүзе (2:138) төрек теленә ничек тәрҗемә ителгән? "Син Аллаһның буявына бак! (Вафтиз де не ки!) Кем Аллаһыдан да матуррак буяу буйый белер? Иште биз она ибадет еденлериз!" (Куръәни-кәрим... Истанбул, 1994). Икенче

берәү шул ук телгә болай тәрҗемә иткән: "Сез Аллаһның биргән төсен алыгыз. "Без аңа гына табынабыз, диегез". (Куръән-хаким. Истанбул. 1998). Димәк, төрек теленә "сыйбгат" сүзе күбесенчә "буяу" дип алынган. Ләкин "сыйгат" - күп мәгънәле сүз. Гарәпчә-урысча сүзлектә аның мондый мәгънәләре күрсәтелгән: "Сыйбгат - 1) краска; 2) цвет, окраска; оттенок; 3) характер; (напр., характер доклада и. т. п.); 4) мнение; направление; исповедание". (Баранов Х. К. "Арабско-русский словарь". - М., 1957, с. 539.) Нигә урыс яки төрек тәрҗемәчеләре "сыйгат" сүзенең беренче мәгънәсен генә алганнар? Мәгълүм түгел. Дөрес, бу сүзнең күп мәгънәлелеген истә тотып тәрҗемә иткән авторлар да бар. Мәсәлән, гасыр башында татар теленә Ногмани тарафыннан болай тәрҗемә ителгән: "Коръән хөкемнәре Аллаһ динедер, шул дингә керегез! Аллаһ диненнән күркәмрәк дин булырмы? Шулай булгач, Аллаһ динен кабул итегез һәм Аллаһка гына гыйбадәт кылабыз һәм аңа гына итагать итәбез, диегез!" Озынрак сүзле булса да, Ногмани бу аятьнең мәгънәсен дөрес биргән. Монда сыйбгат" сүзе "дин" мәгънәсендә алынган, андый мәгънә дөрестән дә бар. Моны зур галим И. Ю. Крачковский да күргән, ул "По религии Аллаха! А кто лучше Аллаха религией? И мы ему поклоняемся!" дип тәрҗемә иткән. Әлеге аятьнең урыс, төрек, татар теленә күчерелгән вариантларын күрдек. Инглиз теленә тәрҗемә итүчеләр бу аятьне ничек аңлыйлар икән? Менә бер вариант: "SUCH is GODs system, and whose system is detter than GODs? Him alone we worship". (QURAN. The final Testament (Рашад Халифа тәрҗемәсе, март, 1992, США). (Татарчасы: "Шундый ул Ходайның "системасы", Кемнең системасы Ходайныкыннан яхшырак? Аның үзенә генә без табынабыз!". "Дин", "мәсләк" сүзен монда "система" сүзе белән биргәннәр. Һәм дөрес тә: "сыйбгат" төшенчәсе Аллаһның мәсләге, дине, тәгълимат системасы булмый нәрсә булсын? Гарәп дөньясында иң абруйлы Коръән-

тәфсирләрдән "Җәләләйн"("ике Җәлил") дип аталган тәфсир бар (Коръән-тәфсир. Бәйрут, 1992). Анда 138 аятьне ничек аңлатканнар? "Сыйбгат" сүзе төрле мәгънәдә булса да, Коръәндә ул "дин", "мәсләк" мәгънәсендә алынган, диелә. Кыска аңлатмалы гарәп теле сүзлеге "Әл-Мөнжәд" бу сүз турында нәрсә ди? Монда да "суга төшерү" мәгънәсе бар, ләкин төп мәгънәсе "дин" дигән (Әл-Мунжад". Бәйрут, 1956). Димәк, "сыйбгата Аллаһы" төшенчәсе "Аллаһның төсе", "Аллаһның буявы", "чукындыру"лар түгел, әлбәттә, "Аллаһның дине", "Аллаһның мәсләге" (ислам диненә алып бара торган юлы), Аның фикере, принцибы, карашы дисәк, дөрес булыр. "Бәкара" сүрәсенең 138 аяте болай тәрҗемә ителергә тиеш: "Аллаһ дине, Аллаһ мәсләгеннән яхшырак (дөресрәк) мәсләк кемдә бар. Без Аңа табынабыз!" Бер генә мисал белән булса да, Коръән теленнән тәрҗемә итүнең кыенлыгы күрсәтелде шикелле. Теге яки бу аятьнең мәгънәсен төрлечә аңлап, төрлечә тәрҗемә итүләр Коръән тәрҗемәләрендә аз түгел. Ләкин күбесенчә мәгънәви, компенсация ысулы белән тәрҗемә ителгән нөсхәләр дә очрый. Тәрҗемәләр ирекле дә була, дидек. Ләкин һәр ирекле тәрҗемәнең чиге була, барыбер төп нөсхәнең мәгънәләрен бозарга ярамый. Төп нөсхәдәге мәгънә ана телебездә дә шул мәгънәдә аңлатылырга тиеш. Бу фикерне түбәндәге мисаллар белән дәлилләп була. Җәлил хәзрәт нөсхәсе турында. Алда әйтелгән Коръән тәрҗемәләренең үзенчәлекләрен күз алдында тотып, Җәлил хәзрәт китабыннан берничә мисал китереп карыйк. Монда без өч мәсьәләгә игътибар итәр идек: 1) тәрҗемә үзенчәлекләре; 2) фонетик язылыш үзенчәлекләре; әлиф-ләм язылышы; 3) синтаксик үзенчәлекләр. Җәлил хәзрәт вәгазь сөйли һәм үзенең сүзләренә дәлил итеп Коръәннән аерым аятьләр китерә. Сүрә эченнән "йолкып" алынган аятьләрнең мәгънәләре алдарак килгәннәрдән өзелеп, бозылалар. Гарәп теле синтаксисы татар һәм урыс телләре синтаксисларыннан

логикасы белән аерылып тора. Мәсәлән, ирекле тәрҗемәләрнең 41 сүрәдән алынган 33 аятьнең бер үрнәге. Гарәпчә: "Вә мән ахсән каүлән-мим-мән дагаа илә Аллаһы вә гамилә салихан-вә калә "иннәни мин-әль муслимиина". Татарча: "Аллаһы янына өндәгән, игелек кылган һәм "мин мөселман" дип әйтүчедән яхшырак кеше бармы?" Җәлил хәзрәт тәрҗемәсендә ул болай бирелә. "Минем сүзләремне адәм балаларына җиткерүчедән дә сөйкемлерәк кеше юк" (20б.). Ләкин аятьнең мәгънәсе башка, анда яхшы кеше булуның өч шарты күрсәтелгән: Аллаһы янына чакыручы, өндәүче, игелек кылучы, үзен мөселман дип танытучы. Җәлил тәрҗемәсендә боларның берсе дә юк; аятьтә булмаган мәгънә - "Минем сүзләремне..." - күрсәтелгән. Ләкин гарәп грамматикасына игътибар итмәүчеләр үк аятьне мәгънә ягыннан дөресрәк тәрҗемә итсәләр дә төрле авторда төрлечәрәк килеп чыга. Мәсәлән, шул ук аятьне Ногмани китабыннан карыйбыз: "... Ислам динен кабул итәргә кешеләрне чакыручы мөселманның сүзеннән дә күркәмрәк, файдалырак сүз булырмы һәм ул һәркайда әйтелер: мин мөселман, бу эшләрне эшләргә мин бурычлымын, дип..." (41:33). Болай киң иттереп күчерү, минемчә, тәрҗемәгә түгел, аңлатма, тәфсирләргә хас. Дөресрәк тәрҗемә ителгән вариантны без Р. Батулла нөсхәсендә күрәбез: "Аллаһка юнәлергә өндәгән һәм дә үзе дә игелекле гамәлләр кылган вә: "Мин мөселман!" - дигән кешенең сөйләшүеннән дә тәмле сүзле башка берәү бармы икән?". "... Тәмле сүзле башка берәү" юк шул, чөнки Коръәндә юк. Бер үк аятьне төрле редакциядә, башкарак мәгънәдә бирүләр еш очрый. Мәсәлән, Ногмани нөсхәсендә: "... Аллаһы нигъмәтләгән пәйгамбәрләр, турылык белән алга чыккан ситдыйклар, Аллаһы юлында сугышып шәһит булган мөэминнәр... Шушы дүрт төрле затларга юлдаш булу - ни күркәм, ни хуш юлдашлыклар" (4:69). Шул ук аятьне Р. Батулла болай тәрҗемә иткән: "Кем Аллаһка вә Рәсүлгә итәгать итсә, менә

шулар Аллаһ тарафыннан хуп күрелгән пәйгамбәрләр, гадел вә тугры булган ситдыйклар, шәһидләр вә игелекле адәмнәр белән бергә булачаклар. Алар гажәеп аркадашлар". Янә берничә мисал. Ногмани: "Тәхкыйк бу кәферләрдән элгәре кәферләр пәйгамбәрне ялганга тоттылар, аларга минем мәкерем газаб белән тотмагаклыгым ничек булды?" (6:18). Р. Батулла аны болай язган: "Хактыр ки, алардан элек яшәгәннәр дә моны Коръәнне ялганга чыгарды. Ләкин минем аларга китергән җәзам нинди дәһшәтле булды". Бусы оригинал текстка якынрак. Әмма барыбер бер үк аятьне икесе ике төрле тәрҗемә итә. Бишенче сүрәдәге сигезенче аятьне Ногмани болай тәрҗемә итә: "Әйе, Аллаһ хөкем итүчеләрнең гадел хөкем итүчеләре түгелме? Барча кешене гаделлек белән хөкем итмәсме?" Батулла: "Аллаһ иң гадел хөкемдарларның иң гаделе түгелме?" Урысча: "Разве Аллах не лучший из судей?" (Священный Коран). Димәк, Ногмани тәрҗемәсендә татар теле аксый, Батулла русчасы-адекват тәрҗемә, "судья"ны "правитель" белән алмаштырган. Җәлил хәзрәтнең икенче китабының 52 битендә бу аять кабатлана: "Аллаһы Тәгаләнең сүзен кешеләргә җиткерүче кешедән дә күркәмрәк кешеләр булмас" дип тәрҗемә ителгән. Җөмләнең гомуми мәгънәсе ялгыш түгел түгелен, ләкин шулай ук тәрҗемә адекват түгел: Аллаһ сүзен кешеләргә җиткерүче сүзләре дә, андый мәгънә дә бу аятьтә юк. Гарәпчә "яхшырак" (кеше турында) сүзен бер урында “сөйкемлерәк", икенче урында "күркәмрәк" сүзләре белән тәрҗемә итүнең зыяны юк, киресенчә, ул текстны матурлый гына. Минемчә, дөресрәк варианты болай булырга тиеш: "Аллага иман китергән, игелекләр кылган һәм "мин чынлап та мөэминнәрдән" дип әйткән кешедән дә яхшырак кем бар?". "Вә мин шарри гасикын иза вакаба" (113:3). " - (Айны) каплаган караңгылык яманлыгыннан Аллаһка сыенам" дигән аятьне Җәлил хәзрәт болай биргән: "наданлыктан, караңгылыктан, үз-үзенә ясаган

золымнардан, Аллаһым, Үзең сакла, Сиңа гына сыенамын". Бу аять Батуллада ничек әйтелгән?: "Дөм караңгы төннәрдәге мәкердән... Саллаһка сыенам".

Фәрит Сәлман тәрҗемәсе турында. Тәрҗемәчеләр күп көч куйган булсалар да, аларның хезмәтләре кимчелекләрдән хали түгел. Әйтик, Фәрит Сәлман хәзрәтнең тәрҗемәсендә урыны-урыны белән татар теле логикасы аксый шикелле. Коръән кебек фәлсәфи, гаять катлаулы китапны тәрҗемә итәр өчен гарәп телен һәм ислам фарыз-гадәтләрен, дога-намазларын яхшы белү генә җитми шул. Үз телеңне яхшы белү дә төп шарт булып тора. Ф. Сәлман нөсхәсеннән берничә мисал алып карыйк. "Аерылдырылган хатыннар үзләре белән өч күрем сагалап торырлар..." (2: 228). Татар телендә "аерылган" хатыннар була, "аерылдырылганнар" очрамый кебек. Шул ук аятьтә: "...Аллаһ карыннарында яратып булдырганны аларга яшерергә рөхсәт ителмәс..." (2:228). Бу җөмләне башка тәрҗемәләр аша гына аңлатып булыр дип уйлыйм. В. Порохова: "... И им запрещено сокрыть, что богом создано в их чреве..." Крачковский да: "... Что сотворил Аллах в их утробах..." Димәк, Аллаһ карыннарында бала яралган түгел, дип аңларга кирәк. Моны Батулла әфәнде бик ачык татарча әйтеп бирә: "... Аерылган хатыннар, әгәр алар Аллага ышансалар, Ахирәт көненә инансалар, үз карыннарындагы (беренче иреннән балага узганлыгын) яралгысын яшерсә, хәләл булмас...". Ялгыш тәрҗемәләр Сәлман хәзрәт нөсхәсендә еш кына очрый шул. Икенче сүрәнең 286 аятеннән бишесен генә күрсәтик. "Тудыручы аналар балаларын ике ел имезәләр... Баласы туучы хәленнән килгәнчә аларны яхшылык белән тукландырырга һәм киендерергә тиешледер..." (2:233). "Сездән берәрегез җан биреп үзеннән соң хатыннарын калдырса, алар үзләре дүрт ай һәм унны көтеп торсыннар..." (2:234). "Диндә ирексезләү юктыр. Тугрылык та ялгышудан аерылды инде... (2:256).

"Әгәр берәү тарлыкта булса, хәле яхшырганчыга кадәр мөмкинлек булсын..." (2:280). "Аллаһка кире кайтып китәчәк көннән куркыгыз! Соңрак ул һәр җанга аның кәсеп кылганына карата бирер һәм алар рәнҗетелемәс тә!" (2:281). Шул ук аятьне, мәсәлән, Батулла ничек тәрҗемә иткән? "Аң булыгыз! Аллаһ хозурына барачак көн турында уйлап, куркып яшәгез. (Ул көнне) һәркемгә үзе кылганнар өчен түләү итеп, гаделлек илә таман өлеш (җәннәт яки җәһәннәм) бирелер" (2:281). Бу, шиксез, чын татар телендә, кыскача аңлатмалар белән аңга сеңдереп әйтелгән фикерләр. Сәлман хәзрәт тәрҗемәсендә икенче сүрәдә генә түгел, башкаларында да татарча аңлаешсыз җөмләләр бар. "Ләкин үзләренең Раббыларыннан курыккан өчен - астында елгалар агып торган түрләр һәм алардан югары төзелгән түрләр Аллаһтан вәгъдә буларак!.." (39:20). Нинди "түрләрдән югары түрләр" турында сүз бара соң? Бу аятьнең мәгънәсен муллалар үзләре дә аңлар микән? Шул ук сүрәдәге 21 һәм 22 аятьләрнең дә мәгънәләре шулай ук "серле йомгак" кебекләр. Шуның шикелле җөмләләрне ничек аңларга кирәк? Тагын бер аятьне чагыштырып карыйк. Ф. Сәлман тәрҗемәсе: "Үз йөзен Аллаһка тапшырып, яхшылык кылучы булып, Хәниф булучы Ибраһим милләте юнәлешендә булучыдан да кем дин ягыннан яхшырак икән?..." (4:125). Нәрсә ул "Хәниф булучы Ибраһим милләте... булучыдан"? Бу җөмләне кайсы татар аңлар икән? Күбесе аңлар-аңламас игътибар итмичә узып китәр, дип уйлыйм. Шул ук аятьне Р. Батулла нөсхәсеннән укыйбыз: "Гадел эшләр кылып, үзен Аллаһка багышлап, Ибраһим хәнифнең Аллаһны бер дип таныган диненә табынган кешедән дә мәһабәт дини кеше булырмы икән?" (4:125). Күренә ки, аңлаешлы татарча җөмләләр гарәпчәдән дөрес тәрҗемә итү нәтиҗәсе генә түгел, алар Коръәннең тирән мәгънәләрен һәр кешенең аңына җиткерүче корал да. Аңлаешсыз сүзләр, кытыршы җөмләләр бер-ике җирдә генә очраса әле бер хәл.

Коръән сүзләрен ялгыш тәрҗемә итеп, ул китапларның Китабын кызганмасагыз, ичмасам, татар телен кызганыгыз, диясе килә. Хәзер тәрҗемә мәсьәләсенә аерым тукталып карыйк. Беренчедән, Сәлман хәзрәт нөсхәсендә тәрҗемә ителмәгән гарәп сүзләре артык күп шикелле.. Мәсәлән, (2:47) "... Мин үзегезне галәмнәр өстендә фазыйләтләндердем". Бу ни дигән сүз? Моның мәгънәсен имамнар да сүзлексез генә аңлый алыр микән? "Фазыйләт" дигән гарәп сүзе татар телендә "өстенлек" мәгънәсендә иске язмаларда очраштыргалый. Ләкин татар фигыле рәвешендә булмагандыр, әлбәттә. Аннары "әл-галәмин" сүзе монда "галәмнәр" (дөньялар) мәгънәсендә түгел, "халыклар", "кабиләләр", "кешеләр" мәгънәсендә кулланылган, чөнки галәмнәр өстеннән Аллаһы Тәгалә үзе генә була ала. Әлеге аятьнең гарәпчәсе: "фаддалтуком галә әл-галәмин...", татарча "...мин сезне (башка) халыклардан өстен иттем", яки "халыкларга карата өстенлек бирдем" дөресрәк булыр иде. "Татарлашып" беткән гарәп сүзләре безнең телебездә шактый, әлбәттә, ләкин алар татарның үз сүзләрен кысрыклап чыгарырга тиеш түгел. Бүгенге татар халкы хәзерге татар әдәби телендә сөйләшә һәм укый, шул телдә фәнни фикер йөртә белә, шул телдә генә башка халыклардан кергән фикерләрнең асылына төшенә. Димәк, тәрҗемәченең юлында берничә киртә күренә. Беренчедән, күп мәгънәле сүзләр; икенчедән, гарәп теленнән татар теленә кергән алынма сүзләр; өченчедән, Коръән теле, сөйләм теле буларак, татар әдәби теленә адекват күчерелмәү әнә шундыйлардан. Тәрҗемә дөрес, матур булса, гарәп телендә булган фикерләр, аятьләрнең мәгънәләре ана телендә дөрес чагылыш тапса, Коръәнне татарчага кайсы телдән тәрҗемә итсәң дә ярый, әлбәттә. Ләкин гарәпчә текст белән "турыламыйча" ярамый. Сәлман хәзрәт нөсхәсендә татар теле стилистикасы һәм лексикасында күбрәк урыс һәм башкорт телләреннән тәрҗемә иткәнлек сизелә. Югарыда күпмәгънәле

сүзләрне тәрҗемә итүдә аеруча читенлек бар, диелгән иде. Аларны Коръәннең беренче битеннән үк, "Фатиха" сүрәсеннән бик ачык күреп була. Беренче аять: (1:1) "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" - "мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһның исеме белән (башлыйм)". Ф. Сәлман: "Дөньяда һәркемгә шәфкатьле, ахирәттә иман әһелләренә генә рәхимле Аллаһ исеме белән" - дип, гарәпчә текста булмаган (Ногманиның тәфсиренә ияреп), үзеннән өстәмә мәгънә чыгарып язган. Икенче аятьтә "Галәмнәрнең тәрбия кылучы раббысы Аллаһка мактау", дигән һәм сноскада "галәмнәр" ике дөнья мәгънәсен бирә, җир, күк кенә түгел, космосны да эченә ала, дип аңлаткан. Бусы, минемчә, артык "ирекле тәрҗемә": алай аңлаткан галәмнәрнең ничек "тәрбия кылу"ы мөмкин икән? Асылда Коръәндә "Әлхәмдү-лилләһи раббиль-галәмин" - "халыкларны тәрбия кылучы Аллаһка дан (булсын)" диелгән (Ногмани нөсхәсен кара). Дүртенче аять (1:4) "Малик йаүми-д-дин" - "кыямәт көненнән падишаһына" дип тәрҗемә ителгән. "Малик" сүзенең ике төрле мәгънәсе бар: 1) хуҗа, ия, бар итүче; 2) патша. Минемчә, бу җөмләдә "малик" сүзе "падишаһ" түгел, чөнки Аллаһ берәр дәүләтнең патшасы гына түгел - кыямәт көне иясе, хуҗасы, бар итүчесе мәгънәсендә йөри (Кара: "Священный Коран, с. 5, пункт 7). "Фатиха" сүрәсенең 7 аяте болай күчерелгән: "үзен ирештергәннәрнең юлыннан, ачуга тарыган һәм тайпылып адашканнарныкыннан түгел!". Бу аятьтә ике мәгънәле сүзләр икәү. "Ирештерү": 1) бәхеткә ирештерү; 2) үчекләү, үртәү. "Ачу" сүзе дә ике мәгънәле: 1) күңел ачу, капка ачу; 2) нәфрәт, ачу килү. Аятьтә Аллаһның ачулануы, аның нәфрәте турында сөйләнә. Бу очракта бәлки "ачуына тарыганнар" яки "синең нәфрәтеңне казанганнар" кебегрәк аңлату кирәк булгандыр. Юкса, Коръәнне беренче аятеннән үк аңлау бик кыен. Күп мәгънәле сүзләрнең иң дөрес ишесен сайлап алу табигый рәвештә дә кыен. Сүзнең мәгънәләре арасыннан нәкъ шушы җөмләне тәрҗемә итәргә

кирәклесен сайлап алуга күп төрле фактлар, шул арада бер дә көтелмәгәне комачаулый. Мәсәлән, Л.Н. Толстойның "Война и мир" романы татарчага "Сугыш һәм тынычлык" дип тәрҗемә ителгән. Дөресме? Юк, ялгыш тәрҗемә. Ник алай? Урыслар үзләре шулай язалар. Ә чынлыкта исә, монда омонимия һәм омография хикмәтләре бар, берүк әйтелешле "мир" сүзе "халык" һәм "тынычлык" мәгънәсендә кулланылган. "Мир" сүзе элек "ъ" - "ять" хәрефе белән язылып, "халык" мәгънәсен аңлаткан. "Мировой судья" - "Народный судья", "На миру и смерть красна" ("Ил белән үлем дә җиңел"), "Пустить по миру" ("Халыктан хәер сораштыру"). Димәк, бу роман "Сугыш һәм халык" итеп тәрҗемә ителергә тиеш, чөнки роман сугышта халыкның катнашуы турында бәян итә. Әмма "мир" сүзеннән "ять" төшеп калгач, "тынычлык" мәгънәсе генә кулланыла башлый. XX гасырның урталарында җәмәгатьчелек аң-телендә сүз шулай үзгәргән икән, шулай булгач, 14 гасыр элек кулланылган Коръәндәге сүзнең мәгънәсе үзгәрүе дә ихтимал. Ләкин тәрҗемәче "уяу" булсын иде. "Дин", "мәсләк" сүзен "буяу", "халык" сүзен "галәм" яки "тынычлык" сүзе белән бутамасын, алмаштырмасын иде. Интуиция түгел, төгәл белемгә таянып тәрҗемә итү мәгъкүл. Мәсәлән, "Йосыф" сүрәсенең 49 аятен Сәлман хәзрәт болай биргән: "Шуның артыннан бер ел килер. Ул елны кешеләргә яңгыр җибәрелер һәм алар чыгарлар". Кемнәр "чыгарлар"? Каян чыгарлар? Ул башкорт телендә чыккан Коръәннән "...ул йылды кешеләргә ямгыр ебәрелер һәм улар (емеш) хыгырдар" җөмләсеннән "хыгардар" сүзен "чыгарлар" дип ялгыш тәрҗемә итә һәм Коръән аятенең мәгънәсен югалта. Юкса, Коръәндә җимеш сутын сыгу турында сөйләнә. Текст бөтен нечкәлекләре, мәгънә төсмерләре, синонимнарның да мәгънәви аермасы белән бирелмәсә, Коръән шикелле борынгы китапның эчтәлегенә төшенү читен шул. Моңа Ф. Сәлман нөсхәсеннән янә бер мисал китерик: "...

Сез үлекләр идегез, үзегезне терелтте. Янә үзегезне үлекләндерәчәк..." (2:28). "Үлек" сүзе ике мәгънәле: мәет һәм эрен, ярага җыелган шакшы үлек. Гарәпчә "йумитуком" - "сезне үтерәчәк" дигән сүз. Коръән сүзенең мәгънәсе белепме-белмичәме бозылган. Моның ише хаталар аятьләрнең мәгънәсен караңгылый, дип уйлыйм. Батулла "йумитуком" сүзен "җаныгызны алачак", дип мәгънә ягыннан дөрес тәрҗемә иткән. Янә бер мисал. (2:36) - "Шайтан исә аларны икесен дә үзенә котыртып абындырды, һәм алар булган төштән үзләрен чыгарды". Моны ничек аңларга кирәк? Шайтан аларны үзенең гәүдәсенә абындырдырттымы, әллә котыртып абындырды, ягъни туры юлдан яздырдымы? Шайтан аларны нинди "төштән" чыгарды? Төш-орлыкмы ул, әллә йокыдагы төшме ул, әллә яшәү урынымы? Менә шундый икеле-микеле җөмләләр укучыны аптырашта калдырачак, әлбәттә. Бу аятьнең мәгънәсен башка тәрҗемәчеләр ничек биргән? Атаклы төрек дин галиме Хәмди Языр бу җөмләне бик дөрес һәм җиңел аңлаешлы итеп болай тәрҗемә иткән: "Шул сәбәпле шайтан аларны... икесен дә муллык эчендә яши торган урыннарыннан чыгарды". Ягъни җәннәттән чыгарды. Шул ук фикерне Порохова да бирә: "Но Сатана увлек их в грех и вывел из блаженства, в котором находились они там". Гарәп сүзләренең Коръәндәге мәгънәләренә тиешле игътибар итмичә тәрҗемә ителгән аятьләр ара-тирә очрый, дигән идем. Кызганычка каршы, бу Коръәннең гадәти сүзләренә генә түгел, аның төп терминнарына (төшенчәләренә) дә кагыла. Һәр тәгълиматның төп фикерләре мәгълүм төшенчәләр - терминнар белән бәян ителә, аңлатыла. Исламның төп төшенчәләре - "иман", "дин", "тәүхид" (Алланың берлеге), "коръән", "сәлам", "салят" (намаз) шикелле терминнар арасында "фуркан" термины-төшенчәсе дә бар. Тәухид - биш фарызның беренчесе, Исламның терәге: "Лә илаһе иллә Аллаһы, Мөхәммәдү расүлү-Аллаһы" ("Алладан башка

Хода юк, һәм Мөхәммәд аның илчеседер"). "Фуркан" сүзе Коръәндә нинди мәгънәдә кулланылган һәм тәрҗемәчеләр аны ничек аңлыйлар һәм укучыга төшендерәләр? "Бәкара" сүрәсенең икенче аятендә болай диелгән: "Ва из атайна Муса әл-китаба ва-әл-фуркана ләгалләкүм тәхтәдуна" (2:53). Бу аятьтә тәрҗемәчеләр "фуркан" сүзенә сөртенәләр. Мәсәлән, Ф. Сәлман хәзрәт тәрҗемәсе: "Тугры юлга күнәрсез дип Мусага китап белән *аергыч* тапшырганны исегезгә төшерсәгез иде" (кыек хәрефләр минеке - М. М.). Монда ике ялгышлык бар. Беренчесе, "фуркан" сүзе аңлашылмый. Бу ни дигән сүз? Моңа урысча текстларда ялгыш тәрҗемәләр булуы да комачаулый. Мәсәлән, И. Крачковский белән В. Порохова "фуркан" сүзен "различение" дип алганнар. Аларга иярептер, башка тәрҗемәчеләр дә "фуркан" сүзенә абыналар. Күрсәтелгән аятьтә генә түгел, Ф. Сәлман нөсхәсенең башка аятьләрендә дә (мәсәлән, "Гыймран" сүрәсенең 4 аятендә) "фуркан" төшенчәсе аңлаешсыз "аергыч" сүзе белән тәрҗемә ителгән (3:4). Бу аятьнең тәрҗемәсендә тагын бер кимчелек бар - "исегезгә төшерсәгез иде" гыйбарәсе гарәпчәдә юк, каян килде ул татарчасында? Шул ук аятьне Р. Батулла ничек тәрҗемә иткән? "Тугры юлны табарсыз, дип Мусага (хакыйкатьтән яманны аера торган хөкемнәрне) Фурканны (Коръәнне) бирдек". Монда "фуркан"ның төп мәгънәсе дөрес күрсәтелгән, ләкин без ике төгәлсезлек күрәбез. Беренчедән, гарәпчә "табарсыз" димәгән, чөнки туры юл Китапта күрсәтелгән инде; "тәхтәдуна" сүзен "туры юлга басарсыз" дип тәрҗемә итү дөресрәк булыр иде. Икенчедән, аятьтә Коръән Мусага бирелгән, дип әйтелмәгән, чынлыкта исә, Коръән Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән. Мусага "аль-китаба ва-ль-фуркана" бирелгән. Әл-китаб - ул Тәүрат (Тора). Бу аятьне дөрес тәрҗемә итүчеләр дә юк түгел. Мәсәлән, 1909 елны басылып чыккан Коръән-тәфсирдә Ногмани хәзрәт тәрҗемәсендә болай диелгән:

"...Мусага китап бирдек. Ул китап хак белән батыл арасын аеручы иде". "Различение" генә түгел шул, хак белән батыл (ялган, хакыйкать белән) арасын күрсәтүче. Бик үк дөрес булмаса да төп мәгънә чагылдырылган. "Ул китап" - тәүрәт, а менә "фуркан" чыннан да хәләл белән харамны аеручы. Башка телләргә "фуркан" сүзен ничек тәрҗемә иткәннәр? Төрекләр вариантын без Батуллада күрдек инде. "Хак иле батылы аеран хукумлери вердик", диелгән Караман тәрҗемәсендә (Kuran-1 kerim ve turkce aciklamali meali, Medine, 1997). Димәк, "фуркан" - күрсәтмәләр, төп кагыйдәләр. Рашад Халифә инглизчә тәрҗемәдә болай дигән: "Recall that we gave Moses scripture and the statute book, that vou mau be guided" (Quran. The final Testament. USA, 1992). "Statute book" - свод законов, ягъни "кануннар мәҗмугасы". Менә сиңа "аергыч"! Менә сиңа "различение". Әгәр Х. К. Барановның гарәп теле белгечләренә бик мәгълүм "Арабско-русский словарь" китабын ачып караган булсак, анда "фуркан"ның мәгънәсен күргән булыр идек: "фуркан - различение (добра от зла). Аль-Фуркан - священное писание; Библия; Коран". Димәк, "фуркан" - җиденче күктә сакланган һәм шуннан Мусага Тәүрат белән берьюлы иңдерелгән төп Коръәннән күрсәтмәләр ул. Аллаһ барлык диннәр өчен дә бер булгач, "тәүхид"нең төп мәгънәсе, аның Сүзе дә бер булырга тиеш түгелме соң? Ләкин изге китаплар күп төрле ич! Аллаһ Сүзенең берлеген ничек аңлатырга? Китапларның эчтәлек ягыннан берлеген "фуркан" тәэмин итә. Төрле вакытта бер үк чишмәдән алынган су кебек, Коръәннең үзендә әйтелгәнчә, барлык Изге китаплар - Тәүрат (Мусага), Зәбур (Даудка), Инҗил (Гайсәгә), Коръән (Мөхәммәдкә) бер үк "чишмә" - бер үк нөсхәдән, "фуркан"нан алып, күчерелеп төзәтелгән, яңартылган төстә пәйгамбәрләргә иңдерелгән диелә. Күктәге Коръән турында Ф. С. Пушкин да язып калган: "С небесной книги список дан Тебе, пророк, не для строптивых; Спокойно

возвещай Коран, Не понуждая нечестивых!" "Фуркан" - яхшыны яманнан аера торган гомуми дин кануннары. Аятьнең дөрес тәрҗемәсе болай булыр иде: "Бәлки сез туры юлга басарсыз дип, Мусага китап һәм кануннар бирдек". Димәк, "тәүхид" төшенчәсе белән "фуркан" төшенчәсе ислам теориясенең (догматикасының) логик бәйләнешен тәэмин итәләр. Фуркан сүзен дөрес тәрҗемә итү - ислам тәгълиматын аңлату өчен бик мөһим шарт. Мәгълүм ки, хатадан берәү дә саклана алмый, бигрәк тә тәрҗемә текстларда. Урысча Коръән укып, йөз чөерүче татарлар күп. Инде татар телендә дә без аларга ярым-йорты фикерләр, ялгыш сүзләр, ватык җөмләләр тәкъдим итә башласак, Коръәнгә сокланып карый башлаган татарлар да бу китаптан бизә башламас микән? Тәрҗемә теориясендә әйтелгәнчә, без оригинал текстның сүзләрен генә түгел, аларның мәгънәсен, хәтта мәгънә төсмерен дә дөрес, матур һәм җиңел аңлаешлы ана теленә тәрҗемә итәргә тиешбез. Фәрит хәзрәт Сәлман да, Рабит әфәнде Батулла да эшне шулай итеп башкарырга тырышканнар, әлбәттә. Барыбер тәрҗемәләр бер-берсеннән аерылып торалар; нөсхәләр күпме булса, аларны камилләштерү юллары да бардыр. Атаклы татар язучысы Р. Батулла каләменнән төшкән нөсхә тәрҗемәнең дөреслеге белән генә түгел, татар теленең матурлыгы белән дә сокландыра. Тагын бер җөмләне алып карыйк. Җәлил язмасында бер үк аять ике төрле тәрҗемә ителгән. Мәсәлән, "Мөлек" ("Падишалык" - 67:18) - "Ва ләкад кәззәбә-әлләзина мин каблиһим фа кәйфә кәәнә нәкир" - "Аллаһ Раббыбыз: үзең танымаган бер генә кавемне дә җир йөзендә калдырмабыз", ди (Җәлил хәзрәт китабы, 122 бит). Димәк, Алланы танымаган халыкны Ул юк итә. Ләкин "Җир йөзендә калдырмабыз" сүзләре гарәпчә аятьтә юк һәм андый мәгънә дә юк. Монда: "Элегрәк булганнар танымаганнар (ягъни динне кире какканнар - М. М.), танымаганнарга ачуым көчле булды", диелгән. Урысча: "И

несомненно, отвергли бывшие прежде них, так же как (ужасно) было неудовольствие мое". Порохова: "Отвергли веру многие из них (раньше), И вот тогда-как страшен был мой гнев!" "Җир йөзендә калдырмабыз" дигән фикер монда да юк! Икенче җирдә, 150 биттә, шул ук аять икенче төрле тәрҗемә ителгән: "Муафыйк булмасагыз, дөньяда динен ташлаган бер генә кавемне дә, бер генә милләтне дә Мин яшәтмәдем" - дигән иде Аллаһы Тәгалә", - ди Җәлил хәзрәт. Әгәр бусы да "ирекле" тәрҗемәгә керә икән, Коръәнне теләсә кем тәрҗемә итә ала дигән сүз! Ә бит элек, әйткәнебезчә, Коръәнне башка телләргә тәрҗемә итү тикмәгә генә тыелмаган. Тагын бер мисал. "Әт-тахиййәту ли-ллахи ва-с-салавату ва-т-тайбату". Бу сүзләрнең мәгънәсе болайрак: "Сәламнәр Аллага һәм догалар, һәм яхшылыклар Аллага (булсын)". Җәлил хәзрәт моны ничек тәрҗемә иткән? "Тел һәм тән гыйбадәтләребез барысы да фәкать Синең өчен генә" (85 б.). Коръән сүрәсендәге (45:13): "Ва сәххәра ләком ма фи-с-самавати ва ма фи-ль-арды җәмиган минһу иннә фи заликә-ль-айяти ликавми йәтәфәккәруна" дигән мәгънә Җәлил хәзрәт тәрҗемәсендә мондый рәвеш алган: "Мин бөтенесен кеше өчен яраттым, Мин бөтенесен кешегә хезмәт итәр өчен яраттым" (62 б.). Күренә ки, гарәпчә җөмләдә булган бик әһәмиятле "күк" һәм "җир" төшенчәләре төшеп калган. Димәк, аятьнең мәгънәсе бозылган. Бу хәл Р. Батулла тәрҗемәсеннән дә күренә: "Күкләрдә һәм Җирдә ни булса, шуларның барысын да Ул үз катыннан иңдереп, сезнең карамакка бирде. Әлбәттә, бу турыда уйлап караган кешеләр өчен гыйбрәтләр бар". Бу тәрҗемә гарәпчәсенә тәңгәл килә, тик "гыйбрәт" сүзе генә урынсыз кебек, чөнки "аять" "могҗиза" дигән сүз.

Моны раслау өчен гарәпчәдән бер вариант китерик: "Җирдә дә, күктә дә булганнарны, (аннан булган бар нәрсәне кебек), барысын да Ул сезгә буйсындырган. Чынлап та, бу фикер йөртүче кешеләр

(кабилә) өчен (аятьләр) могҗизалар". Коръәндә "аять" сүзе, әлбәттә, "могҗиза" ("чудо", "знамения") мәгънәсендә кулланылган, дип уйлыйм. Урысча нөсхәләрдә дә шулай. "И подчинил Он вам все, что есть на небесах и все, что есть на земле, - все, что от Него. Воистину, есть в этом знамения для людей размышляющих" ("СК", 977 б.). Валерия

Порохова нөсхәсендә шулай:

И Он вам подчинил все то,

Что суще на земле и в небе, -

Как все, что от Него исходит.

В этом, поистине, знамения для тех,

Кто размышляет (535 б.).

Алынма сүзләрнең тәрҗемәсе турында

Алынмалар. Татар телендә искергән һәм гамәлдән чыккан яки чыга язган сүзләр бик күп; әйтик, соңра, лязем, гафил, гафләт, тәхкыйр, тәсдыйк, вә, илә шикелле таныш кебек булсалар да мәгънәләре бик үк ачык булмаган сүзләр әнә шундыйлардан. Алар текстны җиңел аңлауга комачаулыйлар. Теләсә кайсы телдән тәрҗемә иткәндә тәрҗемәченең "ялган дуслары" килеп чыга. Ул "дусларның" Бер төре - тәрҗемә ителәчәк телдән кергән алынма сүзләр, ике телдә дә кулланыла торган бер үк лексика. Татар телен бай дибез, аның байлыгы терминнар хисабына да арта. Татар теле терминологиясе төрле чорларда төрлечә үсә. Мәсәлән, техника, механика, физика, химиядән терминнар күбесенчә совет заманасында гына урыс теленнән кергәннәр. Гарәп теленнән татар теленә 10 меңнән артык сүз һәм гыйбарәләр алынган*.

---

* К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сайфуллин. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, Казан, 1965.

Элек мәдрәсәләрдә укып чыккан татар яшьләре дини терминнарны яхшы белгәннәр. 70 елга сузылган совет дәһрилек

дәверендә ул терминнарның күпчелеге телдән төшеп калып юк булганнар. Бүген рухият һәм руханият әдәбиятын укыгандамы, урысчадан тәрҗемә иткәндәме кешеләрнең күбесе эквивалент сүз таба алмыйча аптырыйлар һәм ислам турында сөйләгәндә дә урысча терминнардан файдаланалар.

Татар теленә кергән гарәп алынмаларының бер ишесе актив кулланышта йөри (китап, мәктәп, мәчет, вөҗдан, газап һ.б.ш.); бер ишесе төшеп калган (тәхкыйк, гатыф, имла һ. б.). Актив кулланылышта булганнарының да бер өлешенең мәгънәләре еш кына тарайган яки үзгәргән була. Шуңа күрә, Коръәнне тәрҗемә иткәндә бу сәбәптән дә төрле кыенлыклар килеп чыга. Мисал итеп "нигъмәт" сүзен алыйк. Сүзлектә "нигъмәт" - книж. пища, еда, кушанье, снедь, яства. "Нигъмәтле" - уст. Имеющий пищу (припасы) (Татарско-русский словарь. М. 1966, 398 б.).

Димәк, нигъмәт - китап сүзе, нигъмәтле, гомумән, искергән инде. Гарәп телендә исә бүген дә "нигъмәт"нең беренче мәгънәсе - бәхет, үзенең Раббысына вә аның нигъмәтләренә көфрән нигъмәт кылучылар, ягъни иман китермичә, ислам динен кабул итмичә, үзен-үзе һәлак итүчедер. Монда "нигъмәт" сүзенең мәгънәсе "ризык"ка бер дә якын түгел шул.

Татар телендәге "нигъмәт"нең мәгънәсе бик тар, аны "ризыкка" гына кайтарып калдыралар. Менә "Фатиха" сүрәсенең 7 аятендә болай диелгән: "Сыйрат әлләзина әнгамтә галәйхим". Җәлил хәзрәт тәрҗемәсендә: "Йа, Раббым, безне Үзеңнең киң ризыклы, мул ризыклы юлларга күндер" (Җ., 69 бит). Ләкин "әнгамтә" сүзендә ризык кына түгел, монда "бәхет", "рәхмәт", "шәфкать", "мәрхәмәт" мәгънәләре күбрәк шул. Бу аятьне, мәсәлән, "Священный Коран" китабында: Веди нас по "...стезе тех, кому ты даровал милость" дип тәрҗемә иткәннәр. В. Порохова тәрҗемәсендә дә "Милостью Твоею

одарен..." диелгән. Димәк, урыс тәрҗемәчеләре "нигъмәт" сүзен дөрес аңлаганнар: монда сүз "ашамлык", "ризык" турында гына түгел, бәлки киңрәк мәгънәдә, "рәхмәтеңне бирдең" мәгънәсендәдер.

Батулла: "(Зинһар) юлдан язганнар вә нәфрәтеңә дучар булганнар юлына төшермә" ди. Монда да "ризык" мәгънәсе юк. Димәк, "рәхмәтеңне биргәннәрне юлыңнан алып бар, җитәклә". "Ризык" сүзе белән тәрҗемә итү, гомумән, ирекле тәрҗемә өчен дә "бик ирекле". Ник "рәхмәтеңне" сүзе дөресрәк соң? Чөнки "кемнәргә ул рәхмәтен биргән һәм кемнәр туры юлдан барган?" соравына җавап 4 сүрәнең ("Ниса") 69 аятендә күрсәтелгән: пәйгамбәрләргә, изгеләр, мәрхәмәтле кешеләргә, һәр мөселман аларны үзенә үрнәк итеп алырлык кешеләр алар, чөнки киләсе аятьтә алар болай билгеләп үтелә: "гайрель-махдуб галәйхим ва лә-д-далин". Моны Җәлил хәзрәт "...берүк безне начар, бозык кешеләр белән тоташтыра күрмә" - дип тәрҗемә иткән. Ләкин Коръәндә "начар, бозык" кешеләр турында сүз дә юк ич! Анда "алар, кемнәргә синең ачуың чыкмады (ачуланмадың) һәм адашып йөрмәгән" кешеләр... Кемнәр соң алар? Алар шул ук изгеләр, пәйгамбәрләр, чөнки алар гына адашмыйча йөргән (К: СК, Комментарий, с., 7 п. 9). "Сезне туры юлдан җитәкләүче юлдашыгыз Мөхәммәд галәйһи-с-сәлам туры юлдан һич адашмады, һәм бозылмады, азмады" (53 сүрә, 2 аять; бу "Фатиха" сүрәсенең җиденче аятенә җавап, башкача аның тулы мәгънәсе аңлашылмый да).

Татар теленә кереп тә, мәгънәви тотрыклылыкларын югалткан сүзләр тәрҗемәченең "ялган дуслары" булып йөри, дигән идек. Мәсәлән, "хаким" һәм "хәким" сүзләрен алыйк. Беренчесенең мәгънәсе - "хөкем итүче", икенчесенеке - "акыл иясе". Коръәндәге (95 сүрә, 8 аять) "Әләйсә Аллаһы би-ахкәми-ль-хакиминә"? ("ахкәм" - иң зур акыл иясе, хәким; "хакиминә" - хөкем итүчеләр) Җәлил хәзрәт китабында болай тәрҗемә ителгән: "Хөкемнәрнең хөкемдары

- Аллаһы Тәгалә. Ул хөкем итәчәк безне..." "Хөкемдар" - "правитель", ягъни аятьтәге ике төрле сүз икесе дә бер үк "хаким" мәгънәсендә бирелгән. Бу аять урысча ничек тәрҗемә кылынган соң? "Разве Аллах не лучший из судей?" ("СК", с. 1218). Порохова: "Ужель Аллах не самый мудрый судия?" Монда тәрҗемәче бик зур осталык белән "хаким" ("хөкем итүче") сүзе белән "хәким" ("акыл иясе") сүзен икесен дә дөрес кулланган. Татарча "Аллаһ иң акыллы (зирәк) хакимнәрдән түгелмени?" дип әйтү аятькә якынрак варианты булыр иде шикелле.

Тәфсилләбрәк әйткәндә, алынма сүзләрнең "ялган дуслыгы" шуннан гыйбарәттер - гарәп сүзенең мәгънәсе татар телендә үзгәрү ихтималы бар. Шуны исәпкә алып, кайбер сүзләрнең этимологиясенә игътибар итү зарури. Мәсәлән, гарәпчә "хикма" ("мудрость") дигән күп мәгънәле һәм гаять әһәмиятле сүз татар телендә кулланыламы?

"Хикмәт" сүзен гарәпләр "хикма", "хакәмә" - "тезген" сүзеннән чыгаралар. Димәк, "хикмәт" ("мудрость") кешене яман гадәт-холыктан саклый. Сүзнең мәгънәсе эш-гамәлгә бәйләнгән. "Дөрес гамәл тудырган һәр дөрес сүз - "хикмәт" ул", ди атаклы дин галиме Абу Җәгъфәр. Ләкин "хикмәт"нең функциясе киңрәк: ул гамәлгә генә түгел, хакыйкатькә дә бәйләнгән. Икенче бер дин белгече әл-Җәрҗәни фикеренчә: "Хакыйкатькә туры һәрбер сүз - "хикмәт" ул ("мудрость"). "Ул хикмәтне теләсә кемгә бирә, хикмәткә лаеклы кеше бәхет, игелек бүләген алган" (була) диелә Коръәннең "Бәкара" сүрәсенең 269 аятендә. Димәк, "хикмәт" камил белемгә ия булу һәм шул белемгә таянып гамәл кылу ул. Шулай, Коръәндә "хикмәт" сүзенең мәгънәсе киң; ул пәйгамбәрлек, гаделлек, белем, дөньяны тирән аңлау, акыл белән эш итү һ. б. аңлата.

Без "хикмәт"не ("мудрость"ны) "зирәк" сүзе белән бирәбез, "хикмәт" сүзе татарча - "зирәклек" дип аңлатыла. "Мудрый"ны да -

"акыллы", "зирәк" һәм өченче мәгънәсендә генә "хикмәтле" дип тәрҗемә итәләр (Русча-татарча сүзлек, М., 1984, 277 б.). Сүзлекләрдә әле бер хәл, әмма язу, бигрәк тә сөйләм телендә андый сүзләрнең мәгънәләрен гел урысчадан китереп чыгару - бу инде чикләнгәнлек, әйтерсең лә татарда "мудрый" төшенчәсе элек-электән бөтенләй дә булмаган...

Искерәк сүзлекләрдә - "хакимият" - "власть" сүзе книжный дип күрсәтелгән. Бүгенге көндә ул сүз активлашты шикелле: "Хаким" - 1) повелитель, властелин, правитель; 2) книж. судья; бу мәгънәдә бездә кулланылмый. "Хәким" - уст. книж. 1) ученый, мыслитель, мудрец. философ (Татарча-русча сүзлек. М., 1966, 620 б.) Димәк, сүзлек аны да иске сүзләр арасына керткән, татар лексикасыннан чыгарып ташланган. Шул рәвешле, алфавитларны бер генә йөз ел дәвамында да өч-дүрт мәртәбә алмаштыра башласак, алга таба да ана телебездәге күп сүзләрдән колак кагачакбыз әле.

Тәрҗемәченең "ялган дуслары" татар телендә әлегә аз түгел шул. Мәсәлән, "хәер" сүзе сүзлекләрдә дөрес бирелсә дә, татарның аңында һәм язу-сөйләм телендә ул "хәерче" төшенчәсе белән бәйле мәгънәдә формалашкан. Берәүне ачулансак, "хәерсез!" дип орышабыз ләбаса. "Хәер" сүзе бездә хәерчегә бирелә торган нәрсә итеп, "милостыня" мәгънәсендә генә кулланыла. Ләкин "хәер" сүзенең бездә төшеп калган төп мәгънәсе "игелек", "мал-дәүләт", "яхшылык" дигәнне аңлата.

Шундый ук сүзләр рәтендә гарәпчә "хулькъ" сүзеннән татар теленә кергән "холык" сүзе дә тора. Гарәп телендә аның мәгънәсе - "гадәт", ("нрав"), без "холык"ны рәсми телдә урысчадан кергән "характер" сүзе белән аңлатабыз, "нрав" икәнлеге фәкать "холыксыз" сүзендә генә чагылыш таба. Сүзлектә дә "характер" сүзе "характер", "холык", "табигать" дип бирелә. "Нрав" сүзе татарчага "холык", "табигать", "гадәләр", "гореф-гадәтләр" дип

тәрҗемә ителә. "Мөбарәк" сүзе Коръәндә "благословенный" мәгънәсендә йөри (ягъни "фатиха алган", олы кешенең рөхсәтен, ризалыгын алган). Без ул сүзне "тәбрик итәм", "котлы булсын" кебек мәгънәсендә генә кулланабыз. Татарча сүзлектә - "бәхетле", "имин". Урысчадан тәрҗемә иткәндә ул сүз "благословенный" түгел, "счастливый", "благополучный" булып кала түгелме соң? Тәрҗемәчеләр тиешле сүз (урысныкына эквивалент сүз) таба алмагач, төрлечә боргалап карыйлар.

Гарәп сүзләренең татар телендә мәгънәләре бөтенләй яки өлешчә туры килмәгән андый алынма сүзләр байтак: садака, хаким, хәким, җәза, золым, бәрәкәт, җәннәт, нәфис, мәртәбә, хак, мазлум, залим, нигъмәт, кәлимәт h. б. әнә шундый сүзләр. Гарәпчәдән татарчага күчергәндә алар тәрҗемәчегә "аяк чалалар", татарда урнашкан мәгънәләре тәрҗемәгә механик рәвештә кереп китә (моны фәндә "телләр интерференциясе" дип атыйлар). *

• Психологиядән мәгълүм булганча, кеше өчен конкрет фикерләү ансатрак (күреп, ишетеп, сизеп алган баш, кул, кеше, агач, су, юл, йорт, икмәк шикелле сүзләр (объектлар) тиз аңлашыла, әмма күренми, ишетелми торган әйберләрне таныш булмаган сүз аркылы аңлау читенрәк). Абстракт төшенчәләрне үзләштерү кыен, гарәптән күбрәк җан, намус, җәннәт, дин, фикер h.б.ш. абстракт сүзләр керә һәм алар фикерләү дәрәҗәсен күтәрә, мәдәниятның күрсәткече булып тора. "Нәфес" сүзен татар теленнән урысчага тәрҗемә иткәндә мондый мәгънәләре күрсәтелә: 1) страсть, желание, вожделение, похоть; 2) уст. книж. душа; нәфсе яман - ненасытный, жадный; нәфесле кеше - алчный (Татарча-русча сүзлек, 406 б.). Гарәп телендә бу күп мәгънәле сүз - 1) 1. Җан; 2. Кан; 3. Кеше; 4. Грам. зат; 5. Ният, теләк; аппетит; 6. Тырышлык, дәрт; 7. Горурлык;

8. Асыл, нигез. 2) 1. Үзе; 2. Шул ук. (Кара: Х.К. Баранов. Арабско-русский словарь., М., 1957).

- Коръәндә бу сүз нинди мәгънәдә күбрәк очрый һәм без аны, үз телебездә эквиваленты булмагач, ничек дип тәрҗемә итәргә тиешбез? Билгеле, сүз сөрешенә карап. "Мәсләк" сүзе гарәп телендә "доктрина", "принцип", "убеждение" не аңлата. Шуннан чыгып, татар телендә "мәсләкле"- убежденный, идейный булырга тиеш шикелле. Ләкин ашык-пошык язган тәрҗемәчеләр кул астыннан нинди генә сүзләр чыкмый? "Мәсләкле" түгел, "идеяле", "принциплы" дип язалар, гәрчә татарча сүзлекләрдә "мәсләк" - 1) убеждение, мировоззрение; 2) перен. принцип, идея, цель.

Инде тагын "бәрәкәт" сүзен алып карыйк. Татарча-русча сүзлектә (1966) мәгънәсе болай бирелгән: 1) изобилие, достаток; 2) рел. небесный дар. Татар телендә бу сүздән ясалган сүзләр дә бар: бәрәкәтле - экономный; бәрәкәтлелек - экономность; бәрәкәтсез - неэкономный. Гарәп телендә "бәрәкәт" сүзенең мәгънәсе - "благословенный", "небесный дар" дигәнгә туры килә. Татар телендә киң кулланыла торган "тәбрик", "мөбарәк" сүзләренең этимологиясе "экономный" мәгънәсеннән ерак торалар ("мубарәк" - "благополучный", "счастливый"). Димәк, "бәрәкәт" ике телдә ике төрле мәгънәдә кулланыла торган сүз. Мәсәлән, Коръәндә 16 сүрәнең 18 аятендә ул "благословенный", "счастливый" мәгънәсендә кулланылган да.

"Җәннәт" сүзенең гарәпчә беренче мәгънәсе - "бакча" ("сад"). Икенчесе - кешенең теге дөньяга күчкәч рәхәт хәлдә яшәү урыны. Чиксез, кызган таба шикелле ифрат эссе ком сәхрәсе, бөртек үлән үсми торган ташлы-комлы сусыз чүлләрдә яшәгән бәдәви (күчмә кабиләләр) гарәпләр өчен иң зур бәхет - яшеллек, агачлары күп бакчаларга керү. Чагыштырып карасаң, безнең - татарларның

табигатьнең яшел кочагыннан - "җәннәттән" чыкканыбыз да юк. Шулай булгач, без татарларга ниндирәк җәннәт кирәк икән?

Коръән текстыннан без "җәннәтнең" бер түгел, күп икәнлеген аңлыйбыз. Татарча "җәннәт" сүзе бер генә мәгънәле - "оҗмах" ("рай"). Бәлки аны болай аңлау православие һәм урыс теле тәэсиредер, аларда да "рай" бер генә була. Ана теленә тәрҗемә ителгән "күп җәннәтле динне" татар дөрес аңлармы икән?

Гарәпчә "садака" (каты "с" белән) - "дуслык", "сыйдкъ" сүзеннән килә - "дөресен сөйләргә", "ихлас булырга" дигәнне аңлата. Татарча "садака" (сүзлектә ул сүз "сәдака" дип языла) дип әйтелгән сүзнең мәгънәсен белмәгән кеше юк - ул хәер, хәтта хәер-садака дип тә әйтәләр (милостыня, подаяние мәгънәсендә) гарәпчә ике төрле языла - "даль" хәрефеннән соң озын "а" сузыгы булса, "садака" - мәгънәсе "дуслык"; кыска сузыклы (бездә ул сузык "ә" белән языла - сәдака) булса - "хәер". Коръәндә "садака" сүзе күбесенчә "дуслык", "тугрылык", "дөреслек" мәгънәсендә кулланылган. Бусы тәрҗемәченең "ялган дусты" түгелме соң? "Залим" сүзе татар телендә "тиран" мәгънәсендә генә кулланыла. Ләкин Коръәндә, мәсәлән, мондый җөмлә дә очрый: "...Аллаһ сугыштан баш тарткан залимнәрне белә" (2:246). "Залим" кем ул? Сугышка барырга теләмәүче, хәзергечә әйткәндә - "дезертир".

Хәзерге татар телендә бөтенләй кулланылмаган "тәхкыйк" сүзе Ногмани тәрҗемәсендә бик еш очрый. Ул бер нәрсәнең дөреслеген тикшерү, "хакыйкатьне эзләү", "шиксез" мәгънәсендә дә йөри.

Ногмани 100 сүрәнең 7 аятен болай тәрҗемә иткән: "Тәхкыйк имансыз кеше үзенең имансызлыгына Аллаһуга каршы кылган эшләре белән гуаһдыр". Монда "тәхкыйк" сүзенең урынын табып булмады, "гуаһ" (танык, шаһит) исә хәзерге телдә бөтенләй юк. Бу аятьне Батулла ансат кына тәрҗемә итә: "Хактыр ки, ул яман кылмышлары белән алар көферлекләренә үзләре шаһит".

Аңлашылуы читен булган җөмләләр Ногмани тәрҗемәсендә ешрак очрый шул. Мәсәлән, ул 89 сүрәнең 2 аятен болай тәрҗемә иткән: "Вә ун төн белән ант итәм, ул ун төннең морад зөлхиҗҗә аеның әввәлгесе ун көннәредер, яки Рамадан аеның ахыры ун төннәредер". Р. Батулла шул ук аятьне болай бирә: "Ун кичәнең (Зөлхиҗҗә аеның) исеме изге булсын...". Тәрҗемәче монда "ант итәм" сүзеннән киткән һәм аятьнең мәгънәсен бик матур биргән.

"Чыктым аркылы күпер"

Тәрҗемәнең тагын бер кыенлыгы: гарәп-татар синтаксисларының аермасында, дип инде әйтелгән иде. Әйтик Габдулла Тукай урыс теле синтаксисына ияреп татарча язуны усал итеп тәнкыйтьләгән. Ни өчен дисәгез, татар теленең логикасын бозган өчен. Гарәп телендә логик предикат, урысча "перешел через мост" кебек, субъекттан алда бара. Без моны Коръәннән беренче сүрәсе "Эль-фатиха"дан ук күрәбез. "Әл-хәмдү лилләәһи раббиль-галәмин ар-рахмәнир-рахим". Туры тәрҗемә: "Дан (булсын) Аллаһуга халыклар тәрбиячесе, мәрхәмәтле, рәхимле", - дип татар теле грамматикасын ватып-сындырып тәрҗемә иткән аятьләрне аңларга тырышабыз. Әгәр "Мәрхәмәтле, рәхимле халыклар тәрбиячесе Аллаһка дан (булсын)" дисәк, бу аятьләр үзеннән-үзе дә аңлашыла.

Тагын бер мисал алыйк. Коръәндә: "1) Куль әгузу би-рабби-ль фәләкъ. 2) мин шаррима халәка. 3) ва мин шарри гасикыйн изә вакаба." Урысчага тәрҗемәсе: "1) Скажи "Ищу я убежища у Господа зари". 3) От зла того, что сотворил Он. 3) И от зла тьмы кромешной, когда она приходит".

Формаль логика нигезендә бу өч аятнең структурасы болай үзгәрергә тиеш: 2-3-1, ягъни: "2) От зла того, что сотворил Он, 3) И от зла тьмы кромешной 1) скажи "Ищу я убежища у Господа зари".

Урыс телендә "туры тәрҗемә" инверсиягә саналу ихтимал. Ләкин татар теленә бу бер дә килешми, чөнки татар теле грамматикасында логик предикат (хәбәр) ахырда куела ("күпер аркылы чыктым"). Шуңа күрә өченче аятьне үзен генә бирү ялгыш тәрҗемәгә китерә...

1) Таң Хуҗасына сыенам (Куль әгузу би-раббиль-фәләкъ);

2) Ул яралткан усаллыкның (мин шаррима халака);

3) Дөм караңгылык усаллыгыннан, әгәр килә күрсә.

Бу - Җәлил хәзрәт хәзрәт тәрҗемәсе (икенче бүлек, 192 бит, - тәрҗемәнең өченче варианты). Ничек дөрес булыр иде? Татар синтаксисы буенча, бәлки, киресенчәрәк язарга кирәктер: "2) Ул яраткан усаллыктан, 3) әгәр килә күрсә, дөм караңгы усаллыгыннан, 1) Таң Хуҗасына сыенам".

Синтаксиска карата тагын бер мисал (92:20): "Мәгәр сәваб вә нигъмәтләр бирелер, ахирәт өчен кыла торган гамәлләрен фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә һәм Аллаһ кушканча гына кылган тәкъва кешегә". Биредә дә логик предикатны татар җөмләсенең азагына күчерү дөресрәк булыр иде, ягъни... "тәкъва кешегә... сәваб вә нигъмәтләр бирелер" дип әйтү дөрес булыр иде...

Фонетика. Һәрбер телдә чит телдән кергән сүзләрнең кыен, читен әйтелешенә үзенә күрә бер фонетик чикләнүләр куела. Мәсәлән, татар теленә урысчадан "председатель", "кровать", "больница" һәм башка шундый татар фонетикасы өчен авыр әйтелешле сүзләр керүен кергән, ләкин тел аларны кабул итмәгән, шуңа татарлар "персидәтел", "карават", "булнис" дип сөйлиләр. Урыс теленә күчерелгән гарәп текстларында да андый хәл булгалый. Мәсәлән, урысларда "җ" авазы булмагач, ул "дж" хәрефләре белән бирелә. Османов "хаҗҗ" сүзендәге ишле "җ" не аңлатыр өчен "хаджджж итеп биргән. Мондый язуны урыс та, татар да әйтә алмый, әлбәттә.

Гарәп теле фонетикасы урыслар өчен генә түгел, татарлар өчен дә авыр; чөнки гарәпләрдә ("гайн", "гәйн", "хәмзә", "ха", "хә" кебек махсус авазлар күп, өчтөрле "с", "х", "з" хәрефләре бар. Аларның бер ишесе татарча Коръән текстында дөрес бирелмиләр. Мәсәлән, Җәлилдә "салләллаһу галәйһиссәлләм" дип тоташ язылган җөмләне аерып бирергә кирәк, чөнки анда ике түгел, бишләп аерым сүз бар: "Салла Аллаһу галәйһи ва сәлләм" ("Аллаһ аңа дога кылды һәм сәләмләде").

Фонетик тәрҗемәләр әлиф-лямнең ("әл-китаб", "әс-сәлам" кебек) язылышында да дөрес булырга тиеш. Мәсәлән, "ва йукыймуна ас-салават" урынына "йукиимууна-ссааләәтә" дип яза Җәлил хәзрәт. Шулай ук еш кулланыла торган "бисмиллә" сүзе дә "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" дип язылса, "ләһир" һәм "рахмәнир" дигән аерым сүзләр бар шикелле тоела. Дөресе болай булырга тиеш: "бисмилләһир-рахим" (яки татар сөйләм телендә әйтелгәнчә, "бисмилләһиррахмәниррахим" формасында тоташ бирелсә дә зыян булмас (төрекләр, мәсәлән, шулай язалар да). Вак-төяк ялгышлар да очрый: мәсәлән, татарның үзендә еш кулланыла торган "газап" сүзе Җәлилдә нигәдер гел "гәзәб" дип языла.

Йомгак сүз. Тәрҗемә вариантлар да, ялгышлар да булуы ихтимал, чөнки Коръән тирән эчтәлекле генә түгел, безнең өчен серле Китап та. Кайбер авторлар Коръәнне мәгънә ягыннан өч өлешкә бүләләр: беренчесе - әхлакый тәгълимат; икенчесе - дини мәсләк; өченчесе - риваятьләр, чагыштырма мәгълүмат. Безне өчесе дә кызыксындыра, әлбәттә, ләкин беренчесе, тәрбияви җәһәттән, бигрәк тә әһәмиятле дип уйлыйм. Коръәнне ике генә өлешкә бүлүчеләр дә бар. Беренче өлеше - без аңлый алмаган әйберләр (илаһилык, фәрештәләр, изге китаплар, кыямәт көне һ .б.ш.). Коръән аларга ышанырга өнди. Икенче өлеше - безнең аң-белемебезгә "сыя" торган әйберләр. Бу турыда "Гыймран" сүрәсенең 7 аятендә ачык

әйтелгән: "Ул Китапта ачык мәгънәле аятьләр белән бергә серләре яшерен мәгънәләре әле ачыласы аятьләр дә күп; аларны Аллаһы белә; гыйлемле кешеләр "без Изге Китапка ышанабыз, чөнки Хаким аны үзе безгә индергән" диләр". А. С. Пушкинның "...Да притечем и мы ко свету, И да падет с очей туман" дигән сүзләре нәкъ менә шул турыда да инде. Күзебезне ачып карасак, Коръәндә борынгыларның тормыш тәҗрибәсен, фикер йөртү логикасын, идеологиясен һәм чын хакыйкать өчен көрәш барлыгын күрербез. Коръән Сүзенең эчтәлекле мәгънәсе кешеләргә озак һәм акрын ачыла. Беренче карашка Изге язу тарихтан читтә яши сыман, ул вакыт категориясе белән чикләнмәгән, шуңа күрә дә кешелек дөньясына һәр дәвердә аның яңа тарафлары, яклары күренә, аңлашыла башлый. Шул рәвешле кешеләрнең аңына, мәсләгенә диннең йогынтысы бетми, вакыт-вакыт яңара да. Шуңа күрә Изге китапларның яңадан-яңа тәрҗемәсенә халыкларның ихтыяҗы артканнан-арта барачак. ...Хәзерге вакытта "мусульманский экстремизм", "исламский фундаментализм" шикелле сүзләр белән мөселманнарны хур итәргә тырышалар. Бу тәнкыйтьнең нигезе юк, чөнки сәясәтчеләр, беренчедән, сәясәтне дин белән бутыйлар (бандитларны мөэминнәрдән аера белмиләр); икенчедән, христианнар, православие дине вәкилләре мөселманнарга каршы тору традицияләрен йомшак сүз белән булса да дәвам иттерәләр; өченчедән, исламга тискәре караш наданлыктан килә: россияннар Коръәнне түгел, аның мәгънәви эчтәлеге турында Пушкинны да укымыйлар! Кызганыч ки!